# Казан утлары

4

АПРЕЛЬ • 1978




# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

4

АПРЕЛЬ
1978

## Бу санда

Р. МИҢНУЛЛИН. Ленин Язы. Шигырь . . . . . 3
Ш. МАННУР. Чын сөю бармы! Лирик повесть . 4
Ш. ГАЛИЕВ. Безне Ленин үстерде. Шигырьләр . 86
М. РАФИКОВ. Кыска шигырьләр . . . . . . . 89
Ә. ГАДЕЛ. Италмас. Шигырьләр . . . . . . . 93
Ш. МАННАПОВ. Туган якка кайту. Нәсерләр . . 96
М. ӘГЪЛӘМОВ. Тагын бер Көн... Шигырьләр . . 103
Ә. СИНУГЫЛ. Тауларга карап. Шигырьләр . . . 111
И. ГАНИЕВА. Җиргә кушылып. Шигырьләр . . . 113

ОЧЕРКЛАР

М. ХӘСӘНОВ. Камил гүзәллекне яклап . . . . 115
А. ХӘСӘНОВ. Гәрәбә диңгез ярларында . . . 122

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Р. РӘКЫЙПОВ. Диңгездә. Шигырьләр . . . . 124

«ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

К. КӘРИМОВ. Тәнәфес. Хикәя . . . . . . . . 127

Ш. МӘРҖАНИНЕҢ ТУУЫНА 160 ЕЛ

М. ЙОСЫПОВ. Күренекле тарихчы . . . . . . 134

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Н. ХИСАМОВ. Тукай иҗатында борынгы әдәбият традицияләре . . . . . . . . . . . . . 141

ИСТӘЛЕКЛӘР

А. РАСИХ. Әнием хатирәләреннән . . . . . . 147
В. ХАҖИЕВ. «Әллүки» ничек туган! . . . . . 160

СӘНГАТЬ

М. НИГЪМӘТҖАНОВ. Тибрәтмәктә күңелнең кылларын . . . . . . . . . . . . . 162

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Р. БИКМӨХӘММӘТОВ.** Татар прозасында эшче образы . . . . . . . . . . . . . . 165

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ф. ХӘКИМҖАНОВ.** Күп көч куелган . . . . . 173
**А. ТИМЕРГАЛИН.** Сүзлектә фәнни терминология . 175

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Х. ЗАРИПОВ.** Тын алан шаулый . . . . . . . 179
**С. ШАКИР.** Көйләрендә чорыбыз сулышы . . . 180
**М. РОБЕРТ.** Мөнир Мазунов . . . . . . . . 182

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Ф. ЯРУЛЛИН.** Көз. Шигырьләр . . . . . . . . 184

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**З. НУРИ.** Алтын балык ялвара. Шигырьләр . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (редактор урынбасары), **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 30/XII-1977 ел. Басарга кул куелды 10/III-1978 ел. ПФ 07028. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91 000 экз. Заказ Б-478. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

## Роберт Миңнуллин

### Ленин Язы

Мин үземне бүген
Ленин туган
Язда итеп тойдым мизгелгә.
Бик биектән —
Ленин туган җирдән
Карап торам язгы Иделгә:
Идел тыныч әле.
Ләкин ул да
Язны тоеп, сизеп агадыр.
Талпынуы, ашкынуы аның
Киләчәккә, язга табадыр...
Идел тыныч әле.
Әмма бер көн
Ургылачак Идел, ташачак —
Гасырларның, илнең, бабайларның
Өметләре чынга ашачак.
Революция ташкыны да
Язгы Идел кебек кузгалыр.
Кимсетелгән халык исеменнән
РЕВОЛЮЦИЯ сүз алыр!
Ташудан соң гөлбакчалар калыр,
Кояш балкыр Идел күгендә...

Шул бакчалар
Шул кояшка карап
Чәчәк ата әнә бүген дә.
Бөек Ленин Язы!
Җырлар гына,
Мәдхияләр генә сиңа аз —
Җаныгыз бер, хәсиятегез бер.
Ленин өчен рәхмәт сиңа, Яз!

...Ватанымда — тоташ язлар гына.
Бөек тарих бездә языла...
Иделемдә тагын язгы ташу,
Рәхмәт укыйм Ленин Язына!

## Шәйхи Маннур

# ЧЫН СӨЮ БАРМЫ?

ЛИРИК ПОВЕСТЬ[1]

## Мәхәббәтнең күзе сукыр икән

Һәр вакыт кырыйдагы урынга табарак чигүчән Таһир агай үз хикәясен шулай дип атады. Аннары кәкре башлы таягы өстенә ике кулын асыл-өсле куйды да сүзгә керешеп китте.

— Шул инде менә: яшем тулды, буйга җиттем, армиягә китеп бардым. Илтеп куйдылар безне ерак-ерактагы Польша чигенә. Дөньяның бу иң аргы башы булып күренде миңа. Тагы әзрәк китсәң, җирнең читенә үк җитеп, теге бер солдат шикелле, аяк салындырып утырырга да була торгандыр...

Безнең полк бәләкәй генә бер өяз каласындагы кызыл казармаларга урнашкан. Солдат хезмәте билгеле инде: кәҗә майларың чыкканчы йөгертәләр, биетәләр, сикертәләр. Шулай да боларга артык ис китми, аның каруы, солдат ашы тәмле була, җимертеп ашыйсың карабодай буткасы белән йодрык хәтле кәтлитен, бүгәтир йокысы белән йоклыйсың төннәрен. Өйдәге туган-тумачалардан, дус-ишләрдән хатлар килеп тора. Дөньяң тигез!

Узды бер ай, узды өч ай. Ә дүртенче айда Таһир дигән егетнең эченә ыскырт әче төтен шикелле пошаман керә башлады. Ник дигәндә, үзегез дә беләсез: һәр егетнең үзенә күрә бер «нәмәрсәкәе» була бит инде. Минем дә бар иде ул... Без аның белән «ах-ух» килеп яшерен көрешүләр аркылы дуслашып киткән идек. Фатир хуҗасының кызы иде. Барнаулда эшләгән чакта мин аларның бер бүлмәсендә тордым. Кызның атасы Гайнулла карт революциягә хәтле үк инде шул якка барып төпләнгән. Чәй-шикәр кибете тотып, алты почмаклы нарат өй җитештергән. НЭП чорында яңадан ул кәсебен кузгатмаган, ахры. Кайдадыр төнге каравылчы булып йөри иде. Артык бүлмәләрендә, хәтта мунчасында да фатирчылар тота һәм хакын да каерып ала иде.

[1] Ахыры. Башы — журналның 3 санында.

Кухнә артындагы сигез метрлы, агач тапчанлы, бер бәләкәй өстәл белән бер урындыклы бүлмәгә мин дә егерме биш сум түләп тордым, бу минем хезмәт хакының нәкъ яртысы иде.

Шул хәтле зур акчаны ай саен бу комсыз карт кулына тоттырганда үтем бик сытылгаласа да, чыгып китәсе килмәде. Зөһрә исемле иде аның кызы, һаман дуслаша бардык үзе белән. Кичләрен бергә клубта булулар, мин пианинога утырсам, янына басып «Уел»ны җырлаулары, спектакльләрдә уйнаулар, кинода кулларны кысышып, яңакларны сөйкәшеп, Мэри Пикфордны караулар, әтисе өйдә булмаган кичләрдә минем бүлмәдә сөйләшеп утырулар үтә дә күңелле иде. Аның исеме Зөһрә, минеке Таһир булуы да, әллә ничек серле тоелып, язмыш кушуы буенча чәчләр шулай чәчкә бәйләнәдер дип уйларга мөмкинлек тудыра иде.

Яз килеп җиткәч, бергәләп су ташулары карадык, бозлар озатып йөрдек без Обь ярында. Җәй килеп җиткәч, ял көннәрендә урманнарга чыктык. Озынборыннардан качып яшел одеал астында яткан чакларыбыз да булгалады...

Юк, сөйкемсез дә, әбрисез дә түгел иде ул кыз. Буе-сыны килгән, кара-коңгырт чәчләре бай, күзләре ялкынлы, сүзләре ягымлы дигәндәй тоела иде.

— Син минем Тахирым, ә мин синең Зохраң, без хаман бергә! — дип, түшемә сыенганда, «И минем агач авызым!» дип көлә башласам, назлы гына итеп авызын турсайта иде. Аннары мин аны «Зөһрә» дип, «Таһир» дип, «һаман» дип әйтергә өйрәтә башладым. Шәһәрдә туып үскән шул, андыйларның күбесе тел нәфислеген тоюдан мәхрүм була ич...

Шулай бик күңелле генә яшәгәндә көз якынлашты бит, ә минем — караласы ел. Ә солдатка каралу өчен, ул чаклардагы гадәт буенча, туган җиреңә кайту кирәк иде. Мин дә җыена башладым. Сәфәр исемле дус егет белән бергә китмәкче булдык. Аны Казанга укырга җибәрәләр икән. Шундый озын-озак юлга иптәш белән чыгасы булу бик җайлы туры килде...

Август ахырлары иде, бүгенгедәй хәтерлим, көн кояшлы, Алтай ягы булса да җылы иде, матур иде. Сөйгән кыз өеннән чыгып киткәндә егетлек күрсәтәсе килде: трантаска җигелгән ак атлы ямшек китердем. Барлы-юклы әйберләрне төйнәштереп арба артына урнаштырдым. Аннары Зөһрәне дәшеп чыгардым да, палас түшәлгән арба түреннән урын күрсәттем. Шунда бергәләшеп кенә утырган килеш, Барнаул урамнарыннан келтерәп кенә узып, вокзалга төшәсе килгән иде. Ә Зөһрә бармады, «үзенең Тахирын» озатып җибәрүдән баш тартты:

— Оялам, әти-әниләрдән яхшы түгел, — дигән булды ул. Мин моның төп сәбәбен аңлый алмадым. «Бәлки, дөрестән дә, уңайсыздыр аңа, көпә-көндез бит...» — дип кенә уйладым. Йөрәк дигәнең сызланып куйса да, артык әһәмият бирмәгән шикелле китеп бардым.

Юл, чынлап та, ялыктыргыч булмады. Сәфәр бик җор сүзле, чамасыз күп мәзәк белүче егет иде. Юл буе авыз ерудан туктамадык. Хуҗаның мин белмәгән мәзәкләрен сөйләгәндә көлә-көлә эчләргә кату чыгып бетте. Каян табып өлгерә торгандыр шундыйларны... Шулай да юл буена күз алдымда Зөһрә торды. Моңаеп калган шикелле күренде ул кыз.

Ул чактагы «скорый» белән өч тәүлек дигәндә мин үзебезнең Әгерҗе тирәсендә төшеп калдым. Сәфәр Казанга сәфәр итте.

Авылга кайткач, Зөһрәгә үпкәләнкерәбрәк хат яздым. Җавабы да килде, үпкәләмәскә кушкан. «Син бит барыбер минем йөрәк төбемдә!» дип язган иде. Бу аның актык хаты булды. Шуннан бирле дүрт ай узып китте. Үзем көн саен диярлек хат язам, ә миңа аның тарафыннан ләм-мим, бер авыз сүз юк. Баштарак әллә ни ис китмәгән кебек иде,

сагынырмын дип тә уйламаган идем артык, ә соңга табарак гел шуның белән саташып йөри башладым. Ни булды икән миңа? Ни булды икән аңа? Әллә суга батып үлдеме, тәүбә, тәүбә!.. Йөзәргә бик ярата иде яратуын... Әллә мин язганнар барысы да әнисе кулына эләгеп, ул яшереп тотамы? Әллә үзе юри шулай авызына су каптымы?.. «Тукта, сагын әле, сагын, ныграк өзелсен үзәгең!» дип үртиме мине...

Бик сәер хәлдә калды бит әле егет. Тиле күкедәй йөри башлады. Әти-әниләрдән, туган-тумачадан, дус-ишләрдән хатлар килеп тора. Бар да бик әйбәт, бик җылы итеп язалар. Ә җан теләгән хат юк...

Ял көннәрендә шәһәр уртасындагы бакчага чыгабыз. Җыйнак кына, түгәрәк кенә ул үзе. Бу якларда кыш йомшак килә икән. Җылымса көн, сирәк-мирәк кар бөртекләре иренеп кенә җиргә төшкәли. Кызлар да чыга монда. Кайберсе өч-дүрт яшьлек бала иярткән, кайберләре чана-бишек йөртә, кайберләре киенеп-ясанып, болай гына йөриләр. Араларында бик сөйкемлеләре дә аз түгел. Барысын бергә җыеп, «кухтрест» дип атаган була безнең солдат халкы аларны. Кухаркалар, асраулар, янәсе. Ә үзләре шулар тирәсенә ябырылып төшә.

— Карагыз әле, туташ, үзегез шундый яшь кенә күренәсез, ә үзегезнең шундый зур гына, матур гына кызыгыз да бармыни инде? — дип, җеп очы ялгарга маташалар. Тегеләре чырык-чырык көлгән була.

— Ник булмасын, бар шул! — дип куялар.— Тагын унике малаем өйдә калды әле! — дип тә өстәп җибәрәләр. Шулай итеп сүзгә-сүз бәйләнә, күз-күзгә тоташа. Көлешәләр, танышалар, хәтта гыйшык та тота башлыйлар.

Мин дә йөргән булам шулар арасында. Тик берсенә дә сүз кушасы килми, берсе дә күренми алар миңа. Кайсылай гына атласам да, күз алдымда бары тик Зөһрә генә. Бу ниткән хәл икән бу? Әллә еракта, солдат җирендә, таныш-белеш булмаган кешеләр арасында ялгызсынып яшәүдән килә микән бу? Хәер, алай дисәң, бөтен рота минем иптәшләр ич, барын да беләм. Хәтта үзебезнең як егетләре дә бар. Еш кына бергә сөйләшеп, күңел ачып та йөргәлибез...

Шулай да нигә бу хәтле сагынам соң әле мин? Юк, сагынам гына түгел, өзгәләнәм! Без бит аның белән вәгъдә куешкан кешеләр. «Мин сине көтәрмен, Таһирым! Хезмәт тутырып кайткан көнеңдә үк кавышырбыз!» дигән сүзе бар ич аның. Шулай булгач, нигә мин ут йотам әле? Тыныч булырга кирәк миңа!..

Булырга кирәк! Әйтүе генә ансат! Әнә бит, озата да төшмәде. Әгәр үз итсә, шундый ерак юлга киткәндә озатып калмас идеме кеше? Ә хәзер инде хат та язмый. Димәк, «үпкән-кочкан җилгә очкан» дип кенә уйлаган инде ул... Күз алдында күз көеге булып йөрмәвемә сөенеп калгандыр әле... Хәер, алай ук мәкерле түгел иде бугай. Андый булса, шул чагындук җан бизгән булыр иде, хәзерге шикелле юксынып та, көрсенеп тә йөрмәс идең. Ә ул көннән-көн минем үзәкне өзә бара. Дулкын чәчләрен иңенә салган килеш, яныма басып «Уел»ны җырлый. «Каз канаты»н җырлый. Әллә ни көчле дә түгел аның тавышы, зур залларны яңгыратмас иде. Шулай да ярым бала тавыш белән җырлаганда, күңел түрендә нииндидер саф дөньялы, нечкә хисле изге бер җан иясе хасил була. Бөтен җаның-тәнең белән шуңа омтыласың. Ә ул юк, күз ачып йомганчы юкка чыга! Әллә кайда ул хәзер. Шул Барнаулындамы, әллә дөньяның башка бер адаштыргыч почмагындамы, кем белсен аны? Һаман хатлар яудырам, һаман җавап көтәм, әмма инә күзедәй генә булса да юаныч яктысы таба алмыйча, һаман миңгерәп йөрим. Көн-төн үз-үземә антлар бирен, аны онытырга тырышам, уйламаска телим — берсе дә барып чыкмый! Нинди хәл икән бу?..

Аннары куркып та куям тагы: «Тукта әле, ник уйламаска, ник онытырга, ул нинди начарлык эшләде? Шул ак күгәрченнән баш тартмакчы буласыңмы?» — дип, үземне битәрлим.

«Әллә чын сөю дигәннәре шушындый газаплы була микән?» — дип сорыйм үземнән. Әллә шундый хәлдә җуя микән кеше ихтыяр көчен?.. Берсен дә ачык кына аңлый алмыйча, һаман тинтерәп йөри бирәм. Шулай кыш та, яз да узды, җәй урталары да узып китте. Торабара хат язуларны сирәгәйтә төштем. Алып укыйдыр да, көлә-көлә ертып ташлыйдыр кебек килә башлады күз алдыма. Күңелдә дә ниндидер «барыберлек» уянып килә сыман. Янымда басып «Каз канаты»н җырлаучы Зөһрә белән минем араны ниндидер соры томан сара төште, тавышы да каяндыр бик ерактан, тонык кына булып ишетелә хәзер. «Аллага шөкер, онытыла бугай, ахры... Онытам бугай!» — дип сөенә дә башладым хәтта...

Нәкъ шул көннәрдә Барнаулдан бер хат килеп төште. Карыйм, конвертта Зөһрә кулы түгел. Аннан булмагач, ни кызыгы бар инде аның? Сулагай кул белән генә хатны ачтым да укый башладым. «Таһир абый, сезгә бик күп сәлам,— дигән,— Зөһрә апа монда түгел хәзер, Ростовта яши...» — дигән. Адресын да күрсәткән. Менә сиңа кирәк булса, Барнаул һәм Ростов! Дөньяның бер читеннән бер чите. Моны ничек аңларга? Нинди сәбәпләр шулай еракка чөйгән ул кызны?.. Хатта боларның берсенә дә, әлбәттә, җавап юк иде. Аны Зөһрәнең өченче класста укучы Ләйсән исемле сеңлесе язган. Әнисе әйтеп яздырган булырга тиеш. Күрәсең, мин тинтәкнең ничәмә айлар буена яудырып торган хәтларын ул карчык шушы бәләкәй кызыннан укытып килгән дә инде! Ниһаять, түземе бетепме, миһербаны кузгалыпмы, «мескен егеткә» олы кызының адресын хәбәр итәргә тиеш тапкан.

Көлкеме бу? Хурлыкмы бу?.. Анысын җентекләп торыр хәлдә түгел идем. Бу хат килеп төшү — тау хәтле сөенеч бирде! Сүнә барган самаварны иске читек кунычы белән өрдереп җибәрделәрмени — мин чыжлап, кабынып киттем. Барнаулга түгел, Ростовка агыла башлады хатлар!

Шунысы гаҗәп: озакламый җавап та килеп җитте.

«Син һаман да минем Таһирым, мин һаман да синең Зөһрәң!» — дип башланган ул хат. Аннары үзенең ул якларга бухгалтерлар курсына килүен һәм шунда эшкә калуын аңлаткан. Хат ахырында болай дигән: «Мин һаман да сине сагынам, бик күрәсем килә, хезмәтеңне тизрәк тутыр да мәңгелеккә бергә булырбыз!».

Менә бит нинди ул минем җанкисәгем! Изге бер сулышы белән мин тинтәкне тергезде дә җибәрде! Ә мин аның хакында әллә нинди кара уйларга төшеп, гөнаһлы була яздым. Бактың исә, аннан да тугры фирештә юк икән. Дөньям тигезләнде хәзер. Миннән дә бәхетле кеше юктыр!..

Алпы-салпы йөрүләр беткәч, хезмәттә дә тырышлык күрсәтә башлаганмын икән! Элек тә тел-теш тигәне юк иде югын, хәзер бигрәк тә күңел үсеп китте. Тырышкан табар, дигәндәй, миңа да командирым благодарность игълан итте. Ә политчастьта әйбәт җавапларым өчен политрук әз генә мактап та алды.

Күңел күтәренке булгач, сөйгән ярыңнан әйбәт хатлар килеп торгач, дөнья шундый матур икән ул, киң икән, якты икән!..

Бер уйлаганда гаҗәп сәер хәл булып чыкты әле бу. Әгәр Зөһрәне калдырып шушындый ерак җирләргә китмәгән булсам, күпме айлар буена аның бер хатына зар-интизар булып яшәмәсәм, аны шул хәтле өзелеп яратканымны аңлар идемме мин? Ул да үзен сынап караган, күрәсең. Ничәмә айлар дәшми яшәде ич. Ә инде минем хат — минем сөюем аны эзләп Ростовка да барып җиткәч, түзмәгән. «Син һаман да минем Таһирым!»— дип җавап язарга мәҗбүр булган!..

Менә шуңа күрә дөнья якты икән. Менә шуңа күрә дә мин яңадан тергезелгән мәхәббәт хыялымның зәңгәр бишегендә сабыйдай тирбәләм хәзер...

...Сизми дә калдым, безнең монда килеп хезмәт итә башлауга ел тулган икән. Әле кайчан гына бер көнне, бер атнаны уздыра алмый йөргән чаклар кая китте икән? Без хәзер устав кушкан бөтен өйрәнүләрне, бөтен хәрби программаны үтеп чыккан «карт солдатлар», полк теле белән әйткәндә, «старослужащийлар» булабыз инде. Без хәзер «утны-суны кичкән» кадрлар, вак-төяк йомыш белән чаптырмыйлар. Инде бездән картлар кайтып китте, алмашка яңалар, «яшел яшьләр» килде, ә без аларга мыек астыннан көлемсерәп кенә карыйбыз хәзер...

Тик ул чакларда мыек йөртү беткән иде инде. Борынгыдан килгән атаклы солдат мыегын бөтен полктан көндез чыра яндырып эзләсәң дә табылмас иде. Шулай да без үзебезнең юк мыекларны бөтереп йөргәндә, «төзек хезмәт» иткәннәрне унар көнлек ялга җибәрүләр башланды. Бактың исә, мине дә шундыйлар рәтенә кертәләр икән! Ноябрьнең береннән унына хәтле дип кулыма кәгазь тоттырдылар, акча бирделәр, коры паек бирделәр, аттестат бирделәр. Менә сиңа симез калҗа дигәндәй, көтмәгәндә генә чикләвекле имән ауды да куйды өскә! Тик шунда ук аптырап та калдым: «Инде ничек итәсе, кайсы якка китәсе?» дигән сорау килеп басты каршыга. Әни карчык та бик сагынып яза. «Көн саен сине төштә күрәбез, улым, көн саен иртәнге чәйне эчкәндә әтиең белән сине сагынып сөйлибез. Каз өмәләре җитеп килә. Ичмаса, өч-дүрт көнгә генә булса да җибәрмәсие микән камандирың, сорап кара әле, улым...» дигән сүзләр була аның хатында. Зөһрәнең дә «мин һаман сине сагынам, бик күрәсем килә» дигән сүзләре татлы һәм көчле җыр булып яңгырый колак төбемдә. Кайсыннан китим соң бу юлларның?.. Икесе дә якын, икесе дә кадерле...

Тегеләй уйлап карыйм, болай баш ватып карыйм. Нишләсәң дә вай! Ә инде озын-озакка сузарга вакыт юк, солдат срогы кыска — бүгенге поезд белән китәсе, аңа бары өч сәгать калган. Казарма баскычына чыгып утырдым да авызга тәмәке каптым һәм телефонны корып, сөйләшә башладым тегеләр белән.

— Исәнме, Зөһрә,— дим,— миңа ун көнлек отпускы бирделәр,— дим.

— Бик шәп булган, җаным, кил минем янга! — ди бу— Мин көтәм. Сагынуларым чиктән ашты, килми калма, күз нурым,— ди...

— Нишләргә икән соң,— дим,— әни карчыклар да бик чакыралар, бик сагынганнар, әллә башта берәр көнгә генә аларга күреним дә, аннары синең янга барырмын микән?— дим.

— Юк, алай булмый инде ул,— ди Зөһрә үпкәле тавыш белән.— Әгерҗе белән Ростов арасы — җир белән күк арасы! Мин сине бер күрергә зар булып торам, ә син әллә нинди сәбәпләр табасың... Болай булгач, бер дә яратмыйсың икән син мине!..—дип үк ташлады бу, иң авырткан җиргә сукты.

— Яратмасам, сиңа хәбәр итеп торыр идеммени!— дип куйдым мин дә текә генә.

Арада бәхәс китте, үпкә сүзләр китте. Шуннан соң мин бераз суыну өчен күңел телефонын аннан алдым да әниләргә ялгадым.

— Исәнме, әни,— дим,— миңа ун көнлек ял бирделәр...

— И балакаем,— ди,— бик тә рәхмәт инде камандирларыңа! Безнең сагыну тавышлары барып ирешкәндер аларга! Бик тиз кайтып җит, улым, җәме! Әтиең ындырда әле, кайтуы белән аны да сөендерәм!

— Кайтуын кайту да бит, әни,— дим,— менә шундый-шундый хәлләр бар шул... Ростовка бик чакыралар мине...

Һәм кыскача гына барын да аңлатып бирдем. Байтак вакыт сүзсез торды әни. Аннары сабыр гына тавыш белән әйтте:

— Ярар инде алай булгач, улым,— диде.— Без көтәрбез... Исәнлек кенә бирсен...

Мин тоттым да Ростовка китеп бардым...

Телефон дигәнем, әлбәттә, күңел уены гына. Әни карчык минем Ростовка киткәнне белми дә калган күк, Зөһрә дә мин киләсене алдан белмәде, телеграм-фәлән белән хәбәр итәргә дә баш җитмәгән...

Кичке якта килеп төштем Ростовка. Фанер әрҗәмне камерага тапшырып, урамга чыкканда ноябрь киче караңгыланып килә һәм бер дә туктый белми торган пыскак яңгыр ява иде. Бу калада беренче тапкыр булуым. Урамнары нинди аның, йортлары нинди, матурмы ул кала — минем күзгә берсе дә күренми. Кулдагы адрес буенча сорый-сорый, әллә ничә трамвайга утырып, әллә ничә кәкре-бөкре тыкрыкларны узып, шәһәрнең кайсыдыр кырыена килеп чыктым. Бер катлы агач өйләр, ак балчыклы хаталар башланды. Ниһаять, мин эзләгән 29 лы йорт та табылды. Гайнуллина Зөһрәне сорадым.

— А-а, Зарадыр инде ул, — диде юанрак кына бер марҗа апа чыгып. — Менә бу мазанкадан сорап карагыз әле, шунда булырга тиеш иде...

Инде шактый караңгыланып өлгергәнгә күрә, мин ул «мазанка» дигәнен шәйли алмый торганда, марҗа апа үзе килеп, бер бәләкәй генә алачыкның бердәнбер тәрәзәсен какты да:

— Зара, тебя просят, — дип эндәште, артык кычкырмый гына. Аннары борылып, җәһәт кенә өенә кереп китте, рәхмәт әйтергә дә өлгерми калдым. Озакламый, әлеге алачык ишегеннән хатын-кыз гәүдәсе күренде. Капка баганасындагы күсе күзедәй генә лампочкадан төшкән шәүләдә мин аның тар гына такта сукмак буйлап атлавыннан ук Зөһрә икәнен шәйләп алдым. Үзем дә аңа омтылдым. Өстенә юнгштурм кигән, биленә кухня алъяпкычы бәйләгән, җиңнәрен терсәкләреннән үк сызганып куйган, борын очы әз генә онга буялган Зөһрә килеп басты каршыма.

— Тагирушка! Йа аллам! — дип, кулларын җәйде ул бик тә гаҗәпләнгән тавыш белән. — Ничек болай бу?..

Һәм икебез дә, йөз ел күрешмәгәндәй сагынышкан кайнарлык белән кочакланышып, озак үбешеп алдык. Аннары гына аңга килеп дигәндәй, сөйләшә башладык. Күбрәк мин сөйлим. Куаныч эчкә сыймаганга, үземә ничек кинәт кенә отпуск бирүләрен һәм тиз генә чыгып китүемне аңлатканда — кабаланудан буталып беттем. Шулай сөйләшә торгач, байтак минутлар узып киткәнен аңладым. Шаян бер сорау килде башка:

— Туктале, Зөһрәм, — дим, — ник син өеңә дәшмисең? Әллә мине сүз белән сыйлап шушыннан гына озатмакчы буласыңмы?.. Әллә кияүгә чыктыңмы?..

Кинәт моның йөзендәге елмаю сүнде, кинәт башы минем беләккә сыгылып төште... Үзем дә әллә нишләп киттем. Ә Зөһрә һаман дәшми.

— Юк, чынлап та?.. — дим. Инде хәзер минем эчтә җәһәннәм утлары кайный башлады.

Ниһаять, телгә килде бу.

— Син гафу ит инде, җаным, — ди. — Миңа врачлар кушты... Монда килгәч бик каты башым авыртты, йөземә әллә нәрсәләр чыга башлады, электролечениегә йөрдем, файдасы тимәде, шуннан соң невропатолог әйтте:

— Сезгә хәзер үк иргә чыгу кирәк, моның дәвасы шул гына,— диде.

Минем өчен шаккаткыч яңалык иде бу хәбәр. Чынмы бу, уйлап чыгарылган әкият кенәме? Һич кенә дә ышанасы килми, хәтта көлке тоела!..

Зөһрә, башын калкытып, элекке мөлаемлелеге белән миңа карады.

— Әйдә, керик... — диде ул йомшак кына тавыш белән. — Мин пилмән пешереп йөри идем. Пилмән белән сыйлармын... Павлуша әйбәт

кеше, сүз кузгатмас... Ул безнең дуслыкны белә... Мин аңа барын да сөйләдем...

Минем хәл гадәттән тыш сәер, хәтта сәернең дә теге ягында иде бу минутта. Польша чигеннән, ике-өч тәүлек дигәндәй атлыгып, Ростов хәтле җиргә килдем. Килдем дә тар гына такта сукмакта, янгыр астында басып торам. Каршымда сөйгән кызым — ниндидер ир хатыны икән хәзер! Моннан да кәмит тагын нәрсә булсын?.. Нишләргә миңа хәзер? Солдатча үкчәләрне шык итеп кенә борылырга да кире китеп барыргамы?..

Әлбәттә, шулай кирәк булгандыр! Мәгәр алай булып чыкмады шул. Белмим, Зөһрәнең шул йомшак тавышы буйсындырдымы, әллә аны бик яратканга һәм бик сагынып килгәнгәме, мин, тәүфыйклы көчектәй, аның артыннан иярдем...

— Менә, Таһир килгән, Павлуша, таныш булыгыз...— диде Зөһрә, эчкә кергәч.— Кабул ит кунакны, өстен салдыр, түргә уздыр. Мин хәзер пилмән өлгертәм...

Павлуша да кыстагач, иң ахмак бер хәлдә, мин чыланып беткән шинельне салып, ишек катындагы бер чөйгә элдем, баштагы шлемны да шуңа чәпәдем. Павлуша, нәкъ Зөһрә кушканча, һәрбер хәрәкәтемдә булышлык күрсәтте, бер сүзе яки күз карашы белән дә төкселек, өнәмәүчелек сиздермәде...

Урталай ярган шпаллардан корамаланып, ак балчык белән сылап агартылган тәбәнәк кенә бу куышның түренә табарак барып утырдым. Түшәм уртасында бердәнбер лампочка яна. Аның яктысы хәтта учак тирәсендә кайнаша торган Зөһрәгә дә җитә.

Павлуша, чынлап та, ахры, гади холыклы, киң күңелле кешедер. Бер дә алай төртелеп-тартынып тормый гына сүз ялгап җибәрде. «Хезмәтләр авыр түгелме, бик артык йөгертмиләрме?» — дигән гади сорауларга җавап алганнан соң көрсенеп куйды.

— Эх, бар иде безнең дә яшь чаклар!— диде ул. Мин кинәт көлеп җибәрә яздым. Чөнки Павлуша болай да яшь егет булып күренә иде миңа, бик күп булса, утызда бардыр... Бәлки шундый шаян сүз яратучан кешедер...

— Әйе, бар иде!— дип кабатлады ул.— Алтай тау араларында партизан булып йөргән идек. Башта кызыл тасмалы бәрән папаха, өстә кыска тун, астымда көлтә койрыклы савраска, билдә кылыч булмаса да, җилкәдә винтовка, үземә уналты яшь. Үземә калса — миннән дә отчайни партизан юк!.. Ә хәзер картайдык. Икәүләп менә туган якларга кайткач, гади бер хезмәткәр булып киттем, «благонравный обыватель»гә әйләнеп барабыз бугай... Сездәй ыктымат киенгән хәрби егетләрне күрсәм, әле дә йөрәкләр җилкенеп китә китүен дә, но, увы и ах — бар да узып киткән хәзер.

Мин аңа караган килеш авызны ачтым да калдым. Әнә нинди егет икән ул! Лаеш шулпасын яшьтән үк чөмергән... Ә мин аңа, дошманым итеп, эчемә үч яшереп, кырын-ярын карап утыра идем әле... Күңел ничектер үзеннән-үзе язылып киткәндәй булды... Шулай да «икәүләп» дигән сүзеннән бер төен калды: күрәсең, Барнаулда ук табышканнар... Хәер, ничек кенә булмасын, мин барыбер ахмакларча бер хәлдә идем. Ник килеп кердем мин монда? Нигә шундук вокзалга китмәдем? Боларның үз дөньялары бар икән, нигә миңа аны бозып йөрергә?..

Зөһрә пилмән китереп куйды. Кыстый-кыстый табынга утырттылар. Килеп чүгүем булды, түр почмактагы бәләкәй генә өстәлгә күзем төште. Чигүле ак җәймә корылган бу өстәлдә төрле төстәге перламутрдан эшләнгән җыйнак бер кыса эчендә минем рәсем тора!.. Кинәт битләрем ут яна башлады, кызарып китүемне хәтта үзем дә күргәндәй булдым... Моны ничек аңларга? Ник саклый ул моны? Үзе кияүгә чыккан, үзе ташлаган егетенең рәсемен саклый, альбомда яки иске хатлар

арасында иске бер истәлек итеп тә түгел, ә түр почмак өстәл уртасында, матур бер кыса эчендә... Ул рәсемне мин армиягә баргач та төшеп, Барнаулга җибәргән идем. Ташлап калдырмаган, монда алып килгән булып чыга... Димәк, Павлуша безнең хәлләрне белә дию дөрес була инде... «Врачлар кушканга гына чыктым, мин һаман да сине яратам»,— дию дә хак микәнни соң?.. Юк, һичнәрсә аңлый алмыйм, аңларлык хәлдә дә түгел мин. Барысы да ялган, барысы да күз буяу өчен генәдер, тормышлары да боларның кәмит уены гынадыр кебек тоела...

Һични булмагандай кунакчыл тавыш белән пилмән ашарга кыстыйлар. Ашау кайгысымы миндә?.. Хәер, «Тамак — иблис, тамугка кертер» дигән сүз дә хак микән әллә? Үлеп ачыкканлык сизәм, бүген кайвакытта ашаганым да истән чыккан инде... Кыстагач, ашаган булам. әллә пилмән йотам, әллә утлы күмер йотам. Юк, пилмән кайнар булганга түгел, йоткан хәсрәт утым шулай үңәчләрне яндырып төшә.

Берничә кашыктан соң кузгалдым да, рәхмәт әйтеп, өстемне киендем, икесенә дә кул бирдем, бәхетле тормыш теләргә дә көчем җитте. Мин ишек төбенә килгәч, Зөһрә әйтте:

— Таһир, әз генә сабыр ит, мин сине озата барам трамвайга хәтле...— диде.— Син ашый тор, Павлуша, мин хәзер кайтып җитәрмен...

Монысы да кунакчыллык тәртибендә эшләнәдер инде, күрәсең... Нигә озата бара ул? Ниебез уртак инде безнең хәзер? Аның киенеп беткәнен дә көтмичә, баскыч төбенә чыгып, тәмәке кабыздым. Бөтен кайгыларымнан арынырга теләгәндәй, йотлыгып бер суырдым тәмәкене. Юк, арына алмадым, төтен кире чыкты, ә кайгылар йөрәк төбендә утырып калды.

Яңгыр һаман тукталмаган иде әле. Зөһрә чыгып, мине култыклап алды. Ноябрьның караңгы кичендә ниндидер утсыз урамнардан берсүзсез атлыйбыз. Минем күңел дә караңгы, болытлы күк тә караңгы, һәм бөтен дөнья караңгы... Никадәр тыелып килсәм дә, үпкә сүзләр ташкыны, ниһаять, таш койманы җимереп ташлады.

— Нигә син шушы хәтле эшәке итеп алдадың мине, Зөһрә?— дидем.— Ярар, кияүгә чыккансың икән, баш-аягың бер казан иде, көн күр — көлдә ауна, дигәннәр. Әмма ник син шуны ап-ачык итеп миңа язмадың? Аралар тып-тыныч кына бетәр иде, монда хәтле сөйрәлеп, әдәм хуры булып йөрисе дә булмас иде... «Баш авыртты, врачлар куштылар», дию көлке генә, әлбәттә. Моңа тавык та ышанмас, карга да бот чабып көләр генә!

Киттем тезеп, киттем ярсынып, Зөһрәгә авыз ачарга да ирек бирмәдем. Урамда сирәк-мирәк очраучылар борыла-борыла безгә карап узалар. Шунда гына үземнең артык трагик тавыш белән шактый кычкырып сөйләгәнемне ишеттем.

Зөһрә ничек кенә булса да минем күңелне йомшартырга тырыша.

— Ничә мәртәбәләр сиңа үз хакымда барын да язарга утырдым,— ди ул.— Әмма кулым күтәрелмәде, сине мәңгегә югалтудан курыктым. Аннары шундый уйга килдем: озакламый, Павлуша белән араларны өзәрмен дә, син кайтканны көтәрмен һәм шунда барын да аңлатырмын, дидем...— Ул тәмле теле белән тагын да бик матур вәгъдәләр бирә. Киләчәктә бик бәхетле булып яшәячәгебезне сурәтли.

— Әлбәттә, син риза булсаң гына,— ди.

Туктаусыз яңгыр астында туктаусыз агылган шундый сүзләр белән без вокзалга ук килеп җиткәнбез. Миңа кирәкле поезд инде китеп барган, алдагысы иртәгә генә булачак, имеш...

— Беләсеңме, Таһир, моннан якын гына «Урал» гостиницасы бар,— диде Зөһрә.— Әйдә, мин сине шунда илтеп урнаштырыйм. Иртәгә синең янга килермен. Рәхәтләнеп бергә булырбыз, туйганчы сөйләшербез.

И мескен ирләр инде без! Юмалады, тәки юмалады Зөһрә мине, ышандырды. Хәер, башка чарам да юк иде. Буйсындым...

Тик «Урал»да борын төртер җир дә булмады. Зөһрәне трамвайга утыртып, өенә озаттым. Вокзал сәгате төнге уникене сукты. Мескен Павлуша... һаман да пилмән ашап утыра микән әле? Сөекле хатыны үзенең «бывший» сөйгән егетен озата чыгып киткәндә: «Син ашый тор, мин хәзер кайтам»,— дигән иде бит аңа...

Туктаусыз яңгырдан тәмам күбенеп, авыраеп беткән, итәк очларыннан тамчы тама торган озын шинельне иңемнән салып ташлардай булып, вокзал эченә кердем. Төрле залларында эзләнеп йөри торгач, бер эскәмия почмагына борын төрттем. Арка-җилкәләргә үтләшкән яңгыр юеше йокымсырап барган тәнне туңдыра башлады. Тагын кузгалып, залдан-залга сәяхәт кылырга, буфеттан кайнар кофе алып эчәргә туры килде. Иртәнге алтыны җиткергәнче күпме таптанып, баш төрткән җиремнән ничә кузгатылып, ничә тапкыр документларым тикшерелеп, төнге идән юучылар тарафыннан ничә рәт залдан куылып, тәмам алҗып, талчыгып беткән идем инде мин... Ә үзем ут янам, аһ орам, аннары көләм үземнең җүләр баштан.

Көлүен көләм, ләкин эчтә шүрәлеләр үтмәс пычкы белән утын кисә. Шул хәтле сагынып, сөйгәнең белән күрешү бәхетенә ирешмәкче булып кил дә, шушы хәлгә төш. Менә сиңа бәхет! Җан газабы татып, тәртәләреңне кире бор! Ничек аңларга соң бу кызны? Йөрәктә шундый яра калгач, ул мине нихәтле генә яратса да, киләчәгебез ничек булыр соң безнең? Ә мин аны чын-чыннан яратаммы?.. Берничә айлар күрешми торудан, юксынудан туган хис кенә түгелме? Хәер, әгәр яратмасам, шушы хәтле ерак җиргә, күз күрмәгән-колак ишетмәгән якка аны эзләп килер идемме? Үпкән-кочкан җилгә очкан шикелле, очраклы мавыгулар җиңел генә, эзсез генә җуела да бетә ич ул. Әгәр шундый гына мавыгу булса, мин аның бу хәтле тинтәк сәбәпләр һәм җиңел акыл белән иргә чыгуын болай авыр кичерер идемме? Көлеп кенә уздыра алмас идеммени?..

Аның яратуы да чын сыман шикелле бит. Нигә ул гади солдат рәсемен саклап йөртә, Барнаулдан монда хәтле алып килеп, бүлмәсенең түр почмагында тота? Хәтта иреннән дә яшерми. Кадерле кеше рәсемен генә матур рам эченә куялар түгелме соң? Кияүгә чыккач язудан туктамса да, минем сагыну һәм ярату хатлары монда хәтле килеп җиткәч түзми, чын хисләре кабынып, яңадан яза башлый. Инде шулай булгач, әгәр без чын-чыннан яратышабыз икән — мин аның бу хатасын гафу итәргә тиеш түгелме соң? Яшьлектә кем хаталанмый? Әгәр мәхәббәт чын булса, саф булса, ул бөек, киң күңелле һәм үз сөйгәненең гаебен кичерә алучан көчкә ия булырга тиештер бит! Әйе, минем олы яратуым яктысын андый очраклы күләгә генә сүндерә алмый. Мин аны гафу итәм! Тик миңа Павлуша гына кызганыч. Шул бер очрашуда ук мин аның әйбәт егет икәнен аңлап алдым. Бәлки ул да яратадыр Зөһрәне. Аны югалтуын ул ничек күтәрә алыр? Хәер, безнең яратышулар аңа кадәр үк башланган ич. Ай белән Җир арасына очраклы килеп кергән метеор гына түгел микән ул?.. Шулай да бу мәсьәлә ансат чишелә торган түгел, кыен, четерекле...

Шушы хәлләр белән баш ватканда, вокзалга Зөһрә килеп керде. Иртәнге алты да тулмаган иде әле. Ник килгән ул? Яратмаса килер идеме? Моңа күңел тагын да үсеп, рәхәтләнеп китте.

Мин китәсе поезд алты утызда. Перронга чыктык. Зөһрә миңа сумкасыннан алып үзенең рәсемен бирде. Болай да матур чәчләренә давыл төсе кертеп, юнгштурмнан төшкән открытка. Сокланып карый-карый, гимнастерка кесәсенә тыгып куйдым. Аннары кулыма бер җыйнак кына төргәк тоттырды.

— Моңысы юлыңа әз-мәз генә ризык,— диде.

Шундый юк кына сымак нәрсәләр белән дә күңел таба белә бит ул үзе! Тыны белән океан айсбергларын эретер!..

Инде перронда йөрибез. Бүген, болытлы булса да, өстән коеп тормый, шулай да дымык һава. Поезд кузгалырга санаулы минутлар калып бара. Нигәдер Барнаул вокзалыннан китеп барган чак хәтергә килде.

— Ни өчен инде шунда озата төшмәдең?— дидем.— Үзәкләрем өзелеп, синең бер елмаюыңа, бер генә үз итеп каравыңа зар булып китәргә туры килде ул чакта...

Күптәнге хәл булса да, Зөһрә югалып калмады, җавапны тиз тапты.

— Мин бик төшмәкче идем, Таһир,— диде ул.— Но синең теге бер иптәшең бар иде бит, кем әле, бик көләргә ярата торган кеше?...

— Сәфәрме?

— Во-от үзе, шуннан курыктым. «Квартирант сөяркә...» дип көлә башласа...

Бу сүздән мин дә көлеп куйдым. Ләкин безнең мөнәсәбәтләрне Сәфәр белми иде дип уйлыйм, чөнки бу хакта дусыма бер авыз сүз сөйләгәнем булмады. Гомумән, үзеңнең иң кадерле, иң яшерен һәм изге дөньяңның ишек-тәрәзәләрен, хәтта якын дус-ишең өчен генә булса да, ачып кую мөмкинме? «Юк!»— дип әйтәсе килә. Мәгәр ул изге дөньяң эченә кинәт янгын кабынып, кара төтеннәре синең сулышыңны буа башласа, анда нишләмәк кирәк?..

Минутларыбыз бетте... Актык хушлашу, актык сүзләр, вәгъдәләр... актык караш, актык кул изәүләр... Әкрен генә кузгалган поезд үз хәрәкәтендә. Ачык тамбурдан башымны сузып карасам да, Зөһрә күренми инде. Озын вокзалның актык почмагын узабыз... Шундагы актык прожектор астында бер кеше тора. Ерактан гына карап безнең поездны һәм аның кайсыдыр вагонындагы кемнедер сиздерми генә озатып кала төсле ул кеше... Аның да шундый хәсрәте бар микәнни соң? Тоныклана башлаган прожектор уты аның тулымса түгәрәк күренгән йөзен һәм күзлеген яктыртып калды. Үзенең шул моңсу гына сыман торышы беләнме, кайдадыр, ничектер күзгә чалынган кеше кебек тоелды ул миңа. Ләкин таный алмадым... Инде шактый ерагая төшкәч, әллә... Павлуша иде микән ул дип уйладым... Безне күзәтергә килгәнме?.. Хәер, мондый ямьсез уйны шунда ук кире кактым: булмас, ул алай сыман күренмәгән иде бит. Ә бәлки... үзәге өзелгәнгә килгәндер ул... Зөһрәсен җую куркынычы китергәндер... Ул да кеше бит һәм яхшы күңелле кеше!..

Хуш, яңгырлы Ростов. Хуш, җилбәзәк Зөһрәм. Арабызны бәйләгән изге җепләрне шартлатып өзүче дә син һәм, белмим, ефәк беләнме, белмим, юка белән генәме ялгап җибәрүче дә син... Һаман әле тәмам аңыма килә алмыйм. Бер төн эчендә коточкыч ямьсез һәм искиткеч матур ике төш күргән кеше шикелле аптырап, тулай вагонның урта сәндерәсендә яныңнан китеп барам. Ике төшемнең кайсына ышанырга да белмим. Хәер, беренчесе — чынбарлык. Үз күзләрең белән күреп, үз йөрәгең белән ачысын татыгач, ышанмый хәлең юк. Ә менә икенчесе?.. Белмим, ул төшне миңа кем генә ачык кына итеп юрап бирер икән?..

Мин бит аның бу ялгышын кичердем. Әгәр алар Павлуша белән үз араларын үзләре хәл итсәләр, безнең яңадан бергә бәхетле булуыбыз бик ихтимал ич. Әмма аларның ул эшенә мин кысылмаска тиеш...

Күпме чәйнәсәң дә, бер балык башы дигән кук, һаман шул хакта уйланып ята-ята, көн урталарын уздырып җибәрдем. Әллә ничә рәт чыгып, суык тамбурда тәмәке төтәттем. Ниһаять, бу чишелмәс уйларны болай төйнәп куйдым: тукта, мин бит әни карчыклар янына кайтам, ул көнемне тутырмыйча полкка кайтсам, «куып җибәрделәр мәллә» дип көләрләр иде, шуңа күрә билетны Әгерҗегә алдым. Әни карчыкның җылы сүзе, тәмле ризыгы белән туенып, бераз ял итәм, бу чуалчык

кичерешләрдән айның төшим. Полкка барып, хезмәтемә тотыныйм, әле миңа кече командирлар курсына да җибәрмәкчеләр иде, занятиеләр күп булыр, вакыт үзе миңа юл күрсәтер...

Икенче кичне Казанга килеп төштем. Монда миңа Әгерҗе поездын дүрт сәгать көтәсе бар икән. Вокзалда бер сәгать поезд көтү — бер тәүлектән артык тоелганы сезгә билгеле инде. Сәфәрне эзләп киттем, күрешмәгәнгә елдан артык. Уңай туры килде — тулай торак бүлмәсендә студентларның кичке чәй белән эчәк юган чаклары иде. Сәфәр мине дә утыртты. Танышып, мин солдат тормышларын, алар үз хәлләрен сөйләшеп, чәй эчтек. Бер исәп-хисратенң дә булмаганда, шулай юк-бар сүз суырып чәй эчү шәп нәрсә инде ул. Ә минем эчтә Уссури капланнары тырнаша, һаман тынгылык бирмиләр... Үзе өчен бик кадерле һәм яшерен серләрен иң якын дусына да сөйли алмый кеше. Мин дә авыз ачармын дип уйламаган идем, булмады. Шушы ике-өч көн эчендә уздырылган кичерешләр ташкыны ярларыннан чыгып, түгелде дә китте...

Сәфәр мине озата төшкән иде. Әгәр поезд шундук китеп барган булса, түгелми кала идем, югыйсә. Юк шул, китмәде. Вокзалның буш бер диванына килеп утырдык. Түш кесәмнән Зөһрәнең әлеге рәсемен чыгардым да:

— Менә бу кеше сиңа сәлам әйтте...— дидем, рәсемне аңа сузып.

Юк, Зөһрә аңа бертөрле сәлам дә әйтмәгән иде... Күрәсең, бу ялган миңа сүз башлау өчен кирәк булгандыр...

Рәсемне кулына тоткан Сәфәр андагы давыл чәчләргәме, элеккечә әйтсәк, җазибәле елмаюгамы, әллә башка бер хисләр беләнме, сизелмәслек беравык эчендә күз сирпеп алды да сорады:

— Кайда күрдең син аны, әллә Казанга килгәнме?..

— Юк,— дидем мин.— Ростовта күрдем... Аның яныннан кайтып килешем...

«Күзләре шардай булды» дигән сүзнең хак икәнен шунда аңладым мин. Сәфәрнең дә чиксез гаҗәпләнүдән ут янган күзләре каш өсләренә менеп утыргандай күренде миңа...

— Ничек инде бу? Ничек? Һичнәрсә аңламыйм. Барнаул? Ростов?.. Аның яныннан?.. Юк, аңламыйм,— дип кулларын җәйде егет.

Барын да, барын да түкми-чәчми сөйләп бирдем... Күңел капчыгымның хәтта төбен әйләндереп селкүемне соңыннан гына төшендем.

Сәфәр башта шаркылдап көлде, аннары болай диде:

— Туктале, малай, син арттырыбрак җибәрмисең микән? Ул бит минем белән дус иде, миңа күңеле хуш иде!..

Хәзер инде минем күзләр маңгай түбәсенә сикереп менде! Ничек була инде ул —«дус» та, «хуш» та? Ике куян?..

Ә Сәфәр дәвам итте:

— Әйе, әйе, бер дә гаҗәпләнәсе юк. Без аның белән көннәрне матур гына уздыргаладык. Язын Обь ярыннан бозлар озаттык, эрәмәгә чыгып, Алтай күлләренә барган чаклар да булды. Тик минем комсомол эше белән еш кына командировкада булгалау гына иркенрәк вакыт бирми иде... Ә бер кичне хәтта синең кулга эләгә яздык... Ничек, дисеңме. Бер дә әллә ничек түгел — бик гади. Китәргә икеме-өчме көн кала бугай, Зөһрә минем бүлмәгә килеп керде: «Бездәге кеше дә синең белән китә икән, мин сине озата төшә алмыйм, уңайсыз,— диде бу.— Шуңар күрә бүген мин синең белән «прощальный бал» ясарга килдем...»

Без бик күңелле генә кич утырганда, кемдер килеп ишек какты. Мин ачмадым, чөнки егет каршында кыз «аккош» биюен башкарган чакта кемнең кирәге бар? Әлеге кеше тагын бер шакыды да:

— Ач, Сәфәр, маташтырма,— дип куйды шаян тавыш белән.

Син икәнне белеп алгач, Зөһрә минем янга килде дә: «Бездәге кеше, ача күрмә!»— дип пышылдады. Мин тик торам идән уртасында

елмаеп. Ә Зөһрә, стенага үрелеп, утны сүндереп үк куйды. Бүлмәдә ут сүнгәннән ишек астыннан шәйләп алгач, синең ачу килде, күрәсең.

— Берәр этлегең бар икән болай булгач, ут сүндереп котылмакчы буласың, барыбер эләгерсең, милиция алып киләм хәзер...— дип, юри генә сукрана-сукрана чыгып киттең син...

Юлга чыккач ук син бу хакта бик төпченеп караган идең, әйтмәдем. Ир-егетнең эчендә иярле-йөгәнле ат ятса да кешнәмәс... Күпне белсәң — тиз картаерсың, дигән мәзәкләр белән генә уздырып җибәрергә туры килде. Ә менә хәзер, үзең сорамастан ук сөйләп бирдем... Ач күзеңне! Һәр ялтыраган алтын булмый, диләр. Ни дисәң дә конфет суырып кына үскән кыз бит ул!

Минем хәлләр әйтеп аңлата торган түгел иде. Сыным катты, каным өшеде, баш чатнап ярылды бугай, авызда сүз түгел, тамчы бер төкерек заты да калмады... Ярый әле, мин китәсе поездга утыру башлануын хәбәр иттеләр. Сәфәргә кул бирдемме-юкмы, камерага йөгереп, фанер кисәгемне алдым да перронга чыктым. Туры килгән беренче вагонга менгәндә Сәфәр итәктән тартты.

— Кабаланма, кысылырсың!— дип көлде ул.— Андый хәлләрдән болай саубуллашмый да качып котылу барыбер мөмкин түгел ич!— дип өстәде.

Мин дә елмаерга теләгәндәй иттем. Ләкин ул минутта бөтен дөньяга ишетелерлек итеп кычкыра-кычкыра сүгенәсем килә иде минем. Авыз ерудан башканы белми торган Сәфәрне дә тамбурдан гына килеш тибеп очырырга бик кыҗырыйм. Ниһаять, түзә алмадым, авыз ачтым:

— Ул бит... мыскалланмаган ефәктәй саф көенә миңа тапшырылган кыз... Без аның белән бәхетле тормыш корырга вәгъдәләшкән кешеләр... Ялган синең бу пычракларың, ялган!— дип кычкырмыйча булдыра алмадым.

Сәфәр сискәнеп китте.

— Акылдан яздың мәллә?— диде ул, күзләрен акайтып.— Ник аны әллә кайчан әйтмәдең, янына да бармаган булыр идем!

Дәшмәдем, кул селтәдем дә вагонга кереп киттем. Иң аргы бер караңгы почмакка постым. Минем бу мескенлекне, бу хурлыкны анда берәү дә күрмәс шикелле тоелды...

Бу газап юл буе изде мине. Әгәр дөрес булса? Дөрес булса?.. Дөрестер, хәтерлим — килдем, ишек ачмады, утын сүндерде, кире борылдым. Барын да дөрес сөйләде... «Бездәге кеше»... имеш. Ә үземә: «җаным да бәгърем!» Баксана, бөтен эше-кыланышы, бөтен сүзләре ялган булган икән. Ник мин шул хәтле аңгыра байгыш, шундый да беркатлы тинтәк булдым икән? Ник берсен дә күрмәдем, белмәдем, сизмәдем, һәр сүзенә ышана килдем. «Мәхәббәтнең күзе сукыр була» дигәннәре шушындый ачы хакыйкать микәнни соң ул? Һай, бу дөнья!..

...Әни карчыкның тәмле ашлар белән сыйлап, шәфкать тулы изге куллары белән тәрбия күрсәтеп, кунак итеп җибәрүе дә миңа җиңеллек китермәде. Полкка әйләнеп килгәч, бөтен юк-бар уйларга кул селтәп, бары тик хезмәтем белән генә онытылып яшәргә тырышу да җан тынычлыгы бирмәде. Һаман шул үз хәсрәтем белән изаланудан арына алмадым. Ник мин ул кызның шундый шома ялганнарына шулай тиз ышандым икән?.. Иге-чиге булмаган мондый сорауларның, әлбәттә, берсенә дә җавап табу мөмкин түгел иде. Тора-бара эчтә ниндидер усал давыл купты. Әле һаман кесәдә йөргән теге ялган елмаюлы рәсемне ниндидер рәхимсез хәрәкәтләр белән теткәләп җилгә очырдым. Төче сүзле хатлары килде — аларын да көлгә әйләндердем... Әле кайчан гына якты хыяллар белән саташтырган мәхәббәт — караңгы төн шикелле кара нәфрәткә әверелде...

— Юк ул мәхәббәт, юк ул чын сөю дигән нәрсә! Аңа мин җүләр генә ышанып йөргәнмен!— дип, бөтен дөньяга кычкыра иде Таһир солдатның яралы йөрәге...

Әмма шул да хак — андый яралар да җөйләнә икән...

*
* *

Җәйге челләдә кубынган умарта кортлары шикелле шактый хәтәр безелдәшеп алды безнең җитмешле җилкенчәк яшь егетләр.

— Мәсьәләне бик каты куясың әле син, Таһир дус. Сөю бөтенләй юк булгач, ник соң без кызларга күз атабыз?

— Мәхәббәттән нәфрәткә бер генә атлам, дигәннәр түгелме соң?..

— Ул сөймәсә дә, син сөйгәнсең булып чыга бит!

— Юк, берсе сөйгән чынлап, берсе йөргән уйнап!

Баш артын кашый-кашый, «запчас»ле Ихсан да телгә килде.

— Син алай дип әйтеп әйтәсең дә бит, агай-эне, ә менә мондый хәлләр дә була икән дөньяда...— дип куйды ул.

Камисия шундук эләктереп алды да: «Күп сөйләнмә, эшкә тотын!»— дигән боерык бирде аңа. Ихсан тагын кашыды башын. Тамак кыргалады. Аннары кул селкеп сорады:

## Матурның да матуры

турында сөйләсәм ярармы?

— Синең дә матурыңның әдәм баласы өчен берәр кызыгы булса — ярый!— диештек без.

— Тыңлагыз, алайса...— диде ул.—Кая барып бәрелергә, кемгә килеп күрмәлергә дигәндәй белми йөргән чакта бер кыз белән таныштырдылар мине. Май бәйрәме кичәсендә булды бу. Түгәрәк уенында Зариф дигән иптәшем таныштырды. Мине үз урынына бастырды да:

— Таныш булыгыз, кызлар, бу минем Ихсан дус, кунак егет,— диде. Аннары авызына папирос кабып, шырпы сызды.

— Тартмаска!— дип кычкырдылар.

— Карагыз әле, кызлар. Җәберли күрмәгез инде минем кунак дусны! —дип тел кашыган булды да клуб залыннан чыгып китте Зариф.

Кызларның берсе Зөлфия, берсе Назикә исемле икән. Мондый исемне гомердә беренче мәртәбә ишетүем. Әллә юри генә әйтәме дип, кабат сорадым.

— Ышанмыйсыз мәллә?— диде ул, ничектер бик тыйнак кына елмаеп.

— Ышанам инде сез әйткәч,— дигән булдым. Ләкин үзем барыбер ышанмадым. Кайдандыр бик борынгы китаптанмы, фарсы яки гөрҗи иленнәнме, әллә ясалма исемнәр арасыннанмы килеп кергән шикелле иде бу исем. Әммә ничек кенә булмасын, матур яңгырый һәм нәсенә бик тә хас кебек тоела иде.

«Җәза» бирелгән егет белән кыз урталыкта биеп алгач, түгәрәк уңга таба яңадан әйләнә башлады. Уң кулымдагы Зөлфия шул якка борылып, миңа аркасындагы ике кара толымын гына калдырды. Мин дә уңга борылырга тиеш, мәгәр ни өчендер борыласым килми. Сул кулымдагы Назикәгә муен чокырымны гына күрсәтеп йөрү уңайсыз тоела, баягы мөлаем елмаюы да нигәдер күз алдымда тора. Мин уңга борылмый гына әйләнәм...

Залны яңгыратып агылган «Сакмар» көе әллә кайларга алып китә. Үзенә тойдырмастан гына, Назикәгә карап алам мин. Караган саен тагын карыйсым килә. Ул җыр белән мавыккан, минем урлап кына күз

атканны бик үк сизми дә бугай. Тавышы да аның, баягы елмаюы шикелле, тыенкылык белән чыга. Җәйге таң алдындагы моңсу тынлыкта Сакмарга коя торган чишмәнең көмеш җырын хәтерләтә. Һәм андый чишмәләр фәкать Сакмар ярында гына була торгандыр кебек тоела. Менә шунда инде Назикәнең кулы да, Зөлфия кулына караганда, ничектер татлы җылы һәм җан рәхәте бирә торган йомшак икәнен абайлап алдым мин. Алай гына да түгел, шул сихри җылы минем сул кул буйлап өскә таба йөгерә, хәтта йөрәккә килеп сарыла сыман тоела. Бу хәл мине кинәт әллә нишләтеп җибәрде. Түгәрәк әйләнә, түгәрәк белән бергә минем баш та әйләнә хәзер!

Назикә дигән матур исемле, җыйнак кына сылу гәүдәле, хәтта бөтен дөньясы сөйкемле күренгән шушы кыз белән янәшә басып әйләнү, ниндидер тын гына якты нур сибелә торган зур, уйчан күзләренә яшертен генә бер карап алу — моңарчы минем уема да, төшемә дә кермәгән һәм үзем дә ышана алмый торган гаҗәеп бер куаныч, бәхеткә әверелде хәзер. Ул да кит — бүтән берни дә кирәкми!..

...Җитмешле егетләрнең кайсыдыр тел очын шартлатып куйды, башкалар да көлешеп алдылар.

— Туктагыз әле, егетләр, бик кеткелдәшмәгез,— диде Ихсан аларга.— Сез уйлаганча алай ук «оҗмах кошы» түгел ул, җир кызы. Җир кызы булса да, әллә ниткән фирештәләреңә биргесез минем өчен! Шул таң нуры сибелә торган күзләренә караган саен исергәннән-исерә барам, туктаусыз елмайган булам, шул ягымлы кулын сак кына кысынкырап куям, бер бик әйбәт кенә сүз әйтәсем килә. Тел тибрәнә, төкерекләрне йотам, авыз кибә, ә сүз чыкмый, җан теләгәне табылмый сүзнең!

Нишләдем соң әле мин, ни булды миңа болай көтмәгәндә генә? Дөрес, күңел әллә кайчаннан бирле борчыла иде, нидер җитми кебек иде, әмма болай тиз изрәп төшәрмен, бу кызны күрү белән шулай исереп китәрмен дип һич кенә дә уйламаган идем. Аннары бит әле ул кызның әллә кайчан танышы бардыр, болай гына елмаядыр ул...

Инде Зариф та уенда икән, мин аның кергәнен күрми дә калдым. Тик ул безнең янда түгел, нигәдер түгәрәкнең каршы ягына баскан, һәм күзләре безгә таба юнәлгән. Ул да Назикәгә йотылып карый бугай, ә йөзе нишләптер суык, бер генә дә елмаю чаткысы сизелми. «Әллә көнли микән?»— дип уйлыйм.

Хәер, кешенең эчендәгеn каян белеп бетерәсең инде, монда минем үз хәлем хәл бит әле... Нигә болай телне таш баскан булып чыкты соң әле минем? Бер дә бит моңарчы сүз эзләп чабата кесәмә керми торган идем. Хәер, ул бит үзем ише шапылтыклар белән генә. Ә монда бит яңа кешеләр, берсе дә таныш түгел. Ничек алар янында ук чышын-пышын киләсең?...

Аптырагач, түш кесәмнән папирос чыгарып, авызга каптым да:

— Мин хәзер керәм, яме, Назикә,— дип, коридорга чыктым. Бу ике сүзне сердәшләрчә тавыш белән әйттем, бер дә тартынып-нитеп тормадым...

Шәп папирос бу «Пушка». Нәкъ безнең ише «шырт-куык»лар өчен чыгарылган: үзе бармак юанлыгы, үзе унсигез генә тиен. Бер кул белән бөерәккә таянып кызлар каршына баскан килеш, икенче кулның ике бармак арасына кыстырылган шул беләк юанлыгы папиросны суырып, бер фарсит итеп җибәрсәң, кайсы кызның күзе янмас шундый егеткә! Кеме сокланмас аның шундый егетләрски кыланышларына?

Шулай шәп кыланып тартырга мин дә өйрәндем өйрәнүен, тик бер кызның да миндәй асыл егет өчен утка сикергәне юк әле. Киресенчә, төтенгә тончыга-тончыга, үзем янам менә.

ШӘЙХИ МАННУР ◆ ЧЫН СӨЮ БАРМЫ? ◆

Тәмәкене тилкенләй йотардай булып суыра-суыра таптандым да, бер генә авыз сүз язмакчы булдым кызга. Чынлап та, андый чакта үз телең житмәсә, «сандугач теле» бар ич! Капшанам кесәләрне, таптым бер уч төбедәй генә кәгазь кисәге. Шул почкакка шырпы буедай тына карандаш заты белән болай дип яздым:

«Гүзәлкәй, Назикәй! Рөхсәт итегез сезнең белән танышырга. Бу кичәдән бергә кайтсак, бик күп сүзләрем бар сезгә әйтергә. Кош баласы жим көткәндәй, жавабыңны көтәм: Ихсан».

Мин кергәндә уен дәвам итә, «Керләр чайкый сай жирдә...» дип, «Сажидә»не жырлыйлар иде. Зариф минем урынга баскан. Миңа Назикәнең икенче кырыеннан урын алырга туры килде. Ул хәл минем өчен бик жайлы булып чыкты: түгәрәккә кереп житәкләшкәндә үк әлеге «күбәләк»не Назикәнең учына салдым. Хәер, дөресрәге, ул безнең ике уч арасында йөрде. Жыр белән мавыккангамы, әллә сиздермәс өченме, Назикә миңа таба башын да бормады, Зарифка да карамый иде. Аның күзләре каядыр билгесез еракларга юнәлгән шикелле тоела. Ә үзе онытылып жырлый. Йомшак кына, утә ягымлы гына агылган тыенкы тавышы йөрәккә май булып ягыла диярсең, бөтен жаннарыңны эретә, иркәли, башыңнан сыйпый, шул ук вакытта үзәкне дә өзеп ала шикелле.

Моңарчы гомеремдә бер генә тапкыр да татып карамаган бу рәхәттән мин бөтенләй сәрхуш булып, аягүрә «мәрткә» киткәнмен. Мин, имеш, бөтенләй бу клубта түгел, мин дөньяның иң матур төшендәге иң матур бакчада, гөлләр арасында Назикә белән житәкләшеп йөрим. Аның учыннан минем йөрәккә әлеге татлы дулкын тагын агыла башлады. Гомердә минем уйга да килмәгән унбиш колачлы, шәл яфраклы, бүрек чәчәкле агачларда сайрашкан энже каурыйлы кошлар тавышы күңелләрне кабат саташтырып, әллә кайларга алып китә. Юк, дөнья бакчасы гына түгел, имеш, бу, Фәрхи әбинең без бәләкәй чакта сөйләгән ожмахында йөрибез, имеш, без! «Уф!» «Уф!» дип куям мин эчемнән генә...

Шул чакта түгәрәк әйләнүдән тукталды, шунда безнең учлар аерылды, шунда татлы дулкын киселде, шунда ожмахлар, кошлар югалды, шунда әлеге «күбәләк» кисәге идәнгә төшә язды, шунда икебез дә берьюлы иелештек, шунда безнең чәчләр бер-беренә тиде, шунда Назикә кәгазь кисәген идәнгә төшермичә, кеше күзенә чалынудан элек тотып алды һәм, шунда башын күтәргәндә миңа әз генә елмаенкырап, иптәш кызлары янына китеп барды...

Аннан соңгы уеннарда без инде янәшә туры килә алмадык. Озакламый, таралыша башладылар. Ишек төбендә Назикәне күреп алдым да янына килеп туктадым. Һични булмагандай тавыш белән тел кыймылдаткан булдым.

— Ә жавап нишләптер килеп житмәде...— дидем әкрен генә.

Назикә шул ук тын елмаешы белән миңа карады, күзләренә ниндидер шаян яктылык сибелде. Бераз сүз тапмагандай торды да:

— Ихсан абый... сез бит аны юри генә язгансыз, име? Шаярып кына... Без таныш ич инде... Таныштырдылар.— Сүзләрен шулай өзә-өзә жавап бирде ул сабыр тавыш белән. «Юк, андый танышлык турында түгел иде сүз...» — дип каршы төшмәкче булдым. Әмма, уйлап карагач, ул хаклы булып күренде. Чынлап та, инде таныш булган кызына кабат танышырга рөхсәт сорап хат язу чеп-чи ахмаклык түгелмени? Бик кирәкле сүзләрең бар икән, пышылда шунда уен барган арада. Тик бүтәннәр генә ишетмәсен... Кара син аны, акылы үткен икән бу кызның!

Мин шуңа хәйран калып баскыч төбенә чыкканда, каршыбызга Зариф килеп басты.

— Озатып куйыйкмы, Назикә?—диде ул кыю гына.

Кыз, каршы килмәвен белдереп, әлеге йомшак елмаешы белән генә җавап бирде.

Мин белмәгән караңгы урамнардан әйләнә-борыла, икебез ике ягыннан атлыйбыз кызның. Беребез дә бер сүз сөйләшми, һәркем авызына су капкан. Мин инде, билгеле — яңа кеше. Ә нигә алар сөйләшми икән? Әллә Зариф та минем хәлдәме? Әллә Назикә аннан куркамы? Сәер мин, җыен юләр уйлар минем башта!

Утыртып сугылган гурбил такталардан корылган бараклар рәте белән бара торгач, урам буе рәшәткәле, җиңел капкалы берсенә килеп туктадык.

— Ярый, дуслар, мин кайтып җиттем, бик зур рәхмәт сезгә,— диде Назикә, караңгыда да якты елмаеп. Әллә миңа гына шулай күренде микән?

— Хуш, алайса,— дип кул бирде Зариф.

— Хушыгыз...— дип, мин дә суздым кулны.

Зарифтан соң минем кулны кысты Назикә. Кысты дип үк әйтү мөмкин микән, бәлки миңа гына шулай тоелгандыр. Шулай да аның кулы элеккечә үк җылы һәм бик ягымлы иде.

— Хушыгыз,— диде ул гади генә итеп, һәм инә очыдай бер мизгелдә туп-туры күзләремә карады да ишегалдына кереп китте. Ихтимал, монысы да миңа гына шулай күренгәндер. Әмма шул да мин тилене рәхәт бер дулкын белән күмеп китте...

Икебезгә бер кыз озатып кайтабыз. Әмма, бер-беребездән бик нык сагайгандай, Назикә турында ләм-мим! Икебез дә авызга су капкан! Әйтерсең ниндидер гаебебез ачылудан куркабыз. Зариф белән кайчандыр юлда очраштык без. Ачлыктан качып Уфа ягыннан килешли Чиләбе вокзалында унбиш тәүлек ятканнар да, көчкә-иллэлла безнең вагонга эләгеп киттеләр. Әйбәт малай булып чыкты, дуслашып алдык. Алар «Беренче май» шахтасында калды, безне яңарак ачылган рудникка җибәрделәр. Сүзебез шул чакларны искә төшерүдән узмады.

Өйләренә кереп, аннан-моннан капкаладык та, иске-москы туннар кыстырып, каралты башына мендек. Зариф шунда йоклый икән. Кышкыдан калган печән үзенең хуш исен әле һаман җуеп бетермәгән. Шунда чумдык та, әлеге тун затларын ябынып, тып-тын калдык. Зарифка иртүк эшкә барасы икән, миңа да таңнан ук унбиш чакрымдагы өйгә чабарга кирәк... Белмим, Зариф йоклыйдырмы, ә минем маңгай күзләре йомык булса да, күңел күзе шар-ачык. Кая ул йокы дигәнең! Каршыма Назикә килеп баскан. Мин аның белән сөйләшәм. Үземнең теге «сандугач телен» чын күңелдән язуымны кат-кат әйтеп, антлар итәм. Ул да, әз генә елмая төшеп, миңа җавап бирә, тик мин аның сүзләрен генә ишетә алмыйм. Ишетмәсәм дә, тагын сөйләргә керешәм. Үземнең бүгенге кичәдә аның белән бергә булуымны мәңге онытасым юклыгын әйтәм. «Назикә җаным, әйдә, дус булыйк, мәңгелеккә!» — дим. Ул да, риза булган шикелле, миңа кул суза, әлеге җылы дулкын агыла торган кулын суза, имеш!..

Нәкъ шул чакта минем маңгай күзләре ачылып китте дә караңгы печәнлекнең аргы башындагы түгәрәк тишектән, бур мәче күк, тыптын гына беренче якты килеп керүен күрде, ә колак Зарифның гырлап йоклавын ишетте. Аны уятып торырга иртәрәк иде. Сикереп төштем дә печәнлектән, өсне-башны кагынгалый-сугынгалый, китеп дә бардым өйгә.

Юлны әз генә тундырып җибәргән сыман, атларга җиңел. Таң яктысы һаман арта бара, күк читләренә җиләк суы йөгерткәндәй алсу-

зәңгәр нур җәелә. Якын-тирәдәге сирәк нарат башлары, ак күлмәкле зифа каеннар, алтыннан койган тәсле куркәләрен аскан чыршылар, ап-ак йөнтәс тал песиләре шул нурның әйтеп булмый торган матурлыгы белән коена.

Иң гаҗәбе шул: бу таң нуры бер дә әллә каян — күкләрдән түгел, ә Назикә күзләреннән түгелә, кызкай үзе дә хәтта шул тылсымлы офыкта басып тора, имеш! Күзләр дә минем, акыл да бөтенләй саташкан, ахры...

— Исәнме, Назикәм! — дип эндәшәм таң нурына. Ул җавап бирми, һаман елмая да елмая гына. Аның шул сокландаргыч елмаюыннан кояш килеп чыга дөньяга. Назикә үзе дә шул кояшка әйләнеп китә! Кинәт барлык тирә-юнь яңа бер төс ала: әлеге бөтен агач башлары, бөтен җир өсте, күзләрне чагылдырып, җемелдәргә тотына. Кояшның беренче җылысы килеп кагылуга каяндыр якыннан гына кузгалып киткән сыңар күбәләк тә, юл буе калкуыннан баш төртеп азапланган үлән кыягы да, бүртеп килә торган шомырт бөреләре дә, былтыргы үлән төпләренә сыенган бөҗәкләр дә, үзәннәрдә әле саркып бетмәгән актыккы гөрләвекләр дә, сиздермәстән генә кузгалган талгын җил дә — барысы-барысы да җырлый башлый, яз җыры, куаныч җыры түгелә!..

Күзләрне йомып, юл катысын аяклар белән генә тоеп, җан-тән эрегәндәй рәхәт эчендә тирбәлеп, алга атлыйм. Минем күңел дә җырлый. Көе дә, сүзләре дә серле-сихерле кебек, тик берсе дә яңгырамый, җыр булып агылмый. «И-их, җыру чыгара белмим икән шул мин дивана!..»— дип офтанам.

Шушы мизгелдә һич кенә дә көтелмәгән бер могҗиза булып алды: әле генә таң нуры эчендә басып торган Назикә, күз ачып йомганчы, минем янга килде дә: «Үпкәләмә инде, Ихсан абый, яме»,— дип, култыгыма сыенды. Йөрәгем сикереп чыгардай булды! Кысып кочып алырга теләдем, әмма... шул авыкта юкка да чыкты ул.

— Назикә! Назикәй! — дип кычкырдым артыннан.

Җил генә исеп узды ул яктан...

Кабат күренмәсме дип, агач араларын иләп чыктым күз белән. Йөгерә-йөгерә алга атладым, юрамалай гына качкандыр миннән, дип уйладым.

Юк... Юк!..

Бар да бетте...

Ул арада кешеләр күренә башлады юлда. Татлы хыял дөньясы югалды, мин дә уянып киттем. Бу хәтле дә саташып бетәрмен дип кем уйлаган? Нәрсә икән бу, нигә мин шулай диваналандым әле? Әллә ярату микән соң? Әллә, югыйсә, «беренче сөю», «чын сөю», «өзелеп сөю», «үлеп сөю» дигәннәре шушындый була микән? Әллә шулар барысы да берьюлы чолгап алды микән мине? Әллә күңелнең кая барып бәрелергә, кемгә килеп көйләнергә җай тапмыйча сусанып, чүлдә адашкан юлчыдай кибегеп йөрүләре шул мәхәббәт чишмәләрен эзли белми эзләнүдән килеп чыкты микән?

Мондый күп төрле сорауларның барысына да берьюлы җавап табып бетерерлек түгел иде. Әлсерәп өйгә кайтып кердем. Тамакны туйдыргач, эш урыныма чаптым. Клубның бер почмагында тавык кетәгедәй генә булмә ул, шунда мин избач. Кичләрен яшьләр килгәли, кычкырып укулар оештырабыз, аны-моны сөйләшкәлибез. Алар арасында ничегрәк эшләү кирәклеген мин үзем дә рәтләп белмим әле. Нәрсә белим соң, кичәге коногон бит! Буем озын булгач, яшьне әз генә арттырып, уналтыдан ук аска төшкән булган идем, забойга керәм, янәсе... Юк, барып чыкмады, коногон итеп кенә алдылар. Шунда, кемнәндер ишеткән бер җыр сымак нәрсәне кабатлый-кабатлый, ике ел бахбай кудым:

Сиксән сажин җир астыннан
Чыга икән ташкүмер,
Шул күмерне чаба-чаба
Уза безнең яшь гомер...

Юк, узмый әле узуын. Малайлык тыкрыгыннан көчкә чыгып, егетлек урамына аяк басып килгән чак кына. Хәер, җырның ертыгы бармыни? Әзабойга күчкәч бер ел да тулып җитмәде, актив комсомол дигән булып, алдылар да курска җибәрделәр. Өч ай буе гыйлем төяп кайтуга избач ясап та куйдылар абзагызны.

Менә шул избач Ихсан шушындый хәлгә төште хәзер! Юләр йөрәгенә чыдый алмыйча дөньяга чыккан булды да, колак очларыннан арык гыйшык дәрьясына чумып кайтты. Үзенең шул тавык кетәгендә генә утырса ни булган инде, югыйсә!

Юк шул, утыра алмый, корт керде, ахры, йөрәгенә!

Атна буена «репетиция» ясап, үземне кыюлыкка, оста гына итеп уен-көлке сөйләшеп китәргә өйрәттем дә, алдагы якшәмбедә тагын чаптым «Беренче май»га. Юк, аның белән генә эш җайланмады, җәй буе таптадым мин ул рудник юлын. Хәтта андагы яшьләр куя торган спектакльләрдә суфлер булып та, бизәкле афишалар язып та йөрдем. Алай гынамы соң әле, бер карт ролендә дә уйнадым, ничек тә үземне күрсәтәсе, Назикә алдында дәрәҗәне үстерәсе килә. Сизсен ул безнең кем икәнне!

Һәм сизде дә бугай. Җәен спектакльләр «роща»да куела торган иде. Гел каен утыртылган бер бакча ул. Элек управляющий дачасы булган, имеш. Спектакльдә катнашмаган кичләрнең берендә менә шул зифа буйлы ак каеннар арасындагы серле сукмаклар буйлап әйләндек без Назикә белән. Моңарчы күпме үтенеп карасам да, һаман берәр сәбәп табып, баш тарта иде ул. Ә бу кичтә каршы килмәде. Рәхәтлектән җаннарым эреп, түгелергә торган кайнар хисләрдән йөрәгем тибрәнеп, Назикә белән янәшә атлыйм. Гел икәүдән-икәү генә. Ни алдыбызда, ни артыбызда беркем юк! Инде күптән өйрәнеп куйган сүзләр бетте. Ә күңелдәге хисләр ташкыны һаман көчәя генә бара. Ә хисләрең артык ашкына башласа, телең һаман тотлыга бара икән.

Әллә бу аны артык яратканга, артык фирештә итеп караганга, артык матурга санаганга шулай булды микән? Мин, югыйсә, үзем шикелле гади, төс-биткә әллә ни матурлыгы булмаган кызлар белән иркен сөйләшәм. Уен-көлкесе дә табылып кына тора. Ә Назикә белән пешмәгән балан бәлеше килеп чыга. Үзе дә саран сүзле ул. Эч серләренә алып керердәй бер генә җөмлә дә ычкындырмый...

Булмады. Спектакль бетеп, кешеләр таралыша башлаганы күренде. Без дә аерылыштык. Шулай да кул бирештек. Димәк, җепләр бөтенләй өзелмәде әле. Ә кулы һаман элеккечә җылы, якын, ягымлы иде.

...Зариф та бик булышып карады, югыйсә. Килгән саен аларга туктыйм, сораштырам, бер дә алай начар итеп күрсәтми кызны. Аның белән күрешү җае һич тә чыкмаса, тиз генә хат язам. Зарифның бик чәтнәби генә бәләкәй сеңлесе бар, Зөләйха исемле, өченчедә генә укый икән әле, сәхнәдән бик матур итеп шигырьләр дә сөйли белә. Минем хат белән шуны йөгертә Зариф...

— Бар, Зөли, илтеп тапшыр, үз кулына гына бир!— дип өйрәтеп тә җибәрә әле. Менә, ичмаса, чын дус!

Без баскыч төбендә тәмәке тартабыз. Мин җавап көтәм, ә Зариф нәрсә көтә? Ул да миңа җавап килгәнне көтәдер инде... Ә бәләкәй кыз буш кул белән кайта: «Өйдә юк ул»,— ди. Язуны кире бирә. Минем балта шундук суга төшә. Тагын тәмәке кабызам. Зариф та тарта, минем өчен аның да кайгырганы күренеп тора, менә, ичмаса, иптәш!

Икенче бер көнне җибәрүдә:

— Назикә апа кер юа, вакыты юк,— дигән «җавап» белән кайтты бу бәләкәй кыз.

Сәер хәлгә төшеп барам бит әле мин. Зарифтан ояла башладым хәзер. Шул ук баскыч төбендә икәүләшеп сүзсез тартылган тәмәке төпчеген тырнак белән чиртеп җибәргәч, кузгалдым да:

— Пәйстин абыйларга кагылыйм әле мин, хәлләрен белгән юк,— дип, Зарифлардан чыгып киттем.

— Борыныңны бик төшермә, бер җайланыр әле,— дип калды Зариф.

Аяклар мине бер дә авылдашым Пәйстин абыйлар ягына түгел, ә теге беренче кичтә барган караңгы урамнарның аргы башындагы баракка таба илтәсе килә. Эчемдә әллә ничә төрле ут кайнаганга ихтыярсыз атлыйм. Унбиш чакрымнан һаман җәяү юргалап, инде ничә тапкыр күрми киттем, бүген дә шулай җил койрыгы тотып кына калырмынмы? «Кер юа».— диде бит. Бәлки аның хәзер, ишегалларына бау тарттырып, нәкъ ап-ак керләр элеп йөргән чагыдыр... Шунда атлыга күңел. Ә килеп җитсәм... рәшәткә баганасының шактый өскә калкып торган очлы башында бер ала карга утыра. Борынын сузып түбән караган да юынтык чокырын күзәтә. Шаркылдап бер көләсе килде, куркытудан курыктым. «Мин икән бу!»— дип куйдым эчемнән генә. Икебез дә кирәкне эзләп килгәнбез: аңа — калҗа, миңа — кыз...

— Кач, Ихсан, кач моннан тизрәк, йөрмә адәм көлкесе булып!

Эчтәге бер тавыш шулай дип кычкыра, ә күңел аякларны тотып тора, күз йомганчы юкка чыгарга ирек бирми.

— Туктале, кер эләргә килеп чыкмасмы. Сабыр итеп карыйк әз генә...— Эчтәге икенче тавыш шулай ди.

Итәбез инде... Алай дуамал гына бер дә китеп барасым килми. Ичмаса, күзнең бер кырые белән генә күрсәң дә, йөрәккә ял булыр иде. Әмма юк бит, Назикәнең үзе түгел, җиле дә сизелми!

Ә менә ала карга акыллырак булып чыкты миннән. Килеп кенә җиттем, озак юанмады, башын кыйшайтып миңа таба карады да бер, очып та китте. «Урынбасар килде, китү кирәк инде»,— диде бугай, ахры...

Көпә-көндез кемнендер рәшәткәсе буенда күпме йөрү мөмкин соң? Берәр белгән-күргән кеше бу тирәдән узса: «Ихтиыял, агай-эне, шалкан саклыйсың мәллә монда?»— дип сораса, ни кылырсың? Кереп китәргә җир тишеге каян табарсың?.. «Кер юа»,— дигән иде, кайда соң аның элгән кере? Ичмаса, бер тишек оек та күренми!

Юк, каргадан да ахмак булырга ярамый. «Югал, тинтәк, тизрәк бу тирәдән!» — дип, үземне типкәли-типкәли дигәндәй, алып киттем. Пәйстин абыйларына таба атларга мәҗбүр итәм Мәҗнүн Ихсанны.

Өч-дүрт барак та узмаганмындыр, Җәләй очрады. Шундый таныш та бар минем хәзер. Җип-җирән бөдрә чәчле егет ул. Ходай аңа башны әллә ни бирмәсә дә, аякны биргән. Андый аякларны минем әле беркайда да күргәнем юк. Ул биегәндә иң оста рус егетләре дә телсез кала, аның табан асларыннан агылган «чичетка» музыкасы залга тарала, клубта утыручылар аякларын шул көйгә шапылдата башлый. Кызык малай ул, аның өчен бөтен марҗа кызы үлеп тора, ә болай карасаң, гап-гади, җип-җирән бер Җәләй. Менә шул каршыга килеп чыкты да кул бирде, тәмәке чыгарды.

— Нишләп йөрү, брат?— ди.— Бу тирәдә сине бер дә күргән югые әле,— ди,— наверно, берәр күгәрченне каравыллыйсыңдыр?— ди.

Нәкъ мин курыкканны әйтте дә салды. Исне җыя алмыйча ык-мык итеп тордым, озаклап тәмәке кабызган булдым, ә ул һаман лыкылтаудан туктамый:

— Бу тирәдә бүтән карчыгалар күренмәйде моңарчы,— ди.
Ниһаять, җавапка җай табылды:

— Ә-ә-ә,— мин әйтәм,— шулаймени-и-и?— дим.— Ул карчыгаларның берсе синдер инде алай булгач!..

— Миннән башкалар да бар шул,— ди бу.— Мин бу тирәгә оя корган чыпчык кына. Әнә генә безнең барак, утыз тугызынчы.

— Мин дә узгынчы гына шул,— дим.— Әнә, Лебедянга таба минем авылдаш тора, шуларга барып яткан булу...

Җәләй, ышанган сымак булып, рәшәткәгә терәлде, мин дә сөялдем, тартабыз. Эчне тырный торган мондый сүз кузгалгач, аның төбенә төшәсе килә бит инде.

— Шулай да мин әле аңлап бетермәдем, малай,— дим.— Күгәрчене кем дә, карчыгасы кем соң аның?

— Ну, ну, җүләр сатма, парин!— дип көлде Җәләй. Барын да белгән тавыш белән башын чайкап куйды.— Кем тирәсендә күпме бөтерелгәнеңне күрмиләр дисеңмени?

Мин дә башны кире якка чайкадым.

— Һи-и, болай булгач, гел барып чыкмады инде бу,— мин әйтәм.— Атнада-айда бер күренгән Ихсаннан көнләшерлек хәлгә килгәч, синең үз итәгеңә ут төшкән була түгелме соң?.. Кая, борыл әле, тәтене чыкмыймы?..

— Чепуха!— диде Җәләй, җилкәсен кирә төшеп. Һәм ике теш арасыннан тәмәкечеләрчә генә «черт» итеп төкереп куйды.— Минем ыфкус түгел. Миңа ут уйнаткан кызлар кирәк!

Батыр сөйләшә, ышандыра язды бу мине. Чынлап та, акыл аякта бит аның. Һәм аяк белән ут уйнатучы кызларны яратуы бер дә гаҗәп түгел. Соң алай булгач, нигә ул Назикә тирәсендә «карчыгалар» бөтерелүгә пошына? Миннән көлүе генәме, әллә бүтәне дә бармы?

— Ярый,— мин әйтәм,— син күрше чыпчыгы булдың инде, мин узгынчы карга булдым, ә чын «карчыга» ни төслерәк соң?

— Ни төслерәкме? — диде Җәләй.— Бер дә артык җире юк!

Аннары бик озак сүзсез торды, бер дә исе китмәгәндәй генә унҗиде «клиндер» чыгарды авызыннан. Ул каядыр күзен текәп уйланганда, мин юри санап тордым — нәкъ унҗиде! Бәлки тагын да чыгарган булыр иде, эчендә тәмәкесе янып беткән «кәҗә сыйрагы»на пелт итеп ут кабынды. Ул аны атып бәрде дә таптап куйды.

— Күпме әйттем шул Назькага,— диде аннан соң Җәләй.— давай үрәтәм, дидем. Үзем кебек отлично биюче ясыйм, концертларда икәү выступать итәрбез!— дип тә карадым.

Ул тагын берне чорнап кабызды, тагын бер төкереп куйды «черт» итеп.

— Типичный татарка,— диде ул аннары.— Публика алдына чыгудан курыкты. Үзе болай ничава гына булса да, забитый кыз. Шул Зайкыга сыенды да калды.

Җәләйнең көтмәгәндә болай күп сөйләп ташлавына хәтта аптырап калдым. Мин аны шактый «бикле малай» санап йөри идем, ә ул шактый ачык авызлы булып чыкты. Шуннан тиз генә файдаландым да.

— Зайкы дигәнең кем була соң тагы?— дип сорадым.

— Шуны да белмисеңме?— диде егет мыскыллы караш белән.— Бигрәк тинтәк кулик икән син! Үз дусың ич! Зариф!

— Зарифмы?— дип кычкырдым мин, күзләрне акайтып, борынны очлайтып, кашларны бергә җыеп, колакларны торгызып. Бәлки алай ук булмагандыр, әмма ул минутта мин үземә шундый булып күрендем.

Җәләйнең минем белән шулай байларча кыланып, балконнан торып кына сөйләшә башлавы да, Назикәне шулай юкка чыгарырга маташуы да, Зарифны Зайка дип кенә атаган булуы да җен ачуларымны кубарды.

— Син үзең җирән шайтан ич! Назикә сиңа карыймы соң!— дип, якасына килеп ябышканымны сизми дә калдым.— Эт койрыгы телеңне тыймасаң, ипи шүрлегеңне җимерәм хәзер!

Дер селкетәм тегене ике кул белән. Юка гәүдәле нәрсә ул, калтырана ук башлады, күзләре калайланып китте куркудан.

— Што син, Ихсан дус,— диде бу бөтенләй икенче бер юаш тавыш белән,— мин бит сиңа бер оскорбление дә ясамадым...

Минем хәл дә әйбәттән түгел иде: көпә-көндез, айнык баштан, урам уртасында дигәндәй, якалаша башла, имеш! Кем әйтер мине тиле түгел дип?

— Назикә белән Зариф турында тагын бер лыгырдавыңны ишетсәм, җаның җәһәннәм төбендә булачак! — дидем тегеңә, ярым пышылдап кына. Аннары якасын ычкындырдым.— Бар, сыпырт! Тай моннан!..

Нишләгәндер, борылдым да аннан элек үзем китеп бардым. Пәйстин абыйларга тәки барып җитә алмадым. Әллә ниткән ямьсез тойгылар басты да күңелне, аяклар өйгә таба атлый башлады. Унбиш чакрым буена уй да уй. Ничек булып чыкты соң әле бу? Зарифны Назикә белән йөри диме? Кыз шуңа сыенды дип әйтмәкче буламы? Һични аңламыйм, берсе дә сыймый башка! Әгәр дә мәгәр Зариф ул кыз белән үзе йөри икән, соң нигә ул аның белән мине таныштыра?.. Юк, ышанмыйм, ялганлый ул җирән шайтан, ялганлый! Мине Зариф белән дошман итәргә тели!

Атлыйм-атлыйм да тагын күтәрелә уйлар өермәсе. Әгәр сынамак өчен генә таныштырган булса? Назикәне сыный, янәсе. Мине дә капшап карый.

«Я-ле, кызый, карап карыйк, син ниндирәк кош икән? Үз гөлендә генә сайрый торган сандугачмы, әллә урман күкесеме?.. Ә син, тәти егет, ниндирәк бәндә? Дус итәрдәй иптәшме, әллә кеше ярына да пычрак кулын суза торган этләчме?..»

Һу-у, бик хәтәргә китте бу. Болай ук булмас, үзем арттырам бугай мин. Әгәр Зариф шундый әшәке егет булса, миңа шундый яхшылыклар эшләр идемени? Юк, ялгышам мин, Зариф әйбәт дус! Шулай ышандырам үземне.

Шундый-шундый уйларга муеннан баткан килеш кайтып кердем. Уку йортына киттем, андагы чүп-чар, пычракны күргәч, энекәшне пыртуздырып ташладым, чөнки ачкычны аңа калдырып киткәли идем. Мин югында ул избач булып тора, янәсе. «Торган», бөтен идән тәмәке төпчеге, эрбет кабыгы белән тулган, гәзит почмакларын тәмәкегә ертып, плакатларны умырып, шахмат катыркасын икегә аерып куйганнар. Үзе юкның күзе юк шулдыр инде!

Барын рәткә китереп, эшкә тотындым. «Күп кудың җилне, җитәр, ат койрыгы түгел, барыбер тота алмассың!»— дип әрлим үземне. Чырай чытыкланды, элеккедәй җилтерәп йөрүләр бетте. Әллә нәрсә генә булды шунда: әллә күңелнең, әллә бөтен дөньяның ниндидер бик нечкә бер кылы өзелде кебек...

Шулай атна-ун көн узып китте, унбиш көн дә узды, тагын тегендә барасы килә башлады. Ләкин... бер аяк атлый, икенчесе туктый. Торабара анысын да мәҗбүр иттем атларга. Бик күрәсем килә Назикәне. Бардым, Зарифка кереп торасы килмәде. Саруын кайнатып йөрмәскә кирәк, дим. Менә бит ничек: шул җирән Җәләйнең бер сүзенә дә

ышанмадым һәм ышанмыйм да, югыйсә, ә коткысы күңелгә барыбер утырып калды. Яхшы дусыңа яман кер сылады...

Клуб, китапханәләренә сугылып Назикәне эзләдем. Урамнарына барып, сагая-сагая гына барак тирәләрен әйләндем. Бәхеткә каршы, бу юлы багана башында теге карга юк иде, җирән Җәләй дә очрамады, бары да бик әйбәт, тик шунысы начар: Назикәне күрә алмадым.

Башны түшкә төшереп кире атлыйм. Шулай күрми китәрем микәнни?.. Коры йөреп буш кайтуга ачу килә. Чаттан борылып күпергә төшкәндә теге чәтнәби кыз Зөләйха килеп чыкты каршыма. Олы бер түгәрәк калач күтәргән, тагын ниләрдер. Кибеттән кайтуы, күрәсең. Кинәт кош тоткандай сөенеп куйдым. «Ходайның юри җибәргән изге фирештәседер бу!»— дип уйлыйм.

— Нихәл, сеңлем, абыең өйдәме?— дим.

— Китте бит ул,— ди.— Свердловскига. Әллә нәрсә дигән генә курска. Назикә апа белән икесен җибәрделәр.

Башка таш белән суккандай итте дә куйды. Күз алларым караңгыланып китте. Ни дип әйтергә белми тик торам, көчкә аңыма килдем.

— Ә-ә-ә, шулаймыни?— дип мыгырдандым да ычкындым тизрәк ул тирәдән. Менә сиңа изге фирештә! Чөй өстенә тукмак! Кайчан гына булды икән соң әле бу? Хәер, минем аларны күрмәгәнгә ике-өч атна бардыр шул инде.

Сәер килеп чыкты әле бу хәл, бик сәер. Җәләй мескенне юккарак рәнҗетмәдем микән? Аның лыкылтаганы дөрескә чыга түгелме соң?.. Атлыйм, атлаган саен шаккатып, зиһеннәр чуала бара. Димәк, алар әллә кайчаннан бирле бер-берен яратышып йөриләр... Йөрсеннәр соң, бик яхшы! Тик ни өчен мине буташтырдылар икән үз араларына? «Кызлар белән таныштыр әле»,— дип әйткәнем дә булмады ич Зарифка. Назикә дә: «Минем танышым бар шул инде»,— дип кенә җавап бирә ала иде теге язуга каршы... Уф! Әллә нәрсә бу. Тизрәк кайтып китәсе килә өйгә. Арттан кемдер куа килер дә, әллә нинди начар эшләрдә гаепли башлар кук тоела үземне...

Кырык чакрым юл йөргәндәй, җеп өзәр хәлләрем калмыйча кайтып кердем мин ул көнне. Ә кичен «избач булмәсе»нә бикләндем. Ут яндырмадым. Шакып караучылар булды, кыймылтамадым — избач Ихсан килмәгән бүген!.. Аннары бүлмәнең бердәнбер тәрәзәсен киереп ачтым да тарткан өстенә тарта башладым. Үзем күктәге йолдызларга карыйм. Җәйге булсалар да суп-суык булып күренәләр. Нигә алай икән? Сәбәбен дә эзлисе килми. Башны бер генә уй бораулый: укырга киткәннәр... Бергәләп укырга киткәннәр... Нинди бәхетле кешеләр бар дөньяда! Ә син?..

Туктале, чынлап та... Ә син нигә мүкләнеп ятасың соң монда? Алты классың бар... өч айлык курсларың да булгач, шул житкән дип уйлыйсыңмы? Гыйлемлекне чүмечләп чөмергән Котбеттинмени син? Юк, йөрмә монда җил куып! Кит, аларга үч итеп, укырга кит. Үзләрен генә әллә кемгә санамасыннар!..

Иртәгесен Наробразда идем инде мин. Анда Йосыф абый Сәмигуллин утыра, шахтердан күтәрелгән, бик әйбәт кеше, яшьләрне бер дә кырый какмый. «Безгә эләкмәде инде, давай, энекәшләр, сез тырышыгыз»,— ди ул.

Бик тә ышандырырлык итеп язган гаризамны суздым. Хәрефләп дигәндәй укып чыкты бу.

— Соң бит, брат, әле сине күптән түгел генә укытып кайтардык түгелме?— диде аннары.

— Юк,— мин әйтәм,— ул өч айлык курс кына иде бит, нәрсә бирсен? Әллә кайчан коелып бетте инде ул. Минем укытучымы, врачмы,

инженермы — шундый зурракка укыйсым килә яшь чакта. Һөнәр алырга телим!— дим.

— Һай-һай!— дип көлде бу.— Ә соң эшләрең ничек бара, кызлар артыннан чабып кына көн уздырмыйсыңмы?

Кинәт тотлыгып калдым беравыкка. Әллә беләме, нигә алай дип сорый?.. Күзләренә күз ташладым: юк, алай койрыкка баса торган хәйләкәр очкын күренми. Тиз генә акланырга тотындым.

— Юк ла-а, Йосыф абый,— дим.— Андыйлар белән маташа белмим... Эшләрем дә ал да гөл: фәлән хәтле гәзит-журнал тараттым, фәлән хәтле яшьләрне әзерләп комсомолга алдык. Грамыты булмаганнарына үзем язу танытып, күзләрен ачтым,— мин әйтәм. Тагын әллә нәрсәләр тезеп киттем әле.

— Хәзергә бер урын да күренми, Ихсан дус,— диде ул якын иткән тавыш белән.— Сабыр кыл, эшлә, көт... Ничек тә җибәрергә тырышырбыз. Көзгә таба разверсткалар булмый калмас әле.

Кайттым, эшлим, бер үзем язып стена гәзите чыгарам, тагын өч-дүрт малайны комсомолга кертергә исәп. Хәзер теге юләрлекләр җилгә очты инде. Дөрес, Назикә күңелдән бик чыгып бетми бетүен, әмма нишлисең? «Кеше яры нигә кирәк, үзеңнеке булмагач»,— дип, юкка җырламаганнардыр инде.

...Тәки сүзендә торды бит Йосыф абый, август урталарында хәбәр итте: «Ун айлык курсларга урын бар, китәсеңме?» — дигән. Китмиләрме соң? Дүрт аяклап, дүрт куллап!

Шулай итеп, сентябрь башларында Омски каласына килеп төште бу абзагыз. Монысы да бик шәп булды. Свердловка җибәрсәләр, «безнең арттан куа килгән» дип уйлар иде тегеләр. Юк, андый хәлдә түгел хәзер Ихсан. «Сүнгән учак сүнсен инде, яңалары кабынып», диләрме әле? Дөрес әйткәннәр. Авызы тулы кара кан булса да, кеше алдында төкермәсен ир-егет дигән зат!

Иртыш ярынарак салынган зур бер таш йортка урнаштык. Беренче катта торак бүлмәләре, икенче катта зур клуб, өченче катта спорт залы һәм уку кабинетлары. Ишегалдындагы бәләкәйрәк йортта ашханә. Икенче бер җыйнак кына, матур гына бинада китапханә, аннары хуҗалык корылмалары китә. Элек моны бик бай бер купис йорты булган диләр. Даладан агылган мал көтүләрен казакътан алдапйолдап, юк хакка җыю белән баеган, имеш. Анысы билгеле инде аның.

Ярар, укулар башланып китте. Егетләр дә күп, кызлар да бар, олырак яшьтәгеләр дә шактый. Кайлардан гына килмәгәннәр: бөтен Себер, Урал җыелган диярсең. Кызлар үзебездә әз сыманрак күренсә дә, күрше урамда гына татар-башкорт педтехникумы бар икән. Һәм аны «кәләштрест» дип тә йөртәләр, имеш. Монысы да ярап тора...

Кешедән алга сикереп чыккан юк, койрыкта да сөйрәлгән юк. Укыйм шунда җайлап кына. Бөек француз революциясен өйрәнәбез. Ай-яй, хәлләр булган икән дөньяда! Үзем дә сизмәстән китапларга чума башладым. Клубтагы кичәләрдә дә, җыелышларда да бик кызыклы бәхәсләр була, үзара сөйләшкәндә дә чәкәләшеп китәбез. Анысы күбесенчә йә мәхәббәт, йә мишчәнлек темасына була. Иң хәтәре мишчәнлек икән. Эшләпә кию, галстук тагу, ислемай сөртү, чәч бөдрәләтү, тансовать итү һәм тагын бик күп шуның ишеләр чеп-чи мишчәнлек гадәте икән ул. Пролетариат яшьләре мондый әшәке чир белән агуланмаска тиеш икән. Һәм без шуңа каршы көрәш алып барабыз. Үзебезнең тирәдәге эшче клублары яки уку йортларында тансы кичәләре барлыгын ишетсәк, төркем-төркем булешеп шунда барабыз да, шундук ул тансы-мансыларны күмәк уеннарга әйләндереп җибәрәбез.

Галстук бәйләгән комсомолец булса, ул бозау муенчагын шул минутта үк салырга мәҗбүр итәбез. Бөгәрләп чалбар кесәсенә тыга ул аны. Шул чакта безгә җирәнеп караган була әле, үзен мишчән чиреннән коткарганны аңламый.

Ә мәхәббәт дигәннәре бөтенләй үк пүчтәк нәрсә икән. Күпме җырларда кабатланган «чын сөю» ләр, сагынып-саргаеп гыйшык тотулар да гел юк сүз генә икән ул, борынгы беркатлы кешеләр уйлап чыгарган төче ялган гына. Разный төрле «Ләйлә-Мәҗнүн», «Йосыф-Зөләйха», «Таһир-Зөһрә»ләр дә шулардан калган әкият кенә икән. Сөю дигән нәрсә: кешеләр җәмгыятьтә, эштә бер-бере белән аралашканда иялэшү, якынаю мөнәсәбәтләреннән килеп туган бер нәтиҗә генә икән. Ирекле мөнәсәбәт — ирекле сөю! Шул чорда кешеләрнең бер-берен яратышып, бергә булулары, ә инде яшәү шартлары үзгәрү белән төрле тарафка китеп барулары бик гади һәм табигый бер хәл икән! Ә Казанда инде «Өйләнмәүче һәм кияүгә бармаучылар» оешмасы да яшәп килә икән. Бүтән шәһәрләрдә шундыйрак оешмалар бар, имеш... Моны безнең клубка бер лектор килеп сөйләде һәм барын да бик ышандырырлык сүзләр белән аңлатып бирде.

И, мин томана да булганмын соң, таш кабыкта яткан әкәм-төкәм! Шушыларның берсен дә белми яшәгәнмен. Назикә дип, аңа әллә нинди фирештә сыйфатлары биреп, таң нурына, чишмә җырына һыбы, һыбыларга тыңлап, авыз суы кортып, тинтәкләнеп йөрдем, надан!.. Ярый әле, озакка сузылмады, аларның Свердловка, минем Омскига китүе бик тә әйбәт булды, вакытлы килеп чыкты. Дөрес, әле һаман уйдан чыгып бетми бетүен ул кыз. Хәтта бик матур елмаеп төшкә дә керәли. Хәер, яңалыкта гына бу шулайдыр әле. Онытылачак ул! Җилләр исәр, комнар күмәр аны барыбер! Аннары бит төш үзе дә искелек калдыгы гына икән әле. Шулай булгач, күммичишлисең? Өстәвенә, якын тирәбездә генә күпме укучы кызлар бар, көн саен диярлек кичәләргә йөрибез, арада бик матурлары да әз түгел. Дөньяда ирекле сөю бар чагында, әбиләр әкиятенә ышанып, шул бәхеттән мәхрүм калыргамы? «Күңел — дәрья, күз — шәйтан» дигәннәрме әле? Ә мин аны «күз — күзәтче» дип төзәттем. Һәм минем күзләр кайда нинди асыл кош барлыгын күзәтеп кенә йөри хәзер. Аллага шөкер, элекке йомыклык та бетте, тел дә ничек сайрарга киләклегән өйрәнеп житте. «Кызлар матур, күңел киң, кайсын сөйсәң дә мөмкин!» Моны мин үзем чыгардым ул чакта. Валлаһи! «Әллә шагыйрь микән мин?» — дип тә йөрдем әле эчемнән генә...

Укырга килгәч, беренче танышкан кызым Сәрдилә исемле иде. Педтехникумдагы кичәдә булды бу. Куллардан тотышып түгәрәктә әйләндек. «Җәзага» чыгардылар. «Урамда» дигән шигырь укыдым. Сәрдилә: «Әкрен, жил, монда кабер...» — дип җырлады. Тагын бергә тотышып әйләндек тә, уеннан чыгып, тәрәзә кырыена килеп сөялдек. Ут артык якты түгел, безнең файдага. Киң ачылган олы кара күзләренең агыш күбрәк күрсәтеп, миңа текәлде бу. Ике кулдан шытырдатып кысып алды, күкрәкләре еш-еш тибрәнә башлавы да бүгенгедәй күз алдымда. Мин дә бик житди булырга тырышам. Шулай карашып тора торгач:

— Яратам мин сине! — дип пышылдады бу. Кайнар сулышы йөземә килеп бәрелде. Мин дә, күзне йома төшеп, кулларын кыстым аның. Башка бер сүз дә әйтмәде, кулдан житәкләде дә каядыр алып китте, борма коридорның аргы башындагы торак бүлмәләренә алып керде. Бүлмәдә дүрт карават бар, ләкин бер кеше дә юк, уендадыр инде иптәш кызлары.

— Яратам мин сине! — дип кабатлады ул, ак беләкләре белән муенга сарылды, уттай кайнар иреннәре минем авызны яндырып алды...

...Яз башларында миңа Иркия исемле икенче бер кыз ошый башлады. Миннән калкурак гәүдәле, сары чәчле, сыек зәңгәр күзле ул. Бергә укыйбыз. Барабадан килгән, ирдән кайткан — яратышмаганнар. Берәр атна чамасы узгач, Иртыш ярына төштек. Март урталарының аяз кичә. Аяз булса да, суык түгел. Җил йоклаган, күктәге йолдызлар чекерәешеп җиргә карый. Сыек зәңгәр төс белән җемелдәшеп балкулары Иркия күзләрен хәтерләтә. Икебез дә киез итек, кыска каеры тун кигән. Моны безгә уку йортыннан бирәләр, чөнки ул чакта безнең пальто дигән нәрсә алырга кесә яклары фәләнчәрәк иде әле.

Төн матурлыгына сокланып йөри торгач, 'склад сыман озын, зур бер ташпулатның артына килеп чыктык. Тар гына сукмак, дөнья тып-тын, бер әдәми зат күренми. Каты кар өстеннән сак кына атлап стена буена килдек. Кайнар сүзләр, үбешүләрдән соң туннарны кар өстенә җәеп салдык та, күктәге йолдызларга карашып яттык. Туктаусыз елмаешып балкый иде ул йолдызлар...

Туктагыз әле, хихылдашмагыз шул тикле. Яшьрәк мәлдә үзегез дә кимен куймагансыздыр әле йолдыз санауның.

Көлешү барган арада Ихсан тәмәке кабызып алды да тагын дәвам итте.

Җәй башында укуларны тәмамлап, төрлебез-төрле якка таралдык. Мине бер бәләкәй генә өяз каласына җибәрделәр. Яңа ачылып яткан «Крестьян йорты»на вакытлыча мөдир итеп куйдылар. Электә двор тоткан бер бай йорты икән бу. Киң ишегалды, каралты-кура, амбар-лапас дигәнең бар да җитәрлек. Авылдан килгән агайларны ак җәймәләр өстендә генә йоклату, кайнар чәй эчертү өчен тырышып йөри торган ак халатлы кызлар да әз түгел. Әлбәттә, бер матур күбәләге белән танышып та алдым инде...

Бу эш минем өчен яңа булса да, авыл җирендә үскәнлектәнме, әллә ни кыенлыгы күренми. Дворыңны чиста тот, урлашу-талашу булмасын, Ә хезмәт хакы әйбәт кенә, җаваплы эш бит. Өс-башны рәтләп җибәрдем — полный шәһәрчә. Дәрәҗәгә дә күләгә төшәрлек түгел, шактый җитдиләнеп киттем. Уйлап карасаң, зур бер гостиница 'директорыннан кай җирем ким минем? Андый юк та әле безнең бу Актояк каласында. Урал арты даласында булгангамы, халкының да күп өлеше казакъ белән татар бу каланың, исеме дә безнеңчә. Әллә казакъча микән?..

Шул, танышып алдым алуын да теге үземдә эшләүче Фурсалиния белән, тик нигәдер күңел ятышып бетми үзенә. Болай, югыйсә, халаты да ак, исеме дә шәп, бер дә чәйнәлмәгән матур исем, шулай да — оеткы җитми. Ник дисәгез, бәлкем шуннан булгандыр: өйләнеп карыйсым килә башлады минем. Үзем шикелле директорлар белән җыелыш-киңәшмәләрдә утырган чакта бала-чага булып кына күренәм. Мондый эштә булгач, солидныйлык кирәк дип уйлыйм. Ә теге Фурсалиния төскә-биткә болай әйбәт кенә күренсә дә, үзеңдә эшли торган бер санитар кыз гына ич. Ничек ул хатының була алсын?.. Дөрес, минем өчен әллә ни түгел, үзем дә күмер корымыннан чыккан. Ләкин усал телләр әзмени! Техничкасына өйләнгән дип, күзеңне дә ачырмаслар.

«Бирим дигән колына...» диләр бит әле. Байтак кына эзләнә торгач, бирде миңа да. Чыгарып куйды юлыма! Күршедә генә булган ул. Авылда укытып, каникулга кайткан. Карт әнисе белән яшиләр икән. Миннән өч-дүрт яшькә генә олырак олысын. Хәер, анысы кимчелек түгел, акыллырак булыр. Танышуыбызга ун көн узды. Иртәгә загска барабыз дигән төнне гел бергә булдык. Иртә белән яныма утырды да сөйләп бирде:

— Үткән ел мине ерак бер авылга җибәрделәр. «Син шәһәр кызы, русча яхшы беләсең. Әрендек мәктәбендәге татар балаларына рус

теле укытучы юк, бар шунда»,— диделәр. Мин өяз мәгариф бүлегендә эш йөртүче генә идем. Хезмәт хакы да яхшырак буласын белгәч, киттем. Ул авыл җитмеш чакрымда икәнен белсәм дә, шәһәрдә юлаучы табылмагач, җәяү чыктым. Кичкә таба артымнан бер атлы кеше килеп җитте. Кай якка баруын сораштым. Әрендектән ары булган Тармакүл балыкчыларына бара икән. Әйтүенчә, потребсоюз кешесе. Утыртып алып китте бу мине. Ерак җир, төнгә калдык. Атлаган саен аты туктый, пошкыра, башын аска суза башлады. «Ат талчыкты, ял иттерми булмас, ахры»,— диде бу. Юлдан эчкәрәк кертеп, бер елга буена атын тугарды да үләнгә арканлады. Учак ягып, тамак ялгадык. Аннары арбадагы коры печәнне яшел үләнгә түшәде дә өстенә күн палас сымак бер нәрсә китереп салды. «Ятыгыз, ял итегез»,— диде. Мин ул кешенең яхшылыгына рәхмәтләр укып, урынга яттым. «Зинһар соңга калмыйк, таң беленгәч тә кузгалыйк, яме»,— дип үтендем.

«Әлбәттә»,— дип кенә куйды ул. Юл кожанын салып, минем өскә япты. Аннары атын барлап килде, аннары ут каршына утырып тәмәке тартты, озак уйланып утырды. Аннары, инде сүрелә барган утлы күмерләрне як-якка таратып, күн итеге белән таптый-таптый учакны сүндерде. Инде йокымсырап бара идем, ул олы гәүдәсе белән кинәт килеп минем өскә капланды да кочакларга, үбәргә маташа башлады. «Курыкма, җаным, мин бит яратып кына...» — дип, пышылдый кайнарланып. Үзе һаман кысрыклый бара. Бар көчемә чырыйлап кычкыра-кычкыра сикереп тордым да далага йөгердем, төн эчenә. Август ахырларының караңгы төне, ай түгел, сыңар йолдыз да юк, ичмаса. Болыт баскан күкне. Бер-ике ыргылуда куып та җитте ул «бүре» мине. Тагын бөгәрләмәкче. Тагын кычкырып чаптым. Инде хәлем бетте, тез буыннарым сыгыла, күзләрдән ут чәчри. Кычкырам: «Коткарыгыз! Коткарыгыз!!»

Тирә-як үле. Ник бер генә бер тарафта бер генә бер җан иясе барлыгы беленсенче! Әйтерсең ачы зар тавышын йотып ала торган борынгы кара чүл бу...

Билгеле, шушындый хәлдә мине куып җитеп, төртеп егу өчен аңа әллә ни күп көч кирәк булмагандыр... Шулай ерткычларча мыскыл ителгән кыз юлдан әллә кайда, читтә, дала уртасында күзләрен ачканда, бәләкәй чемоданын гына күрде янында. «Котырган бүре» үзе качкан иде инде...

Менә шул, дустым, сиңа хатын булачак кеше — корт тимәгән ефәк түгел... Калганын үзең кара, үзең хәл ит...

Ул шушы сүзләр белән тукталып калды. Ә минем күзләр тулы кайнар яшь, мин аны кызганып җылый идем.

— И-и бичаракаем! — дип, кочаклап алдым, башыннан сыйпадым, аннары иртәнге чәйдән соң загска киттек. Ул чакта алдан гаризалар биреп, чиратлар көтеп йөрисе юк иде, бер сәгать эчендә язылдык та кайттык. Ә теге «потребсоюз кешесе» дигән этне эзләп табып, җанын алырга ниятләп куйдым эчтән генә.

Минем кәҗүнни бүлмәдә кәҗүнни урын-җирдән башка һични юк иде. Кәримә (исеме шулай иде аның) үз әйберләрен алып килде. Шыксыз бүлмәгә ямь кергәндәй булды. Торабыз әкренләп кенә, көннәр җай гына агыла бирә, әллә ни әрләш-тиргәш тә юк, хәтта ярatышабыз да бугай әле! Ә бер кичне кочаклашып яткач, әйтте хатын:

— Безнең нәнибез булачак...

Сикереп торып утырдым:

— Малай! Только малай булсын! — дип заказ бирдем.

— Ярар, тырышып карарбыз...— диган булды ул.

Һе! Абыегыз малайлы булачак, малайлы! Эчтән шулай горурланып ятам. Ә бактың исә, ул малайлы абыйга егерме яшь тә тулып җитмәгән икән әле! Үзе дә малай... Булсаны соң? Картаерга ашыкмыйк әле, өйләндем дип, үзеңне караваг аягына арканлап кую — юләр эше ул!

Теге кыз белән дә аралар суынып җитмәгән әле безнең. Хәер, ара дигәч тә, әллә ни булганы юк. Дөрес, авызын турсайткалаган була булуын, әмма барыбер ярата ул мине, әллә кая бара алмас...

Әйбәт булып чыкты бит әле бу «Крестьян йорты»ның мөдире булып тору. Хезмәт хакы да яхшы, эшләр дә начар бармый, андый-мондый шелтә-фәлән дә юк, шелтә булмагач, түш тә киеренке, баш та югары. Хатын да ярыйсы, төннәрдә малайның «этта, этта» дип тибешкәнен дә тоеп ятабыз, шуның өстенә сөяркәбикә дә бар! Мин аны хәзер санитарлыктан алып кастеляниша иттем. Йортның бөтен чүпрәкчапрагын бикләп тота торган бәләкәй бер склад бүлмәсе бар аста. Юлы да билгесез түгел...

Шулай хозур гына яши торгач, хатынның бала табар көннәре дә килеп җитте, тудыру йортына илтеп куйдым. Ә икенче кичне кыюлык өчен бер-ике стакан гына төшереп алдым да шыпырт кына астагы бүлмәгә килеп кердем. Шундук теге Фурсалинияне сиздерми генә артыннан кочаклап, ялт үземә таба бордым да, татлы иреннәренә капландым.

— Туктале, тукта, нишлисең син, абый, котырдың мәллә? — ди бу. Йодрык хәтле булган күзләре ут яна.

— Юк,— мин әйтәм,— булмый болай! Әйдә, кавышыйк инде!..

Һаман ыграк кысрыклыйм моны.

Көтмәгәндә йолкынып китте дә бу, ачыргаланган тавыш белән әйтте:

— Кабахәт икәнсең, Ихсан абый, пычрак җан! — диде. Лач итеп битемә төкерде. Һәм, күз ачып йомганчы, бүлмәдән юк та булды. Мин чуалган керләр арасында буталып, битләрне сөрткәләп калдым. Шул чакта теге потребсоюз кешесе хәтергә килде минем...

Шулай да Фурсалиния шау кубарып йөрмәде, хатынга да җиткермәде, рәхмәт төшкере. Ә капчык барыбер бүселде. Һәм бөтенләй мин көтмәгән яктан тортеп чыга башлады безләр. Әллә каян гына горкомхоз комиссиясе килеп чыкты да төпченергә керешге. Имеш, мин эш рәте белмим, хуҗалык таркалу хәленә килгән. Ишегалдындагы коеның суы сасы, ат сарайлары ишексез. Килгән крестьян, атын каравыллап, арбасында куна. Баскыч-коридорлар, бүлмәләр пычрак, тәртипсез, ятакларда кандала бар... Тавык та чүпләп бетермәслек!

Барлыгын үзем дә беләм, әлбәттә. Һәрберен үз бармагым белән чеметеп утка салыр идем, чукынмышларның! Булмый гына бит, кем чүпләп бетерә алсын аларны? Даруы да юк ич аның. Шул кәрәчин белән исерткәч, артын күккә күтәреп, әз-мәз истән таеп тора да, айнып төшүенә тагын сыза ярыкка. Вәт, бетер син аны!

Шулай итеп, күптән укылган әкияттәге балыкчы бабайның карчыгы хәлендә калдым. Кичә — «патша», бүген — кырчын Корамша...

Яңа мөдиргә бүлмә кирәк булгач, фатир эзләп йөрергә вакыт та булмады, ашык-пошык җыенып, хатынның әнисенә күчтек. Бәләкәй булса да үз өйләре. Мин хәзер бик әйбәт ир булып киләм, җылаган чакларында кызны күтәреп төн буе идәндә таптанып чыгам. Мин аңа, хатын бик үк теләмәсә дә, Авангардия дип, үзем ясаган исемне куштырдым, малайга дип әзерләгән исем иде. Чынлап та, төнлә җылау буенча авангард булырга тырыша бугай ул кызчык. Көндез миңа эш

юк. Хатын да декретта чагы булгач, гел өйдә, әби дә эш яшеннән узган. Хәер, эшлим дисәң, эше дә юк бит әле анын. Кырыкмаса-кырык җиргә сугылганмындыр, һич каян хезмәт таба торган түгел бу өяз каласында.

Шулай, бушны бушка бушатып йөри торгач, ике ай узып та китте, уңайсыз була башлады. Хатын эшләп ала торган утыз ике тәнкәгә өч тамак яшибез. Тәкы-токы белән тартып-сузып, күпме көн күреп була? Әби кеше дә, мыгырдана-мыгырдана, «төртке буткасы» пешергәләргә кереште. Кухня яктан чыжылтый ул: «Үгездәй ир башы белән хатын җилкәсен кимереп ятсын әле!...» — дигән «май» салып, борын башына өчәр кашык дигәндәй бәрәңге кыздыра.

Монда килеп эшли башлагач ясаткан костюм әйбәт иде әле. Талчукка чыгып шуны унбиш тәнкәгә биеттем дә, биш тәнкәсен хатынга биреп, юлга җыендым. Егет чакның фанер тартмасын чолан почмагыннан чыгарып, бер кат күлмәк-ыштан, ярты ипи салдым.

— Мин сезгә язып торырмын, — дидем хатынга. — Эшкә урнашу белән акча да җибәрергә тырышырмын. Хуш, хәзергә...

Ул мине озатып калды. Урал якларына килеп, төрле эштә йөрдем. Мөмкин булганда әзме-күпме балага да җибәргәли тордым. Күп уйланырга туры килде. Барын да яңабаштан корып җибәрәсе килә. Әмма ничек итеп? Белмим. Бу хакта безгә эти-әни дә, укытучы да, бик оста сөйләргә яраткан лекторлар да һични өйрәтмәгән. Ничек атларга соң бу тормышның шундый бормалы, чокыр-чакырлы юлларыннан? Анлавымча, туры булырга, ярашып, икейөзле булып яшәмәскә кирәк. Болары авыр түгел, чөнки тәлинкә тота белмим, туры бәрдерүдән кайчакта дусларымны да югалтып куям. Ә тормышның тагын бик күп төрле яклары бар икән бит әле. Нишләтергә хәзер миңа бала белән хатынны? Бәлки үз янына алдыру кирәктер? Ә ничек алдырасың? Тимер юлда баллас таратып, шпал аслары төйгечләп йөрим. Иң өч тиенлек эш! Ун-унбиш чакрымнан әйләнеп кайтабыз да такта баракның тоташ сәкеләренә тәгәрәп йоклыйбыз. Җыен һөнәрсезләр җыелган монда. «Түрә»лектән сөрелгәч кенә үзеңнең кем икәнең күренә икән! Ярый әле, вакытында селтәделәр. Юкса, гел шундый юк-бар «урын»га алданып, гомергә тәгәри бирер идең тигез җирдән. Теләсәң-теләмәсәң дә, ялманып яшәргә өйрәнеп җитәр идең. Ир егетнең кулында һөнәр булырга тиешлеген дә белә идем, ә һөнәрле булыр өчен уку кирәклеген Мәнди анасына да билгеле нәрсә... Эх, теге вакытта укырга киткәндә ныклабрак уйлаган булсам соң! «Инженермы, доктормы»... дип шапләнгән идем бит. Юк, максатсыз малай икән мин. Ә кешенең үзе өчен олы максаты булмаса, дөньяда яшәү — бушка чабата туздыру гына түгел микән?..

Ул чакта тизрәк башны алып олагу да шул Назикә белән Зарифка уч итәргә маташудан булды инде. Янәсе, мин дә китәм — кая булса да барыбер! Ә соңыннан ишеттем: рабфакка хәзерлек курсларына җибәргәннәр икән аларны. Хәзер инде Свердлов рабфагының икенчеме-өченчеме курсында укыйлар, имеш. Озакламый, шундагы университетка керә инде алар. Ә мин монда шпал төбе төюче «инженер!»

Эх, Назикә, Нәзекәй! Җилкендерден дә, җилпеп тә ташладың син мине. Юк, сине гаепләмим, үзем пәпелтек булдым, үзем! Хәзер инде син — кайчандыр ялгыш күргән сихерле төш кенә минем күңелдә. Кабат ул төшне беркайчан да күрү мөмкин түгел...

Менә бит мин нинди бозык җан. Үзем хатынлы, балалы кеше, ә үзем Назикә турында уйлыйм. Хәер, искә төшкәч кенә бу. Алай өзгәләнеп яшәмим аның өчен. Дөресен әйткәндә, хатын-кызларны ярату, сөю мәсьәләсендә мин үземне һич кенә дә аңламыйм. Әнә бит, ун көн эчендә өйләнеп ташладым, балам да булды, ызгыш-талаш белән дә җәфаланмадык, ә калдырдым да киттем, уйга да кермн хәзер. Хәтта бик

газиз тоелган балам да ак томан эченә кумелә бара шикелле хәзер. Юк, ярата белмимдер мин, ахры. Йә булмаса, «ирекле сөю» теориясен чыгаручылар сүзе дөрестер. Бар микән ул чын сөю дигән нәрсә? Ай-һай... Мин белмим. Назикә өчен үлеп йөрүләрем дә сүрелгәч инде, ни дип әйтим? Шул «яңа теория» өйрәтте булса кирәк мине тормышка, дөньяга җиңел генә карарга. Кайнар хисләреңне кабызмыйча гына сайранып, чәчәкләрне өзгәләп китәргә... Җыры да бар бит аның:

Өз гөлләрне чәчәк аткан чакта,
Узар-китәр алтын көннәрең.
Өзми калсаң үкенерсең бер көн:
Чәчәкләре шиңәр гөлләрнең...

Баш катып бетә шундый уйлардан. Берсенең дә очына чыга торган түгел. Ә тормыш һаман үз сикәлтәләре буйлатып сикертә бирә мине. Кыш җитте, ачы кыр җилләре сызгырганда ком таратып, шпал төеп йөрүләр, алла күрсәтмәсен, бик тә рәхәт икән!

Чиләбегә киттем. Аннары Киштыйм, Калата, Златаус, Алапай, Уфали якларын йөреп чыктым. Кая барма — ике кул һәм көрәк белән кәйлә дигән машина! Теләсәң, шундый һөнәрнең профессоры бул! Шомарган биш тиендәй шулай йөри торгач, килеп җитте солдат хезмәте, ике ел анда узып китте...

«Әкиятеңнең әкәмәтен мич астына мүкәләттең», — дисезме? Үзем дә сизем, егетләр. Озын сүздән аркан ишеп булмый, дигәннәр бугай.

Шул: хезмәтнең актык елында хозчасть писаре ясадылар үземне. Вакыт җитәрлек. Баштарак койрыкны кәкрәйтеп, «кухтрест»лар артыннан бик нык чапкан идем, соңыннан уй төште: «укырмын» дигән сүзең кайда?» дип сорадым үземнән. Үз-үзеңне шулай яңаклагач кына белем арттыру, вузга хәзерлек курсларын узу мөмкинлеге табылды. Хезмәт тутыргач, Казанга килдем. Армия бирә торган льготадан бик нык файдаланып, пединститутның тарих бүлегенә керә алдым. Гомерләр уза бирә, инде өченче курсны да бетереп киләм. Июнь ахыры, актык имтиханнарны тапшырып йөргән чак. Педагогларның РСФСР күләм конференциясе бара икән Казанда. Көндезге утырышларын институтның карурмандай борынгы матур паркында уздыралар икән. Мин дә озакламый укытучы буласы кеше ич. Актык фәнне «яхшы»-га тапшырган сөенечтән, иптәшләргә ияреп, шунда сугылдым. Арттагы рәтләрнең берсеннән урын да табылды. Трибунада олы яшьләрдәге бер ханым. Ул үз мәктәбендә тарих дәресләренең ничек барышы турында сөйли. Нәкъ миңа кирәкле сүз! Бу чыгышны бик бирелеп тыңласам да, минем туң башка үтеп җитми. Укытучы булыр көннәр ерак киләчәктә зәңгәр томанлы бер сукмак шикелле генә тоела. Китәмме әле мин ул сукмактан, юкмы?..

Килеп утырганнан бирле үк инде «зал»дагы халыкны күздән кичерәм: яше дә бар, карты да аз түгел; юаны да, нечкәсе дә, ямьсезе дә күренгәли. Ә шулар арасыннан бер таныш әдәм дә күзгә чалынмый. Хәер, мин ул дөнья кешесе түгел ич. Шулай да президиумдагы ханымнарның берсендә ниндидер таныш сымак чалымнар күренгән шикелле тоела. Нижитте кыланмыйм тегеләй, югары куначаны күзәтәм! Әйе, үзе ул минем яшьләр тирәсендә булыр. Бөтен гәүдәсенә, килеш-килбәтенә укытучылык сеңгәнлеге сизелеп тора, ә шулай да сөйкемле күренә үзе. Кем булыр икән ул? Үзем белгәннәрне күңел күзеннән үткәреп карыйм. Юк, һич андый сөйкемле апа килеп чыкмый хәтер чаршавы артыннан. Эзләнә торгач, яшь чакларга кайтып төштем: кемнәр бар иде соң әле? Кем булсын, минем беренче хатын укытучы иде бит! Юк, ул түгел бу. Моның бөтен кыяфәте кемнедер — бик белгән кешене хәтерләтә, исеме дә менә тел очымда гына тора, тик әйтеп кенә булмый. Әйдә, булмаса булмас, аның белән баш ватып

торыр хәл юк. Конференция иртәгә дә барачак бит әле, шунда беленер...

Янга малайлар килде, курсташлар. Күз кысалар. Исән-аман тапшырсак, «сәпкулларга» барырбыз дип сүз куешкан идек иртә белән. Ә «сәпкуллау» дигәне — сыра эчү дигән сүз инде аның. Чөнки безгә немец теле укытучы Сәпкул иптәш, кайчан гына керсәк тә, шул пивнойда чөмереп утыра. «Ну сәпкуллый бу Сәпкул абый!» — диде безнең бер малай. Менә шуннан «сәпкуллау» китте. Шулай итеп, без дә «сәпкулларга» киттек. Актык имтиханны «юып» алмыйча булмый бит инде.

Иртәгесен мин ул конференциянең ябылу кичәсенә генә килә алдым, анда да малайлар кыстагач кына! Чөнки үз җыелышларыбызда да кирәкмәгән озын сүзләр тыңлап, туеп беткән кеше. Аннары каникуллар алдыннан болай да төрле мәшәкать җитәрлек була ич.

Студентлык билеты әйбәт нәрсә — теләсәң кая алып керә ала, трамвайда да штраф түләтмиләр, театр залына да уздыралар икән. Инде кичә башланып ята, залда сәхнәдән төшкән якты гына. Буш урын күзәтеп, уңга-сулга карый-карый, алга атлыйм. Тыштан керүгә зал шактый караңгы сыман күренә. Тагын бер-ике рәтне шулай капмаланып дигәндәй узуга, кемдер арт яктан җиңемә кагылды җиңелчә генә итеп. Борылып карасам: берәү кул изи сабыр гына елмаеп.

— Безнең янда урын бар, Ихсан абый,— дип пышылдавы да ишетелде.

Күрсәтелгән урынга килеп утырам, исәнләшергә кул сузам, ә үзем кем икәнен һич танымыйм. Шундый яхшы кызны беләсе, рәхмәт әйтәсе килә бит... Иелебрәк тагын бер карасам, ис-акылларым китте.

— Назикә! — дип кычкырып җибәрә яздым.

Ашык-пошык кылануым белән кешеләрне борчый-борчый, пышылдарга тотындым:

— Ә мин сезне танымый да торам!

— Ә сезне мин кичә үк таныдым.

— Кичә мин дә президиумдагы бер матурны танырга тырышып, баш ваттым. Ләкин сез дә бу киңәшмәдә булыр дип, кем уйлаган?..

Йөрәк дөп-дөп тибә, хәзер үк, шушы сулышта ук әллә ниләр, әллә ниләр сөйләп китәсе килә. Юк шул, күп пышылдап булмый, кулын тына кысам. Кайчандыр минем җанга-тәнгә кайнар дулкын агылдырган кулын кысам! Мәгәр ул кулдан бу юлы андый рәхәт ялкын агылмады, ул тыенкы, инсафлы иде. Минем «ач» кулны җай гына ычкындырып җибәрде... Хәер, безнең күрешмәгәнгә унөч ел узып киткән шул инде... Унөч ел! Нинди сулар акмагандыр аның гомер юлларыннан? Ә үземнекен мин яхшы беләм...

Назикә мине үзенең икенче кырыендагы иптәше белән таныштырды: Казан укытучысы икән, фамилиясен дә әйтте. Бу хәл мине шундук сагайтып һәм айнытып куйды: «Күз тоткан кешесе микәнни? Әллә иреме?.. Араларында дуслык барлыгын искәртеп куюы, бик шашынма, диюедер инде...» Әллә нәрсәләр уйлап бетердем. Хәер, чыпчынын гына әйткәндә, күңелдә нигәдер элекке ялкыннар дөрләми икән хәзер... Шактый тынлык...

«Тегеартистның хәтере калмасын, монысы үпкәләмәсен», — дип төзелгән бик тә матур концерт программасын тәмамлап, без театрдан таралганда төнге уникеләр булгандыр. Теге кеше дә безгә ияреп чыкты. Хәер, иярүче бәлки мин булганмындыр аларга? Нәкъ әлеге яшел яшьлек көннәрендә шушы кызны Зариф белән озаткандагыча килеп чыкты бу. Тарихның һаман кабатлана торуына ачу килде. Ник кысылып йөри инде бу кеше?.. Ул да минем хакта шулай дип уйлыйдыр инде.

Хәзерге «Казан» кунак йортының ишек төбендә тукталдык. Икесенә дә суык кына кул бирдем. Тизрәк аннан ычкынырга исәп.

— Мин әле авылга барып киләм, Ихсан абый,— диде Назикә.— Әгәр сез каникулга китеп өлгермәсәгез, бәлки очрашырбыз да, язган булса... — дип өстәде. Соңгы сүзен миннән көлеп әйткән шикелле тоелды ул.

— Ярар... — дидем мин үле генә тавыш белән. — «Язган булса — яз көне, кушкан булса — кыш көне», дигәннәр бит... Хушыгыз, хәзергә...

Мин китеп бардым, алар сөйләшә калды.

Кайткач уйланып яттым: ник көлде әле ул миннән?.. Бәлки соңгы ике сүзен уйнап кына өстәгәндер... Бәлки аның «авылга барып киләм» дигән сүзе «бүре дә тук булсын, сарык та исән калсын» өчен генә әйтелгәндер... Бәлки алар якын танышлардыр, әнә ич, сөйләшеп калдылар...

Ә бәлки алай ук түгелдер: бу кичә аның белән киңәшмәдә генә танышкандыр... Минем күк бер «мескен» буйдактыр?.. Ә Назикәнең «авылга барып киләм...» диюе «мине көт, күрәсем килә» дигән сүзе түгел микән соң?..

Гел юк белән юана торган Хәчтерүш, ахры, мин! Ихсан дигән тинтәк иртәгә аны эзләп килмәсен, озата төшәм дип юләрләнмәсен өчен генә әйтелгән сүз ич бу. Аллам сакласын, төшәмме соң! Тагын шул поши белән очрашып, «өченче артык» булып, бер дә йөрисем килми, җитәр! Юк, элекке Назикә күренми хәзер. Күңелдәге сокланагыч таң нуры сүрелгән инде...

Кичтән шулай баш катырып яттым да, иртәгесен Бакалтайга таба төшеп киттем. Анда утын складлары бар, анда агач төягән баржалар туктый. Кышка кирәк чанаңны җәен җайлап куймасаң, Әндри казнасы бирмәс сиңа. Стипендия тае ай уртасына хәтле генә тарта ич ул...

Назикә турындагы буш уйлар әллә кайчан утын арасына коелып бетте. Үзе дә күренмәде, эзе дә беленмәде. Әлбәттә, шулай юмалап китүе генә булган инде ул аның. Әйдә, бик яхшы, җан тыныч...

Кич кайткач, утында чиләнгән аркаларны майлаштырам да, йөзтүбән капланып, йокыга китәм. Кызлар дигәненә дә ис китми хәзер. Беренче хатынымны искә төшергәнгә дә биш былтыр. Диплом алып эшкә урнашмыйча, барыбер өйләнеп булмаячак бит әле. Утыз икедә институт бетерәсе «яшь егеткә» кысыр гыйшык тотып маташулар, ничектер, көлке генә тоела...

Шулай да бүген якшәмбе ич әле, таныш-белеш кызларның берәрсенә сугылмый ярамас... Торырга иренеп ятам: күзләр түшәмдә, ике кул баш астында, уйлар әнә шул проблеманы хәл итә алмый маташа. Чынлап та, кайсы якынрак? Хәдичәме, Бикәме, Нурфияме, Гөлфияме? Әй, бар да бериш лә! Бар да юри генә елмайган була. Ну мин кабармын әле бер: «Сайлаган — сазга, очраган — тазга!» — диләр бугай. Берсе дә ошамый, һаман сайлаган булам үзем...

Сак кына ишек кактылар. Кем булыр болай таң тишегеннән? Җыештыручы апа микәнни соң? «Тизрәк чыгып кит, идәнеңне юып чыгарасым бар!» диюдер инде. Кичә шулай сөйләшенгән иде бугай.

«Хәзер торам, әз генә иркәләнеп алыйк инде...»

Эчтән шулай дип, үз уйларыма гына тотынган идем, ишекне тагын каккандай иттеләр.

— Хәзер торам, торам, Сафия апа. Менә бер күз генә ачылып җитмәгән, — дип шаяртkan булам, Шулай да, ялкау гәүдәне иренчәк кочагыннан сөйрәп торгыздым да, чалбарны каптырып ишеккә килдем, ачкычны бордым.

— Әйдә, Сафия апа, — дип, урын җыярга борылдым. Одеалны ашык-пошык кына җәеп, мендәрне кабартып кайгач: «Ник бу карчык

бер дә кыштырдамый, дәшми әле», — дип әйләнеп карасам, ишек төбендә юаш кына кыяфәт белән Назикә басып тора! Бер кулында чемодан, икенчесендә киң зәңгәр сетка, ул да шыплап тутырылган. Идәнгә дә куймаган, ичмаса...

«Тагын күзгә күренә мәллә бу?» — дигән уй белән җәһәт кенә каршына килдем. «Исәнме!» — дидем, әйберләрен түргә илтеп куйдым, үзем бөтенләй каушап калдым. Нәкъ мондый кунак кабул итәрлек кенә иде мин торган бүлмә! Дүрт шәрә койкада дүрт иске матрас ыржаеп ята, ертык-тишекләреннән бүселергә торган саламнары нигәдер сарык абзарын хәтерләтә. Аслы-өсле итеп почмакка өелгән өстәл, тумбочкалар, төрле урындагы тәрәксез утыргычлар, минем анда-монда ташланган кием әйберсе, тәмәке төпчекләре — бу бүлмәнең матурлыгын тагын да арттыралар иде.

Миннән дә ныграк каушап калган Назикә сүзне үзе башлады.

— Болай борчып йөрүем өчен гафу итегез инде, Ихсан абый, — диде ул, күптәннән үк минем күңел түренә утырып калган йомшак тавышы белән. — Гостиницада урын булмады бит. Администраторлары белән сөйләшеп китсәм дә, калдырмаганнар. Республика активы чакырыла икән, урып-җыюга хәзерлек. Бер җирдә бер койка табу мөмкинлеге юк. Ә минем поезд иртәгә кич белән генә китә... Ничек тәүлектән артык вокзалда ятасың? Гаеп итмәс әле, дип уйладым да сезне эзләп килдем...

Аның кабалана төшеп әйтелгән бу сүзләрендә борчып йөрүе өчен гафу үтенү генә түгел, монда килеп керүенә бик тә уңайсызлану һәм үкенү хисе дә бар кебек иде. Мин, баягы каушауларны бөтенләй онытып, шаян тавыш белән кешнәп җибәрдем:

— И яхшы да булган соң урын табылмавы! Менә бит «Һотель класс люкс»! Хакы да бик арзан — аена утыз көн генә! — дип тезә киттем. Шундук кочаклап үбәсем килде үзен. Юк, ярамый, үпкәләтермен, мин бит әле бит тә юмаган!

Сөлге алдым да юынгычка чыгып киттем. Мин керүгә юл киемнәрен алыштырып, кулына шулай ук сөлге-сабын тотып тора иде ул.

— Сиңа да кирәкме? Әйдә, — дип юл күрсәттем дә тиз генә урын-җирне җыештырырга тотындым. Шәрә матраслар өстенә гәзит җәйгәләп чыктым, идәндәге чүп-чарны себергәләп ташладым. Үземдә йөз төрле сорау: ничек болай соң бу? Авылга барып киләм дигәне чын булды микәнни? Ничек керәсе итте икән? Кыюлыкмы, мәҗбүрилекме? Ә теге кешесе нәрсә икән соң — озатмады, каршыламады микәнни?.. Ярар, аңлашылыр әле. Ул юынып керүгә мин инде булган өс-башның юньлерәген киенеп куйган идем. Кыз да әз-маз бизәнеп-сөртенеп дигәндәй кергән...

Бауман урамындагы хәзерге «Елочка» кафесына алып килдем кунакны. Тамак туйдырдык та янадан бүлмәгә кайттык. Студент халкы дәрес әзерли торган озын өстәл читенә кара-каршы утырдык та сүзгә керештек. Мин сорашкан хәлләр турында сөйли ул. Менә шул чакта гына минем күзләр аның йөзенә, бөтен килеш-килбәтенә юнәлде. Теге кичтә мин аның үзен түгел, күләгәсен күргәндәй генә булып калган идем. Бүген дә рәтләп күз күтәрергә вакыт булмады. Бактың исә, Назикә дә олыгаеп килә икән ләбаса. Элекке матурлыгы шактый сүрелә төшкән, йөзенә ниндидер нәзек моңсулык йөгергән. Маңгай өсләренә нечкә генә җеп сызыклары яткан, шундый ук чалымнар ирен почмакларына да урләгән төсле. Күзләренең унөч ел элек хәтердә калган яктылыгы да ничектер берхәтле томанланыбрак киткән сыман тоела. Шулай да барыбер сөйкемле ул. Элеккедәй үк үлеп ярату сизмәсәм дә, күңел һич бизмәгән икән әле...

Аның болай бер дә көтелмәстән килеп керүенә мин һаман гаҗәп-

ләнәм әле, ничек тапкан? Нигә килеп кергән? Теге кешесе бар иде бит... Әллә күңеле миңа табамы?..

— Табуы кыен булмадымы соң?— дигән булам.

— Үзең әйттең ич театрда,— дип көлемсери ул.— Кольцода, почмак йорт. «Институт тулай торагы» дип язылган, диден. Мондый төгәл адрес булгач, аны табуы кыенмыни Казанда?

Минем бакчага таш атуы инде бу... Назикә дә кыюланган икән хәзер!

— Ә синең Зариф дусың рабфакны бетерде дә Свердловның бер нэпман кызына өйләнеп җибәрде...

Бу хәбәр мине аяктан еккандай булды. Ничек алай ул? Дүрт ел рабфакта укып та Зариф шуны аңламаганмы? Нэпачның бал да мае авыз суларын китергәнме, әллә сыйнфый сизгерлеген дә онытыр дәрәҗәдә каты яратканмы кызны? Алай дисәң... Назикә белән дус иде бит ул... Мин шул якка басым ясап карадым:

— Кайбер иптәшләрнең «әбеченә» тигән, ахры, бу хәл...— дигән булдым.— Хәтерлим, Җирән Җәләй кайчандыр аңлаткан иде...

Икебез дә көлешеп алдык. Назикә әз генә кызарынып киткәндәй булды.

— Алай ук егылып үләрлек булмады булуын да... Шулай да сәеррәк килеп чыкты...— диде ул тыныч тавыш белән.— Һич аңлый алмадым ул Зарифны. Әйе, без аның белән сиңа хәтле үк таныш идек. Җәләй мине биюче итәргә маташканда, бу мине Галиябану итте дә үзе Хәлил булды. Шулай сәхнәдә уйный башладык. Ә яшьлектә сәхнәдәге — күңелгә дә бик тиз күчә икән. Зариф һәр яктан бик актив, булдыклы егет булып күренде миңа. Аның ягына таба авыша баруымны сизми дә калдым. Шуннан ул мине Җәләй белән битәрләргә тотынды. Ә минем ул малай истә дә юк иде. Аннары инде Май бәйрәме кичәсендә синең белән таныштырды. Шунысы кызык: сине минем янга бастырды да үзе тәмәке тартырга чыгып киткән булды. Кем инде үз кызын шулай тиз генә икенче бер егеткә ташлап китә? Беренче тапкыр күргән ят кешегә? Ә тартып кергәч, икенче яктан безнең каршыга килеп басты. Күзләре гел бездә үзенең. «Көнче микән бу малай, сынамакчы була микән? Ышанмый микәнни соң ул миңа?..»— дигән суык уй эчне туңдырып җибәрде шунда. Синең кич буена бер сүз эндәшми йөреп тә, соңга таба учка записка салуыңны да күреп торган икән. Иртәгесен желеккә тиде: «Сезнең серләр бик килеште кичә, ул сиңа хат та бирде бит. Кая, күрсәт әле, ниләр язган?»— имеш. Ә мин ул кәгазь кисәген кайткач та ертып ташлаган идем. Шаярып язган дип кенә уйладым. Аның сеңлесе аркылы тапшырткан хатларың өчен дә шактый эләкте миңа: «Ник алдың? Ник кире кайтармадың? Беләм мин сине: миннән яшерен җавап язгансың син аңар!»— дигән кебек шелтәләр явып кына тора иде. Шуның өстенә, сез ул хатларны икегез бергә язгансыз, икәүләп мине мыскыл итәсез сыман тоелды. Шулай да мин синең белән Рощада әйләнүдән баш тарта алмадым. Күңелнең әллә кай җире генә сиңа ышанган кебек иде. Җитәкләшеп йөргәндә куллардан бәлки сизелгәндер ул. Әмма синең, үпкәләмә, яме, төклетура йоткан тавыктай кыткылдый алмый йөрүең, бик тә гаҗәпләндерә иде мине. Әйтер сүзе юкмы, яратмыймы? Әйе, яратмыйдыр ла!..— дип уйладым.

Үзем, елмайгандай итеп, тыңлап утырам Назикә сүзләрен, үзем гарьләнәм. Ай-яй, яудыра бу миңа! Хәер, үзем гаепле. Шул хәтле дә мәгънәсез булырмы кеше!..

Назикә тагын дәвам итә:

— Зариф белән кинәт кенә бергә китеп бару да сәер тоелгандыр сиңа. Бусы Йосыф абыйдан килеп чыкты. Ул безгә ике көн вакыт

бирде. «Юкса, курслардан колак кагасыз, өч көннән укулар башланачак!»— дип кырт кисте. Ә бит ул чакта укырга китәсе бик тә килә иде!

Свердловта без инде әкрен-әкрен бөтенләй сүрелешә башладык. Зарифның мин аңламаган үз интереслары һаман арта барды... Уйлап карасаң, чынлап яратышу иде микән ул? Үсмер чак мавыгулары гына булмады микән? Чөнки аны жую — миңа һичбер төрле газап-сагышлар, авыр кичерешләр китермәде, аралар суынуга аның да исе китмәде.

Мәнә шулай итеп, бу апаң Жирән Жәләйдән дә, көнче Зарифтан да, авызына бер җиләк су кабып йөргән Ихсан абыйсыннан да колак какты. Дүрт ел рабфак, биш елга якын вуз, аннары укытучы булып балалар дөньясына чуму — Назикә апагызны карт кыз итеп калдырды да куйды. Әллә ничек, күрми дә калдым... Утыз тутырган кешедә элекке җилкенчәк күңелләр тымызык күлгә әйләнә икән. Көннәр кояшлы булганда да чабак уйнамый анда хәзер...

Бу минутта никтер кызгандырып куйды ул мине. Юк, Назикә үзе бер дә кызганыч булып күренергә, алай кыланырга да теләми. Моңсулык йөгертелгән җор сүзләр белән елмаеп сөйләгән була. Ләкин... гүя үзем сөйлим мин ул сүзләрне! Ул елмаюларның һәр сулышында, һәр тынышында, ул сүзләрнең әйтелеп бетмәгән нокталарында дигәндәй, ниндидер уйчан сагыш, югала барган яшьлекнең кабат кайтмау үкенече, татылмый калган кайнар хисләрнең, әйтелми калган татлы сүзләрнең, җырланмый калган сөю җырларының үзәк өзгеч ачысы ята кебек... Үземә дә утыз бер тулды ич!.. Назикәнең хәле ник аңлашылмасын?..

Алайса, без икебез «бер ятим» икән?.. Күңел — шайтан. Әллә кайларга керде дә китте! Ә теге кешесе?..

Аның хакында Назикә болай диде:

— Ул мондагы кеше. Укытучы икән. Такташ әйтмешли: «...туры килде безнең урындык...». Ике көн бергә утырдык, сөйләшә киттек. Ул миңа үзенең хатыны үлүен, яше кырыкка баскан кеше өчен ялгызлык кыен икәнен сөйләде. Аннары, миңа мактау сүзләре яудырып, беренче күрүдә үк күңеленә хуш килүен әйтте. Әйтте дә аучыларга тотынды. Ә минем карт күңел кымшанмады. Бер дә белмәгән-күрмәгән җиде ятка ничек дуамал гына килеп сыенырга мөмкин?.. Юк, ул миңа нигәдер, белмим, ошамый да бугай... Теге кичне озата барганда син бик көлке идең. Бәләкәй малайлар кебек авызыңны турсайтып, тизрәк китү ягын карадың. Ә ул мине вокзалга озата төште, утыртып җибәрде. Тик мәнә монда кайтканны белми калды. «Шуннан гына китәм», дигән булдым. Гостиница таба алмагач, үкенеп тә куйдым, ярый әле, син өйдә туры килдең...

Назикәнең бу хикәясе мине артык гаҗәпләндермәде. Ул кешенең тикмәгә генә йөрмәвен болай да сизенгән идем бит. Ә мәнә кызның соңгы сүзләре... Һе!.. Сиңа ишарәле түгелме соң, Ихсан дус! «Белгәнгә — белек, белмәгәнгә — кул селек!»— диләр бугай әле. Инде дә авыз ачып калсаң, сиңа да сулагай кул селекмәсләрме?

Шайтан күңел тәмам атлыга башлады. Әйе, әйе! Авыз ачып калма!.. Яшьлек үкенечен... исеңдә тот! Ычкындыру һич кенә дә ярамый.

Кич булды, караңгы төшеп килә, кунак кызын ашарга алып чыктым. Шунда берочтан «Родина»да кино да карап кайттык. Куллар кулда булды, хәтта яшь чакның беренче татлы дулкыннары да агылгандай тоелды ул куллардан.

Кайткач, әллә ни сүз булмады. Көйкамә урын җәеп, аңа тәкъдим иттем. Барлы-юклы чүпрәк-чапракны табып, буш көйкаларның берсенә үземә дә урын әмәлләдем. Утны сүндердем. Чишендек тә, ятабыз сөйләшеп ике урында икебез...

Азгын күңел тагын кычкыра: «Чакыр, чакыр үз яныңа тизрәк!— ди.— Меркетәп булма!»

Алай да болай боргаланам.

«Яхшы түгел... әшәкелек булыр,— дим.— Үзеңнең яшьлек дусыңны рәнҗетү булыр... Барыбер каршы килер... ярамас».

Эчтәге Иблис бөтенләй муенга ук атланып алды хәзер: «Гелләрем дә туң тумран, тинтәкбаш икәнсең!— дип өстәл суга бу.— Син нәрсә көтәсең тагы? Ул бит яшьлегеңнең өмет кошы! Синдә күпме кайнар хисләр, хыялый ашкынулар, сөю матурлыгы дигән татлы ялганнар уятып та, кинәт сине читкә кагып, сары сагышларга батырып, янган утларга салып, алтын канатларын җилпи-җилпи җиңел генә очып югалган кошны син тагын шул көйләй очырып җибәрерсеңме? Яшьлек үкенечеңне дә кайтармый калырсыңмы?..»

Тәки котыртып җиткерде бит бу.

— Сиңа суык түгелме анда, Назикә?— дим, үземчә бик йомшак кына тавыш белән.— Кил минем янга... аркаларыңны җылытырмын...

— Нишләп суык булсын,— ди Назикә,— юк, бик җылы...

Чыннан да! Тышта җәй уртасы, июль ае, ә мин: «суык түгелме», имеш! Моннан да мәнсезлек, моннан да тунбашлык булырмы дөньяда? «Ата казың күкәй саламы?»— дип сораудан да пүчтәгрәк бит инде бу!

— Алайса... минем арка туңа... одеал да юк бүтән... Җылыт әле, Назикә...— дидем дә, бардым да яттым янына!.. Каравыл кычкырмады. Беткән баш беткән, муен калса — җиткән, дигәндәй кочаклап алдым. Ярым тарткалашып булса да, аның куенына ашыктым. Өй хуҗасын җәберләүдән куркыптыр инде, төртеп төшермәде...

Ниһаять, уянып киттек. Сыңар студентлык тар гына койкада берберебез белән тыгыз кочакланышкан килеш йоклаган булганбыз. Җәйге кояшмы, әллә оятмы битләрне пешерә иде безнең. Ниндидер җиңел шатлык белән иң элек мин сикереп тордым...

Төштән соң мин аны вокзалга озатып, поездына утыртып җибәрдем. Көн буе сүрән кәефле, салпы күңелле, моңсу йөзле булды ул. Мин дә үземне шаптан сизми идем. Булдыра алганча иркә сүзләр әйтеп, юатырга маташтым. Әмма өмет бирердәй, ышаныч баглардай чын сүзләр нигәдер телгә килмәде...

— Башкалар алдында мактанып, чүп таратып йөрмә инде,— диде ул поезд кузгалыр алдыннан.

— Тыныч бул... Хәерле юл сиңа...— дип кенә мыдырданып калдым мин. Поезд вокзалдан югалды. Баскан җиремдә күпме торганмындыр, икенче вагоннар килеп тукталгач кына, айнып киттем.

...Ярар, актык курста мин хәзер. Җаваплы ел. Яхшы диплом өчен теш кысып тырышырга исәп бар. Нәкъ шул чакта тез астына китерде дә сукты икенче бәхет. Бүгенгедәй хәтерлим, октябрьнең янгырлы көннәре иде, чыланып торакка кайтып кердем. Вахтер апа янында почта әрҗәсе, гадәт буенча күз төшерми узмыйсың. Минем хәрефтә нидер күренә, алып карасам — Назикәдән! Ашык-пошык кына бүлмәгә уздым да, гаҗәпләнеп һәм кабаланып хатны ачтым. Моңарчы бер авыз сүз язганы юк иде бит... Тигез хәрефләр тезелгән озын хат. «Исәнме, кадерлем!..»— дип башлаган. Эчкә җылы инде, рәхәт булып китте. Аның әле бер дә миңа болай дип әйткәне юк иде. Сәламен әйткәннән соң, үзенең быел Пермь каласына күчерелеп, андагы урта мәктәптә укыта башлавын, киткән укытучының квартирын да аңа бирүләрен язган, коллективка ияләшәм инде, дигән...

Бик яхшы, эшләгән җирендә кешенең башкалар белән тату яши белүе — мактаулы сыйфат... Күзләр хат юллары буйлап ары йөгерә. Тукта, тукта, нәрсә дигән?

«Ихсан җаным, лачыным! Безне алда бик зур куаныч көтә: безнең нәниебез булачак!..»

Нәрсә бу? Саташкан мәллә? Кабат укып карыйм — тагын шул. Мин бәләкәй чакта әнинең кычытканлы суга биш тапкыр батырып-батырып манчыган «кертли» тавыгы шикелле тәмам шәбәреп, корышып каттым. Менә сиңа лачын! Менә сиңа «яшьлек үкенече!» Кабаланып бармакларны саный башладым. Июль, август, сентябрь... октябрьның яртысы... Өч ай ярым тулган икән шул! Болай булгач, белмичә сөйләми... Чынлап та «куаныч» көтә икән... Юк иде ди минем андый куанычлар! Шул гына җитмәгән иде!..

Өрәңгенең соңгы яфрагы шикелле сүлпән генә төшеп өстәлгә яткан хат укылып бетмәгән. Шул көйгә йомарлап тәрәзәдән ыргытасы килә аны, тик кулга тоту куркыныч... Тагын нинди хәсрәтләр бар икән анда?.. Түзмим, күз почмагындагы иң озын сөңгене бер чакрымнан сузам кәгазь өстенә. Ә ул шундый сүзләр элеп китерә миңа:

«...Күптән түгел әти-әниләр кунак булып китте. Аларга да әйттем үз шатлыгыбызны. Мин Казанда кияүгә чыгып кайттым, Ихсан Шәфигуллин дигән егеткә. Сез аны беләсездер, «Ветка» руднигында эшләде, яшьлектән үк дуслар идек, бик яхшы кеше, дидем...»

Тә-тә-тә, тә-ә-ә!.. Ишетәсеңме, тәти егет?! Син яхшы кеше! Ну каптырды бу сине! Суганлап та борычлап, боргычлап та сургучлап дигәндәй, шәп итеп пичәтләде дә куйды! Ай-яй, хәйләкәр икән бу юаш бәрән. Уеннан килеп чыккан уймакны әти-әниләре каршында законлаштырып та өлгергән! Исәнме, яшь кияү, кәефләр ничек?..

Ә кәефләр — кәкәйнең дә кәкәе! Минем бит аңа өйләнү дигән нәрсә башыма да кергәне юк иде. Ничек аңа өйләним мин? Элекке юләр хисләр әллә кайчан суынып беткән. Соңгы очрашуда аны яшьлектәге Назикә дип әйтерлек тә түгел иде. Бөтенләй үзгәргән, сулган-суырылган, кайчандыр сөйкемлелек балкыткан йөзләренә нәзек кенә пәрәвез җепләре сарылган, хәтта картайган булып күренде ул миңа. Юк, аңа өйләнү мөмкин түгел. Минем хыял күгемдә аңа караганда яшьрәк, матуррак кыз рәсеме басып тора. Мин шуны табарга тиеш!..

Ярар, нишләргә соң миңа хәзер? Башны алып олагыргамы берәр якка? Ә кая олагасың? Укуны ташлапмы, әничә еллар ирешә алмый йөргән максатны җилгә очырыпмы? Юк, булмый. Бетерергә кирәк...

Хәер, шүрәле күз яшеннән файда юк инде хәзер. Ничегрәк дип җавап бирү хакында уйларга кирәк. Хәсрәт җиле китереп ташлаган әлеге хатны баштанаяк яңадан укып чыктым.

«...Минем хәлләр җиңелдән түгел... Картларга шулай дип аңлатмый булдыра алмадым. Буендагыны буйга сеңдереп булмый ич. Кешеләргә дә Казанда ирем бар дим. Шунсыз мөмкин түгеллеген үзең дә аңлыйсыңдыр...»— дигән сүзләр дә бар икән әле анда!

Әйе, аңлыйм... Син укытучы бит, яманатың чыкканын да ишеткәнем юк. Тик нишләргә икән соң? Бер дә генә өйләнәсе килми ич... Әгәр дә мәгәр аборт турында киңәш итсәң?.. Бөтен җан-тән кинәт чымырдап китте: аңа хәзер җан кергәндер бит инде! Димәк, кеше үтерү! Үземне коткару өчен мин ул анага үз баласын үтерергә кушам?.. Ә кеше күзе, шул ук ата-ана күзе күрмимени моны? Шуның өстенә — тыелган эш. Әллә нинди әби-сәбиләргә тапшырылса, Назикә үзе исән калырмы?..

Шулай башны ташка бәргәндәй миңгереп, айдан артык йөргәч, өч авыз хат җибәрдем: «Көтелмәгән куаныч. Рәхмәт. Табарсың инде... Калганын күрешкәч сөйләшербез...»

Кыш узды. Нәкъ беренче апрель көнне телеграмма китереп бирделәр:

«Малаең белән тәбрик итәм икебез дә исән-сау Назикә».

Беренче апрель мәзәгедер бу дип уйларга теләдем. Назикә алай усал

итеп шаяра торган кыз түгел. Димәк, тагын бер тапкыр «әти» булдым. Гел барып чыктым мин хәзер! Шәп тә икән бу ирекле сөюләр! Бу юлы җавапны озакка сузмый гына бирергә туры килде.

«Чиксез бәхетлемен бик-бик рәхмәт август башларында күрешербез».

Моның шул хәтле төче ялган икәнен Назикә үзе дә бик тиз аңлар, әлбәттә!

Хәер, шулай дип язмыйча булмый иде. Инде койрыгың кияү күлендәге бозга каткач, ата дигән исем дә күтәргәч, ул балага бер күз дә төшермәстән, ничек итеп тып-тын каласың һәм кая олагасың? Инә түгел бит — печән кибәне эченә шылып булмый!

Ярар, фәлсәфә куертмый гына сүзне дәвам итик: дүрт фәннән дәүләт имтиханы, унбишләп фәннән зачетлар тапшырып, кулга диплом алдым. Шулай итеп, Ихсан абыегыз Казанның Калинин урамындагы бер мәктәптә тарих укытучысы булып эшкә урнашты. Закон буенча тия торган бер айлык ял белән хезмәт хакы да бирделәр. Малый Крайный тыкрыгында торучы бер апаның шактый киң почмагында һәйбәт кенә «чаршаулы бүлмә»дә әмәлләде. Хәзер инде аның бер кайгысы да юк иде. Үз вакытында укый алмый йөрүнең үчен кайтарды. Өйләнеп, бала кайгыртып йөрисе дә юк, бар да әзер аның өчен. Берәү түгел, икәү! Әкияттәге чуртан кушуы буенча диләр иде элек. Ә хәзер кибернетик автомат!..

Үз ахмаклыгыңнан көлү кызык сыман тоелса да, әйткән сүзеңдә торырга кирәк булды. Киттем Кама буйлап пароход өсләрендә генә. Анысы да үзем шикелле туры килде тагы: бер катлы гына. Хәер, минем акчага зур пароходта каюта алып, өске палубада гүләйт итеп кенә барулар тәтемәс тә иде шул. Өч тәүлек дигәндә килеп җиттем Пермьгә. Үзем белән бер яшьтәге фанер чемаданны күтәрдем дә күрсәтелгән адрес буенча эзләп киттем. Шәһәр читендәге иске бер урам. Шактый гомер иткән ике катлы агач йорт. Миңа кирәкле номер өстә булып чыкты. Сары буяулы такта баскычтан күтәрелеп, звонок бирдем. Ишек ачылуга шактый яшь чырайлы бер карчык, аның артыннан юка гына гәүдәле, кара түбәтәйле бер карт күренде.

— Әйдүк, кияү, әйдүк, көтеп кенә торадырыек! — диеште алар. Аңладым: картлар да монда икән. Әйтерсең әллә кайчаннан күреп беләләр икән. Ул арада Назикә дә килеп басты. Алдына кухня алъяпкычы бәйләгән, кулына кашык тоткан. Шул кашыклы кулы белән муенымнан кочып алды, икенчесенә минем фанерны эләктерде. Шулай шау-гөр килешеп дигәндәй, тар гына коридордан эчкә уздык, сулдагы бер бүлмәгә кердек. Тәрәзәләре ишегалды якка караса да, якты гына икән...

Андый чакта кияү шикелле кадерле кунакны ниләр белән сыйлап, ниләр сөйләшеп чәй эчертүләрен әйтеп тормыйм инде. Үзегезгә дә билгеле... Табыннан кузгалырга да өлгермәдем, бала тавышы килде.

— Әнәтерә, сезде бит атасының килеп җитүен,— дигән булып, әби кеше җәһәт кенә кузгалды да, каршындагы бәләкәй бүлмәдән аклызәңгәрле төргәк күтәреп чыкты.

— Шулай, Айдар улым, шулай. Әти килгәч, озак йокламыйлар,— диде ул.— Ач күзләреңне. «Исән килеп җиттеңме, әтием», диген. Әнә ничек сагынган ул сине: «Кил, улым, кил!» ди.— Китереп кулыма да тоттырды.— Суйган да каплаган инде, кияү. Бу хәтле дә үзең төсле булыр икән!— дип өстәде.

Мин дә бик җитез генә хәрәкәтләнеп, бик «куанган» әти булып, төргәкне кулга алдым.

— Һай-һай, ничек үскән минем улым! Тежжет-тежжет! Инде көлә дә башлаган бугай,— дигән булып, җиңелчә генә сикертеп тә куйдым.

Әбидә генә түгел хәйләкәрлек, миндә дә җитәрлек! Шулай уйнаткан да елмайткан булып, астыртын гына төс-битен «өйрәнәм» баланың. Миңа охшаган җире бармы, янәсе. Ә ул, кып-кызыл ит кисәгедәй бит-

ләрен картларча җыерчыкландырып, әче тавыш белән җыларга да тотынды. Минем шул «әйбәт» нияттән хурланды бугай, ахрысы. Тиз генә әнисе килеп алмаса, эшләр харап иде...

Чәйдән соң картлар «шәһәр күреп кайтырга» чыгып киттеләр. Алар да кичә генә килеп төшкән икән әле. Уфадагы кызларыннан кайтышлый монысына да тукталганнар. Бөтен дөньяны тигезләп йөри торган «пинсияле кунаклар»...

Икәү генә калдык. Диванда бала имезеп утырган Назикә каршындагы урындыкка мин дә килеп атландым. Урындык арасына терсәкләрне җәеп салдым да, гаепле малай шикелле тын алмый, аңа карадым.

— Йә, «Шаян Шәяхмәт», күңелең булдымы инде?—диде Назикә, үзенә генә хас моңсу тавыш белән.— Икебез дә карт юләр икәнбез... Шушы яшькә җитеп... Әдәм көлкесе!..

Ул авыр көрсенеп куйды. Мин дә, башны сала төшеп, аңа төбәлгәнмен. Дәшмим. Дәшер сүзем дә юк... Шул моңсу тавышы белән ул тагын дәвам итә:

— Картлар туй ясарга кушалар, ясатмыйча китмибез дә, кияүне дә җибәрмибез, дип куркыталар... «Килгән көнне үк загска барыгыз» дип, алдан кисәтеп куйдылар. Менә кайсылай таба китте эшләр...

Минем авыздан һаман әле сынык сүз дә чыкмый. Ул әйткәннәргә, картлар кушканга каршы да түгел, кушылып кул да күтәрмим. Беткән баш беткән, сынмаса—җиткән... Ходайның мөгезсез тәкәсе булып сөзешми-нитми генә калырга исәп.

Кичен ишегалды күршеләре «кияү белән кыз»ны мунчага дәшеп алдылар. Ятим балалар шикелле икебез ике почмакта юынып утырдык. Шулай да Назикә килеп минем арканы юды, мин дә шуны ук кыландым. Без аннан чыгуга картлар олы бүлмәдә йоклаган иде инде. Без кече бүлмәгә урнаштык. Әби кеше, кат-кат мендәрләр кабартып, ап-ак җәймәләр җәеп, безгә дә урын түшәп куйган. Аяк очындагы чыбык арбада Айдар йоклый. Яттык. Кочаклашып, яратышып ятабыз... Ирле-хатынлы уйнап...

— Кирәкми,— ди Назикә.

Мин эндәшмим. Минем бер сүз бар, аны да эчтән генә кабатлыйм: беткән баш беткән...

Икенче көннең кичендә туй да ясалды. Назикәнең күрше-күлән, таныш-белешләреннән унлап кына кеше булса да, бик шәп итеп, шау-гөр килеп уздырдылар. Безгә бәхетле тормыш, тиң мәхәббәт һәм тагын әллә ниләр теләп, чәкешүләр әз булмады. Минем дә барлы-юклы өч йөз сум шунда кереп китте. Хәзерге акча белән утыз-кырык тәңкә дигән сүз инде ул...

Бер-ике көннән соң бабайларны озатып җибәрдек. Икәүдән-икәү генә калдык хәзер. Иртәгесен Назикә базарга киткәч, бишектә йоклап яткан Айдар янына килеп бастым. Бик үк яңа булмаса да, әйбәт исем табылган малайга.

Малайга. Ә минеке микән соң ул малай?.. Әгәр бу исем әнисенең бер кадерле кешесенә багышлы булса? Әгәр ул аның малае булып чыкса? Ышан син хатын-кызга! Аларның эчендә җитмеш җиде төрле ялган ята диләр түгелме?..

Һаман шундый уйлар, йөрәкне корт шикелле кимерә торган каһәр төшкере шикләр баштан чыкмый. Малайның як-ягына чыгып, нелә-бөгелә йөзенә карыйм: бармы миңа охшаулы берәр җире? Чәчләре кара... минеке дә... Хәер, әнисе дә кара чәчле ич! Күзләре, авыз-борыннары ничек?.. Тукта, борын кимерчәге киртләчләнебрәк тора түгелме соң? Җәлт кенә үз борынымны тотып карыйм: юк, минеке андый түгел бугай ич? Күзгә каршына басам. Бик җентекләп карасам да, андый киртләч таба алмыйм.

— Әйттем түгелме, ышан син хатын-кызга!— дип тагы кычкыра тегә тавыш эчтән. Тагы ике арада калам.

— Шушы кып-кызыл ит кисәгеннән нәрсә белеп, нәрсә танып, нинди хөкем чыгарып була соң? — дип, тагын тынычландырырга тырышам үземне.

Караклыкта тотылудан качкан кеше сыман малай яныннан читкә китәм. Ник мондый чишелмәс төен белән баш катырам соң әле? Минем фикер болай да нык һәм ачык ич. Мәсьәлә күптән үк хәл ителгән!

«Егермесеннән дә калмый эштә булырга тиешмен», дип, алдан ук әйтеп куйган идем, сәбәбен дә аңлаттым: өй-борынча кереп, мәктәп яшендәге балаларны язып йөрергә кирәк, яшь укытучыга шундый эш тактылар... дидем. Назикәне моңа ышандыру кыен булмады, тик аның бер дә мине җибәрәсе килми. «Монда күч, эш табылыр»,—дигән сүзләрен кабатлый. Ә минем һич тә генә күчү теләге уянмый. Чөнки элекке Назикә юк хәзер... Ул тагын да ныграк ябыга, картая төшкән, күп эшләп йончыган кеше төсе кергән. Алай гына да түгел: аның бөтен гәүдәсенә, килеш-килбәтенә ниндидер хәсрәт иңгән төсле. Хәтта мескен сыман булып күренә ул. Ә моннан унөч ел элек? Иртәнге кояшта таң чыклары белән җем-җем итеп утыручы ак каен — яшь каен — зифа каен шикелле, нур түгелеп торган сылу кыз иде бит ул! Кайда ул Назикә, кайларга киткән икән ул?..

Мин шулай саташып утырганда үзе кайтып керде. Ул әзерләгән тәмле сыйлар белән иртәнге тамакны туйдырдык. Күз йомып булмый: аш-суга осталыгы әллә каян күренеп тора. Чәйдән соң пристаньга төшәсе иттем, уналтысында китәсе пароходка билет алып куярга кирәк.

— Мине дә ияртәсеңме?— дип сорады Назикә.

Миңа нәрсә, әйдә, төшсен...

Баланы имезеп, янында күрше карчыгын калдырды да, чыгып киттек. Билет юнәткәч, ул мине Кама буеның пароход-баржалардан читтәге яшел чирәмле, вак кына әрәмәле матур бер җиренә алып китте. Үз хәлләребезне сөйләшеп йөри торгач, текә бер яр башына килеп утырдык. Сүзебез күбрәк истәлекләр тирәсендә әйләнә, үткәндәгеләр хәтерләнә. Свердловта укуларын бетергәч, Назикәне, Юрга стансасындагы татар урта мәктәбенә җибәргәннәр. Ул ябылгач, Чиләбегә килеп урнашкан. Шуннан конференция делегаты булып Казанга баргач, Ихсан дигән иптәшкә «тормышка чыгып» кайткан да, гаилә сәбәпләре буенча, Пермьгә күчәргә мәҗбүр булган...

Боларны ул тыйнак кына елмаеп, мине дә көлдерергә теләгәндәй итеп сөйли. Аңлыйм, бу хәлләр аны нинди кыенлыкларга дучар иткәнен дә төшенәм, тик, күңелен күтәреп, аны да көлдерерлек юату сүзләре генә таба алмыйм. Шуннан соң ул мин тинтәккә туп-туры әйтеп бирүгә күчә:

— Ихсан җаным, торыйк бергә, тормыш корыйк,— ди.— Үкенмәссең... Улыбыз да канатланып үсәр. Омски ягындагы кызыңны да (бу хакта мин аңа әйткән идем инде), әнисе бирсә, үзебезгә алырбыз, икесе бергә бертуган булып үсәрләр, укытырбыз, кеше итәрбез...— Аннары тирән сулап, битләре буйлый тәгәрәгән яшьләрен яшерә алмыйча, оялчан гына җылап та куя ул. Аның бер сүзендә дә, хәтта җылавында да нинди дә булса усаллык тавышы, янау-өркетү билгесе сизелми. Ялыну, үпкәләү яки кызгандыру өчен мескенләнеп кылану да ишетелми бу сүзләрдә. Әллә нинди алтын таулары да вәгъдә итми ул.

Ә мин, җирдә яткан мүкле кискәдәй — сүзсез. Тартам гына. Берсеннән икенчесен көйрәтәм. Башта — уйлар чуалчыгы. Кайсына тотынма, өзек тә төтек. Бер караганда, чынлап та, ник безгә бергә тормаска, Назикәнең кай җире ким, кай төше начар? Холкы-фигыле яраусызмы, ират белән яманаты чыкканмы? Юк, табалмыйм, ишеткәнем дә юк, андый кыз икәнен белмим. Киресенчә, бөтен күңеле яхшылыкта гына; өстә-

венә, квартиры да бар, ә син — кеше почмагында йөрисең. Ул бит сине яратып чакыра: үзенә яр итеп, балага ата итеп... «Беләм, белә торып бәләм!» — дип әйткән ди берәү, комсыз сөяркәсенә актык малын ташый-ташый.

«Менә шунда да шул инде хәйләнең иң нечкә җире! — дип куя күңелдәге шайтан.— Ул синнән мал сорамый, үзеңне сорый. Үзенә баш булып алгач, нужа чанасына җигәргә, инде картаеп та өлгергән хатын белән торып, гомер буе җәфа чиктерергә, үкенеч зарында сине дә бик тиз картайтырга тели! Ә син җиләктәй җегет ич әле, аннан яшьрәкне, күп өлеш матурракны таба алмассыңмыни? Бар бит андыйлар дөньяда, бар, җаның теләгәнне сайлап ал!..»

Ниһаять, телгә килеп, ипле сүз белән генә әйттем Назикәгә.

— Мин баланы онытмам, кулымнан килгәнчә җибәрә торырмын. Суд белән рәсмиләштерсәң дә, каршылыгым юк, үпкәләмәм, ачуланмам. Ул бит минем фамилиядә. Син аны загста шулай теркәтеп, дөрес иткәнсең. Үзең белән алып барып, таныклыкка кул куйдыруыңа да риза булдым. Баланың гаебе юк... Әмма... беләсеңме, нәрсә, Назикә дустым: бергәләп тормыш коруга күңел тартмый. Бик күп уйландым, юк, кулымнан килмәстер... Авыр булыр бергә, кыен булыр. Ябышмас... Яшьлектәге хисләр әллә чын булмаган, әллә гомер җилләре каядыр очырып бетергән аларны, әллә давыл сындырган... Бер-беребезгә үпкәләшеп, үкенеп тә көенеп яшәргә калса, ни кызыгы булыр?..

Яр өстендә тезләрен кочаклап, башын иеп утырган килеш, берсүзсез тыңлады ул моны. Мин тукталгач та әле, байтак вакыт агымсуларга карап утырды да сүлпән генә аягүрә басты, мин дә кузгалдым. Шунда аның әкрен генә җырлаган тавышы ишетелде.

Әллә агып китим микән
Суларга дулкынланып...

Гадәтенчә тыйнак кына көлемсерәп, миңа карый үзе.

— Син курыкма,— ди,— җырның ертыгы юк, диләр. Болай гына хәтергә килде ул... Бер дә агып китәсем килми... Яшәүне яратам... Хәзер мин ялгыз түгел ич!..

Безгә ашыгырга кирәк иде. Айдар ачыгып беткәндер, моны икебез дә сизәбез. Җәһәт-җәһәт атлый башладык. Белмим, нигәдер мин аның кулыннан алдым. Сабыйларча җитәкләшеп кайтып кердек.

Бу темага башкача һичбер сүз кузгатмыйча, иртәгесен озатып җибәрде ул мине. Җыламады да, караңгы чырай да күрсәтмәде...

Шулай атна-ун көн дигәндәй ирле-хатынлы уйнагач, җилкәннәренә җил тутырып, Казан каласына сәфәр кылды Ихсан дигән егет.

Шушында бер тыныш куеп, әкиятчене сыйлап җибәрсәк тә ярый торгандыр...

Кесәсеннән «Беломор» алып, кара пирчәткәсенең бармак арасына берне кыстырып куйды. Аннары шул ук кесәсеннән зажигалкасын чыгарып ут кабызды, аны яңадан кесәсенә тыкканда протез тезе шыгырдап китте.

— Аяк оешкан, — дигән булды ул, сузып-язгалап куйды. Уң як түшендәге «сугыш билгесе» кечкенә кояшта елкылдап алды. Орденнарның да иң шәбенә охшаган бу билгене һәр вакыт тагып йөри ул. Дөрес, бүтәннәре дә күп аның. Аларын тик Тугызынчы майда гына тагып чыга. Орден-медаль белән ике түше дә тулган була.

— Да-а, егетлек шәп булган синең! — дип куйды Аңбаш Шәңгәрәй. — Үкенечен куймагансың.

— Әллә егетлек, әллә этлек! — диде Сәгыйдә карчык шактый усал тавыш белән.

— Әйтерең бармы? — дип өстәде икенчесе.

Барыбыз да көлешеп алдык.

— Бакчи, нинди апаларыгыз! Мыеклары ничек кабарган!..

Хатын-кызлар әз безнең арада. Алар күбесенчә тыңлап кына утыралар, бүген беренче тапкыр сүз кыстырулары әле.

— Әйттем бит,— диде Ихсан — гаепләштән булмасын,— дидем.— Шомартмыйча гына, дөресен сөйләсәң, шулай була инде ул, ошап бетми...

Аның тавышында хәтер калу билгесе сизелде. Тартып бетерә язган папиросын читкә селтәде дә яңасын кабызды.

— Туктагыз әле, әрепләшмәгез, яшьләр! — дип тынычландырырга тырышты Шәңгәрәй.— Башта сабагын тыңлатып бетерсен, аннары кәмиссия карар, үз хөкемен чыгарыр. Тыңлыйк.

— Тыңлыйбыз, тыңлыйбыз, давай, сөйлә, Ихсан дус! — диештек без.

Ул тәмәкесен суырды, өф-ф иттереп төтеннәрен өреп җибәрде, әйтерсең бу тәмәке төтен түгел, каяндыр эчтән чыккан ачы сөрем иде, шуннан качмакчы була иде Ихсан. Тагын бер чумылдырып суырды да:

— Бу ягы аның иң авыры инде... Белмим, очына чыгып булырмы,— дип дәвам итте.— Кайтып эшкә тотындым. Шунда инде мин күнел түрендә яткан теге кызны да очраттым, Рәшидә исемле икән ул. Матурның да матуры: ай да, кояш та, йолдызлар да бар йөзендә. Ул чәчләре дисәң — җил чуалткан коңгырт болыт. Ул күзләре дисәң — ике түгәрәк диңгез, батып үлсәң дә үкенмәссең. Буй-сыны да коеп куйган, телгә-сүзгә дә йомшак, яше дә әйбәт — миннән ун гына яшькә кече. Кыскасын гына әйткәндә, килмәгән җире бер дә юк. Үлеп тора бу минем өчен. Үзем дә һаман аңа тартылам, аны ярата барам. Укырга килгән һәр көнне иң элек аны күрү — иң зур куанычым була.

Шулай иттереп, хәлләр шактый куерып китте безнең. Өйләнешү мәсьәләсе килеп басты көн тәртибенә. Тик өен генә каян табасы да җиһазын гына ничек булдырасы? Мин һаман кеше почмагында, чаршау артында бит әле. Ярар, күп эзләнә торгач, анысы да җайланды. Иске янгын сараеннан әмәлләнгән бер бүлмәле, бәләкәй генә кухняле коммуналь квартир кисәген таптым. Ленинградка күчүче бер инженер аны миңа итәк астыннан гына өч меңгә сылап китте. Дус-ишләргә муеннан бурычка батарга туры килде. Нишлисең, — кирәк, чөнки зифа буе үзгәрә башлады Рәшидәнең...

Озакламый кыз балабыз туды. Икебез дә эшлибез, бала караучы табарга кирәк булды. Авылдан килгән бер әйбәт кенә кыз алдык. Куыш бәләкәй булса да, сыябыз инде шунда...

Мин сугышка киткәндә икенче балабыз туды, анысы малай булып чыкты. Исән-сау күрешүләр теләп, фронтка китеп бардым. Озатканда Рәшидә күз яше күрсәтмәде. «Маладис икән, кайгысын йота белде», — дип куйдым үземә генә...

Сугышта ниләр күргәнне сөйләп торуның кирәге юктыр. Башкалар сугышканда мин дә сугыштым, сыбызгы пулеләр күрми узды. Инде томан артларында калган тиле яшьлектә комсомолдан колак какканыма һаман үкенеп йөри идем.

— Син, Шәфигуллин, нигә партиягә кермисең? — диде бер көнне политрук.— Взводың башкалардан ким сугышмый, егетләрең — лачын, үз түшләрең дә буш түгел.

— Алмассыз бит, — дидем. Теге вакытта нәрсә өчен очырганнарын сөйләп бирдем.

— Яз гариза, менә сиңа анкета, — диде ул планшетыннан кәгазь чыгарып.

Иртәгесен немецләрнең контратакасын кайтарып, Двина аръягына кудык, калдырган блиндажлары бик тә шәп иде. Үр кырыена гел ак каеннан гына корганнар, урындыкларына хәтле каен ботакларыннан

ясалган, дача корганнармыни Двина ярына! Шундагы җыелышта карадылар минем гаризаны, кандидат итеп алдылар. Ә инде өч айдан соң сул як түш кесәсенә кызыл тышлы билет та кереп ятты. Мактану түгел бу, әле сүз иярә сүз чыккач кына...

Мактанудан бигрәк, сабыйларча сөенеп, үземне бик бәхетле кеше санап йөри идем мин. Ник дисәң — чөнки! Үзем инде дүртенче ел сугышта йөрим, үземне әле сукыр черки дә тешләп узганы юк, аллага шөкер. Атна саен диярлек өйдән хат килеп тора. «Үзебез исән-сау, балалар үсә, сагынабыз», — дигән сүзләр була анда. Ул хатларны укыгач, суык окоп төбенә кояш җылысы ингәндәй була. Җә, кем әйтер мине бәхетле түгел дип? Шуның өстенә, мин бит әле сугышны сержанттан башлаган кеше идем, ә хәзер: «Иптәш гвардия капитаны»,— дип эндәшәләр.

Менә шулай борынны шактый киереп йөргән көннәрнең берендә кинәт кенә тез астына тагын китереп суктылар минем. Аяклар кылдый-былдый килеп куйды, көпә-көндез күзләрдән очкын чәчрәде. Әйтерсең фриц сиздерми генә елышып, арт яктан хәнҗәр кадады йөрәккә. Казаннан җибәрелгән имзасыз хат иде бу...

«...Балаларың ачлы-туклы интегә, ә хатының бик күңелле яши. Сәламдәшләре күп... Калганын үзең аңларсың... Яраланып кайткан дусларыңның берсе...»

Өзгәләнүнең чиге булмады. Барысына да ышанып, ут йотып, төнкөн уйланып йөри торгач, гүләйт итә торган хатын да, зар җылап яткан балалар да кино булып күз алдында күренә башлады. Дөньяда торасы килми, үлем эзлим. НПда булырга тиешлекне «онытып», сугышның иң әшәке котырган җиренә барып керәм. Рота егетләре минем арттан ташлана, арысландай сугышып, дошманны үз җирендә һаман кысрыклый баралар. Сәер килеп чыга: мин үлем эзлим, ә егетләрем батырлык күрсәтә!

Чөй өстенә тукмак дигәндәй, атна саен килеп торган хатлар да киселде бит. Инде ике ай була бугай, өйдән һичбер хәбәр юк. Әллә чынлап та чынмы бу каһәр төшкере ялган хат?..

Сугыш беткәнгә ничәмә еллар бит инде, ә мин һаман аңламыйм әле андый хат язучыларны! Ник кирәк булды икән ул хатлар солдат өчен! Нинди «изге» максат белән яздылар икән? Куллары кормады микән ул бәндәләрнең?..

Ичмаса, үлеп тә булмады бит! Түзмәдем, тоттым да мин ул хатны, яңа конверт эченә тыгып, Рәшидәгә җибәрдем. Үземнән бер авыз сүз дә язмадым, кул бармады, күңел кушмады...

Озак көттермәде ул.

«Һи, җаным, ышанасыңмы син шушы ялганга? Бу бит ниндидер кара эчле көнчеләнең минем өскә яла ягуы гына. Бер иптәшең кереп чыккан иде безгә, күзләрен бик майландырып кына сөйләнгәләп утырган иде. Якты чырай тапмагач, бәлки шул язгандыр. Ышанма дошманга! Синдәй арысланымны алыштыраммы соң мин разный тыл күселәренә!..»

Бу сүзләр йөрәктәге бөтен кара канны юды да ташлады. Яңадан мин кырык канатлы лачын!

Лачынын лачын, ә шушы хаттан соң башка хәбәр килмәде. Ихтимал, без һаман алга баргач, кайдадыр адашып калган булуы мөмкин, дип уйладым ул хатларны. Сугышның озакламый бетәчәге дә ачык инде хәзер. Кырык бишнең язы килеп җитте, без — Кенигсберг төбәгендә. Ә башка юнәлешләрдә Берлинга якынлашып килә безнекеләр. Шулай булгач, хат юклыгына артык борчылмаска булдым, кайткач барысы да аңлашылыр...

Апрельнең бишләре тирәсендә микән, Кенигсбергка актык һөҗүм башладык. Немецның миңа дигән минасы да калган икән әле. Соңын-

нан белүемчә, иптәшләр мине казып алганнар. Ә беренче тапкыр аңга килеп күзләрне ачканда, бөтен җирем ак бинт белән уралган иде, гәүдәне кыймылдата алмыйм, тик баш кына төрле якка борылгалый. Беренче сөенеч: баш исән икән әле!

Тора-бара уң аяк белән сул кулның да хәрәкәтләнә алуын аңладым. Уң кул белән сул аякның гына хәлләре мөшкел икән... Сугыш бетеп, дөнья тынып калганы турында да көн-төн эшләгән радиолар хәбәр итте. Ә миңа әле озак, бик озак ятарга кирәк икәнлеге дә мәгълүм булды хәзер. Хәлне аңлатып, өйгә кыска гына хат сызгаларга туры килде. Җавап булмады. Хәзер инде фронтка бара торган хатларның бомбежкада чәчелеп, җилгә очуы да мөмкин түгел иде...

— Түз, гвардии майор! — диде Ихсанга. Миңа ул исемне полк командиры килеп хәбәр итте, түшкә I Дәрәҗә Дан ордены беркетте. Кенигсберг өчен икәнен әйтте. Батальондагы иптәшләр дә килә торды. Һәммәсенең авызында бер сүз: бүген-иртәгә приказ көтәләр — тизрәк, тизрәк өйгә!..

Ә мин, кирәге калмаган ватык-җимерек сөякләрне кистереп атып, менә бу «запчастьләр»не киярлек булганчы ремонтта яттым. Кырык алтының җәен җиткергәч кенә өйгә кайтып кердем. Өйдә бала караучы кызыбыз утыра. Исеме Җәмилә иде аның. Янында гимнастеркалы, ияге җөйле бер егет утыра. Ул да сугыштан кайткан кеше булса кирәк. Бүлмәгә күз йөгертеп чыктым, әллә ни үзгәреш сизмим.

— Апаң кайда соң, балалар кайда?— дип сорыйм.

— И абый...— диде кыз, коелып иңгәндәй булып. Озак кына сүзсез торды. — Ул бит... ни... — дип куйды аннары. — Китте... Синең каты яралану хәбәрең килгәч китте... «Ул имгәк кемгә кирәк инде, ичмаса, үлмәгән дә...»— дип, күз яшьләрен сөрткәләп йөрде дә, бер лютчик белән китеп барды... Язу ясатып бирде дә балаларны детдомга тапшырырга кушты миңа...

Калган сүзләрен ишетә алмадым мин аның. Лап итеп идәнгә каплануым гына хәтердә. Төнлә мине «ашыгыч ярдәм» белән алып киткәннәр. Шифаханәдә унбиш көн ятып өйгә кайттым. Җәмилә әйбер-сәйберен төйнәп куйган иде.

— Абый, бу минем иптәшем Гайнан, таныш булыгыз,— диде ул.— Аллага шөкер, сугыштан исән-сау әйләнеп кайтты, хәзер без тормыш кордык, Яңа бистәдән бер куыш та таптык, шунда китәбез инде. Сиңа бик күп рәхмәт, абый. — Балаларны тапшырган язу — камод тартмасында. Бик матур булып үсәләрие, бәбекәйләрем...

Бу сүзләрне ул, миңа күтәрелеп карамыйча гына, кабыл-тибел тезеп чыкты да әйберләренә тотынды. Әйтерсең мин югында булган хәлләрнең бөтенесенә дә ул гаепле иде... Гайнаны икенче төенчекне күтәргәч, тын гына чыгып киттеләр.

Өнме бу, әшәке төшме — белмим. Күзләр югары почмакка текәлгән, анда һични күренми, эзләмим дә. Кузгалырга да курыккандай утыра бирәм буш, шыксыз, ташландык өйдә... Башта да шундый ук бушлык. Бер-беренә ялганган бер генә уй да юк. Мондый хәлдә әдәм баласының ниләр кичергәнен үзегез дә шәйлисездер, сузмыйм.

Ике көн чын диванага сабышып, өйдән чыкмый уздырганнан соң, өченче иртәдә сискәнеп киттем: «Балаларың!» дигән тавыш ишетелде. Сикереп тордым да, әрҗәдәге кәгазьләрен табып, мәгариф бүлегенә юнәлдем. Эзли-тикшерә торгач, ул детдомның Сарташ дигән авылга күчерелүен әйттеләр. Ерак районлагы ул авылны эзләп таптым. Балаларым мине танымый. Мин киткәндә кызым ике ярым яшьтә иде — оныткан. Ә малай ике айлык та булмагандыр. Каршымда басып торалар, икесе дә минем төсле. Күчтәнәчләр, тәтиләр биргән булдым, «Сапасибо» диделәр, ә яныма килеп кочагыма кермиләр — ятсыналар. Моннан да авыр нәрсә бармы икән дөньяда? Шулай да кочагыма кысып, сөеп,

үбеп карадым. Кулымнан котылу белән читкә йөгерешеп киттеләр... Тимердәй түзем күңелле булсаң да алар янында артык тору мөмкин түгел иде. Олы яшьтәге мөдирә апага үз хәлләремне кыскача аңлаттым да, хәзергә шушында яшәп торуларын үтенеп, озакламый кабат килермен дип, Казанга кайттым.

Мәгариф бүлеге, минем «запчәстләр»не искә алып, күрше урамдагы әйбәт кенә китапханәгә мөдир итеп билгеләде. «Йөрергә якын булыр, эше дә мәшәкатьле түгел»,— диделәр.

Кышмырдый бирәм, хәрәкәтләнгән булам. Яшәүме бу, юкмы — белмим. Үзләрен күреп кайткач, балалар да бөтенләй күз алдыннан китми хәзер. Нишләтергә соң аларны? Өйгә алып кайтсам, тәрбияли алырмынмы? Берсенә — җиде, берсенә — биш, бигрәк тә бәләкәйләр ич. Эшкә, анда-монда чабарсың, кем янында калырлар? Өйләнү турында сүз булуы мөмкин түгел, хатын-кыз дигән җенеснe күрәсем дә килми. Шулай да мин аларны Дербышкидагы балалар йортына күчертүгә ирештем. Җайлы булып китте: буш арам булу белән алар янына чабам. Әкренләп иялəшә башладылар. Иң элек малай килеп сыенды, ир заты шул! Аннан күрмәкче кызның да кыргыйлыгы кими төште, күңел дигәнең канатланып киткәндәй булды.

Ярар, яшим мин шулай өнесенә поскан яралы аю шикелле. Кеше белән дә артык аралашмыйм, дус-иш тә юк. Чөнки тегеләй дә-болай төпченә башлыйлар, җәлләгән булып саруны кайнаталар. Үземнеке үземә болай да җиткән... Көн саен баштан чыкмый торган төп кайгы— әнә шул ике кечкенә. Нишләтергә шуларны? Сугыштан ничектер үзгәребрәк кайтканмын, ахры. Элек бала-чагага артык ис китми иде минем. Кайда ташлап калдырсам, шунда кала бирделәр. Олылары өчен артык хәсрәтләнмим дә — әниләре бар, исән үсәләр, ким-хур булмаслар. Ә менә бу ике бәләкәйне нигәдер үз янымa теркисе килә. Карар кеше тапсам, өйгә алыр идем, алар хәзер миңа иялəнеп беттеләр дияргә ярый. Үзләре белән бер чөкердәшеп утыру да — җан рәхәте.

— Әти, китмә инде,— дип җылап калалар, яннарына баргач...

Олы кыз Авангардияне эзләп табарга булдым. Күрәсез, кайчандыр ташлап калдырган бала кирәк була башлады хәзер! Аны табып монда китерсәм, кечкентәйләрне өйгә алырга җайлырак булыр иде. Барып чыкмады ул ният. Кызга егерме яшь тулып узганын сизми дә калганмын. Ул кияүгә чыгып, иптәше белән яшьлек юлыннан ерак Төньякка төшеп киткән хәбәре генә килде. «Кабул булмаган ураза күктә асылынып калыр икән», ди торган иде безнең Гөлзифа әби. Кайчакта шул күз алдына килә: капчык-капчык ураза парашут шикелле күктә йөзә, бар да ак бәздән тегелгән. Бер уйлаганда, бу ходай тәгалә дигәннәре шактый бюрократ булган булса кирәк: бирәүләр ай буе ачка интегә-интегә тотып, капчык-капчык ураза җибәрәләр, ә ул тилкенләй генә кабул итми, сайлаган була: монысы ярый, монысы ярамый, имеш! Минем изге ният тә шулай күктә асылынып калды...

Шулай тинтерәп йөргән көннәрнең берендә хат килеп төште. Конвертына күз йөгертәм — Назикәдән! Ах, алла! Монысы ни тагы? Ачтым, укыйм:

«Синең сугыштан исән калуыңны күптән түгел генә ишетеп, бик сөендек. Ничәмә еллар буена бер хәбәрең дә булмагач, ул инде фронттан кайта алмагандыр, дип уйлый идем. Улыма да шулай аңлатып килдем. Малаең озакламый унны бетерә. «Казан университетына китәм, әти янына!»— дип җилкенә. Белсәң иде, ул ничек ярата, ничек сагына сине! Элек әтисе исән булмауга моңаеп йөри иде, ә хәзер башы күккә тиде, тулып-матурланып, горурланып китте. Төннәр буе әтисе хакында сөйләтә миннән... Җаның бармы синең? Ник бер авыз сүз язмыйсың? Беләм, хәлләреңне сөйләделәр миңа, барын да беләм диярга ярый. Бәлки шуңа гарьләнә торгансыңдыр, кыендыр сиңа...

Ә син бирешмә. «Агач башыннан йөрми...»— диләр түгелме, дөнья булгач, ни булмас?

Ялга чыккач, үзебезгә кил, тормышыбыз ярыйсы гына, күңелебез киң!..»

Хатны куяга тоткан килеш тораташтай җансыз калдым. Аннары бөкшәеп, бөкрәеп төштем, хәл китеп урындыкка чүмәштем. Баш түшкә салынган, күзләр — идәндә. Теләсәң, үз әшәкелегеңнән егыл да үл, теләсәң — сөенечтән күкләргә оч. Сәер минем хәлләр: берсен мин әзлим, икенчесе мине әзли, тагын икесе Дербышкида көтеп тора. Дүрт бала атасы булганмын! Ә рәтле-башлы тормыш корып яшәгән дә юк...

Сагына дигән. Әлеге «шикле малай» сагына икән мине... Ул бит белми, төсмерли дә алмый әтисен, бишектәге өч-дүрт айлык бала нәргә хәтерләсен? Үсмер чакның зәңгәр хыялларына урап, әллә нинди шәп батыр кыяфәтләрдә күрәдер ул ата булган кешене...

«Эх син, Ихсан!— дидем үземә шул чакта.— Этнең дә әшәкесе бит син, азгыны, иясезе, яхшылыкны белми торганы,— дип пышылдадым колакка гына.— Юк, тары бөртегедәй дә акыл заты кермәде сиңа, дустым,— дидем иплән кенә.— Үзең дә оя кора белмәдең, бүтәннәрне дә бәхетсез иттең...»

Үземне шулай тавыктай пешекли-пешекли йолкып ташлагач, Назикәгә сәлам хат яздым. Сүзләр сәлам гына булып чыкты. «Мәлҗерәмә!» дип кычкыра тордым үземә. Бу соңгы елларда күргән-кичергәннәр, җан газаплары ычкынып, агылып китәргә бик ашкынсалар да, муенын борып калдым хисләрнең. Алар мәңге ачылмаска бикләнгән чуен йозаклы чуен сондыкта хәзер. Юк, хәзер генә түгел, госпитальдән үк...

Шул ук сәлам сүзләр белән малайга уңыш теләдем укуларында. Ник алай иттем? Белмим. Дөньяга сулагай кулны селтәп яши башлаганнан килгәндер инде...

Мин, әлбәттә, Назикә янына бармадым. Авызы пешкән, чабатасы янган шәп егетләр бик гарьчел дә, тәкәббер дә була, диләр, мин дә шулай булып чыктым. Малайны бик күрәсем килсә дә, ни битем белән барып керим мин анда?.. Шулай да, кулдан килгәнчә, әз-мәз акча җибәргәли башладым. Без бит алиментлашмаган...

Тагын байтак вакытлар узып китте. Балаларны өйгә алдым хәзер, шунсыз булмый. Үзләре дә бик теләде, ни дисәң дә туган өй бит. Кыз икенчене бетерә, малай — беренчене. Яше җиткәнче үк үрмәләде ул парта арасына. Маташкан булабыз шунда көн итеп. Кичләрен бергә чөкертәшәбез, хәтта миңа да күңелле булып киткән сыман тоела, ә балаларны инде әйткән дә юк, тәгәрәшеп туймыйлар... Тик кызым гына нигәдер боеграк күренгәли. Нигәдер түгел инде, әнисен юксына ул. Былтыр ук детдомның бер почмагына алып китте дә мине, пышылдап кына сорады:

— Әти, кайда безнең әниебез? Ник бер дә килми икән ул?..

Энесеннән дә яшерен сүзе иде бу аның. Малайның алай борчылганы сизелми, онытып өлгергәндер, күрәсең. Ә кызга туры җавап бирү бик кыен иде. Юатырдай әйбәт ялган табу җиңел түгел икән мондый очракта.

— Андый сораулар белән баш ватма, кызым, борчыма үзеңне,— дидем.— Кайда икәнен үзем дә белмим шул. Мин кайтканчы юкка чыккан бит... Берәр җирдә тиф-фәлән авыруы белән үлеп киткәндер ул, тере булса, түзмәс иде... Сугыш еллары бик авыр булды ич...

Үлгәнлегенә бик ышандырасым килеп әйттем. Эзләү, табу өмете белән яшәмәсен, әкренләп онытсын, күңел ярасы төзәлсен, дип уйладым. Андый ана кайсы балага кирәк? Бәлки мин ялгыш иткәнмендер. Әмма нишлим? Ничек тә булса чыгару кирәк иде бит аны бала күңеленнән!..

Ә жәй урталары тирәсендә әйтеп әдәм ышанмаслык, күргән күзләреңә ышанмаслык хәлләр була башлады өйдә. Бөтен җир бездә булмаганча бик тәртипле итеп җыештырылган, тәрәзәләр яп-якты, идәннәр сап-сары итеп юылган, почмаклардагы пәрәвез ояплары юкка чыккан, ишек төпләренә чиста чүпрәкләр салынган мин кайтып кергә. Шаккаткан хәлдә карап торам. Дөрес, кыз да маташтыргалый иде мондыйларны, ләкин бу аның кулы түгел. Балалар үзләре өйдә юк. Үгез башы кимерердәй булып ачыккан идем, алар да ачтыр дип, кухняга уздым. Аш салырга кирәк. Без аны өчәүләп пешерәбез. Мин керогазга ут кабызып, су куям, ит кисәге салам, тегеләр бәрәңге әрчи, ярма юа, суган турый. Бар да минем команда белән бара. Җәмәгать тукланыуы буенча яшь кадрлар хәзерләүче баш повар-гвардии майор Ихсан. Ә бүген — керогаз өстендә кәстрүлдә кайнар аш тора! Гаҗәп хәл, кыз шулай үсеп тә җитте микәнни соң? Сизми дә калдым бит...

Өлгергән ашының эчләрне кытыклый торган тәмле исе аягыннан егардай итте ач бүрене. Кәстрүлнең яртысын сыпырдым да куйдым!

Кыз белән малай кичке кояш батып барганда гына кайтып керде, алардан сорыйм.

— Бер апа килде безгә,— ди кыз.— Шул эшләп китте.

— Кем соң ул, исеме ничек, ни йомыш белән йөри? — дип әллә ничә төрле сорау бирсәм дә, артык нәрсә белә алмадым. Исемен дә сорамаганнар, ичмаса. Бала-чага шул.

— Ә ул «апа» дигәнегез әллә ниткән яман кеше булса? Өйдәге юкбар нәрсәгезгә кызыкса? — дидем.

— Ю-у-ук, бик әйбәт апа ул, безне бик яратты, — диештеләр болар икесе беравыздан.

— Тагын киләм, дип әйтмәдеме соң?

— Юк, әйтмәде, — диләр.

Сәер хәл иде бу. Шундый яхшы ният белән генә йөрсә, рәхмәттән башка сүз юк, әлбәттә. Әмма кемнең кем икәнен каян беләсең? Казан бит бу. Шулай да, сагаю зыян итмәс. Хәрби киемнәр яңа бит әле минем. Аларны заем облигацияләре белән бергә еракарак тыктым да, бикләп алдым. Калганы иске-москы...

Искечә әйткәндә, бу «гаиб кунак» [1] атнасына ике-өч тапкыр шулай килгәләвендә булды. Балалар мине күргә: «Һәүзи апа килде, Һәүзи апа!» дип кычкыра башлады. Ул көннәрдә мин бик тәмле итеп пешерелгән аш ашый идем. Тора-бара безнең керләр дә юылып, үтүкләнеп, тәртип белән комодка салына торган булды.

Баштарак баш ваттым:

«Һәүзи... Һәүзи... Һәүзи?..»

«Кем икән соң бу дим? Нинди табышмак апа? Кайсы әкияттән килеп чыккан «йорт анасы»? Әллә күршеләрдән берәрсе юрамалый шундый бала-чага уены маташтырамы? Әллә кызымның иптәш кызлары шулай булышамы? Һични аңламыйм. Артык төпченәсе дә килми. Әйдә, бу дөньяның шундый рәхмәт яуган изге бәндәләре бар икән — яшь бирсеннәр, күрсәтә бирсеннәр игелекләрен! Түләүсез-нисез өй караучы булды бит әле!» — дип йөрим эчтән генә.

Балалар да гел шуның хакында гына сөйли хәзер: кызны чәчен тарап үрергә, оек тишекләрен ямарга өйрәтә икән. Малайның да шалкан чәчәрдәй булган колак эчләрен юып чыгарган. Икесенә дә җырлар өйрәтә, кызыклы китаплар китереп укыта, имеш. Менә гаҗәп!

Иң гаҗәбе шул: кыз әнисен юксынып моңаймый хәзер, малай да канатланып киткәндәй күренә. Мин генә артык ис китмичә йөри бирәм. Ачыклап маташирга вакыт та тими. Ә соңга таба малай белән

[1] Гаиб кунак — юктан бар булган, көтелмәгән кунак, яшерен.

кыз мин эштән кайтканда өйдә дә булмый башлады, кич кенә кайтып керәләр. Сорасам, «Һәүзи апаларда булдык», диләр.

Мәгәр бу дөньяның яшерен серләре мәңгелек түгел, күрәсең. Айга да барып кайттылар бит инде. Һичбер уйламаган-көтмәгәндә генә минем иске янгын сараендагы «яшерен сер» дә ачылып куймасынмы бер көнне. Сайлаулар алды иде. Горкомда буласы киңәшмәгә телефон белән генә чакырып куйдылар. Партбилетны гел кесәдә йөртеп булмый ич, барышлый шуны алып чыгарга дип өйгә сугылдым. Ни күрим: эчке күлмәктән генә калган бер хатын бөкрәеп идән юа, аның янында мунчала тоткан минем кыз басып тора, ул да эчке күлмәктән генә.

— Ай алла! — дип кычкырды тегесе һәм яшен тизлегендә кухняга качты.

Үзем дә каушап калдым. «Гафу итегез» дип, өстәл тартмасыннан тиз генә партбилетны алдым да, кухняга качучыны күзәтергә кыймыйча чыгып киттем. Кабалана-кабалана атлыйм, ә кая кабаланганны онытканмын. Ник дисәгез, шуның өчен: теге хатын шулай да минем күзгә таныш сыман булып чалынды.

«Юк, булмас, каян килсен ул монда?..»

«Шул инде, шул!»

Үз-үзем белән бәхәсләшеп бара торгач, трамвай тукталышын узып киткәнмен. Тукта, кая барам соң әле мин? Ә-ә, горкомга иде бит... Кире әйләнеп килеп, трамвайга утырдым. Юлда да, киңәшмәдә дә шуның белән баш ваттым.

Ике сәгатьтән соң кайтып керсәм, шаклар да каттым: чынлап та таныш кеше булып чыкты ул — Назикә! Китмәгән, балалар белән өстәл артында китап укып утыралар. Ничек болай соң әле бу? Һични аңламыйм. Күрештек. Минем шыгыр-шагыр килә торган «запчәст»ләргә аның бер дә исе китмәде шикелле. Әйтерсең әллә кайчан күргән, белгән...

— Шушымыни инде ул «Һәүзи» апагыз? — дим.

Малай да, кыз да: «Шушы, шушы!» — дип йөгерешеп килде дә, минем каршыга баскан Назикәгә сарылды. Бер дә тартынусыз, үз итеп сарылдылар алар. Шулай да мин моңа сыгылып төшмәдем. Дөресен генә әйткәндә, аның эше ошамый да, аңлашылмый да иде миңа. Нигә андый «кызык» лар ясап йөрергә?..

Билгеле, бүген дә аш әзер иде. Өстәл әйләнәсендә дүрт кеше түгәрәкләнеп, эшкә керештек. Тамак туйгач малай урам ягын каерды, кухняда апасы тирәсендә маташкан кыз да, чышын-пышын килеп, малай артыннан сызды. Сүз берләшеп куйганнар шикелле тоелды. Икәү генә калдык. Кабарган мыекны бөтереп, бастырып куярга тырышам. Ә телне бастырырга бастырык та ярдәм итмәс иде булып чыкты:

— Нигә соң син, кәмит уйнап йөргәнче, туп-туры гына килеп кермәдең? — дидем мин кырку гына итеп.

— Туп-турымы? — дип елмайды Назикә. Күптәнге, бик күптәнге һәм бик таныш булган йомшак кына елмаю иде бу.

— Куып чыгарыр дип курыктым.

Мин дә елмайган сымандай итеп куйдым.

— Ә болай, табышмак «Һәүзи апа» булып, экиятләрдәге «йорт иясе» булып, яки «игелекле фирештә» сыйфатларына кереп, безнең чүпрәкләрне юучы, аш пешерүче, «түләүсез техничкага» әйләнеп маташулар нигә кирәк? — дидем аннары. — Мине үзеңә бору өченме? Юк, барыбер исәбем юк борылырга! Чөнки бөтен хатын-кыз бериш, ике тиенлек тә ышанычым калмады берегезгә дә.

Назикә миңа озак кына карап торды. Елмаюы сүнсә дә, йөзенә үпкә билгеләре чыгармады, гарьләнү эзе дә сизелмәде.

— Их, дустым! — диде ул аннары. — Син һәр вакыт киресен генә уйларга яратасың, һәр нәрсәнең ямьсез ягын гына күрәсең шикелле... Эш чүпрәкләрдәмени соң?.. Беренчесендә туп-туры килүем иде, өйдә булмадың. Балаларың белән сөйләшә киттек. Күрәм, күңелләре салпы, моңаешып утыралар. Өс-башлары да бик үк чистадан түгел, ертык-тишекләре дә күренгәли, табак-савытлары да юылмаган, бүлмәләре дә ни... шыксызрак... Нидер бик кирәкле нәрсә житми иде аларга. Гомернең күп өлеше балалар арасында узгач, мондый хәлләр таныш миңа. Ана жылысы житми аларга! Өендә шул жылыны тапмаган бала урамга чыга, бөтенләй башка юллардан китеп бара. Ә бит жылыны баланың аркасыннан сөйгән булу, кулына канфет тоттыру белән генә биреп булмый. Юк, ул жылыны анадан башка берәү дә бирә алмый балага. Ә күп кенә педагог, әгәр теләсә, шулай да баланың якын дусты, киңәшчесе, хәтта сердәше була ала. Шуның белән ана әзме-күпме жылы биреп, күңеленә туңа башлаган бозны эретә. Хәсрәтләре юылып киткәндәй була баланың...

«Лекция!» — дип кычкырмакчы булдым, ләкин тыелып калдым. Чөнки бу сүзләрдә нииндидер орлык бар иде, хакыйкать орлыгы шикелле тоелды ул миңа.

— Алайса, нигә ул «Һәүзи апа?» — дип кенә сорадым.

— Анысы да синең тәртә кыскалыктан, — дип көлемсерәде Назикә. — Белсә, балаларына юл куймас дигән шик килде күңелгә. Ә икенче килүемдә: «Исемегез ничек, апа?» — дип сорады кызың. Фәүзия апа дип әйтерсең, дим. Ә малаең: «Һәүзи апа?» — дип кабат сорады. «Әйе, Һәүзи апа»,— дидем. Балалар «серлелек» не ярата ич!..

Үзе рәхәтләнеп көлә Назикә. Минем генә көләсе килми. Һаман «эт күмелгән жир» не эзлим. «Аның болай йөрүләре мине аулар өчен генә» дип уйлыйм. Ауласа, кем соң мин? Нинди укаларымны коюдан куркам? Курыкмыйм, тик йөрәккә кан сауган!

Тагын допросларга тотынам тегене:

— Ә нишләп син Казанда соң әле? Малай кайда? — дим.

— Мин сиңа язган идем бугай... — диде Назикә сабыр гына сыман тавыш белән. Аннары әллә ниләр сөйләп китәргә жыенган кешедәй, байтак кына сүзсез торды, өстәлгә таянган ике кулы өстенә иягең куйды, күзләрен йомгалады, керфекләре дерелдәгәне сизелде, яшь күрсәтмәс өчен тырыша иде ул. «Эченә тулганнарны чыгарып селкә инде бу хәзер», дип көттем. Ә ул, ниһаять, үзен кулга алды булса кирәк, тирән итеп бер сулады да:

— Мин кыштан бирле үк Казанда инде... — дип кенә куйды.

— Кыштан ук?! — дидем мин чәчләр үрә торгандай булып.

— Әйе, кыштан ук, — дип кабатлады Назикә. — Айдарың да синең күк ич, суйган да каплаган. Көн-төн китап кимерде дә, үзсүзләнеп Казанга китте, кабул итү имтиханнарын кирәгенчә биреп тә кайтты... Миңа нишләргә калды соң! Ике бөртек кенә була торып та аеры-чоеры яшәргәме?.. Хәзер ул икенче курста...

— Ник соң ул минем янга килми, ник күренми? — дим.

— Мин кушмадым. Сабыр ит, дидем. Башта үзем беләсем килде синең хәлләрне... Ә малаең мин кушканны көтеп тормаган, күргән ул сине, хәтта китапханәңә барып, нииндидер китап алган. Аннары Тугызынчы май көнне бакчада күргән. Таный алмаслык горур булып кайтты өйгә. Айдарың бик нечкә күңелле, сагышлы бала булып үсте. Ул кылларның әз генә саксыз кагылуга да зеңләп өзелүләре бик мөмкин иде... Үзең уйлап кара, туганнан бирле дип әйтик, ата күрмәгән малай бит ул. Башта, әтиең хәрби хезмәттә командир, тиз генә кайтмаячак, дип алдадылар аны. Аннары, сугышта дип, аннары, үлде дип ышандырдылар. Сугыштан соң, елдан артык узып та, синең хакта, озын колактан гына булса да, һичнн беленмәгәч, мин үзем дә

сине үлгән дип йөри идем... Кинәт шушы хәбәр. Минем авыздан да түгел, Казаннан килгән, сине белгән кеше авызыннан... Бу хәбәр Айдарның бөтен дөньясын әйләндерде дә салды. Үлгән дип ышанганнан соң синең хакта сүз кузгатканы юк иде. Ә бу хәбәрне ишеткәч, көн саен: «Сөйлә дә сөйлә!» Ә мин нәрсә сөйлим соң? Санап санына чыга алмаслык йокысыз төннәрнеме? «Күз яшьләрем күл булыр...» дигән җырда да хакыйкать барлыгынмы? Хәтта әйбәт кешеләр сораганда да ул баланы үги аталы итә алмаганымнымы?..

Хәер, болар бары да әкренләп сүрелә-сүрелә еракларда югалып бара иде инде. Күңел кичке күл өсте шикелле тынып калган иде. Ләкин... алай ук булмаган икән шул. Айдарның гына тын дөньясын давыл кочагына ташламадың син!..

Сабыр гына баш калкытып, күзләрен миңа таба борды ул. Кинәт бу күзләрдә бик күптәнге таң нуры балкып киткәндәй булды. Тетрәнгән гәүдәм буйлап ут йөгерде, үземне кая куярга белмәстәй хәлдә калдым. Әллә кайчан онытылган тиле яшьлек кинәт күз алдымнан кичте. „Назикә!" дип, кычкырып җибәрә яздым. Ярый әле, үземне авызлыклап өлгердем, юкса, бөтенләй җебеп төшкән булыр идем.

— Бик матур сөйлисең,— дип көлгән булдым аннары. Бөтен үкенечләр, әрнүләр тилереп аягүрә басты. Гомернең бөтен ямьсез яклары калкып чыкты. Бөтен дөньясына кул селтәвем тагын да дөресрәк булып күренде...

— Агач аяк, агач кул, калдык-постык гәүдәсендә йөз ямау — кемгә кирәге булыр икән ул бәндәнең? — дип, каш җыердым.

Назикәнең йөзе кырысланды, күзләрен очлайтып миңа карады: хәтере калганлыгы күренеп тора иде.

— Мескенләнмә, Ихсан дустым,— диде ул.— Беләм мин сине, юри генә кыланасың. „Бәндә" ләр синең төсле булмый. Әгәр мине ачык сүзгә мәҗбүр итәсең икән, әйтим алайса: Айдар улыңа ата кирәк. Студентлык яшенә җиткәнче сыңар канат белән генә үскән балага икенче канат — ата кирәк. Ул атаның дөньяны читтән генә күзәтеп тормыйча, утны-суны үзе ерып чыккан булуы аңа нинди омтылышлар бирәчәген аңлыйсыңмы син?.. Ул гына да түгел: мондагы сабыйларыңа мин кирәк! Ана була алмасам да, дус була алырмын мин аларга. Ул ике сабыйның да бәхетле кешеләр булып үсүенә синең белән мин җаваплы түгелмени?.. Әйткәч әйтим, хәзер элекке кыюсыз, юаш Назикә юк инде: син минем үземә дә кирәк! Башка бер генә кадерле кешем дә булмады минем...

Җавап бирергә өлгермәдем, балалар кайтып керде. Назикә безгә кичке чәйне әзерләп эчертте дә, балаларга: «Тегеләй итәрсез, болай итәрсез»,— дигәләп, өенә китеп барды. Аптырап утырдым: ул инде үзен бу бәләкәй почмакның бөтен язмышын үз өстенә алган тулы бер хуҗа итеп саный кебек тоелды. Чын сыйфатмы бу, тычкан уты гынамы?..

Уйлы башка ут кабар дигән сүз бар бугай. Татлы ял бирә торган йомшак йокы мамыклары көеп бетте, инде икенче төн күзләр йомылганы юк. Як-якка күпме генә әйләнсәң дә, һаман бер сорау: ничек аңларга соң бу Назикәне?.. Юк, аңлый алмыйм, үтер аңлый алмыйм! Башка бер хатын булса, үзен шул хәтле рәнҗеткән әдәмнең җанын йолкып алырлык итеп үч кайтарыр иде. Ул үч ни дәрәҗәдә каты, мәрхәмәтсез булса да, гадел һәм хаклы саналыр иде. Аннары әллә кайчан судка биреп, кешеләр арасында әдәм хуры ясар иде дә шартлатып алимент алыр иде. «Усал ниятле түләмәүче», «балаларын урам чатларына чәчеп йөрүче» дигән әйбәт сүзләр дә бик килешер иде бит миңа карата! Ни таратса — шул батар иде! Ник ул боларның берсен дә эшләмәде икән?.. Малаен атасына дошман итеп тә үстермәгән. Андый хәлләр дә күп ич бу тормышта. Күңелендәге бөтен ачысын баласына

йоттыра бит андый хатын. Атасына дошман булып кына калмый, әнисен дә дошман күрә башлый андый бала...

Юк, аңлый алмыйм, бу хәтле үк киң, олы күңелле булган хатынны әүвәл тапкыр күрәм. Беренчесе, загслы хатыным, озак түзеп тормаган иде: бер-ике тапкыр яндырып-пешереп дигәндәй, әчеле-төчеле хатлар язды да, баласын әнисенә ташлап, кияүгә киткән булып чыкты. Нәкъ минем ише инде! Икенчесе миннән дә барып чыкканрак булды. Ә бу? Бу ник алай түгел икән соң? Барын да белә бит, югыйсә. Минем койрыксыз төлке икәнлекне дә күрә... Малайны үз тәрбиясендә укытыр өчен мең бәла белән квартирын алмашып, сугыш вакытында бәрәңге үстергән җирендә барлыкка килгән җиләк-җимеш бакчасын күршеләренә калдырып, Казанга килгән. Мин югында, качып-посып дигәндәй, бу канатсыз балалар янына килеп, алар күңеленә юл табарга, җилкәләренә канат үстерергә маташып йөрүләре дә бик сәер. Сәер генәме соң, кычкырып көләрлек! Ә бер уйласаң — гыйбрәтле дә!.. «Мин кирәк аларга»,— ди. Дөрес әйтә бит! Әллә туганчук чын тәрбияче, чын ана булып туа торган кызлар да була микән дөньяда?..

Уйлы баш — орлык тулы тубал баш дигән кук, урамга чыксам да, эшкә барсам да, шул тубал авырлыгыннан гел сыгылып йөрим хәзер. Берсенең дә очына чыга алмыйм. Ай-һай, тагын ялгышмаммы, тагын йөрәк яраланып, бөтенләй юлдан язып китмәмме, дигән шикләр бәгырьне кимерә. Нишләргә миңа?.. Назикәнең нияте ачык: шушы икеояны бергә кушып, бер туган итеп үстерергә тели ул. Барып чыгар микән соң бу? Дистәгә якын ел ялгыз яшәп, кыргыйланып бетмәдем микән мин? Күңел түрендәге нәфрәт бозы эрерме? Назикәне ярата алырмынмы?.. Ә ул? Ул да ярата алырмы соң мине? Аның бу нияте ихлас күңелдәнме? Берәр төрле үч кайтарырга гына йөрмиме ул?... Тиле баштан мин салган җәберләр аның йөрәген дә тирән яралаган булса һәм ул яңадан яңарып китсә, бөтен матур хыяллар челпәрәмә килмәсме? Гомергә татуланышмас ике дошман булып әверелмәбезме?

Уйлаган саен бу уйлар — ерып чыга алмаслык карурманга әйләнә икән. Шул карурманда адашып йөри торгач, туган көн килеп житкәнен дә онытып җибәргәнмен. Фронтовой дус Хәбиб шалтыраткач кына искә төште. Хәер, ничәмә ел фронтта йөреп, кайтуыңа тагын шундый хәлләргә дучар булгач, ничек хәтерләп торасың аны. Бишләрдә генә кайтып кердем. Өй буш. Балалар урамдадыр, күрәсең. Мәктәптә болай озак тормаслар иде. Өйдә пошынып ятасы килми. Каядыр барып, туган көнне берәр дус-иш белән әз генә билгеләп утырасы килә. Өскә «чылтыравык тәтиләр» тагылган хәрби кительне кидем, чалбарны алыштырдым, итекне ялтыраттым, башка хәрби картузны элдем дә «Казан» ресторанына юл тотмакчы булдым. Шунда баргач, Хәбибкә шалтыратырмын да әзрәк чөкертәшеп утырсак, шул җитә... дип план кордым.

Ишеккә барып тотынуым булды, тыштан звонок тавышы килде. Ачып җибәрсәм: малай белән кыз, алар артында Назикә белән бер яшь егет. Барысы да чәчәк тоткан, төргәк-төенчек күтәргән, барысының да авызлары ерык. Килеп керделәр дә болар, дүртесе дүрт яктан мине кочаклап алдылар, чәчәк белән күмделәр. Барысы бертавыштан:

— Котлыйбыз, туган көнең белән котлыйбыз, әти!.. — дип кычкырдылар. Баш әйләнеп китте. Каршыма теге егет килеп басты:

— Исәнме, әти! — дип кулны кысып алды, тагын кочаклады, аннары каршымда килеш карап тора башлады. Мин дә аңа карап каттым: үзем буйлык, киң җилкәле егет. Бөтен җире — мин. Хәтта теге вакыттагы «шикле борын» да минеке!

Ул арада Назикә белән кыз табын да өлгерткәннәр. Назикә мине өстәлнең түр ягына утыртты. Айдарны да минем янга урнаштырды. Үзе, ике ягына ике баланы алып, каршыбызга утырды. Шампанский ачуны миңа тапшырдылар...

Ни дип атыйм мин бу хатынны? Каян белгән дә ничек оештырып житкергән? Нинди оста, нинди үткен кылана бит! Астыртын хәйләле куштанлыкмы бу? Берәр кара ниятенә ирешергә телиме? Белмим, мине үз ягына аударып нинди генә файда күрер икән, нәрсә отар икән ул, минем нинди байлыгыма ия булыр икән? Юк, ни төпченеп карасам да, усал ниятен таба алмыйм мин аның.

Күңелдәге кире беткән кәжә мөгезен чайкый, тәрәзәдән тышка сикермәкче була! Шул ук күңелдә яп-якты сөенеч тә туып, тулып китә төсле... Юк, тәрәзә тибеп кача алмадым. Жиңелдем, каравыл кычкыра-кычкыра жиңелдем...

Жиңелсәм дә, мәгәр ышанмадым. Үзем бергә яшим, үзем һаман тыпырчынам, эчтә һаман шик ята, берәр «сере» ачылуын көтәм. Хирург тураклаганнан калган ярым-йорты, калдык-постык «ир заты»-ның ни хажәте бар икән аңа?.. «Юк, моның астында берәр әшәке хәйлә ята торгандыр!..» — дип уйлыйм.

Кай көннәрне юрамалый кашны-күзне жыерган, төсне-битне жимергән суръәттә кайтып керәм, гаеп тапкан булып балаларга бәйләнәм, шул гаугага аны да катыштырмакчы булам. Башта жавабын әйбәтләп кенә бирә дә:

— Карале, матурым, күлмәгеңнең менә бу сәдәбе төшеп калыр хәлгә житкән икән бит синең, кая, истә чакта тагып ташлыйм әле, салып бирсәңче, — ди аннары каршыма басып.

Алып керә кухня якка, салдыра күлмәкне һәм шул чакта кочаклап бер үбеп ала да сәдәпкә тотына. Соңыннан гына аңлап алдым: бу мине дулаудан туктатуның оста бер хәйләсе икән! Ике ай буе сынап, Назикәнең иң зур «кара нияте» шушы булуын ачтым мин. Аннары бер көлештек кычкырып һәм кочаклаштык.

Ихсан абзагызның туган көне менә шундый булып чыкты. Аны бер үк Назикәгә икенче тапкыр өйләндерделәр һәм икенче тапкыр тудырдылар. Һич кенә дә үкенми ул моңа. Аннан да матур, аннан да сөекле хатын юк икән бу дөньяда! Шулай итеп, ышанмасам да кабат жиңелдем, гомерлеккә жиңде ул мине. Юк, мылтык белән атып та түгел, ястык белән дә түгел, яхшылык белән атып екты ул мине!..

Тора-бара дүрт бүлмәле квартир белән дә сыйладылар үзебезне. Юк, борчак сиптерү түгел, дөресе шулай. Чәйгә килегез, юарбыз!

Ә инде балаларга килсәк, Айдар улым Мәскәүдә фәннәр докторы хәзер, кыз — аспирантурада, төпчегем төзү инженеры. Әнә университетның яңа корпусын күрәсезме, шунда эшли. Үзебез — әле житмешне генә узып киткән яшь кенә пионерлар!..

Шактый озакка сузылган бормалы-сырмалы бу хикәядән соң безнең житмешле егетләр һәм кызлар гөжләшеп алдылар.

— Ай-һай, — дип куйды берсе, — китаптан гына төшмәде микән бу хатын? Исеме үк әллә ничек, колакны кытыклый...

— Чынлап та,— дип куәтләде сержант Сәхәби,— әгәр тормышта мондый итеп сөя белә торган кыз булса, мин аңа үземнең Дан орденымны бирер идем, валлаһи, бирер идем!

— Мин дә ышанып бетә алмыйм,— диде Әбүзәр карт.

— Чөнки кайчандыр йөрәкне бик нык яралап узган яшьлек хәлләре әле һаман да онытылып бетмәгән...

Шуннан соң без барыбыз бер авыздан дигәндәй аңа ташландык.

— Яле, я, Әбүзәр дус, селкеп кара сөю капчыгыңны, ниләр коелыр икән аннан?

— Нинди асылкош яралады икән синең йөрәкне? — диештек.

— Сез инде Иблис токымнары, беләм, — диде Әбүзәр. — Рәхәтләнеп авыз ерырга булса, сезгә шул җиткән. Шулай да тел кычытынкырабрак тора торуын... Яшь чакларны искә төшерүнең әллә ни гаебе булмастыр сыман күк тоела...

Ул кесәсеннән «мятный» канфет чыгарып, авызына капты, кайсы көнне кич буе симәнке чирткәләп утыра. Әйтүенчә, тәмәке ташлап азаплана икән.

— Алтмыш кына ел тарткан идем, ташласам, әрәм була инде, — дип, көлдереп тә алган булды. Аннары канфетын бер-ике тапкыр тәмләп кенә суырып куйгач, сүзгә кереште. — Бала-чага күзенә көтмәгәндә генә бер тәти курчак күрсәтсәң, ул шундук гашыйк була аңа һәм даулый башлый. Яшьлегемнең тулып, ташып килгән мизгелендә миңа да шундый бер

## Читлек кошы

күрсәттеләр һәм кинәт кенә гашыйк булды бу егет. Ниндидер ярсу шаян җил бакча башындагы печән чүмәләсенә әллә каян гына очкын ташлап узган шикелле, минем күңел дә күз ачып йомганчы «гөлт!» итеп кабынды да китте. Һич тә көтмәстән, эзләмәстән килеп чыкты бу...

Гашыйк эзләр чак түгел иде әле. Авыл хәбәрчесеннән калкынып газиттә эшли башладым. Аннан мине Мәскәүдәге журналистика институтына җибәрделәр. Менә шуның соңгы курсыннан кышкы каникулга кайткан чак иде.

Якшәмбе көнне урамда карт егет, Карагайлы дигән шагыйрь очрады. Гел төче әйберләр генә яза торган бу кеше нилектәндер мине якын иткән шикелле күренә иде.

— Без бүген Бишбалтада яшь көчләрнең нәни генә мәҗлесен җыябыз, — диде ул бик мәгънәле итеп. — Карт-корыдан берәү дә булмый, гел яшьләр генә иркенләп бер утырмакчы булабыз... Йә, йә, авызыңны ерма, мине карт димәкче буласыңмы? Юк, түгәрәккәем, абзаңа уналты яшьлекләр гыйшык тоталар әле!..

Аннары ул, тагын да серлерәк итеп иелде дә, имән бармагын авыз уртасына китереп, нечкә генә тавыш белән пышылдады: — Кызлар да була... Башка һичкемгә әйтмә... Ә сиңа, беләсеңме, дустым, шундый асыл бер сандугач баласы таптым, күрсәң акылдан язачаксың! Кәнфит инде менә, шикалад кәнфит, суыр да йот!

— Туктале, агай-эне, «миңа кыз тап» дигәнем юк ич минем! — дидем мин үпкәлерәк тавыш белән.

— Димәсәң ни! Мин үзем күреп торам ич, һәйбәт бер кыз кирәк сиңа! Әллә минем хакым юкмы? Мин синең олы абыең. Ә олылар кечеләрнең күңел юанычларын да кайгырта белергә тиеш!

Көлешеп алган булдык. Шулай да мин һаман карыштым, язучы булмавымны да әйттем.

— Беләм, беләм, — диде ул бармак янап. — Ике шигырең чыктымы? Кечерәк булса да бер хикәяң чыктымы? Тагын ни кирәк? Полный язучы инде син хәзер! — Аерылып китә башлагач, кабат өстәп куйды: — Килми калма, кара аны! Аның расхуты пүчтәк: борын башына ун гына сум, акчаң булмаса, үзем түләп тора алам.

Юк, андыйлык кына акча бар иде барын. Ике бишлек чыгарып бирдем дә мәҗлеснең адресын язып алдым.

Сәер иде ул Карагайлы дигән кеше. Үзе кырыктан узып барадыр инде, үзе һаман егет булып йөри, уналты яшьлекләргә гыйшык тоткан була, башкаларны таныштыра, күргән-белгәнгә кыз димли, аларны өйләндерергә тырыша. Аның белән бөтенләй читләшеп тә булмый, чын-

лап ук дуслашып та китә алмыйсың. Аның: «сандугач баласы», «синең өчен генә...» дигән бу сүзләренә дә сагаеп карау, хәтта ышанмау урынлырак булачак. Кулдан-кулга йөреп, шомарып беткән биш тиен акча да, башкаларга караганда матуррак булып, ялтырабрак күренә бит. Бәлки ул да шундый бакыр алтындыр? Аннары, егет кеше үз дигәнен үзе тапмасмы? Ни өчен аңа башкалар кулыннан алырга? Кыз дигәнең — товар түгел ич ул...

Шушындый уйлар белән студентлар ашханәсенә сугылып, тамак туйдырдым да, Черек күл буендагы иптәшем бүлмәсенә кайттым. Эскадронда бергә хезмәт иткән идек, шунда дуслашып киттек. Ачык күңелле, әйбәт егет ул Салих. Булдыклы да үзе. Әнә Казан хәтле Казанда бүлмәле дә булып өлгергән, радиода диктор булып эшли, хезмәте кызыклы. Сөйгән кызы да бар, сөйкемле генә күренә. Ә минем әле үземнән башка бернәрсәм дә һәм беркемем дә юк...

Өс-башны алыштырып, яңадан урамга чыгуга караңгы төшеп тә килә иде инде, кышкы көн — бер карыш дигәннәр бугай. Көмештәй җемҗем иткән балык тәңкәләре төсле җиңел һәм иркә кар яуган гыйнвар киче иде бу. Келт итеп Такташ искә төште. «Сандугачлы таңнар, зур урманнар аның гыйшкын бизи алмады... Күңел язы шаулап үтте аның тәңкә карлар яуган буранда..»

Матур, шайтан алгыры, матур! Әллә нинди гаҗәп шагыйрь бу Такташ. Яратам шуны. Беркемгә дә әйтми, үзем генә сокланып яратам. Нәрсә язса, шунысы күңелдә кала. Бөтен яшьләрнең күзен бәйләп, үзенә табындыра. Әллә нинди мәһабәт йөрәкнең ягымлы җылысы үзенә тарта... Зөбәйдәнең гыйшкы чәчәк аткан кышкы кичләр менә шундый булгандыр инде, күрәсең, дип уйлыйм..

Ерактан ук майсыз арба тавышы белән шыңкырап, трамвай килеп җитте. Халык күп җыелган иде, көчкә генә түбәнге басмачага эләгә алдым. Трамвай тагын калтыр-колтыр кузгалып китте. Бишбалтага хәтле тимер тоткага ябышып барган куллар өши язды. Трамвайдан төшкәндә, тәңкә карлар һаман уйнаклап кына ява, урам утлары аларның юка гына булып җиргә түшәлгәнен, энҗе бөртекләредәй җемелдәтәҗемелдәтә, күзләрне чагылдыра иде. Уңдагы тыкрыкка борылып бераз баргач, өйрәтелгән әлеге йортның номерын таптым. Кыйшаеп беткән агач өй иде бу. Бер якка сөрлеккән шыгырдавык баскычлардан икенче катка күтәрелдем. Гомердә аяк басмаган бу йортка ничек килеп керергә икән?.. Утлы өйалдында яка һәм бүрекләрдәге кар тәңкәләрен каккалый-каккалый, берхәтле уңайсызланып торганнан соң, әллә кайчангы киезләре таланып беткән ишекне кактым.

— Әйдүк, хуш киләсез! — дигән тавыш ишетелде.

Эчкә кергәннән соң да бу йортның иң элек шул искелеге күзгә ташлана икән: түшәмнәре дә түбәдәге балчыкны күтәрә алмагандай, сыгылып төшкән, стена бүрәнәләре дә урам якка таба бүселгән; тәрәзәләре дә, үпкәләгән шикелле, шул таба турсайган; сары буяулы чиста идәннәре дә шунда сөрлеккән. Керми кергән кешегә монда яшәве дә куркынычтыр кебек тоела иде. Әмма хуҗаларның артык исләре китми булса кирәк: бик тере басып йөриләр, хәтта мәҗлес ясарга да рөхсәт биргәннәр.

Эчке яктан инде шау-шулы сүзләр, уен-көлкеле ыгы-зыгылар, мандолина чиертүләр ишетелә иде. Байтак кеше җыелып өлгергән, күрәсең. Ишек буе стенадагы чөйләргә әллә нихәтле кием-салым өелгән. Мин дә шулар өстенә пальтомны эләргә маташканда, түр яктан Карагайлы килеп чыкты.

— Шәп килеп җиттеңме, түгәрәгем? — диде ул куанган тавыш белән. — Менә монда эл, буш чөй бар. — Әйтерсең бу өйнең гомерлек хуҗасы ул, кайда буш чөй барлыгына кадәр белеп тора.

Шул чагында яшьләрнең берничәсе килеп кул бирде.

— Ник әз язасың, шигырьләрең әйбәт күренә ич, — диде кайберсе.
Икенчеләре хикәя язарга димләде.
— Өмет бар синдә! — дигән булдылар.
Мин тирләп төштем, оялам, байтагысын танымыйм да.
Бик ыспай киемле берсе килеп кулын төртте дә:
— Тәхәү Былбылый, — диде. — Минем «Бөдрә былбыл»ны укыдыңмы? — дип сорады.
Ни дип әйтергә белми ык-мык килеп торганда, Карагайлы килеп җитте дә башкалар белән таныштыра-таныштыра олы як бүлмәгә алып чыкты мине. Өйнең түр почмагыннан зур-зур яфраклы гөлләргә сыенып утырган бер кыз яныннан урын күрсәтте.
— Танышыгыз, яшьләр, — диде дә үзе бик йомышлы кешедәй тиз генә китеп тә югалды.
Кул бирештек:
— Әбүзәр, — дидем мин.
— Мәдинә, — диде кыз.
Ул аз гына, инсафлы гына рәвештә, елмаеп куйды. Кыз йөзендәге бу ягымлы елмаюның ясалма яктылык шикелле тиз сүнмәве һәм килешкилбәтенең шундый сөйкемле күренүе минем баягы шикле уйларны читкә куа башлады. Алай гына да түгел, мин аның каршына баскан килеш кымшана алмыйчарак калдым. Мәдинәнең татар кызларында еш очрамый торган аксыл-сары ефәк сыман чәчләре, җиңелчә генә кабарып, табигый рәвештә җай гына тирбәлгән дулкынны хәтерләтә, чигәләрендә һәм җилкә әйләнәсендә ул чәчләр үз-үзләреннән бөдрәләнеп, нинди дер нечкә гүзәллек һәм иркәлек чәчеп торалар кебек иде. Ә шактый зур күзләренең үтә күренердәй саф зәңгәр булуы һәм тирән зәңгәрлек эченнән кешенең күңеленә шундук барып җитә торган мөлаем бер яктылык сибелүе матурлык хисләренә тиз бирелүчән бу егетне бөтенләй исертеп ташлады. Минем инде хәзер айнык тәнкыйть күзләре һични күрми, бары тик йөрәк кенә кармакка эләккән балыктай тыпылдый һәм кызның алсу ак битләре, яңаклары, муеннары, нәни кызыл иреннәре, түгәрәк иякләре — барысы, барысы да төштәге кебек сихри матур булып, кабатланмас гүзәл һәм саф булып күренә иде. «Чыннан да, сандугач баласы икән!» — дип уйладым. Менә бит кешенең бер сүзе нишләтә! Әгәр Карагайлы алдан ук миңа бу кызны мактап, башны әйләндереп куймаган булса, ничек булыр иде икән? Күз һәм күңел аңа шулай тиз тартылыр идеме? Һай, бу адәм башын ашый торган яучылар!..
Үз нәүбәтендә кыз да минем «матурлык»ны күзәтеп өлгерде бугай. Минем бик үк мактанырлык булмаган тәбәнәк буйны да, гади генә йөзне дә, үзләреннән-үзләре ачылып китәргә һәм нинди дер сәер сүз әйтеп ташларга торган тулымса иреннәр белән соры күзләрне дә, ничә тарама — һаман тырпаерга гына чамалаган кара чәчләрне дә күргәндер инде ул. «Тик буе гына кечерәк икән, минем идеал түгел...» — дип тә уйлагандыр. Чөнки ул үзе дә үсмер гәүдәле генә сыман иде әле. Ә андый кызлар һәр вакыт озын буйлы егеткә кызыгучан була...
Бу кара-каршы басып тору бәлки бер минутка да сузылмагандыр, шулай да бер-беребез турында күп нәрсә белгәндәй булдык. Ниһаять, кыз утыра башлады һәм, әле һаман сокланып, бөтен дөньямны онытып торган миңа да урын күрсәтте:
— Утырыгыз, Әбүзәр абый, — диде.
Сөйләшеп киттек. Мәдинә әле үткән көз генә Бәләбәйдән Казан техникумына күчкән һәм быел аны тәмамларга җыена икән. Укулары күп булгач, күңел ачарга да вакыт тими, имеш. Менә бу кичәгә дә Карагайлы абыйсы бик кыстагач кына килгән, ул аларда укыта һәм әдәби түгәрәктә аларның шигырьләрен дә тикшерә икән...
— Әле сез шулай шагыйрә дәмени? — дип сорадым мин гаҗәпләнеп.

Мәдинә татар кызларында гына була торган сөйкемле оялчанлык белән башын түбән иде һәм, ничектер куырылыбрак калгандай, сүзсез торды. Кызның мондый тыйнаклык күрсәтүе миңа тагын да ошый төште. Буш мактанчык сыман күренми. Көндез башкачарак уйлавым өчен хәтта уңайсызланып та куйдым. Хыяллар кинәт еракларга йөгерде: «Әгәр шушындый гүзәл кыз, чынлап та, шагыйрә булса? Һәм матур шигырьләр дә яза алса? Нинди шәп булыр иде! Хәер, үзе шигырь бит ул, үзе!..»

— Ягез, алайса, укып та күрсәтегез инде,— дидем мин инәлгән тавыш белән.

— Ю-ук, Әбүзәр абый, ул өйрәнчек кенә әле... Үсмер чак мавыгуы гына, — дип кызарынды Мәдинә. — Шигырьне бик яратсам да, үземдә андый көч бардыр дип уйламыйм...

Без шулай сөйләшкән арада кунаклар да килеп бетте булса кирәк, табын да өлгерде һәм, бары да түгәрәкләнеп, зур өстәл әйләнәсенә утырышты, тәлинкәләргә пар бөркеп торган пилмән салынды, рюмкаларга портвейн тутырылды һәм алар чыңлашып югары күтәрелде. Ул чаклардагы яшьләр стакан тутырып акны тондыру яки «ярты»ны «гурласыннан» гына голтлату кебек «батырлыкны» хәзерге шикелле белмиләр иде әле. Ә кызлар, рюмкаларын чәкәшкән булсалар да, авыз тидерүдән бөтенләй баш тартты. Егетләр дә әллә ни комарланмады: берәр рюмка күтәрү белән кинәт йөзләре һәм телләре ачыла төшеп, уенкөлкегә бирелделәр. Мин дә кулга мандолина алган булдым, кызлар кушылып җыр суздылар: «Мәдинәкәй», «Сакмар», «Зөлхиҗә», «Су өсте», Сәйдәш көйләре — берсе дә калмады. Аннары, бу җимерелергә торган өйне дер селкетеп, биешеп алдылар. Шуннан килеп «почталы уен» башланды. Моңарчы үзләренең хисләрен әле бик ачык сиздермәгән егетләр, кинәт кыюланып чия бакчасына ташланган чыпчыклар шикелле, Мәдинә тирәсенә ябырылдылар һәм, барысы да диярлек, аңа «күбәләк» яудыра башлады. Чибәрлектә Мәдинә белән тиң булмаган башка кызлар бөтенләй исәптән төшкәндәй булып калды. Хәтта шактый басынкы һәм житди күренгән Тәхәү Былбылый да, үзе ияртеп килгән Талия исемле итләч кенә гәүдәле кызын исеннән чыгарып, Мәдинә тирәсендәге тар гына арага кысылды. Кысылды да кесәсеннән бик матур кечкенә блокнот чыгарып, ул вакытларда әле бик сирәк кешедә генә очрый торган авторучкасы белән яза башлады. Ләкин шундук язуыннан аерылды да, күкрәк кесәсендә генә торган алтын чылбырлы пенснесен киеп җибәрде. Һәркемнең күзенә ташланырлык матур шакмаклы материалдан тегелгән өр-яңа костюмын ипләштереп алды, гәүдәсен дә турайтыбрак, җилкәләрен башкалардан аерыбрак куйды. Аның бөтен торышы бу чибәр кызның игътибарын үзенә җәлеп итүгә юнәлдерелгән иде. «Эшләр хәтәр болай булгач, безгә рәт бетте икән!» дип торам мин эчтән генә... Ул шулай, уклау йоткан кебек, гәүдәсен катырып утырган килеш кенә хатны язып бетерде дә, блокнот битен ипләп кенә ертып алып, пөхтәләп кенә дүрткә бөкләп, Мәдинәгә күндерде.

Үзенә хатлар күп язудан уңайсызланып, хәтта беркадәр кызара төшеп, башка кызлар алдында гаепле кебек утырган Мәдинә, бу хатны да теләр-теләмәс кенә кулына алды һәм ачып, күз йөгертте. Аннары, ирексездән, көлемсерәгән кыяфәт белән шул блокнот бите артыннан гына Былбылыйга күз кырыен төшерде. Ниләр укырга теләде икән бу яшь кыз аның йөзеннән? Биргән хаты шулай көлемсерәрлек бик тә кызыклы иде микәнни соң? Ә Тәхәүнең шактый җәенке битле йөзе, суган кабыгы төслерәк күзләре гаҗәеп бер җитезлек һәм тирән канәгатьләнү белән балкый иде. Мәдинә ничек итеп күргәндер, ә миңа ул шулай туптуры муен катырып утырган килеш кайдагыдыр билгесез бер ноктага горур караш белән оеп калган, тирәсендәге иптәшләрен дә, Мәдинәне дә, хәтта үзенең Талиясен дә бөтенләй оныткан кебек күренде. Мәгәр

бу шигъри онтылу түгел иде. Аңлавымча, ул иң элек үзенә гашыйк һәм шуңа бик масаеп кына: «Күрәсезме, абзагыз нинди матур кыз белән утыра!» дип, күккә карый төсле иде. Хәер, минем ялгышу да мөмкин, көнче кытыгы култык астында гына ич.

Мәдинә шул блокнот бите артыннан гына аңа күз сирпеп алган җиреннән бөтенләй гамьсез бер кыяфәт белән икенче якка борылып, кемнедер күзәткәндәй карана башлады. Кулындагы кәгазь кисәге кипкән яфрактай өстәлгә төшеп ятты. Анда язылган сүзләрне минем күзләр үземнән сорамыйча ук укып чыктылар:

Сез чибәр, сез гүзәл,
Сездә шәп зәңгәр күзләр.
Мин сезгә гашыйк,
Кил, танышлашыйк!

— диелгән иде анда. Шундук җан тынычланды һәм кычкырып көләсе килде — андый гына шигырьне мин дә яза алам!

«Почта»ның болай бер якка гына йөрүе калганнарга ошамавын Карагайлы-карт төлке бик тиз сизеп алды да яңа уеннар башлап җибәрде. Мин дә моңа бик шатланып кушылдым. Чөнки «бал чебеннәре»нең һаман бер тирәдә безелдәве минем саруны да кайната башлавын үзегез дә сизеп торасыздыр инде.

Гел үк күзле бүкән түгел идек заманында. Андый кичәләрнен уртасында булырга, күмәк уеннарны кызыклы итеп оештырырга, җор сүзгә, шаян җырга, көлке-мәзәккә кесәгә керәсе түгел иде. Монда да колачны шулайрак җәеп җибәрдем. Кулдагы мандолинаны чиртә-чиртә такмак әйткән булдым, кызларны җырлаттым берәм-берәм. Бактың исә, Мәдинә дә сөйкемле генә җырлый икән. «Каз канаты»н шундый итеп әйтеп бирде, сәхнәдә ялан тәпи канат җыеп йөрүче әлеге кыз күз алдына килде дә басты! Аны гына түгел, хәтта Тәхәү иптәшнең Талия туташын да җырлаттым.

Талдан-талга кунып, былбыл,
Сайраган буласыңмы?
Берне ташлап, берне башлап
Сайлаган буласыңмы?

— диде ул, егете каршына түш киереп баскан килеш. Гөр китереп кул чабу һәм көлүдән өй селкенеп киткәндәй булды. Ә Мәдинә белән безнең күзләр нииндидер сөйкемле бер караш белән һаман очраша торалар. Үзебез генә белгән яшерен телдә сөйләшәләр һәм бер-берен ап-ачык аңлыйлар төсле иде.

Бу күңелле яшьлек мәҗлесенең төн урталары әллә кайчан узганчы сузылуы сизелми дә калды. Менә бервакыт кешеләр, ах-ух килеп:

— Трамвайлар күптән туктагандыр инде, — дип,

— Болай да бетеп бара торган «барабыз»лар да беткәндер, — дип ашык-пошык таралыша башлады. Мәдинә әрле-бирле йөгергәләп, Карагайлы абыйсын эзләгән була. Хәйләле кыз икән! Әмма теге әллә кайчан югалган булып чыкты. Җитмәсә тагын, аның белән бергә үзендә тугызынчы класста укучы Камилә исемле кызның да юкка чыкканы мәгълүм булды.

— Яшьләр алдатмыйлар! — дип көлештеләр алардан.

— Сез кайгырмагыз,— дидем Мәдинә янына басып.— Рөхсәт итсәгез, үзем озатыйм...

Кыз каршы сүз әйтмәде һәм без, соңгылардан булып, йорт хуҗасы Мәгърифә апага рәхмәтләр әйтеп, чыгып киттек.

Әле генә Мәдинә тирәсендә сайрашкан егетләр, «бәхет»нең мина әләгүен күреп булса кирәк, төрлесе төрлечә таралышып беткәннәр, күрәсең. Бишбалтаның бу очында байтак кына трамвай көтеп, һич югын-

да, «барабыз»-фәлән булмасмы дип торсак та, аларның берсе дә юк иде инде. Үкенебрәк ишек төбендә таптанган Былбылыйны да Талиясе выжт кына алып китеп өлгерде. Ычкына алса, исәбе Мәдинәне озата бару икәнлеге ялтын-йолтын килгән күзләреннән үк күренеп тора иде...

Гыйнвар төне таңга борылганда без, Мәдинә белән икәү генә калып, ерак дамба буйлап Казанга таба җәяү атладык. Кышкы төн тып-тын иде. Дамбада җәяүлеләр дә, атлылар да күренми. Трамвай юлы да буш. Кар да яумый, җил дә дуламый, тик ул әллә каян Идел өсләреннән сизелмичә генә килә дә, салкынча кулы белән битләрне, чәчләрне юаш кына сыйпап, кием чабуларына кагылып, тагын югала...

Җилнең бу шаян уйнаклавын искә дә алмастан, һаман атлый бирәбез. Кыз күңелендә ниләр бардыр — миңа караңгы. Болай тыныч һәм борчылусыз күренә. Йөзеннән җылы яктылык балкыган шикелле тоела. Ә мин, мавыгучан күңел иркенә бөтенләем белән бирелеп, дәртле куаныч давыллары эчендә кайныйм. Татлы хыяллардан алтын бишек үрәм. Табылды, ахры, табылды! Үз дигәнем, җан теләгәнем табылды! дип кычкырасы килә. Бөтен барлыгым, яшьләргә хас рәвештә гүзәлеккә табынучан бөтен рухым, хәтта һәр сулышым моңарчы әле беркайчан да татылмаган бөек бер шатлык белән сөю җыры җырлый. Ул җыр шушы караңгы төн тынлыгында әллә кайдагы еракларга тарала, аны бөтен табигать сокланып тыңлый кебек. Менә бу кар келәмнәре өстенә җәелеп яткан шыксыз кышкы төн дә шул җырга оегандай тынып калган. Шуңа күрә матур булып күренә ул. Юк, кышкы төн шыксыз түгел, бу суык җил рәхимсез түгел, — алар хәзер үзләре дә шул сөю җырына кушылып, ягымлы моң белән барысы бергә җырлыйлар. Һәм бу куәтле җыр бөтен дөньяга ишетелә! Бу җыр хәтта күкләргә менеп, ай һәм йолдызларга таралыр иде, тик алар күренмиләр. Аларны төнге болытларның кара толыбы каплаган...

Мин шушы сөйкемле кызны җитәкләгән килеш шушы тигез дамбы өстеннән, шушы ләззәтле хыялларга уралып, төн буе да, көн буе да, хәтта гомер буе да гел шулай барыр идем! Барыр идем, талмас идем, туймас идем шикелле тоела...

Артыграк исәрләнеп китүемне үзем дә сизәм сизүен: кыз бит әле миңа өмет бирерлек бер генә сүз дә әйтмәде, тик ягымлы карашлары белән генә сихерләп алды, тик теге «чыпчыклар»ның берсенә дә җим бирмичә, минем белән кайтып бара. Култыгыма сыенып, үз җылысын миңа да күчереп дигәндәй яннан атлый. Ә миңа шул җиткән. Сүздәмени хикмәт, яратам дип кычкыру кирәкмени соң?..

Хыял канатларында шулай очынып барган чакта алдагы төн караңгысы эченнән нindидер карачкы-күләгәләр күренүе мине бу исерткеч рәхәтлектән айнытып җибәрде. Кинәт күңелемдә шик, хәтта курку хисе туды. Нинди карачкылар ул? Чит-читләрендә бер генә торак та булмаган бу өч чакрымлы дамбыда нинди генә әдәмнәр йөрмәс тә, ниләр генә кылмас?.. Алай-болай була калса, нишләргә? Миңа ышанып юлга чыккан шушы кадерле җанны саклый алырмынмы? Көчлелек белән мактаныр эш тә юк. Бу бәләкәй юка гәүдә белән кемне өркетә аласың?.. Хәер, өстеңә алгансың икән инде — теш-тырнагың белән булса да, сакларга тиеш син аны!..

Кыз да ул күләгәләрне шәйләп, хәвефләнде булса кирәк, култыкка сыенарак төште, кечерәеп киткәндәй булды. Мин дә аның беләген кысыбрак тотып, үземә табарак тарттым. Саклану чаралары әзер хәзер — килсен дошманың!..

Ә ул «шомлы дошманнар» килеп җитеп, узып та киттеләр. Алар көрәк-кәйлә күтәргән юл эрчүчеләр булып чыкты. Уф!.. Иркен бер сулыш алып куйдым, алдан ук «бүре» күрүем өчен кычкырып көләсе килде. Эчемдәгене яшерә белмәгәнлектән, кызга да әйтеп бирдем, барыбер сизгәндер ул:

— Беләсезме, Мәдинә, мин хәзер бик курыктым, — дидем. — Башыма әллә нинди коточкыч уйлар килде!..

— Мин дә курыктым, Әбүзәр абый, — дип җавап бирде Мәдинә елмаеп. — Шушында икебезне дә үтереп ташласалар... Алла сакласын.

— Ә мин сезнең өчен курыктым, сезне саклый алмасам, нишләрмен, дип котым очты. Дөресен генә әйткәндә, бер дә батырлардан түгел шул мин...

Монысы артыграк булды бугай, авыздан ычкынгач кына сизеп алдым. Шул инде ул: әйткән сүз — очкан кош, тотып алу мөмкин түгел.

— Әллә чынлап та бик йөрәксезме сез, Әбүзәр абый? — дип куйды кыз.

— Чынлап та шулай. «Һау!» дип, бер өргән этне дә җиде чакрымнан әйләнеп узам.

— И-и, бигрәк инде сез! — дип көлде Мәдинә.

— Чыны шулай булгач — нишлим? Дөрес, бүре кысырыклаган куян да, башка һичбер чарасы калмагач, дошманының башы аркылы сикерә диләр. Шуның шикелле, миндә дә бик кирәк чакта «батырлык» табыла табылуын...

— Ә ничек?

— Әллә нәрсәсе юк. Бәләкәй чакта, шулай бер менә сезнең кебек сары чәчле кызчык, инешкә су коенырга керде дә, бата башлады. Мин балык каптыра идем. Нишләргә? Малайлардан ярда берүзем генә. Тегенең эше харап! Тоттым да суга сикердем. Һәм, бата-чума йөзеп җитеп, чәчләреннән ярга сөйрәдем. Үземә дә инеш суын бирәр чиләк кенә йотарга туры килде. Менә шул...

Мәдинә рәхәтләнеп көлде:

— Кара, нинди икәнсез!..

— Ә икенчесе менә кызыграк булды, — дидем мин, кызны тагын да көлдерәсем килеп. — Уралда эшләгән чакта бер урт тешем сызлап, җелеккә тия иде. Ә теш суырту шикелле куркыныч эштән минем көт чыга!.. Бик авырта ич ул. Беркөнне үзебез белән комсомолда эшләүче матур гына рус кызы белән кинога киттек. Башланырга 15—20 минут бар әле, бакчада йөрибез. Менә бер заманны тотынды минем теш: урлекырлы сикертә! Кая ул кино! Күзгә ак-кара күренми... Бер кул белән яңагымны кыстым да тик утырам посып. «Булмый, мин әйтәм, Ольга, әйдә кайтыйк».

Ул да бик борчыла башлады. Ничек тә бер ярдәм күрсәтәсе килә аның. Шуннан әйтә бу: «Әйдә, безгә, — ди. — Минем әни теш врачы, ул бирәр дару табар», — ди.

Йөгерә-йөгерә дигәндәй, аларга барып кердек. «Мамочка, помоги, Абузер умирает!» ди кыз. Мине теш креслосына утырттылар. Карчык ак металл кораллары белән авызга кереп тә китте, шык-шык китерә, ә минем ул кагылган саен җан чыга!

— Уһу, — ди Ольганың әнисе, — монда дару белән генә эш чыгара торган түгел, суырырга туры киләчәк...

Мин креслодан сикереп үк тордым. Кая ул суырту! Әмма Ольга минем артта гына икән, җилкәмнән урап кочаклап алды да кире утыртты. «Миленький, не бойся», ди ул һәм ак беләкләреннән мине һаман ычкындырмый. Ә шул чакта әнкәсе үзенең рәхимсез келәшчәсен әлеге теш төбенә батырып та өлгерде. Күздән миллион утлар чәчрәде, битләремнән яшьләр агып төште, тәки батырлык күрсәттем бит шул чакта — кычкырмадым да, ичмаса — түздем!

— Ай-я-яй!.. Монысын инде, Әбүзәр абый, уйлап чыгардыгыз, — дип көлде Мәдинә. — Теш суырту да булгандыр, бәлки түзгәнсездер дә. Ләкин ак беләкле Ольгасы булмагандыр! Мине үртәр өчен генә әйтәсездер...

— Ник булмасын! — дип көлдем. — Хыялымда бар иде ул минем. Югыйсә, тешемне шатырдатып суырганда мин ничек түзәр идем?..

— Әй һәмит тә сөйлисез инде сез! — дип, Мәдинә тагын бер рәхәтләнеп көлде.

Шулай сөйләшә-көлешә барганда сүзләрнең әчкерсез гади һәм хәйләсез агылуы безне ничектер тагын да якынайтыбрак җибәрде шикелле. Шулай да минем теш суыртудан куркуыма ышанасы килмәде аның.

— Берәү булса, үзен гел батыр итеп кенә күрсәтер иде әле, ә сез?..— дип миңа карады ул. Сынаулы итеп карады. — Сезгә куркак булырга ярыймы соң, Әбүзәр абый? Шагыйрьләр бит һәммәсе дә батырлык турында шигырь яза. Димәк, сезнең үзегезгә дә батыр булу кирәк!..

— Гел дөресе белән чынын әйтәсез, — дидем мин сүзне уен-көлкегә борып. — Тик белтеки генә төзәтмә бар. Беренчедән, мин шагыйрь түгел, булырга теләсәм дә, биш батман тоз ялыйсы бар әле. Икенчедән, кәгазь өстендә без барыбыз да батыр ла анысы. һәм батыр булып кылану — матур яңгырый. Тыныч кына ояда, чын арыслан — куян да! дип әйтергә була. Ә менә эшкә килгәндә ничек булыр? Белмим...

Шуннан соң безнең сүз үзеннән-үзе шигырь һәм шагыйрьләр тирәсендә әйләнә башлады. Мәдинәнең бу темага сөйләшүне аеруча яратуы беленде. Кемнәрнең ничек язуын җентекли торгач, байтак кына гайбәт тә чәйнәп алдык. Шулай да Такташның «Мокамай» белән «Алсу»ын мактарга мәҗбүр булдык. Аннары инде Мәдинә, бөтенләй үзләшеп китеп, бая мәҗлестә телгә алган шигырен дә укып күрсәтте.

... Менә ниндидер алтын ылыслы көмеш наратлар, бакыр кәүсәле алсу чыршылар үсеп утырган мәһабәт урман... Урман уртасында бамбук озынлыгы буын-буын зәңгәр камышлар, ут яныл торган кара чәчәкле абагалар, кып-кызыл ахак чынаякларын җәеп, нур сибеп утырган төнбоеклар һәм күбәләк чәчәкле кыялар белән уратып алынган бер күл. Күл өстендә җәй буе аккош төркемнәре йөзә, алар камыш аралларында кизләнеп, түмгәкләрдә бала чыгаралар. Таң кояшы балкыганда һәм кичке шәфәкъ нурлары сүнгәндә шундый матур итеп, сихри бер моң белән кангылдашалар: бөтен урман патшалыгы яңгырап, чыңлап тора; бөтен кош-кортлар, җәнлек-киекләр, хәтта болан һәм капланнарга кадәр, яр буена җыелып, бу моңны онытылып тыңлыйлар. Менә шулай җырлап та сайрап рәхәт кенә яшәгәндә кинәт салкын көз килә, ачы җилләр өрә башлый, күл өстен томалап яңгыр коярга тотына. Урманнар шәрә кала, дөньяның яме югала. Менә бер суык һәм өшеткеч кырау төшкән иртәдә ак төркемнәр күл өстенә кыйгачланып күтәрелә дә, ниндидер үзәк өзгеч моңсу һәм өндәүле тавыш белән каңгылдашып, шушы турны ике тапкыр әйләнеп уза һәм, җепкә тезелә-тезелә, кыйбла якка табан сузылып, күздән югала...

Ә күл өстендә ялгыз бер бала кош кала. Ул да иптәшләреннән калмаска тырыша. Ләкин ул оча алмый, әз генә күтәрелүгә яңадан түше белән чупылдап су өстенә килеп төшә. Аһ, бичара балакош! Ни булган аңа, ни булган?.. Ул мескен балакош бүрекле һәм кара муенлы булып туган. Тик шуның өчен генә аны бөтен туганнары талап, кыерсытып бетергәннәр, аның күе мамыклар белән капланып җитмәгән муеннарын усал черкиләр сырып алып, канын суырганнар. Шыксыз көз килүгә ул җитлекми калган. һәм менә хәзер күл уртасыннан күтәрелгән ялгыз, зарлы тавыш белән урманны яңгырата. Ә көз һаман рәхимсезләнә бара, үз янына кышны чакыра. Кыш инде яр буйларын үзенең боз калканы белән каплап йөри, өрәнге яфрагы хәтле карларын очыра. Күл һаман кечерәя, аның өстендә мескен балакош инде рәтләп йөзә дә алмый. Ниһаять, ул бер караңгы, буранлы кичтә боз өстенә чыгып баса да ачы моң белән кычкырып куя: «Каң-ңгыяк, каң-ң-гыяк!..» Аннары ул, сыңар аягын күтәреп, җылы мамык эченә яшерә, моңсу башын кырын салып, күзләрен йома. Ә икенче аягына һаман көчлерәк булып

суык үрмәли бара, ахырда ул аяк бозга ябышып, таш булып туңа. Таң атканда күл өсте бөтенләй боз белән капланган һәм балакош, ап-пак йомшак карларга күмелеп, ак мәрмәрдән чүкелгән һәйкәл төсле, мәңге хәрәкәтсез калган була...

Бу озын һәм ялыктыргыч шигырьне Мәдинәнең бер дә тотлыкмыйча, җиде төн уртасында күңелдән укып бирүе бик тә сокландырды мине. Зиһене алтын икән бу кызның дип уйладым. Фантазиясе дә нәкъ яшь кызларныкыча: тормыштан бөтенләй читтә, җир белән күк арасында дигәндәйрәк. Әниләре кочагыннан аерылмыйча күп кенә китаплар укып яткан яшь кызлар, бигрәк тә шәһәр кызлары, шундый зәңгәр хыяллар эчендә йөзүчән һәм шуннан матурлык эзләүчән була ич.

Әлбәттә, мин аңа бу сүзләрне әйтмәдем. Хәтта, үзем белгәнчә, мактадым да әле. Ничек мактамыйсың. Ул эчкерсез яшь кызның, үзен яраттыра белгән ул гүзәлнең күңелен күтәрмичә дә мөмкин түгел. Аның шундый романтик дөньяда яшәве миңа да тәэсир итте, ул миңа тагын да сөйкемлерәк һәм баерак рухлы булып тоелды...

Төн соң иде инде, Мәдинәгә өенә ашыгу кирәк иде. Хәзерге Галиәсгар Камал урамындагы бер агач йортның капка төбенә тукталып, күл бирештек. Әйтеләсе бик күп сүзләр атлыгып калса да, саубуллашу кирәк иде. Мин аның капкадан кереп киткәнен карап калдым һәм, аяк тавышлары тәмам сүнгәнче тыңлап торгач кына, үз юлыма киттем.

Рәхәт иде бу могҗизаи төн, бу бәхетле төн! Беркая кайтып кермичә, һаман йөрисе, йөрисе, бөтен Казан урамнарын әйләнәсе килә. Искиткеч җиңел, рәхәт миңа. Нинди дер олы шатлык үз канатларында гиздерә, күңелдә әллә нинди якты омтылышлар, матур җырлар уяна төсле иде.

Шулай итеп абзагыз көтмәгәндә генә гашыйк булып кайтты ул кичәдән. Карагайлы әйткән «сандугач баласы»на алдан ук тәнкыйть белән карап барган иде, югыйсә, күргәч-белгәч тә кире какмакчы иде. Бактың исә, колакларыннан ук чумып кайтты. Ә гыйшык дигәннәре бик сәер икән ул: интәшеңнең идәнендә аунаганда да үзеңне патша сараенда, мамык түшәктә яткандай тоясың икән. Башында мең дә бер төрле уй, мең төрле хыялый план — бар да шәп, бар да матур. Безнең кодрәт синең кулларда, ни телисең — шуны эшлә. Бөтен җир шары — синең уч төбендә. Ә диңгезләре, океаннары синең тубыктан гына. Бер минутта барып чыктың Мадагаскар атавына, икенче минутта менеп бастың Һималай тауларына! Малай чактагы җәгърафия буенча бөтен дөньяны гизеп чыгасың. Ә күңел тулы җыр — һаман җырлыйсың, һаман тынмыйсың!

Ә каникул дигәнең шәп! — муеннан кысып та алды. Мин сөю суктакларыннан көн-төн дигәндәй чабулаганда бетеп тә киткән ул. «Көнтөн» дә түгел инде, өч кенә кич очраштык Мәдинә белән, өч минут та булмагандыр кебек тоелды. Нишләмәк кирәк, төштем вокзалга, кердем тулай булып тулган упшый вагонга, мендем сәндерәнең өченче катына. «Алаканат»лар белән студентларның яраткан урыны нәкъ шул инде! Юк, беркемгә дә әйтмәдем. Мәдинәне күрсәтәсе килмәде. Аның белән уналты минут перронда йөрдек. Минем өчен сәгать дигән нәрсә дөньяда, әлбәттә, юк иде, кулда да юк иде әле ул чакта! Ә Мәдинә карады. Кирпеч вокзал битендәге олы түгәрәк сәгать әйтерсең аның беләзегендә иде. Оялды да ул, тартынды да. Еш-еш карангалады да. Күргәнбелгән кешеләр килеп чыгуыннан курка иде, ахры. Актыкка ике минут калды аның әйтүенчә. Шунда гына тәвәккәлләдем: өскә менә торган күпер баскычы астына килеп кердем дә үбәргә теләдем.

Теге көннәрне ничә очрашып, ничә озатып та кыюлык җитмәгән иде, бу юлы яндырып, онытылмаслык итеп үбәргә теләдем. Ә Мәдинә кочагымнан шома гына шуды да чыкты.

— Ашыккан ашка пешкән, — дип көлде.

Җир ярылса, шунда кереп китәр идем гарьлегемнән. Ярылмады. Паровозның гына актык кычкыртуы ишетелде һәм мин, гафу үтенеп, вагонга сикердем...

Бу хәл безнең араларны суытмады, ак канатлы күгәрченнәр һаман оча бирде. Мәскәүдән Казанга, Казаннан Мәскәүгә алсу конвертлар эчендә ялкын ташыдылар, йөрәк ялкыннары! Мәдинәгә хат язарга утырсам, әллә ничек үзеннән-үзе шигырь агыла башлый иде. Мәдинә дә гел шигырь белән җавап бирде. Күпме сөю җырлары язылды ук чакларда! Чистый шагыйрь булып җитә язган идем, калса — биш минут калгандыр!..

Әмма хатлар нихәтле генә еш йөрмәсен, җырлары никадәр генә кайнар булмасын, гыйшык күленә башкөлләй чумып, колак очлары да күренми башлагач, сагынуга артык түзеп булмады. Алда торган җәйге имтиханнарга да, тәртип кагыйдәләренә дә кул селтәп, май башларында тагын Казанга китеп бардым. Хәтта Мәдинәгә алдан хәбәр дә итмәдем, туп-туры үзләренә килеп кермәкче идем. Ә Казан вокзалына төшкәч, йөрәк җитмәде. Ярап бетмәстер. «Бу ниткән әрсез нәрсә!» дип уйлар ата-аналары дигән фикер туды.

Киттем Черекқүл урамындагы Салих дустыма. Ишеген кагуым булды, каршыма яшь кенә бер ханым килеп чыкты. Миңа әллә кайчан таныш булган Әлфия туташ иде бу.

— А-а, исәнмесез, эшләр болай ук булып чыктымыни инде сезнең? Ә миңа бернәрсә белдермиләр... — дип, куанычлы тавыш белән юри генә үпкәләгән булып, өйгә кердем. Салих өстәл артыннан кузгалды:

— Гаепли алмыйсың! — диде ул. — Менә үзеңә шул хакта хат язып утыра идем. Рәхим ит, тапшырыйм, почтага да мәшәкате булмас, конверты да янга калыр... Әле бер генә атна бит.

Көлешеп алдык. Аннары өч аяклы шыгырдавык өстәл тирәсенә утырыштык та чәй эчә башладык. Миңа, кунак кеше булгангадыр инде, стакан эләкте, Салихка йомры таш савыт, Әлфиянең үзенә зәңгәр бизәкле сапсыз чокыр тиде. Ниндидер яньчелеп беткән калай чәйнектән яшь ханым шуларга чәй ясады. Кайнар һәм куе иде ул чәй. Шикәре житенкерәмәсә дә, тәмле тоелды миңа...

Яңа гына башланып киткән яшь гаилә эченә болай коры кул белән килеп керү — әллә ничек уңайсыз булып китте. Болар һәммәсенә дә мохтаҗ икән, ни булса да күтәреп кайтасы иде бит...

— Мин хәзер кайтырмын,— дип ай-һайларына карамый чыгып киттем. Урамда искә төште: хәзер бит Ташыяк ярминкәсе вакытлары. Тукта-ле, шунда берәр әйбер табылмасмы?

Ташыяк павильоннарында дугалар да тәртәләр, агач көрәк, юкә бау саталар булып чыкты. Кешеләрнең «уңышлардан баш әйләнү» еллары иде бу. Шулай да, эзләнеп йөри торгач, бер кибеттән өч пар чынаяк, икенчесеннән юан гына бүксәле бер ваза табылды. Һич югында, сөт чүлмәге итеп файдаланырга да була иде аны.

Студентның барлы-юклы акчасына менә шуларны күтәреп, Ташыяк базарыннан чыгып кына килә идем, көтмәгәндә Мәдинә очрады. Ул нин дидер кызыл чәчле бер кыз иярткән, икесе дә бер төсле диярлек киенгәннәр. Мәдинәнең өстендә матур итеп тегелгән җыйнак кына шәмәхә атлас күлмәк, җилкәсендә шундый ук атластан, сары ефәк эчле кыска гына накидка. Бу киемнәрнең язгы кояш нурында ничектер бик матур җемелдәп-уйнап торуы Мәдинәнең сөйкемлелеген тагын да арттыра иде. Монысы кем икән соң моның? Ничек ул шундый ямьсез кыз белән йөри икән?.. Хәер, контраст куюыдыр. Үз матурлыгын чагыштырма күрсәтү өчендер, каһәр, һай, бу кызлар хәйләкәр дә соң!..

Мәдинәнең зәңгәр күзләрендә үпкә һәм шелтә чаткылары яшьнәде,

ләкин ул аларны артык сиздермәскә тырышып, гади танышларча гына якты йөз белән кул сузды:

— Исәнмесез, Әбүзәр абый, кайчан килдегез?.. Таныш булыгыз: бу минем апам Нәфига.

— Исәнмесез, — дидем кул биреп. — Бик шат, сезне күрүгә бик шатмын!

Шулай юк-бар сөйләшкәләп, Болак буеннан атладык. Ул яз Идел ташуы шәп булганлыктан, Болак елгасы су белән тула язган иде. Көннәрнең җылы килүе сәбәпле, яр читләрендә саф яшел чирәмнәр калкып чыккан, кәкре-бөкре тирәкләре кучкылланып яфрак ярган. Табигатьнең шушындый юмарт җиһазлары белән безнең ул һичкем тарафыннан каралмый торган ташландык «Болак нәһре»без дә ямьле бер инеш төсенә кергән иде.

Таш күпергә җиткәч, бетон рәшәткәгә таянып, Болак өстенә карадык. Ак, яшел, зәңгәр һәм бүтән төсләрдәге җиңел көймәләргә төялеп, гармуннар уйнашып, җырлашып, күпер астыннан Кабанга таба узучы яшьләр бәйрәме сокландыгыч иде. Бу күренешләрдә яз матурлыгы, яшьлек шатлыгы бөркелеп тора. Бар дөньябызны онытып дигәндәй, тик шушы табигый матурлык белән генә сихерләнеп калдык.

— Әйдәгез, без дә киттек көймәдә! — дидем.

Мәдинә шундук риза булды. Тик апасы гына әллә нинди йомышлар табып, бу сәяхәттән баш тартты. Сеңлесен читкә дәшеп алды да нидер пышылдашканнан соң, үз юлына китеп тә барды. Аның китүе өчен ходайга мин рәхмәтләр генә укыдым. Икәү янында өченче артык дип, әллә кайчан әйткәннәр ич.

— Апаң бик акыллы кыз икән! — дип көлдем мин.

Йөгерешеп күпер төбенә төштек тә, рәссам картиналарында гына очрый торган озын бөдрә сакаллы, тузган чәчле, авызында беләк буе чилеме булган бер карттан көймә алып, утырып та киттек. Кулдагы төргәкне көймә әрҗәсенә тыгып, ишкәкләргә тотындым. Болакта Иделдән кергән саф су күп булса да, мунчалардан, урам торбаларыннан төшкән сулар үзләренең «хуш исләрен» барыбер белгертәләр иде. Шуңа күрә кызу-кызу ишеп, күперләр астыннан тын алмый гына уздык та Кабанга чыктык. Мәдинә күзләрендәге баягы очкыннар шелтә яңгыры булып ява да башлады.

— Сөю турында матур сүзләр сөйләү — кайбер иптәшләргә ансаттыр инде ул, күрәсең... Ә үзенең киләсен хәбәр итү... бәлки әһәмиятле нәрсә дә түгелдер...

— И, сандугачкаем, бигрәк матур итеп үпкәли беләсең икән! — дип көлгән булдым. — Мин бит туп-туры үзегезгә килеп кермәкче идем... йөрәк кенә җитмәде... Аннары шунысын да уйладым: син барыбер каршыларга төшә алмас идең, уңайсыз ич ул...

— Бәлки җаен тапкан булыр идем әле. Ир-егетнең кулында җитмеш төрле һөнәр булса, кыз баланың күңелендә җитмеш төрле хәйлә бар, дигәннәр...

— Ай-я-яй!.. Бик күп ич ул. Әгәр син чынлап та шундый хәйләкәр булсаң, мин нишләрмен?

Рәхәтләнеп көлешергә шул да җитә иде. Ишкәкләрне әкренәйтә төштем, көймә үз җаена шома гына тирбәлеп бара башлады. Беркем кулы белән дә ясалмаган һәм бер генә шәһәр уртасында да булмаган бу мәһабәт, бу сокландыгыч матур күл өсте, язгы Идел ташкыннары белән тагын да киңәеп-тулып ераклардан килгән легенда серләрен яшергән килеш, нииндидер колач җитмәс сихри көзгедәй, кояшка каршы тыныч кына ялтырап ята иде. Шушы якты киңлек өстендә без тик икәү генә бәхет көймәсендә тирбәләбез кебек тоелды миңа. Сагыну тулы күзләр Мәдинәгә төбәлгән, ярсу йөрәк тә аның янында. Үзем дә бер тимтенүдә

янына барып утырыр идем, аны кочар, назлар идем, тик ишкәккә ябышкан куллар гына җибәрми. Нишлисең, ишкәкче булырга да кирәк ич!..

Мәгәр дә гүзәллек дөньясында ялгыз без генә түгел идек. Язгы Кабан өсте күңел ачучы яшьләр төялгән йөзләрчә көймәләр белән чуарланган. Әллә ничә яктан гармун, мандолина һәм җыр тавышлары яңгырый, әллә ничәшәр кеше төяп, кырыена хәтле баткан каеклар безнең тирәдән үк, шау-гөр килеп узалар, ә кайбер очлы борынлы кара көймәләр, су өстенә ябыштырып куйган шикелле, бер урында туңып калганнар. Көймә уртасындагы бердәнбер балыкчы, үзенең нечкә саплы кармагын күл өстенә ыргыткан да, чын күңелдән ходайга гыйбадәт кылган кебек, тәләкәсенә карап оеган һәм әйтерсең, изге бер дәрвиш буларак, бу гөнаһлы дөньяның бөтен ләззәтләреннән ваз кичкән.

Язгы көннең шушы әйтеп бетергесез яме, һәм Казанның кояш нуры белән яктылы-күләгәле булып шушы күл өстеннән күренә торган иске мәчетләре, чиркәүләре, фабриклары, Тукайны сагындырган «Болгар» номерлары — барысы бергә ниндидер күтәренке шатлык белән урап ала кешене. Күңел көр, йөзләр елмаюлы һәм сүзләр дә үз-үзләреннән агылырга тора иде.

— Бәхетлеләр кавышалар, бәхетсезләр — сагышта, дип көйләгән булдым мин, башны кырын салып. — Солтан белән Әлфияне әйтәм...

— Чынлап та бәхетлеләр, — диде Мәдинә. — Алар инде күптән берберен яратышалар иде бугай. Икесе дә тыныч, басынкы, акыллы кешеләр, бик пар килгәннәр...

Күзләргә үземчә матур моң тутырып, әз генә елмаеп, маңгай астыннан гына кызга карадым. Бу озак караш Мәдинәне оялтып җибәргәндәй булды.

— Нәрсә?.. — дип сорый куйды ул.

— Ә без, Мәдинәкәй, синең белән пар килмәс идекмени? Бәхетле була алмас идекмени?..

Кызның йөзенә алсу кызыллык йөгерде, көлемсерәгәндәй итте.

— Белмим шул, Әбүзәр абый... Мин бу хакта бер дә уйлаганым юк, мин бәләкәй бит әле...

— Бәләкәй? Их-ха-ха! Әниенә бәләкәй син!

— Әнием әйтә шул, бәләкәй әле син, ди.

— Эх, Мәдинәкәй! — дидем кайнар тавыш белән. — Белсәң иде ничек яратам мин сине! Син минем өчен Ай! Кояш! Якты күк! Елмаешып торган йолдызлар! Юк, алай гына түгел, бөтен дөнья! Могъҗиз көчләре һәм сихри матурлыклары белән тулган бөтен Галәм! Мин сине шуларның уртасына куяр идем дә гомерем буе сиңа гыйшык җырлар җырлар идем һәм шул мине иң бөек бәхеткә ирештерер иде!..

Бер сулыштан сиптердем дә ташладым шушы ялкынны.

— Һай! — дип куйды кыз. — Никадәр югары аһәңле сүзләр, Әбүзәр абый! Чынлап та шагыйрь бугай, ахры, сез.

— Юк, Мәдинә, мин ихлас күңелдән әйтәм, алдап сөйли белмим... Яратам мин сине! Бу сүзләрне бәлки мин йөз тапкыр әйткәнмендер инде, мең тапкыр әйтергә дә, гомер буе кабатларга да әзермен!

Мәгәр кыз алай гына эреп төшмәде. Хәйләле генә елмаеп, әйтә куйды.

— Ә бит яраткан кеше теле белән әйтми, диләр, Әбүзәр абый, батырлыгы белән күрсәтә, диләр...

— Монысын син инде, җаным, рыцарьлар романнары буенча әйтәсең. Кирәк икән, без дә каһарманлык күрсәтә алабыз. Куш хәзер: сикер суга! диген. Сикерәм. Күлнең теләсә кай башына йөзеп чыгарга куш. Йөзәм дә чыгам!

— Ә теге вакытта курыктыгыз түгелме соң?..

— Анда төнлә иде бит ул. Буш дамбыда...

Безнең бу рәхәт шаян сүзләр бүлендe. Каяндыр уң яктан бер көймә килеп чыкты да юлны кисте.

— А, Әбүзәр иптәш, исәнмесез, нинди гүзәлләр белән гүзәл истирахәт кыласыз икән!..

Кап-кара сумала белән катырган көймәдә житен чәчле, юнгштурм киемле Рәхми дигән журналист егет белән шигырь тирәсендә чуалучы Ишбай утырган. Ул нииндидер йөнтәс битле, гел уйнаклап торган «тоз күзле» егет иде. Алар каршына шактый буяулы ике кыз урнашкан. Ишбай кулында тальян гармун чыелдый. Көймә төбендә буш шешәләр түнеп ятканы күренә, ә егетләр шактый ук кәефле иде.

— Ә сез мине танып житкермисез, ахры, Мәдинә туташ, — диде Ишбай, алаптай авызын ерып. — Үткән якшәмбедә генә Мәдәният йортыннан озатып куйган идем бит үзегезне...

Көймәдәге кызлар зәһәр генә чыркылдашып алдылар. Бу «күбәләк чибәр»не ни өчендер өнәмәгәннәре күренә иде аларның.

Мәдинә кинәт кып-кызыл булды. Бик озак сүз таба алмый торганнан соң:

— ... Сез... исерек, — дип кенә пышылдый алды ул.

Ишбайның муен тамырына ишкәк белән берне сыларга куллар бик кыҗыраса да, сабыр итәргә туры килде, чөнки теге тәтиләрнең дә Кабан суын чөмерүе мөмкин иде. Кызны бу кыен хәлдән тизрәк коткару өчен ишкәкләрне каерып-каерып сала башладым. Көймә житез шуып алга китте. Ишбай, нәрсәдер әйтенеп, тагын тальянын боргалады, ә көймәдәге кызлар тагын чырык-чырык көлделәр.

— Ышанмагыз, Әбүзәр абый, ул нахалның ялганына, — диде Мәдинә инәлгән тавыш белән. — Тегермән эте шикелле әрсез нәрсә икән ул. Әллә нинди трагик тавышлар белән әллә нәрсәләр сөйләнеп минем арттан үзе килде; әйләнеп тә карамадым, җавап та бирмәдем.

— Борчылма, аппагым, беләм мин аны! — дип юаттым кызны. — Озатса да инде сине, Ишбай ишеләр түгел, бәлки миннән җүнлерәкләр генә озатыр...

Көтелмәгән бу әшәкелек киемгә кинәт чәчрәгән су шикелле, кәефне беркадәр бозса да, әллә ни озакка бармады. Күңелләр, күл өсте кебек, яңадан мең төрле бизәкләре белән тирбәлеп уйный-уйный, баягы саф җырларын дәвам иттерде. Озын көнне кичкә житкереп, таш күпер төбенә әйләнеп кайттык. Мәдинәнең кулыннан җиңел генә тартып, көймәдән чыгардым да шулай бәхетле житәкләшкән килеш аларның өенә таба киттек.

— Дүрт көннән Салих белән Әлфиянең туе була, — дидем капка төбенә житкәч.— Зурдан түгел, яшьләрне генә җыялар. Чакыруым шушы. Киләсең бит?

— Килермен...

— Ә без кайчан?.. — дип сорадым мин ярым шаяру тоны белән.

— Әй, Әбүзәр абый, бик тирәнгә керәсез, хушыгыз...

Мәдинә бик серле һәм хәйләле тавыш белән матур итеп бер көлде дә күздән югалды.

Инде Казан өстенә күгәрчен түшедәй күгелҗем эңгер төшеп килә иде. Мин дә җилбер-җилбер килеп, нииндидер җинел канатлар шикелле җилпенеп торган кулларны да селти-селти, Салихлар бүлмәсенә кайтып кердем.

— Менә ул, «Хәзер кайтам» атлы алдар таз! — диде Әлфия. — Уникe генә сәгатьтән соң әйләнеп тә кайтты.

— Ә?! Ах!.. — дидем дә шап итеп суктым маңгайга мин. Кинәт теге төргәк искә төште. — Әй, тай типкән дә инде минем башка! — дип ишеккә ташландым.

— Тагын кая ычкынмакчы буласың, төн уртасы житкәндә? — диде Салих кашларын җыерып.

— Ни бит... кечкенә генә бүләк алган идем... Инде нишләргә? Көймәдә онытылып калган ич!

— Нинди көймәдә? Нинди бүләк? — дип төпчеңделәр.

— Әй, сорамагыз ла инде. Мәдинә очраган иде, көймәдә йөрдек, ә бүләк дигәнем шунда әрҗәдә калган...

— Минә бит гыйшык зәхмәте нишләтә кешене-е-е...

— Юк ла, хәтер шундый тишек минем — төшә дә кала...

— Нәрсә иде соң ул?

— Әллә ни түгел түгеллеккә дә... Өч пар чынаяк та бер ваза табып алган идем. Хәзер йөгерсәм, ничек булыр икән?

— Көймә хуҗасы сине таң атканчы көтәчәк инде, әлбәттә! Ул синең чынаякларыңнан тәмләп чәй эчә torгандыр инде күптән!

Бу вакыйга кич буе көлешергә җитте. Яшь кияү белән яшь кәләш чаршау корып, үзләренең тар гына караватларына урнаштылар. Ә мин кечкенә генә прихожий идәненә тәгәрәү белән изрәп йокыга киткәнмен.

Зарыгып көтелгән җиде ай, хатлар йөреп торса да, җиде ел шикелле озак узып, ниһаять, вәгъдә көннәре килде. Әйе, Әлфия белән Солтан туе көнне вәгъдә куешкан идек. Шул кичтә Мәдинәне капка төпләренә хәтле илтеп куйдым. Юл буе өтәләнеп сөйләгән сүзем: яңа тормыш коруның матурлыгы һәм кызны шуңа күндерү турында булды. Күңелең тәмам ташып түгелә башласа, акыллымы ул, көлкеме, барын да әйтеп калырга ашыгасың икән.

— Беләсеңме, җаным, мин сине кайнар мәхәббәтем белән иркәләрмен, иң якын дустым итеп һәр вакыт сине кайгыртырмын, ышанычлы терәгең, турылыклы иптәшең булырмын. Андый гына көч бар миндә! Валлаһи бар! — дидем.

Шундыйрак сүзләр белән бик күп кыстаулардан соң Мәдинәнең борылыр җире калмады бугай. Ниһаять, ул болай диде:

— Укуларым алдагы кышта тәмамлана. Шуннан соң инде...

Сөенечтән яшь бала шикелле куана-куана аның ике кулыннан кысып тоттым:

— Димәк, вәгъдә, алайса? Вәгъдә? — дип сорадым кайнарланып.

— Вәгъдә... — диде Мәдинә пышылдап кына.

Шәһәр яшьләренең күбесе белән була торганча, без дә, төнге капка төбендә беренче мәртәбә үбештек. Күзләр йомылды, күкләр әйләнеп җиргә төште. Җем-җем итеп, береннән-бере якты балкый торган йолдызлар мириадасы җир өстенә түгелгән иде. Дөнья шундый матур иде, бөтен әйләнә-тирәдә бары тик бәхет кенә, бары тик яхшылык кына, бары тик мәхәббәт кенә ак канатларын җәйгән иде...

Менә шуның өчен дә кышкы имтиханнарны алдан ук тапшырдым да Казанга ашыктым. Салихларның ишегеннән күренү белән үк, аларны кызулый башладым:

— Әзерләнегез, дусларым, бөтен ышанычым сездә генә, зинһар ташламагыз! — Кесәдә булганны чыгарып, өстәлгә салдым. — Туйга тотыгыз, мин хәзер Мәдинә янына чабам, шушы якшәмбедән дә калдырмаска кирәк булыр...

Алар минем чын дуслар иде, барын да тиз аңлап алдылар.

— Бездән эш калмас. Килен генә төкле аягы белән килсен, — дип озатты Салих.

Мәдинәне эзли-эзли җан чыкты. Өйләренә барып керер идем, ишекләре кая таба ачылганын да белмим. Ата-аналары белән дә таныш түгел. Мин аларны Мәдинәдән ишетмеш буенча гына беләм: элекке приказчикмы, сәүдәгәррәкме кешеләр бугай. Анысы чурт с ним. Әллә

ни социал аерма күренми, алар белән торасы түгел, кызлары белән торасы ич. Ә мин аны үземчә тәрбияләрмен...

Ниһаять, әлеге дә баягы Карагайлы ярдәме белән генә таба алдым Мәдинәне. Кызларның кая басып, кайсы урамнан йөргәнен белеп кенә тора иде ул кеше. Әллә нинди Сәлимәләргә, Заһидәләргә, Нурияләргә шылтыратып бетерде һәм, кызны тәки табып, бүлмәсенә китерде.

Икәүләп Мәдинәне үгетли-үгетли, бөтен нәрсәне аңлатып бирергә тырышабыз. Кыз, теге вакытта вәгъдә биргән булса да, үзе курыккан каршылыклардан һаман арынып бетмәгән иде әле.

— Белмим шул, — диде ул күңелсез генә. — Әтиләр барыбер риза булмас. Алар бит борынгы фикерле кешеләр. Болай гына минем үземә дә әллә ничек...

— Бәгърем, Мәдинәкәй! — дидем ялварулы тавыш белән. — Аның бер әллә ничеклеге дә юк, мин аларга шушы минутта ук барып, һәммәсен сөйләп бирергә риза. Тик алар, үзең әйтмешли, тиз генә аңламаслар һәм бөтен эшне бозып ташлаулары мөмкин. Әгәр инде без, шушы якшәмбедә комсомолларча туй ясап, дүшәмбе көн язылышсак, аннары парлашып аларга кунакка барып керсәк, алларына тезләнеп: «Менә без шушлай-шушлай инде, фатиха бирегез!» дисәк, алар нишли алыр? Шулай итик. Без ирекле кешеләр ич! Мин синең өчен бөтен нәрсәләрне хәзерләдем инде. Мин үз вәгъдәмдә тору өчен утка-суга да керәчәкмен, башыма таш яуса да вәгъдәмнән кайтмаячакмын; ул — минем изге антым!

Бу сүзләр бик кайнар чыкты бугай минем, кызым бурлаттай булып кызарды, уңайсызланып башын түбән иде.

— Юк, мин дә вәгъдә бозарга теләмим, — диде ул акланырга тырышкандай бер тавыш белән. — Ләкин ничектер башкачарак итәсе иде дим. Әйтик, туйдан соң кияү белән кәләш кайда булырга тиешләр инде? Салихлар идәнендәме?..

Батырды! Көпә-көндез төпсез суга ыргытты. Ул хәтлесен уйларга минем бөтенләй баш җитмәгән. Тиң мәхәббәт белән кавышкан бәхетлеләр өчен туйдан соң кайда куну мәсьәләсе — вак нәрсә бит ул, чүп кенә!

Тилмереп Карагайлыга карадым. Иллә дә егет картлач икән, шундук хәйләсен тапты:

— Ничек кайда булсын? — диде ул. — Минем бүлмәдә буласыз. Мин бит туйдан соң ук төнге поезд белән Уфага китәм, ашыгыч чакыралар... Әйтмәдеммени, Әбүзәр, сиңа.

Мин дә бу саламга тиз генә ябышып, ярга чыктым. Туй шатлыгы белән зиһеннәр чуалып китүен әйтеп көлдердем. Алай гына да түгел, Мәскәүдә Гаделша абзыйлар үзләренең бер бүлмәләренә кертәчәкләрен дә хәбәр иттем (гәрчә әле ул хакта сүз кузгатканым юк иде алар белән).

— Язмышым шушыдыр инде... — диде Мәдинә тирән сулап. Аннары кулын бирде, ә кулы уттай кайнар иде, яратулы иде. — Тик әнкәем белән тагын бер җайлап кына сөйләшеп карыйм әле...

— Димәк, якшәмбе көн, кичке җидедә, Әлфияләрдә! Мин сине таш күпердә көтеп торам.

— Ярый...

Һәм менә ул якты якшәмбе киче!

Кунаклар каршылауны Салих белән Әлфиягә тапшырдым да, сәгать алтыдан ук диярлек, таш күпер өстенә йөгердем. Уфылдап килеп җиткәннән соң, җиде тулганны көтеп, күпме таптанып йөрдем анда! Җитмәсә, буран уйнаклый тагын, муенга кар бөртекләре сибеп кытыклый, аякларга шиблет табаннары аркылы суык йөгерә. Әкрен генә тамган тамчы шикелле салмак минутлар минем кебек ашыкмыйлар. Шулай бит ул вакыт: көткәндә — озак, аерылганда тиз үтә. Һаман йөренгәлим,

йөрәктә шатлыклы түземсезлек... Ниһаять, минә жиде тула, минем күзләр узган-барганнарга кичке караңгылык аша тагын да текәлебрәк карый, эзли, һәр узган кешене танырга тырыша. Әмма таныш күләгә күренми әле... Хәер, менә «эһ» дигән арада килеп тә житәр. Әз генә киенеп өлгермәгәндер...

Таш күпернең бетон рәшәткәләренә сөяләм. Түбән карыйм. Яз көне монда нихәтле су иде, аның жинел дулкыннарында нихәтле көймәләр тирбәлә иде. Кабаннан борылып кайтышлый бүләк чынаяклар да шушында калган иде бит, шул көйгә юкка чыктылар. Иртәсен бу күпердән яңадан узсам да, көймәче карт күренмәде...

Караңгылык һаман куера бара. Болай бер урында озак тору мөмкин түгел икән — суык. Тагын Болакның бер ягыннан бер ягына килэп сара башлыйм. Әйтерсең бик тырыша-тырыша таш күпернең озынлыгын үлчим. Шулай йөренә торгач, ун минут, унбиш, егерме, утыз минут узып китә. Ә Мәдинә һаман юк та юк. Бу нинди хәл соң, нәрсә булды икән, нигә тоткарланды икән?.. Куанычлы уйлар әкренләп томалана башлый. Аяклардан аркаларга таба әкрен үрмәләгән суык шикелле, сиздерми генә эчкә пошман үрмәли һәм күренмәс тырнаклары белән йөрәкне тырнарга тотына. Туктале, ничек булды соң бу? Әллә мин аны, кичке караңгылыкта шулай йөренә торгач, уздырып жибәрдемме? Әллә ул шаян кыз юрамалый башка күпер аша китеп, инде күптән туйның түрендә утырамы? Чынлап та, әгәр аңа бу күпер аша узарга нәрсәдер комачаулаган булса? Яки берәрсе сагалап торасы булса? Нигә ул техникум янындагы күпер аша китмәсен?..

Кинәт урынымнан кубып, Салих бүлмәсенә йөгердем: эх, жүләр дә соң мин, шуны да абайламаска!

Мин кайтып кергәндә сәгать сигез тулып узган иде инде. Ишек ачкан Әлфиядән бик тә кабаланып сорадым:

— Мәдинә килгәндер бит!..

— Ничек инде ул? Сез бит бергә килергә тиеш идегез...

— Килмәдемени? Юкмыни ул монда?.. — Тавыш сынып китте минем. — Менә әллә нәрсә булды ич, күпме вакытлар көттем — юк...

Инде эчке бүлмәгә жыелып өлгергән биш-алты кунак, нидер сөйләшеп, көлешеп утыра иде. Минем борчулы тавышны ишетеп калган Салих килеп чыкты, аның артыннан Карагайлы да күренде. Ишек төбендә тәжел генә киңәшмә башланды.

— Инде нишләргә?..

— Хәзергә кунакларга әйтмичәрәк торырга, бәлки килеп житәр...

Карагайлы үзе белән алып килгән кызны дәшеп чыгарды:

— Мәдинә белән дуслыгың бармы, Сәкинәкәй? Әйдә, өйләренә таба барыйк әле, син кереп чыгарсың, мин көтеп торырмын. Әйдә, Әбүзәр, син дә...

Салих белән Әлфиягә кунакларны юатып торырга куштык та киттек. Биш атлыйсын бер атлап дигәндәй, Г. Камал урамына барып житкәч, без, ирләр, капка төбенә килдек. Сәкинә караңгы ишегалдына кереп китте, һәм бераздан аның агач баскычларны шыгырдатып икенче катка күтәрелүе ишетелде. Байтактан соң ул кыз кире әйләнеп чыкты.

— Күпме шылтыраттым, күпме йодрыгым белән ишекләрен шакыдым, кулларым авыртып бетте, ичмаса бер тавыш-тын булсачы! Әллә үлеп беткәннәр тагы! — диде кыз.

Баш түбән иелде дә төште минем, әйтер сүз табылмады. Әллә нинди караңгы уйлар, күңелсез хисләр басты. Бөтен дөнья ямьсез, жылысыз булып, һәм бу якшәмбе киче шомлы бер кара төн булып күренде...

Өчәүләшеп тып-тын кире атладык. Хәтта һичбер вакытта жиңелми торган Карагайлы да телсез калды.

Без кайтып кергәндә, кунаклар таралышкан иде инде. Аңлашылмаган бу күңелсезлекне озак жентекләп сөйләшкәннән соң Карагайлы

белән Сәкинә дә кайтып китте. Салих белән Әлфия дә ятты. Миңа да өсне чишенми-нитми генә прихожий идәненә капланырга туры килде...

Шулай...

Ак җилкәннәрен җилдә җилфердәтеп, сөйгәнең янына ашыга торган мәхәббәт көймәң комга утырса, җиде төн уртасында да ачы газап тулы уйларың сүрелми икән. Битләрең пешеп яна һәм аларның кызыллыгы шул караңгы бүлмә эчендә дә ачык күренәдер шикелле. Нинди оят, нинди хурлык! Җир тишеге булса, кереп кенә китәр идең дә бит, җир тишеге юк шул! Туй итәм, имеш!..

Инде моннан соң ничек кеше күзенә күренергә? Әдәм көлкесе булдың ич! Хәер, көлкесенә төкерергә дә булыр иде, ә менә алдануы, ах, алдануы!.. Яратам дигән булды, вәгъдәләр биргән булды... Һәммәсе ялган икән! Ә син тиле, бәхет кояшым дип, шуңа табынып йөргәнсең, бөтен изге хисләреңне белән сөйгәнсең, аның алдавыч сүзләренә малайларча ышанып, буш хыяллар дәрьясында йөзгәнсең. Нинди бәхетсезлек, нинди кара бәхетсезлек! Нигә болай бу: кешеләрдә матурлык була, ягымлы елмаю була, хәтта тәмле тел, ышандыргыч сүз була, әмма гаделлек һәм турылык булмый кала. Алар хәтта моны үзләре өчен мәҗбүри сыйфат дип тә санамыйлар...

Минем җәберләнгән хисләр шундый шашкын хөкем чыгара. Бу хөкем буенча әлеге Мәдинә дигән җинаятьче кыз бүген дөнья йөзеннән юк ителергә тиеш! Тик күңелнең кайсыдыр ерак почмагыннан зәгыйфь кенә бер аваз килә:

«Туктале, кыз гына гаепле ме соң монда?..— ди ул.— Үзең дә ялгышмадыңмы? Ни өчен кызның ата-анасы белән күрешеп сөйләшмәдең? Аларны санга сукмау түгелме бу? Ни өчен туйдан соң сыеныр почмагың да, чәй эчәр чынаягың да булмаган көйгә өйләнергә ашыктың?.. Кошлар да бит башта оя кора, аннары гына бала чыгара. Әллә син кәккүкме, шушы гап-гади нәрсәне дә белмәдеңме?..»

Тегермән ташыдай авыр газаплар астында басылып, мең төрле үкенечләр, җан әрнеткеч сызланулар белән җәфа чигә-чигә, көчкә таң аттырдым. Йокы күрмәгән күз кабаклары ут янып сызлый, ә баш — меңнәрчә чикерткәләр оялаган шикелле, өзлексез чыңлый иде. Дөнья яктысы күзгә күренмәде: тордым, юындым, бер чынаяк чәй эчкән булдым да:

— Хушыгыз, дуслар,— дип чыгып киттем. Вокзалга юнәлдем. Чөнки Казан миңа җәһәннәм чокыры булып күренә иде. Чөнки бу минутта миннән дә бәхетсез әдәм юк иде...

Трамвайдан төшеп әйберне камерага тапшырдым да кассадан билет алдым. Әле өч-дүрт сәгать вакыт бар икән поездга. Ничек аны күрми китим мин? Эчтә янартаулар дуласа да, аны күрәсе килә, бер генә сүзен булса да ишетәсе иде. Ник килмәвен әз генә аңлатса да тынычланыр идем.

Киттем. Этләре таламаса, куып чыгармаслар әле. Үткән төндә капшап йөргән коймаларны узып, капкадан эчкә кердем. Түрдәге йортның икенче катына күтәрелдем, каршыдагы ишек уртасында сыңар яшел «күз» миңа карап тора. Стенадагы ак сәдәпне басуга, үрдәк тамаклы звонок түгел, ә «келтин-пелтин» генә килеп, музыкаль тавыш уйнап җибәрде. Елмаеп куйдым, Мәдинә күз алдыма килде: аның эшедер инде бу дип уйладым.

Эчке яктан кемдер ишеккә килеп, әлеге яшел күздән озак кына карап торды да:

— Кем бар анда? — дип сорады.

Исем-фамилиямне әйттем, Мәдинәне сорадым. Ишек әкрен генә ачылды. Каршымда Мәдинәнең әлеге җирән апасы тора иде.

— Ул өйдә юк шул, укуда... — диде кыз. — Тиз кайтмас әле...

Уң як бүлмәдән бер ханым күренде: тулымса гәүдәле, җыйнак буйлы. Төс-бите белән Мәдинәне хәтерләтә. Яше кырык бишләр тирәсендәдер.

— Өйне суытасың ич, кызым, — диде ул. — Ачык ишектән сөйләшү җәй көне генә кызык. Өйгә чакыр кунагыңны.

Кыз мине тупсадан уздырды.

— Мәдинә кунагы бу, инәй, — диде ул аннары. — Әбүзәр абый.

Ханым мине бик горур караш белән баштанаяк күздән кичерде.

— Шушымыни инде ул Әбүзәр дигәнегез?.. — диде ул башын минем тирәдә җир шары шикелле әйләндергәләп. — Әллә ниткән кәмитләр корып йөрүче!..

Әнисенең болай шактый гайрәтле тонда сүз башлавын ишеткән җирән кыз, «минем бер катнашым да юк» дигәндәй, эчке якка кереп китте. Ханым коридордагы бердәнбер урындыкка утырды, миңа урын тәкъдим итеп тормады, сүзен дәвам итте:

— Яшь кызларның башын катырып йөрү ир-егеткә бер дә килешми, Әбүзәр... иптәш. Кызыбызны урамдагы узгынчыга кияүгә бирә алмыйбыз. Без — ата, ана. Аның бәхетле булуы, көн күрердәй хәллерәк кеше белән тормыш коруы өчен без җаваплы. Ә сез безне кешегә дә санамагансыз. Килеп күренү, ризалык сорау ата-бабадан килгән йола түгелмени?.. Икегез дә укып бетермәгән, бер нәрсәгез дә булмаган килеш әйләнгән булып кылану көлке генә бит ул! Юк, минем кызларым әйбәт урында яхшы хезмәт хакы ала торган, үз куышын менә дигән итеп корган акыллы кешеләргә генә тапшырылачак. Менә шул. Бигайбә. Хушыгыз.

Ханым җәһәт кенә кузгалды да әлеге бүлмәсенә кереп китте. Ярлы шәкерт хәлендә калган мин тинтәк тә, ник килеп керүемә мең тапкыр үкенә-үкенә, чыгып тайдым. Бар да ачыкланды. Бертөрле канатлы хыяллар да, янып-көеп сөюләр дә, яшьлеккә хас иллюзияләр дә кирәкми икән бу дөньяда! Бу ханым-апа әйткәннәргә ирешсәң — Мәдинә синеке булачак...

Укуны бетергәч, Казанга кайтасы итмәдем. Суынсын мескен эзләр, җуелсын сөю сукмаклары, тигәнәкләр үссен өсләренә!.. Шулай уйладым.

Ул елларда Мәскәүдә чыккан татар гәзитләренең берсендә эш табылды. Метро, Фили һәм автозавод төзелешләрендәге татар эшчеләре тормышыннан хәбәрләр ташыдым, хәтта мәкаләләр язарга да өйрәндем. Әмма шигырь язган булып маташу бөтенләй онытылды, язасы килмәде, сүнде шигырь утлары. Хәер, «Мәхәббәт һәлакәте» шулай дөнья җимереп узганнан соң аның кирәге дә калмады...

Шулай яши торгач, «оялы» да булып киттем. Мәскәүнең үзеннән булмаса да, Клязьма поселогыннан бер бүлмә бирделәр. Ерак түгел, редакциядән утыз гына чакрым ул. Эшләрем дә начар бармый, хезмәт хакым да теге апа әйткәнгә якын хәзер. Тәки «әдәм рәтенә» керәм бугай, ахры. Тик Мәдинә салган яра гына һаман төзәлеп җитмәгән иде әле йөрәктә...

Шул көннән соң ул кыз күренмәде, мин дә аны эзләп йөри алмадым, әлбәттә. Бар да очраклы гына булган бу хәлләр, бар да чуалчык бер иллюзия генә... дигән фикергә килә башладым.

Моңсу да, куанычлы да булып яз килде. Күгәрченнәр коена торган кояшлы гөрләвекләр тора-бара бозларны актаручы ярсу ташуларга әй-

ләнделәр. Язгы ашкынуларыннан арынган күңелдә дә ниндидер салпы гына, канатсыз гына тынычлык урнашкандай булды. Ул кызның кайчандыр сокландырган җете зәңгәр күзләре дә, аксыл-сары ефәк чәчләре дә, күбәләктәй җиңел хәрәкәтле гәүдәсе дә күз алдымда һаман тоныклана бара, бөтен килеш-килбәте белән кайдагыдыр ерак офыктагы томан артларына кереп эри, җуела бара сыман иде. Күңелдә аңа эллә ни үпкә дә, ачу да юк. Нигә кирәк? Ул бит — әнисенең кызы икән. Ул ханым әнә ничек тәрбияләгән ич аны! Сал дөньяның бөтен уңай якларын аның уч төбенә — шунда кыз синеке! Кызын сатып бирә ул сиңа, хәлеңнән килсә — ал. Юк, әйбер һәм дәрәҗә коллары — минем идеал түгел!.. Җир белән күк арасы. Үз вакытында үзлегеннән нокта куелу — бик тә урынлы булган.

Үземне шундый «тынычлык туннары» белән төреп йөри торгач, август урталары килеп җиткән икән. Салих белән Әлфиядән хат килеп төште. Алар Мәдинәнең Казан мединститутына кабул ителеп тә кире кагылуын, бу эштә Миңфасыйк дигән бер егетнең күп «тырышлык» күрсәтүен язганнар иде.

Инде күптән томаннар артына кереп югалды дигән Мәдинә шул минутта ук яңадан күз алдыма килеп басты. Бу юлы ул элекке шикелле көлемсә йөзле, шат күңелле кыз булып түгел, ә бәлки боз каплый килгән теге күл уртасындагы ялгыз аккош баласы булып күренде миңа. Нидер кыласы, ничектер коткарасы килде аны. Мединститутка булмаса, башкасына да ярар дип, Мәскәүнең үзем белгән бөтен вузларын әйләнеп чыктым. Берсендә дә буш урын табылмагач, Ленинград белән элемтәгә кердем. Анда Йосыф дигән бер доцент дусым бар иде. Медвузда бер урын таба алачагын хәбәр итте. Шул көнне үк туп-туры Мәдинәнең үзенә дә, Салихка да телеграмм бирдем. Ике көннән соң Мәдинәне Казан вокзалында каршы алдым. Янында әлеге җирән апасы да бар иде. Ялгыз җибәрергә курыкканнар икән. Октябрь вокзалыннан утырып, Ленинградка илтә киттем.

Ничәмә сәгатьләргә сузылган бу юл — җәһәннәм газабы булды. Казан хәбәрләрен сораштыргалап, вак-төяк мәзәкләр сөйләшкәләп барган булам. Үткәндәгеләргә берәү дә кагылмый. Монысына мең шөкер! Шулай да авыр, бик авыр булды бу юл. Менә-менә сынып, өзелеп китәрдәй минутлар кичерелде. Үзең һаман уен-көлке сөйләгән булсаң да, каршыңда утырган шул якын һәм бик ерак, һай ерак булган кыздан күзләреңне ала алмау бик тә кыен иде. Элеккедән дә матуррак, соклангычрак булып күренә иде ул. Кинәт кенә бөтенесен онытып, аны иркәлисе, ягымлы сүзләр белән күмәсе, шул ефәк чәчләреннән сыйпыйсы килә иде. Оят булса да күкрәккә кысып җылый-җылый, барын да гафу итәсе килә иде.

Әмма бер хәрәкәт тә ясый алмадым, күңел богавын өзеп ташларлык бер сүз дә ычкынмады авыздан. Тик Мәдинәгә төбәлгән күзләр генә татлы газап белән исергәннәр иде. Аларга да хуҗа була белдем: күзгалып, вагон коридорында йөрендем, бу якларның урман-яланнарын, абагалы-камышлы сазлык, күлләрен күргән юк иде,— туйганчы шуларны тәрәзәдән карап бардым.

Шулай Ленинградка килеп җиттек. Мәдинәне үз сеңелем итеп, әлеге Йосыф дустым ярдәме белән вузга урнаштырдым. Йосыф яхшы кеше иде, тулай торакта урын булганчы дип, кызга үз танышларыннан бер почмак та табып бирде.

Мәдинә аңа да, миңа да күп рәхмәтләр укыды. Апасы белән вокзалга төшеп, мине озатып калды. Күңелләр дә, телләр дә чишелмәде. Хәтта теге кичтә «туй»дан кая качып калуын да сорашмадым. Рәсми һәм әдәпле төстә аерылыштык. Үкенмәдем дә. Җепләр тәмам өзелгән, күрәсең. Һәм шулай булуы яхшырак та.!.

Ә ел узганнан соң сәер бер хәбәр ишетелде: «Мәдинә кияүгә чыккан, имеш. Ире бик дәрәҗәле, кинотрест башлыгы ди. Мәһабәт буйлы, матур чырайлы, Тахаутдинов фамилияле кеше ди...» Ышанмадым. Көлдем. Акыллы кыз ул, укыр, алай ук ашыкмас, дип уйладым.

Озакламый Мәдинәнең үзеннән дә хат килеп төште. Укырга керүдә ярдәм итүләрем өчен күп рәхмәтләр әйткән, аннары инде: «Тормышлар киң, дөньябыз тиң, бәхетләр мул, өйгә кунак бул. Күрешеп алыйк, дус булып калыйк...» дип, бәетләбрәк язган иде ул. Адресларын да күрсәткән — Мәскәүдә яшиләр икән!

Менә бу юлы инде минем ачу килде. Иң элек үземнең кеше таный белмәвем өчен. Хатын-кызның да кешелек сыйфатын таный белү кирәк икән ләбаса. Ә без — матур кыз елмайса, изеләбез дә төшәбез.

«Хәзер стенографистлар курсына йөрим», дип мактанган бит әле. Менә сиңа институт, менә сиңа — булачак врач!

Аннары көлдем үземнән: «Күзләреңне карат син, Әбүзәр дус, чыпчыкларны былбыл итеп күрсәтми торган күзлек тап!» дидем... Кинәт ул минем күз алдымда шундый гына бер кошка әйләнеп калуына үзем дә тетрәнеп киттем.

Бу хат онытылганга да инде биш былтыр дигәндәй вакыт узган иде. Чөнки мин җавап бирмәдем. Ялган сүзләр белән котларга да баш житмәгән хәтта. Ул да тынып калды...

Ә көзге салкын көннәрнең берендә кемдер ишек какты.

— Рәхим итегез, ачык! — дип кычкырдым.

Ишек әкрен генә ачылды, һәм бүлмәгә, моңсу гына елмаеп, бик тә купшы киенгән бер ханым килеп керде. Утка сикергәндәй булдым, — Мәдинә иде бу!

— Әбүзәр! — диде ханым ниндидер әрнүле йөрәк тавышы белән. Һәм минем әби патша заманыннан калган шыгырдавык диванга килеп капланды да, үкси-үкси җылый башлады:

— Мин ялгыштым, Әбүзәр...

Ә мин, урнымнан сикереп торган килеш, ни кылырга, ни әйтергә белмичә, аптырап калдым. Аны юатырга, күз яшьләрен туктатырдай йомшак сүзләр әйтергә, шул ефәк чәчләреннән сыйпарга кирәк иде. Әмма авыз ачып әйтердәй бер җылы сүз табылмады, бер хәрәкәт тә ясый алмадым... Кайчандыр бәхетсезлек һәм гарьлек утында янып куырылган бәгырь — инде таш булган икән... Хәтта үпкә сүзләр дә түгелмәде.

Мәдинә башын авыр гына калкытып, миңа карады. Аның хәсрәтле зәңгәр күзләрендә мөлдерәп торган яшь бөртекләре күк чәчәк өстендә җемелдәгән иртәнге чык тамчыларын хәтерләтә иде. Шактый сула төшкән боек йөзе бөтен эчке дөньясының челпәрәмә килүен, чиксез үкенүен сөйли кебек иде.

— Әбүзәр... — дип кабатлады ул тирән сулыш белән. — Мин бары тик сине генә яратам икән... Мин моны хәзер бик яхшы аңладым... Мин синең кадереңне белмәгәнмен...

Эндәшмәдем. Ерак үткәндәгеләр күз алдыма килеп, эчтә әрнү давыллары күтәрелсә дә, тыныч күренергә тырыштым.

— Хәтерлимсең күл өстендә ялгыз калган кара муенлы аккош баласын?.. Мин — шул инде хәзер... Аны кар кочкан, ә минем җанымны боз коча... Суык миңа, суык бу дөнья!..

Кабат тетрәнеп киттем. Аккош баласы... Ул шигырь укылган төн нинди могҗизалы, нинди бәхетле төн иде. Мәхәббәтнең ялкын чәчәге беренче тапкыр дөньяга күзен ачкан сихерле кышкы төн иде! Кайда ул төн?.. Нинди шашкын бураннар күмеп китте аны?..

— Ул кипкән кыяк төсле коры кеше,— дип дәвам итте Мәдинә яшь аралаш. — Үз дәрәҗәсенә генә гашыйк ул. Мал колы. Шул мөл-

кәт эчендә мин дә җанлы бер курчак... Җитмәсә, көнләшә, шул кадәр көнләшә...

— Алай булгач, бик яратадыр... — дидем чак кына көлемсерәп.

— Юк, сөелүче түгел мин... Үз ише дәрәҗәле кунакларга мактанып күрсәтелә торган читлек кошы гына. Алар киткәч, «ник тегенә карадың! Ник моңа елмайдың?» дигән җәнҗал чыгара...

Эндәшмәдем. Үзең белмәгән-күрмәгән кешене хөкем итү — егетлек түгел. Үз эшләре, теләсә нишләсеннәр...

Мәдинә, бәләкәй генә челтәрле яулыгын җиң очыннан чыгарып, күзләрен сөртте, чәчләрен рәтләде һәм, якты бер караш белән әйтте:

— Кичер мине, Әбүзәр, аяк астында туфрак булыйм. Күңелгә кире какма сүзләремне!

Әллә кайчаннан бирле бер сорау кытыклап тора күңелне. Түзмәдем:

— Кем соң ул? — дигән сөаль ычкынды авыздан. Ниемә кирәк иде миңа аның кемлеге? Үзем дә белмим.

Мәдинә, башын түбән иеп, бик озак дәшми торды. Беркавымнан соң гына әйтә куйды әкрен тавыш белән:

— Син аны беләсең... Тәхәветдинов... Әгәр Бишбалтадагы бер кичәне онытмаган булсаң... хәтерләрсең... Миңа «кош теле» язучылар арасында ул да актив иде...

— Туктале, тукта, соң ул бит Казанда шагыйрь булырга йөри иде түгелме? Һәм син аны яратмаган кебегрәк идең бугай? — дидем мин кабаланып.

Мәдинә елмаенкырагандай сыманрак итеп куйды.

— Мин яратмасам да, әни яратты шул... — диде ул боек кына тавыш белән. — Мәскәүгә күчеп эшли башлагач юнәткән ике бүлмәле, ванналы квартираны яратты, үзенең «Кинопрокат» директоры булуын яратты. «Моннан да кулай кешене каян табарсың, диде, үзе директор, үзенең Мәскәү хәтле Мәскәүдә ике бүлмәле, ванналы фатиры бар! Үзе тагын шигырьче дә икән. Күр дә тор, сине дә шундый нәмәрсәкәйме, йә кинада уйнаучы артистмы итәр әле. Акылың булса, минем сүземне аяк астыңа салма, кызым, атаң да бик яратты кияү буласы кешене...» дип, көн-төн башымны кимерде. Былбылый иптәш үзе дә көн саен дигәндәй килеп ялынды, вәгъдә итмәгән нәрсәсе калмады... Үзең дә беләсеңдер, Әбүзәр, нишли ала соң кыз бала? Укуымны бетергәч, дип ризалык бирергә мәҗбүр иттеләр... Ә инде Ленинградта укырга урнаштыруда син ярдәм иткәнне ишеткәч, атна саен килеп җылады: «Бер генә елга булса да отпуска ал, өйләнешик, язылышыйк, сөекле хатыным бул, аннан укырсың», дип, укуны ташларга мәҗбүр итте... Менә шул...

Кинәт бу кызны кызгану хисе уянып китте миндә. Урындык алып, каршына утырдым. Мәдинә минем кул өстенә кулларын салды һәм дәвам итте:

— Өченче көн мин бер төш күрдем: матур җәй көне. Без, имеш, синең белән яңа гына өйләнешкәнбез һәм, туй сәяхәтенә чыгып, синең туган якларыңа килгәнбез. Анда без теге бәхетле көннәребездәге шикелле җитәкләшеп, болыннарда йөрдек, әллә нинди матур чәчәкләр белән бизәлгән яшел тауларга мендек. Һаман җитәкләшкән килеш ул таулардан йөгереп төшеп, син сөйләгән Баллыяу елгасында сулар коендык, ак көймәдә йөрдек. Шунда безнең ул ак көймәбез ак канатлы ак торнага әйләнде дә безне әллә кайларга очырып алып китте... Шуннан без — мин туган Эстәрле якларындагы төнбоеклы түгәрәк күлләрнең берсенә килеп төшкәнбез, имеш. Ак торнабыз тагын ак көймәгә әйләнгән, имеш. Безнең тирә-ягыбызда аккошлар йөзәләр һәм безгә карыйлар да озын ак муеннарын күкләргә сузып, шат тавышлар белән куанышалар, имеш. Мин шунда уянып киттем дә тирән уйга баттым... Нигә мондый төш кирә?.. Юк, безнең язмышыбыз мәңгегә бергә булган, тик яшьлек җүләрлегем белән ялган бизәкләргә кызыгып, мин генә

аны җимерергә маташканмын. Ә ул һаман җимерелми, син һаман йөрәктән китмисең... Менә шул төш, Әбүзәрем, монда килергә тәвәккәллек бирде миңа. Язмыштан узмыш юк, диләр. Элекке изге һәм бәхетле хисләребезне кире кайтару мөмкинме?.. Хәер, аларны кайтарасы да юк, алар икебезнең дә йөрәк түрендә генә, тик ирек кенә бирәсе бар ул изге хисләргә! Мин үземнең киләчәгемне тик синең белән генә күрәм һәм сине яратып, сиңа тугры булып, мәңге бергә яшәүне үземнең иң бөек бәхетем саныйм...

Мәдинә, кабаланып, кайнарланып шулай сөйләде дә, беравыкка тынып калды. Озынрак тоелса да, аның йөрәгеннән җыр булып агылган бу матур әкиятне тыңлау бик-бик рәхәт иде, башларың әйләнүдән исереп китәр дәрәҗәдә татлы иде. Татлы булса да, уянырга туры килде. Бер хәрәкәтсез онытылып утырган җиремнән кинәт турайдым да Мәдинәгә карадым. Аның җавап көткән үтә зәңгәр күзләре миңа төбәлгән иде...

Җавап? Һай, ул җавап!.. Тар гына бүлмәдә ишекле-түрле атлый башладым, тау күтәргәндәй авыр иде уйлар. Төзәлмәгән икән яралар. Бу кыз ниләр генә сөйләсә дә, кабат ышанмау — боз шикелле туңдырып тора иде йөрәкне. Ниһаять, башны селкеп куйдым, сүзләрем кырыс чыгасын алдан ук сизсәм дә әйттем:

— ... Үзе егылган җыламас, дигәннәр бугай... Акыл сата димә. Тиз кабынучан һәм тиз сүнүчән хисләргә бирелеп, бер хатадан икенче хатага ташланмыйк, Мәдинә... — дидем. — Кин дөньядан үзе читлеккә барып кергән кошчык аны тарсынмастыр дип уйлыйм...

— Юк, Әбүзәр җаным, алай түгел, мин бик күп уйладым... Мин аны яратмыйм! Мин тик сине генә...

— Син яратмасаң, ул яратадыр. Яраткан кешенең бәхетсезлеккә төшүе никадәр авыр икәнен мин бик яхшы беләм... Син, бәгырькәй, миңа мөнын бөтен ачылыгын йоттырдың. Инде аны да бәхетсез итикме? Кирәкми... Килешерсез, нәниләрегез булыр, тату гомер кичерерсез... Юк, мин карак түгел, кеше бәхетен урлыйсым килми...

Бу сүзләр аның хатын-кыз горурлыгына тукыну булып ишетелде, ахры. Чиксез җәберсенгән тавыш белән әйтте:

— Таш икән бәгырең! — һәм тагын үксеп җибәрде.

Аны юатырдай җылы сүзләр бу юлы да табылмады миндә.

— Сүзләрем кискен чыккан булса, гафу ит, — дидем. — Башкача булдыра алмадым. Бәгырем таш булмаса да, йөрәк күмер генә шул хәзер... Аны тергезергә нинди утлар табылыр — әлегә билгесез...

Мәдинә үз-үзен кулга алырга, үпкә хисләрен яшерергә тырышты, хәтта, елмайгандай итеп, урыныннан кузгалды.

— Очрашканда исәнләш, ичмаса, авыр чакларымда киңәш сорап килсәм, борып җибәрмә, — дип кул бирде дә, горур адым белән чыгып китте.

Чыгып китте... һәм... мине җиргә егып китте! Күпме тыныч булырга, таш бәгырьле булып кыланырга, чын хисләремне аяк астыма салып таптарга тырышсам да, булмады! Ул чыгып китүгә артыннан ишеккә ташланырдай атлыгып калдым. Сүнеп килә торган янартаулар күңелдә яңадан кабынган икән, ут давылы кабат дулый башлады... Ул утырган диванга килеп капландым да үкенергә тотындым. Кеше, гәүһәр ташыдай мең чаткылар чәчеп торган саф йөрәген учына салып, күз яшьләре белән синең каршыңа килгән, ә син аны, суык вәгазь-нәсихәт укып, кире кактың! Эх, син!..

Әмма күпме үкенсәң дә, кая ташланырга, җанны кая куярга белми күпме йөрсәң дә — соң иде инде...

Ихтимал, шулай кирәк булгандыр, шулай дөрес булгандыр...

Давыллар барыбер кайчан да булса бер тына икән... Тормыш миңа гади генә, әйбәт кенә бер дус бирде...

Мәдинә дә шул кешесе белән гомер итә дип ишетәм. Тик очрашырга туры килгәне генә юк. Төрле калада яшибез...

Бәхәс чишелмәде әле. Берсе: «Яшел төлке» ди, берсе: «Зәңгәр күке» ди. Чын сөю барлыгын Ихсан үзенчә исбатлап күрсәткән иде, Әбүзәр агай аның киресен әйтеп бирде. Әнә хәзер Акбаш-Шәңгәрәй сүзгә кереште.

— Чын сөю бит караблар янса да, әллә нинди ачы язмышлар аерса да

## Барыбер сүнми...

Шәңгәрәй үз хикәясен шул ике сүз белән башлап җибәрде.

— Мин авылда туып үскән малай... — дип дәвам итте ул аннары.— Егерме бишенче елның кышы иде. Кантон каласында укыган җиремнән каникулга кайттым. Үземә калса шәһәрләшеп бара торган укымышлы егет булсам да, туган як барыбер сагындыра, озаграк кайтмый йөрсәң, Тубылгыярда әллә нинди искиткеч яңалыклар булгандыр кебек тоела башлый иде...

Кайттым да, дәү абыйның олы малае Вәсим белән гармун күтәреп, төнге авыл буйлата чыгып киттек. Вәсим гармун колагын шактый ук шома тарта иде, шуңа күрә аның яшьләр арасында дәрәҗә юк түгел икән. Каравыл өе янында безгә авылның берничә егете кушылды. Авызларны урамның иненнән-иненә дигәндәй киереп җырлый-җырлый, югары очка менеп киттек. «Шәһәрләшкән» егет өчен кыргый иде бу. Кыргый булса да, матур иде, кызык иде...

Зәп-зәңгәр аяз төн. Түп-түгәрәк олы көмеш подностай айны нәкъ күк уртасына элеп куйганнар. Кырыйларына учлап-учлап алмаз белән бриллиант ташлары, ераккарак вак-вак утлы күмер сипкәннәр. Урамнарга түшәлгән кар да сыек сөт төсле зәңгәрсурак булып күренә. Үзе, аяк баскан саен, каен тузы шикелле шыгырдый. Киереп ачып җырлаган авызлардан тәмәке төтене булып зәңгәр пар бөркелә.

Бер әйләндек, ике әйләндек. Йөри торгач, аркаларга суык тәпиле таракан йөгерә башлады. Кайтып китәргә иртә. Кайда кереп жылынырга соң?

— Гөлнисаттәйләрдә юк микән берәр нәрсә? — диде теге егетләрнең берсе.— Анда кызлар еш кына кич утыручан була...

Гөлнисаттәй, ире тифтән үлгән, яманаты чыкмаган, ике кызы житеп килә торган әйбәт кенә тол хатын. Авылның инешкә башлаш түбән урамында яши иде ул. Шунда киттек. Безнең бәхеткә, чынлап та, анда дүртбиш кыз кич утыра икән. Тасма телләрне сузып ялына торгач, керттеләр безне.

— Әйбәт кенә утырыгыз түлке,— дип, Гөлнисаттәй үзе мич башына менеп ятты. Карт сөякләрен йомшартырга.

Җылына төшкәч, күзләр ачылып китте безнең. Һәм мин мич буендагы ушага утырган килеш, үзем танып бетермәгән бер яшь кенә кызга карадым да таң калдым. Ул йөзлек буенда, бик матурлап бизәкләнгән каба төбендә, миңа каршы гына утырып җеп эрли. Аның бөтен килешкилбәте нәкъ җырлардагы шикелле: тыгызлыгы һәм кайнарлыгы сизелеп торган ике бите — алсу алма. Нечкә кыйгач кашлары — карлыгачның канат очы. Керфекләре гүя сөрмәле, шулар астыннан караган шомырт кара күзләреннән менә-менә якты нур тамчылары сибелеп төшәр төсле. Буеның дингез камышыдай зифа икәнлеге каба төбенә утырган килеш тә күренеп тора. «Йа, сөбханалла! — дип сокланам мин картлар-

ча. — Кайчан туып, кайчан үскән бу? Менә, әйттем бит, кайтмый торсаң әллә нинди яңалыклар булып бетә шул. Күрми дә кала язганмын! Моны бит үткен тырнаклы, ач күзле тилгәннәр хәз-зер күтәреп сызачаклар! Әллә башка авыл кызы микән соң бу? Үзенә, күп булса, унҗидедер, алай булса әле! Ә үзе — пешкән кура җиләге!..

Кыз да миңа күз төшергәли башлады сыман. Бер дә сиздермәскә тырыша үзе. Әлеге сихерле керфекләрен, мин башкалар белән сөйләшкән арада, сирпеп-сирпеп кенә алган була. Ә мин барыбер күреп өлгерәм һәм тегенең күз очларын тотып алам. Әйтерсең качышлы уйныйбыз. Ул үзенең тотылуыннан уңайсызланып, кызаргандай булып китә дә эз генә елмаеп куя. Аның саен матурлана ул, нур өстенә нур түгелә. Эх, шундый вакыт сайратып кына сөйләшә бел иден! Күңелемә ошаган кыз белән сөйләшергә кирәк булганда, бал күреп телен йоткан малайдай, сүз таба алмый гаҗиз була идем мин ул чакта. Шулай гел югалып калмадым. «Кыз янына кергән чакта тел ачкычы бир, ходаӣ!» дип, эчемнән генә тели-тели хәрәкәтләнә бирдем.

Ул арада йөзек салышлы уеннарга тотындылар. Кабалар, тәрәшле, орчыклар түргә этәрелде, барыбыз да йөзлек буена тезелешеп утырдык. Вәсим әкрен генә гармун сыза, ә Гөлнисаттәйнең олы кызы җырлап йөзек сала. Минем яндагы бер егет сикереп чыкты. Йөзек аңа салынган. Һәркемнең учына йөзек салган булып ул йөри хәзер.

Төлке кергән абзарга,
Тимәс микән казларга...

— дип көлдерде бу. Аннары җырның ахырын кинәт кенә икенчегә борып җибәрде:

... Теләр идем, гүзәлкәем,
Сине генә назларга!..

— һәм әлеге кыз алдында тукталып калды. Мин кинәт бәкегә төшкәндәй булып киттем: «Ах, үләт тигере, ярата икән! Әллә йөриләр дәме?..» дип уйлап та алдым. Ә кыз, оялгандай гына итеп, сөрмәле керфекләрен түбән төшерде, тиз генә сикереп тә чыкмады. Мин дә аска карап кына утырам, мәгәр тегенең хәрәкәтләрен күзәтергә барыбер җай табам. Шулай бит ул: яраткан кешеңнең нишләвен ниндидер дүртенче күз белән дә күреп торасың.

Кызлар аны кыстый башладылар:

— Я инде, Зөлхи, көттермә!..

— Ялындырма! — дип кычкырды егетләр дә.

Әһә, Зөлхиҗә икән! Нинди матур исем!

Ул, җитез генә кузгалып, аягүрә басты һәм җырлап йөзек салырга тотынды.

Ап-ак итеп карлар яуган,
Яумаган үзәннәргә.
Нигә болай күңеле сүрән,
Ни булган гүзәлләргә...

һәм... йа хода, нинди бәхет бу! Зәңгәр фирәзә кашлы көмеш йөзек минем кушучка килеп төште!.. Йөзек түгел, учыма күктән утлы йолдыз төшкәндәй, сикереп тордым, кыз минем урынга утырды. Ә мин, кулымдагы нәни генә йөзекне әйләндереп карый-карый, уйга калдым. Җыр белән җавап бирергә кирәк бит, ә ул җырны ничек табарга? Дөрес, мин каз көткән чакларда байтак кына җыр белә идем, аннан соң да ишеткәләгәнем бар. Әмма менә иң кирәклесен генә каян алырга соң? Үзе нинди мәгънәле итеп әйтте бит: ник ачылып сөйләшмисең, ник елмаймыйсың, әллә безне тиңсенмисеңме, янәсе. Тиңсенмәгән кая инде ул! Әгәр минем иркемдә булсаң, башыңдагы аксыл-зәңгәр шәльяулыгың

төсле шушы төндә, шушы бәхетле минутта ук күкрәгемә кочтырыпмы, патша кызыдай җилкәмә утыртыпмы — җир читенә хәтле алып китәр идем!..

Нинди генә җыр белән җавап бирим соң?.. Шул чакта әллә йөзләп җырны күңелдән кичергәнмендер тагы, тик берсе дә ошамады, ә җавапны тизрәк бирергә кирәк иде. Җитмәсә, шунысы бит әле аның: шул бер җыр синең язмышыңны хәл кылуы мөмкин: я беттең, я кыз күңеленә кереп утырдың! Күрәсең, теге малай белән алыш-биреше юк булса кирәк аның. Күңелен ничектер мин кытыклаганмын, ахры. Шуннан соң тоттым да үзем укмаштырдым җавапны. Укыган егет бит, шүтке түгел!

Күзләремне талдырсам да,
Карап туймам йөзенә.
Күңел тулы серләремне
Әйтермен тик үзенә...

Шулай дип җырладым да йөзекне кыз учына салдым. Җыр, билгеле, шәп түгел, ясалмалылыгы күренеп тора иде, шулай да кыз кире какмады, яңадан җитез генә уртага чыгып җырлый башлады.

Әмма бу хәл бүтәннәргә ошамады. «Гел кара-каршы җырлашуга киткәч, кызыгы юк!» дип, уенны сүттеләр. Таралыша башладык. Кызлар безне озата чыкты. Өйалды караңгысында мин Зөлхиҗәнең кулын эзләп таптым, ут күк иде ул. Минем кысуыма ул да, әз генә кулымны кысып, җавап бирде. «Сөеклем!» дип пышылдадым. «И алдакчы!» диде. «Тагын кайчан күрем мин сине?» дидем. «Качып барганда», диде. Әмма болай сүз уйнатып озак тору мөмкин түгел иде, егетләр инде урамга чыкты, кызлар өйгә кереп китте, ә минем Зөлхиҗә күлмәкчән генә. Шулай да мин аны ычкындырасым килми, өйалды караңгысында минем кыюлык арта гына бара, «Кер минем куенга» дим, пальто чабуларымны чишеп җибәрәм. «Акылың алтын икән, куенын салкын икән», ди дә бу, өйгә керә дә китә...

Менә бит ашыгу нишләтә! Мин ут йотып урамга чыктым, тегеләр артыннан куып җиттем дә кычкырып-кычкырып җырларга тотындым. Йөрәккә, чынлап та, ниндидер ялкын кабынды, шуны басылдырасы килә. Ничәнчедер этәч кычкырганда өйләргә таралдык. Таң атканчы күз йомып булмады. Торып чәй эчтем дә су юлына киттем. Зөлхиҗәне күрәсе килә. Безнең Тубылгыяр Күшинеш суының ике ягына утырган. Кыш көне арьяк кызлары, боз өсләтеп, бирге яктагы олы чишмәгә йөриләр. Шуларның сукмагы тирәсендә чуалам, бозның көрт салмаган җирләре көзге шикелле ялтырап ята, шунда шугалап алам. Бервакытны минем янга малайлар җыела башлады. Шудырма шуып, шар сугарга тотындылар. Мин дә катышып киттем. Ике-өч сәгать шулай тырай типкәнмендер, әмма Зөлхиҗә күренмәде. Мескен булып өйгә кайттым.

Күңелне кая куяр җир табып булмый. Төштән соң күрше Нәгыйм абзыйның киң табанлы имән чаңгыларын кидем дә (ул куян куарга яратучан кеше иде), Яңатауга киттем. Ни өчен алай дип атаганнардыр. Әйтерсең тауның яңасы яки искесе булуы мөмкин! Хәзер дә белә алганым юк әле мин моны. Сөзәк булып әллә кайларга менеп китә ул Яңатау. Түбәсеннән үк шуып төшәргә малай чакта ук кызыга идем, йөрәк кенә җитми иде тик.

Минем тирәгә тагын малайлар җыелып алды. Хәер, алар тауның чирегенә дә менеп җитмичә, үзләренең аннан-моннан гына әмәлләгән бәләкәй, кыска чаңгылары белән мәтәлә-түнә төшеп тә киттеләр. Гайрәт җитми юеш борынлы егетләрнең! Ә мин түбәнең иң очына хәтле мендем дә, аякларны без катырып, чаңгы таякларын очар канат итеп, түбәнгә томылдым. Хәтәр дә, рәхәт тә икән биек таудан шуу! Альпинист! Болынга төшкәч тә ярты чакрым шуып барганмындыр.

Шулай бер төштем, ике, өч төштем. Төшүе шәп булса да, менүе читен, күп вакытны ала. Кич булды, ап-ак кар өстенә күгелҗем төс җәеп, әз генә күләгә ята башлады. Кайтырга кирәк. Мәгәр каршыда тагын бер текә тау бар. Бакырлы тавы дип йөртәләр. Анысыннан да бер җилеп төшәсе килә. Чаңгыларны күтәрдем дә бер кырыйлатып менеп киттем. Түбәгә үк менеп җиткәч, тауның нәкъ авыл каршындагы урта бер җиренә бастым да, чаңгыларны беркетеп, таякларымны артка сузып төшеп тә киттем. Тауның урта сыртына килеп кенә җиткән идем, чаңгылар кинәт өскә сикерделәр. Әйтерсең трамплиннан очып киттем! Очып та киттем, мәтәлчек атып, баш белән тирән карга килеп тә чумдым. Чаңгы беркетелгән аяклар кар өстендә тырпаеп калды, күрәсең. Сизәм, читтән карап торган кешегә минем бу хәл бик көлке тоелгандыр, чөнки үзем дә, кар астыннан чыгып аякка баскач, бот чабып көлдем. Таяклар икесе ике якта ята, бүрек әллә кая тәгәрәп киткән, чәчләр бозланып каткан, баш юеш булгандыр инде. Тауның нәкъ шул сыртына гына күп итеп киртләч кар өйгән икән каһәр. Ә мин аны кичке якта күрмәгәнмен. Шулай үземнән көлә-көлә әйберләрне җыеп алдым да кайтып киттем.

Ә моны су китерүче кызлар чишмә башыннан карап торганнар икән. Зөлхиҗә дә шунда булган. Башкалар ихахайлап тел шомартып торган арада бу, бернәрсәгә дә исе китмәгән булып, буралы чишмәдән су алып маташа икән. Тегеләр:

— Ай, егылды, мәтәлә-кадала барып төште! — дип кычкыруга, Зөлхиҗәнең сулы чиләге көянтә башыннан чишмә төбенә чумган. Менә көлә башлаганнар:

— Нәрсә булды, наныкаем, нигә каушадың? — имеш. Фәлән дә фәскать. Күзен дә ачырмыйлар икән мескеннең. Чиләген эләктереп чыгара алмыйча тик җәфалана, имеш.

Иртәгесен безнең яшь җиңги бөтенесен миңа сөйләп бирде моны. Ә мин тилебәрән орлыгы ашагандай шашынып, эчә торган чынаягымны да бетермичә, өйдән чыгып йөгердем. Озын сүзнең кыскасы, дигәндәй, эзләдем, таптым, күрдем. Хәзер инде мин аның Гөлнисаттәйләр күршесендәге Сәйфи абзый кызы икәнен белә идем. Гөлнисаттәй кызы аркылы аларга чакырттым. Зөлхиҗә сүс төяргә керде. Без аның белән кышкы лапаста кара-каршы басып, ефәктәй җитен сүс төябез. Икебездә ике киле сабы, имән киле төбендә яткан учмаларны алмаш-тилмәш дөңгечләгән булабыз. Күзләр күздә. Ике кояш ике йөздә, авызлардан ак пар бөркелә. Юк, ак пар булып безнең күңел түрләреннән җылы, татлы сүзләр агыла. Эх, егетләр, шуннан да күңелле, шуннан да бәхетле чаклар булды микән бу дөньяда!..

Шулай итеп, йөрәктәге серләр чишелде, ул да мине ярата икән булып чыкты! Чиләге төшеп киткәч, оялуыннан кая керер урын тапмаган. Ник алай тиле кыланасың, дип, мине әрләп тә алды. Сайраштык, серләштек, кич саен күрешергә сүзләр куештык.

Мин хәзер кичтән үк чыгып югалам. Иң элек кибетче Шәйдигә керәм дә, бер кесәгә канфет, бер кесәгә прәнник салам. Кочаклар җылысында җыр булып агылган сөю сүзләренең иге-чиге булмый. «Мәңге, мәңге бергә булырбыз!» диген кайнар вәгъдәләр дә бозылмас закон булып йөрәкләргә язылган инде. Тиздән киләсе бәхетле көннәребез турында сөйли-сөйли таңнар җиткергәнебезне сизми дә калабыз. Ярый әле, гашыйкларның төнге сагында этәчләр бар. «Кикри-күк!» дип, алар өч тапкыр кыркыткач, аерылышырга туры килә. Куркыныч барын белгертәләр ич. Олы түгәрәк бакыр подностай кызарган айны күл читенә бастырып өйгә кайтканда, ике кесә дә кап шикелле кабарып, ядрәдәй тук төшле сап-сары чикләвек белән тулган була. Иртәгесен мин аны бик ләззәт белән чикелдәтеп вата-вата ашыйм.

Ул кесәләрдә канфет-прәнник кенә йөрмәде, әлбәттә. Исле сабын, ислемай шикелле нәрсәләр дә Зөлхиҗәне куандыралар иде. «Үпкән-

кочкан — җилгә очкан» дигәннәре дөрес түгел, егетләр. Зөлхиҗәнең иркә җылысы әле дә кочагымда саклана кебек! «Яшь кызларны үпкәнем бар: авызы шикәр, теле бал» дип җырлаулары бигрәкләр дә дөрес мәнәтерә. Зөлхиҗәнең дә нәкъ шулай иде!..

Ул арада булмады, «Без өйләнгәч төн кыска булды» дигәндәй, каникул узып та китте. Ә мин — комсомол кеше, кантон педтехникумында укыйм, киләчәктә укытучы буласы. Димәк, дисциплинага алдан ук күнегергә тиеш. Иртә таңнан ук юлга чыгасы булгач, Зөлхиҗә белән актык мәртәбә күрешергә киттем. Күңелдәге иң кадерле сүзләремне әйтәсе бар... Ә ул мине тыңларга да теләмәде.

— Юк, Гәрәй абый, иртәгә китмисең, — ди. — Иртәгә әтиләр Шүләнгергә кунакка китә, берме-ике кичкә куна баралар. Ә без монда аулак өй ясыйбыз. Иртәгә кич үк кызлар җыям, синең өчен генә җылгыр[1] пешерәм,— ди.— Ә бүген, бар кайт, мин әтиләрне мунча кертәм, үзем дә корымлы да сөремле! — ди.

Шулай итеп, китте дә куйды. Дисциплина дигән сүзне ишетергә дә теләмәде. «Андый читен сүзләрне әйткәндә ничек телең сынмый», дип көлә тагы үзе. Бераз хәтер калды калуын, шулай да муенчаклаган бозау хәлендә идем мин: ул кая сөйрәсә, шунда барырга әзер.

Иртәгесен көне буе буран булды. Кичке караңгы төшү белән, боз өсләтеп кенә аулак өйгә киттем. Сукмак бөтенләй югалган, боттан диярлек кар ерып барам. Мин килгәндә, кызлар гына иде әле. «Ник таң белән үк килмәдең, Шәңгәрәй абзый? дип көлделәр усаллар. Ну, егетләр озак көттермәде, «эһ» дигәнче өй эче шыгырым тулды. Китте җыр, китте уен. Йөзек салышлы да, түгәрәкле дә, почталы да, арка сугышлы да — берсе калмады. Шуннан соң бөтенләй көтелмәгән бер яңалык булды. Зөлхиҗә белән Гөлнисаттәйнең ике кызы кече якка кереп киттеләр дә, нидер пышын-чашын килеп, яңа күлмәкләр, укалы хәситәләр, энҗеле калфаклар киеп чыктылар. Өчесе дә берочтан киенгәннәр. Зөлхиҗә, йөзлеккә утырып, бик матур бер кыска көйгә кубыз чиртә башлады, ә тегеләр икесе, итәкләрен җилфер-җилфер китереп, биергә тотындылар. Без авызларны ачтык та калдык. Ул чакта безнең авылда кызлар бии торган гадәт юк иде әле. Егетләр дә җыен-сабан туенда гына «чабата көе»нә селкенгәли иде. Шуңа күрә без күргән күзләребезгә ышанмадык. Аннары Зөлхиҗә үзе төшеп биеде, тегеләре пар кубыз чиртеп торды. Аның зифа буеның, тал чыбыктай нечкә биленең сыгылма хәрәкәтләре, наз тулы муен борылышлары урман күле читендә аккош биюе шикелле тоелды миңа. Искиткеч матур концерт булды бу...

Инде уйнап, җырлап тәмам арыгач, җылгыр белән сыйладылар, чәй эчерттеләр безгә. Эх, ул җылгырны тагын бер генә авыз итсәң иде, егетләр! Тел өстендә эреп кенә югала иде ул!..

Инде таралышыр вакыт җитте. Зөлхиҗә миңа күз кысты: алдан чыгып кит, янәсе. Минем арттан өйалды ишеге бикләргә чыкты.

— Лапаста бер йөк салам бар, кер дә чум шуның эченә,— диде.— Без егетләрне озатып бетергәч, тавыш-тын басылу белән ян тәрәзәне чиртерсең, чыгып алырмын, — диде.

Ятам мин лапастагы салам эчендә. Бөтенләй күмелеп беттем — борын белән күзләр генә калды. Ә тегеләр, өй белән тыш арасында һаман киләп сарып, сайрашалар да серләшәләр. Егетләрнең китәсе килми, сагыз шикелле сыланырга маташалар. Кыз кочагы бит ул, аның җылысына кем генә сыенырга теләмәс! Ә кызлар карышадыр, яманат чыгарудан ходай үзе сакласын!

---

[1] «Ару оны» камырының эченә киндер орлыгы төше салып, казан парында гына пешерелә һәм шул орлык мае белән ашала торган вак «бөккән» дияргә мөмкин. *(Автор.)*

Минем аяк-куллар, аркалар буйлап бозлы тараканнар йөгерә башлады, туңам һәм үземне әрләргә тотынам:

— Син бит комсомолец, аулак өйләрне пыр туздырып, тиргәп йөрүче идең. Нишләп ятасың монда, корчаңгы бозау шикелле, салам эчендә? — дим.— Әдәм көлкесе, калада иптәшләрең белсә?.. Комсомолдан «чәчәк аттыралар» бит сине дә! — дим.

Эчтән икенче тавыш юаш песи шикелле генә мияулый:

— Соң, клуб булмагач авылда... — ди. Тагын әллә нинди акланулар тапмакчы була...

Ә тегеләр һаман таралмыйлар, ә минем тешләр тешкә орына: шыкшык-шак! Дерррр-дерр! Менә, ят салам эчендә бур мәче шикелле күзләреңне елтыратып. Синнән дә ахмак кайда бар?..

Ниһаять, кызлар инде үпкәли, ачулана башлагач кына, теге сагыз егетләр, гармуннарын чыйкылдатып, югары урамга табан менеп киттеләр. Тиз генә чүмәлә эченнән чыктым да тәрәзәгә йөгердем. Минем өс-баш гел салам, якада башаклар, күз һәм борын төпләрен, муеннарны кылчык чәнчә иде, әмма кагынып торырга рәт калмаган, тәмам шакырайганмын. Боздай каткан бармакларым белән пыялага чирттем. Зөлхиҗә йөгереп чыгып өйалды ишеген ачты. «Туңдыңмы, җаным?» ди.

— Юкы-кы-кык, — мин әйтәм, — мымымы-май күкеке-күк эреп кенә яттым!

Ә ул рәхәтләнеп көлә-көлә мине караңгы өй эченнән кече якка алып кереп китте. «Хәзер җылынырсың», ди пышылдап. Өсне салып аттым да йомшак урынга чумдым. Әллә нинди мамык мендәрләр салып, кабартып җәйгән бит! Һәм боз күк гәүдәмне үз куенына кысып, кочаклап алды ул. Бу минутта миңа тизрәк җылыну кадерле иде. Шуңа күрә кызның кайнар кочагы уттай кызган тимер мич шикелле булып тоелды миңа.

— И гөлкәем, — дип пышылдый Зөлхиҗә, — бөтенләй өшеп беткәнсең бит, — ди, аркаларымнан сөя, кайнар беләге белән боз муенымны кыса, битләрен суык битемә куя. Майдай җылы күкрәкләрен түшләремә кысудан да тартынмый. Бар икән дөньяда рәхәтлек! Бар икән дөньяда шулай кайнар сөя белүче җан иясе! «Әгәр көн саен моны кабатлау мөмкин булса, мин һәр вакыт кар астында ятарга да риза булыр идем!» дип уйлыйм.

Ниһаять, тора-бара кеше хәленә килдем. Кешечә хисләрем уянды. Чиктән ашкан яратуым белән үзем аны сөя, иркәли башладым. Ул шаянланып, тагын да сөйкемлерәк, сөеп туймаслыграк булып китте. Шуннан соң ул урыныннан калыкты да, шүрлектән нәрсәдер үрелеп алып, миңа бирде. Баш очында гына түр тәрәзә иде, шуның шәүләсендә әйбернең нииндидер бизәкле булуын шәйләдем. Сүтеп карасам, таң алды төсле бик йомшак батистка чигелгән кулъяулык булып чыкты ул. Бәләкәй тәрәзәдән төшкән зәгыйфь кенә төн яктысында аның чигешләре әллә нинди сихри чәчәкләр булып, әллә нинди серле, тылсымлы бәхет юллары булып күренде миңа! Мин ул яулыкны битләремә, күзләремә каплап, аннан аңкыган хуш ис белән исергәндәй, урта бер җиреннән үптем дә, сак кына яңадан бөкләп артымдагы сандык өстенә куйдым, соңыннан кесәмә салам, янәсе. Аннары кызның үзен үбәргә тотындым.

Олы якта кызлар ята. Алар һаман чырк-чырк көлеп, сөйләшеп яталар. «Кияү белән кыз» дип безгә дә инәләрен җибәреп куйгалыйлар. Шуңа күрә без бик сак кыланабыз. Хисләребез артык ашкынулы булса да, авызлыклап тотабыз, дөбер-шатыр килү, ишеттереп сөйләшү юк. Әйтмәсеннәр безне начар кешеләр дип.

— Минем төсем итеп тот, яме... — дип пышылдый Зөлхиҗә. — Кесәңдә генә йөрт, кулыңа тигән саен алып кара... Шуннан мин төшәрмен синең исеңә. Онытмаска әйбәт булыр...

— Онытаммы соң, бәгырем! — дим мин.— Син минем мәңгелек ярым!..

— И, арттырасың инде бигрәк... — ди кыз. — Китәрсең дә көлеп йөрерсең әле... аннары гел онытырсың!..

— Ышту син, — мин әйтәм, — честный комсомольски! Оныту кая инде ул. Мин синнән башка яши дә алмам төсле хәзер. Әйдә минем белән бергә китик! Бергәләп укырбыз, минем сине укытасым килә!... — дим.

— И, Гәрәй абый! — ди кыз, — бик китәрием кана. Мин шул укый да белмим, яза да белмим... Безгә эләкмәдә ич ул...

Минем йөрәкне әллә нәрсә тырнап алды. Шушындый матур кызның, җыр-музыка, сәнгать ярата торган гүзәлнең укымый калуы бик кызганыч булып китте. «Үзем өйрәтермен, үзем укытырмын!» дип пышылдадым мин, кайнарланып.

Билгеле инде, кыз алай гына чыгып йөрергә риза булмады. Мөмкин түгел иде ул, сөю кочагында туган хыял гына иде. Шуннан без сүз куештык: мин җәй көне укуларны бетереп кайтам да аны үзем укытам, этиләре бик каршы килмәсә, комсомолга кертәм, каршы килсәләр, ябыштырып чыгарам да бергәләп яңа тормыш корабыз.

Ул бер карусыз минем юлдан китәчәк булды.

— Җир читенә хәтле барырга да риза синең белән! — диде.

Сөйләшә торгач, сөешә торгач, ничәдер тапкыр әтәчләр кычкырганын да сизмәгәнбез. Тик өй эче тагын да караңгыланып киткәч кенә, олы яктан усал кызлар кычкырды:

— Әй, кияү белән кыз! Әллә төн кыска булдымы?.. Аерылышырга вакыт!.. Әнә бит таң алды караңгысы төште!..

Авызларына шайтан төкергән нәрсәләр, үзләре һаман чырк-чырк көләләр. Бер дә теләмәсәм дә, кайнар кочактан аерылып төн суыгына чыгып китәргә туры килде. Тышта буран һаман басылмаган икән, дөньяны кар баскан. Шулай да олы урамнардан әйләнеп йөрисе килмичә, боз өсләтеп кенә, көрт ера-ера, кайтып киттем. Зөлхиҗәләр бакча башыннан ага торып Кушинеш тармагы, дугайланып-дугайланып, безнең күршеләр бакча башына килә, чишмә сукмагы да шул тирәдән уза. Мин шул сукмакны капшый-капшый алга атлыйм. Аръяк болындагы Ерак чишмә ягыннан килә торган умрак җил әле бүрекне умырып китәргә чамалый, әле арт чабуларга китереп суга да тез асларын сыгылдырып куя, әле төерле карны биткә китереп бәрә дә күз төпләрен, колак-борыннарны чеметтереп ала. Күз ачкысыз буран дигәннәре шушыдыр инде ул дип уйлыйм мин.

Нәкъ шул чакта арттан, ерактан нечкә генә бер тавыш килә. Борылам, колак салам: «Гәрәй абый, Шәңгәрәй абый!..» дип кычкырган кебек ишетелә. Мин аптырап калдым: нәрсә икән бу? Кем кычкыра икән?.. Ул арада булмады: бәләкәй генә кара күләгәнең бата-чума миңа таба йөгереп килгәне аңлашылды. Мин дә аңа таба омтылдым. Менә каршыма күлмәкчән, оекчан килеш кенә йөгергән Зөлхиҗә килеп басты.

Ис-акылларым китте! Башына шәл дә бөркәнмәгән, ичмаса, маңгай өстенә генә беркеткән әлеге энҗеле калфактан гына! Тыны-көне беткән, үзе көлә, үзе мышный, үзенең ике бите уттай кызарып янганлыгы караңгыда да беленеп тора. Җил тузгыткан калын кара чәчләренә, нәзек кашларына бөрчек-бөрчек кар кунган: әйтерсең калфагындагы энҗеләре бөтен гәүдәсенә сибелгән иде.

Юк, аның ул секундтагы сихри матурлыгын һич кенә дә аңлатып бирә алмыйм мин хәзер. Әллә ул әнә шул Ерак болындагы Акчишмә әрәмәләреннән килеп чыккан тылсымлы бер төн кызы, әллә ул таудагы серле урманнар куеныннан йөгереп төшкән әкият кызы, әллә ул кышкы басулардан шушы буран, шушы җилләр белән уралып килгән кар кызы. Әллә инде безнең гади генә авылдагы гади генә йортлы, гади генә игенче Сәйфи абзыйның бер дә гади булмаган гүзәле — мине гашыйк иткән Зөлхиҗәсе! Ул вакытта боларны аеру минем көчемнән килми иде.

— Мә, Гәрәй абый, — диде ул әз генә үпкәле тавыш белән, — бүләкне ташлап китмиләр аны...

Үлдем дә киттем. Ай, мин тинтәк! Ай, мин тавык мие эчкән ишәк! Ул биргән чигүле яулыкны сондык өстендә онытып киткәнмен ич! Ул миңа шуны сузгач, оятымнан боз тишегенә кереп китәрдәй булдым, тик янда бәке генә юк иде. Ашыгычлык белән булган инде бу. Теге нәләт төшкән кызлар көлеп каушаттылар, ашыктырдылар бит. Рәнҗетүем өчен җыландай телләремне аяк астына салып, кичерүен үтендем, ялвардым.

Ә ул миңа җавап биреп тормады, үрелеп битемнән бер генә тапкыр «әп» итте дә көлә-көлә кире йөгерде.

— Тукта! — дип кычкырдым мин һәм, бер сикерүдә артыннан җитеп, пальто кисәгемне аның башыннан ук бөркәндердем дә, җил җинеллеге белән күтәреп җилкәмә утырттым һәм күз ачып йомганчы бакча капкаларына хәтле илтеп тә куйдым. Бөтен дөнья бөек һәм соклангыч бер матурлыкка чумган иде бу мизгелдә. Таң алдының күгелҗем-күе төстәге юка пәрдәсе безне үзенең серле куенына яшереп барды. Тантана белән генә уйнаклап очкан кар күбәләкләре өсләребезгә кунып, ак чәчәкләр белән күмә кебек иде безне.

Юк, сүз булмады бу мизгелдә. Сүзләр артык иде. Җилкә өстемә утыртып, ике яктан ике кулым белән аның кулларын тотып барам. Әнә шул куллардан килгән кайнар агым иң гүзәл бер җыр тудыра минем йөрәктә, мәңгелек бәхет җыры. Ә җилкәмдә килүче Зөлхиҗә үзе әкияттәге патша кызы Таңсылудай тоела миңа.

Тик бу бәхетле мизгел озакка бармады. Ул ашыкты: җилкәмнән сикереп төште дә «хуш, җаным-бәгырем!» дип, юкка да чыкты. Мин кулларымны гына сузып калдым. Ничек өскә кигәнемне, ничек кайтканымны да хәтерләмим...

Иртәгесен күршенең гармунчы Вәсиме калага алып китте мине. Чанага бәйләп салган сугым малы хәлендә идем: бөтен дөнья ямьсез, күңелсез, суык, боек иде миңа. Чанадан төшеп, каядыр, әллә кайларга качасы килә...

... Шушы урында Акбаш үзенең сәер хикәясеннән тукталып калды. Карчыгы тарафыннан көненә ике генә данә бирелә торган сигаретының берсен калтыранган куллары белән кабызды да, йотлыга-йотлыга суырып, дәррәү тартып та бетерде. Аның бу хәтле саксыз кыланганын моңарчы һич күрмәгән егетләр гаҗәпкә калдылар. Тартып бетергәннән соң да эндәшмәде ул. Чыраен төн төсле караңгылык басып алган иде. Сүз кушуы да уңайсыз иде аңа. Мәгәр хикәянең матурлыгына соклангнан Хәйбери түзмәде:

— Соң бит, бетмәде әле бу, ярты юлда калды! — диде.

Башкалар да егетнең кыз белән кавышу көннәрен көтәләр иде.

— Ярты юлда калды шул... Бөтенесе ярты юлда өзелде... — дип куйды Шәңгәрәй карт бик озак сүзсез торганнан соң. Аның артык сөйлисе килмәве күренә иде, шулай да безне кире кагарга базмады, ахры, дәвам итте:

— Авыл кулагының Бадамша атлы малае бар иде. Сазаган егет, суккан көлтә, башкисәр нәрсә иде. Шуның өстенә үзе яман да чибәр иде, каһәр. Шул чибәрлеге һәм явызлыгы белән бик күп авыл кызларының мескен башларына җиткән бандит дияргә дә ярый. Шуның Зөлхиҗәгә нәфсесе төшкән бит. Яучы җибәреп караган, бик күп маллар да вәгъдә иткән. Кыз бармаган. «Минем вәгъдәләшкән кешем бар» дип, туп-туры үзенә әйткән. Шуннан соң нәкъ иске авылдагыча хәл булган. Хәер, ул чакларда авылны әле бик үк яңа дип әйтеп тә булмый иде шул.

Таң белән кызлар талкы талкыганда пар ат җигеп, тагын бер сатлык егет утырып килгән дә, Зөлхиҗәне кычкыртып урлап, башка авылга чапкан. Шунда ук көчләп, «алдым-бирдем» ясатып, аны үзенә хатын иткән. Аннары өйләренә алып кайткан. Зөлхиҗә өч көн, өч төн беркая

чыкмыйча җылаган. Дүртенче көнне кичке эңгердә чишмә суына киткән җиреннән кайтмаган. Беркем күрмәгән кичке караңгыда бәкегә ташланган ул. Аның яртылаш кар күмгән чиләк-көянтәсен икенче көнне генә бәке яныннан табып алганнар. Бик борынгы, бик иске заманнардагыча килеп чыккан бу хәл. Бөтен якты өметләре, бөтен матур хыяллары пира-зара килеп тапталгач, шундый үлемгә мәҗбүр булган иде ул гүзәлкәй...

Зөлхиҗәнең әтисе Сәйфи абзый, күрше-күләнең җыеп, агым буена бозны ватып, багорлар, тимер ыргаклар белән өч көн эзләгәннән соң гына табып алган аның гәүдәсен. Кушинешнең тирән сулары шактый ерак агызган булган Зөлхиҗәкәйне...

Кантон каласы безнең авылдан кырык чакрым гына. Шулай да бу йөрәк яргыч хәбәр атна-ун көннән соң гына килеп ишетелде миңа. Акылдан шашкандай ярсып авылга кайттым, урамнарны, боз өсләрен, Зөлхиҗәләрнең йорт тирәсен, өйләрен әйләнеп-айкап чыктым. Беркайда да, бер генә сулышка да җаным тынычлык таба алмады. Үтермәкче булып теге бандитны эзләдем: аны кулга алганнар иде. Хәер, кул пычратудан ни файда соң? Зөлхиҗәкәй әйләнеп кайтмаячак бит, кайтмаячак!..

Төн уртасында торып зиратка киттем. Аның кабер балчыгын әле кар күммәгән иде. Хәтта суынып җитмәгән кебек иде әле аның кабер балчыгы! Егылдым да шул каберне кочаклап үкси-үкси еладым. Аны чакырдым.

— Ник дәшмисең, күз нурым?! — дип өзгәләндем.— Ник миңа хәбәр итмәдең, ник мине көтмәдең? Кайткан булыр идем, аңлаган булыр идем мин сине! Якты бәхетебезгә ул вәхшилек табы барыбер төшмәс иде!..

Кабер җавап бирмәде...

Күрәсең, ул чактагы унтугыз яшьлек авыл малаеның мәхәббәте һәм таудай хәсрәте шулай яшереп булмас дәрәҗәдә көчле булгандыр. Сез көлмәгез инде, егетләр, хәзерге Шаңгәрәй булса, ихтимал, башкачарак кыланыр иде. Һәм үчен дә кайтарган булыр иде.

Шул төндә мин яңадан авылга кайтып тормадым. Таң беленгәндә, Зөлхиҗә кабереннән кузгалдым да зират яныннан гына Чәрчә авылы үренә менә торган кыйгач юл белән китеп бардым. Укулар да калды, якты хыяллар да сүнде. Күз күрмәс, колак ишетмәс еракларга китеп олагасым килде. Җәяүле язмыш һәм бәхетсез язмыш мине таҗик илләренә китереп чыгарды...

Мәгәр яшьлектә кабынган саф сөю ялкыны барыбер сүнми икән...
Ул биргән чигүле яулык та озак еллар кесәмнән төшмәде. Фронтта да үзем белән иде ул. Кырык бернең кышында камалыштан чыкканда бер иптәшемнең өзелгән кулын бәйләргә туры килде аның белән.

Тетрәнгән хәлдә идек без. Кабат бер сүз дә эндәшмичә тын калдык. «Менә нинди икән ул!» дип уйладык. Кинәт үз булып, тагын да якын һәм аңлаешлы булып китте безнең Акбаш.

Ә бәхәс дәвам итте...

1974—1976.

## Шәүкәт Галиев

# БЕЗНЕ ЛЕНИН ҮСТЕРДЕ

## Ленин бабай икмәк бүлә

Ленин бабай әкмәк бүлә
Күкрәккә куеп кына.
Икмәк аның йөрәгенең
Җылысын тоеп тора.

Илнең ишле табынына
Тигез итеп бүләсе,
Өлешсез кала күрмәсен
Читтә-чатта берәрсе...

Элек гел бакырдан булса
Өлешкә тигән көмеш,
Бусы булыр иң гаделе —
Эшенә тигән өлеш.

Ленин бабай икмәк бүлә
Кадерен белеп кенә —
Валчыгын да исраф итми,
Бик тәмләп телеп кенә.

Ул якка да, бу якка да
Калынрак каермас ул,
Үзе дә аерым капмас,
Тамак та аермас ул.

Ленин бабай икмәк бүлә...
Белеп бүлер иде ул —
Җир шарын да гадел итеп
Бүлеп бирер иде ул.

Хәер, уйлап карар иде
Бүлү-бүлмәү хакында —
Бөтен көе бирер иде
Җирне хезмәт халкына!

... Ленин бабай икмәк бүлә
Күкрәккә куеп кына.
Җир шары юмарт йөрәкнең
Җылысын тоеп тора.

## «Бик мөһим дәүләт эше»

— Автомобиль!
— Автомобиль!
Онытыла кузналар —
Гүя машина җиленнән
Бөтен урам кузгала:

Тәпиләрен ялтыратып,
Тыннары каба-каба,
Машина белән ярышып
Бер көтү малай чаба.

— Абый, утырт әле! — диләр,
Җавап көтмичә генә,
Туктатыр диеп әллә ни
Өмет итмичә генә...

Шофер бик җитди, белсәләр
Барганны нинди кеше —
Вакыты да бик тар аның,
Эше дә дәүләт эше!

Ленин елмая: кара син,
Ничек шәп элдерәләр,
Машинаны якыннанрак
Күрик дип йөгерәләр...

Нәүмиз калдырып боларны
Ничек узасың җилеп —
Кагылды шофер иңенә,
Утыртыйк, әйдә, диеп.

Ачык машинага менеп
Малайлар кунаклады.
Каш җыерып кына шофер
Каршылый «кунакларны»:

— Эшем кешеләре, имеш,
Болар кая ашыга?
Ә малайлар, алга карап,
Сүзсез калган барсы да...

Ишеттеләр, шоферына
Әйтте мөлаем кеше:
— Киләчәккә ашыгалар —
Бик мөһим дәүләт эше!

## Безне Ленин үстерде

Биек-биек күтәрде,
Үчти-үчти иттерде,
Революция бишегендә
Безне Ленин үстерде.

Чөйде-чөйде югары,
Үсте-үсте иттерде,
Канат куйды күңелгә —
Безне Ленин үстерде.

Курыкмаска өйрәтте,
Очты-очты иттерде,
Галәмгәчә җиткерде —
Безне Ленин үстерде!

## Мәҗит Рафиков

# КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР

●

Җидеболак буе мәтрүшкәсен
Алып килдем җыеп Казанга.
Туган җирнең хуш исләрен иснәп
Рәхәтләнәм — чәйгә салам да.

## Җәлил һәйкәле янында

Чылбырларны өзеп,
Үлемнәрне җиңеп,
Дөнья яулаган хаклык —
Илем йөзенә аклык!

## КамАЗда

Гөрли төзелеш, яңара тормыш,
Хезмәте — ләззәт, яллары — рәхәт!
Тимер-бетоннар — каркас кына ул,
Эчтәлеге бит — дуслык, мәхәббәт.

## Үземә

Яшь талантлар ат уйната,
Аксакаллар алкышлый...
Яшь шагыйрь булып китсәңче
Алтмышларга барышлый!

●

Читтә йөреп тансыклаган кебек
Туган җирнең җимеш-җиләген,
Тансыкладым кузең карашларын,
Җылы кулларыңны, чибәрем.

•

Нахак бәла ягу бар икән,
Йорты ләхетләрдән тар икән...
Әҗәлдән яман нахакның газабы.
Туган чишмәләргә төшем куеп
Сулар эчәр көнем бар икән...
Татлыдан-татлы тугрылык савабы!

## Суша суына карап

Урман ярып аккан су,
Ярга тулып яткан су,
Таллар шаулап торган су,
  Кошлар сайрап торган су,
Камышлары үскән су,
Аккошлары йөзгән су,
Ак балык айкалган су,
Ак болыт чайкалган су, —
Шәрәләнеп ярлары,
Болганчыкка калган су!..

## Кәләш

Бабаң тапкан кәләшен
Печән җыюын күреп,
Атаң тапкан кәләшен
Чигү чигүен күреп...
Ник син дәштең бу чибәргә,
Урам гизүен күреп?..

•

*Кайсын ага Кулиевка*

Җаны бар кешегә
Ташның да җаны бар,
Ташның да ярасын
Бәйләргә җае бар.

•

Иртән эшли белмәгәннең
Күңел ачар киче юк.
Кешедән олы кеше бар,
Эштән олы кеше юк.

## Анаң яккан мич җылысы...

Анаң яккан мич җылысы,
Анаң җыйган табын яме,
Җыештырган өй эчләре,
Мендәрдәге йокы тәме —
Кайда алар?.. Барсы күчкән
Күңелеңә, кулларыңа.
Шул өйдән бит кеше булып
Чыктың тормыш юлларына.

●

Комбайннар гөрли, машиналар...
Игеннәр шәп! Нәрсә әйтергә?
... Көлтә ташыр атлар ут эчендә
Туп сөйрәгән юллар хәтердә...

●

И бу бакчада бишмәтләр ташлап,
Әкиятләр сөйләп, йолдызлар санап
яткан малайлар!..
Менә шул ук йорт, шул ук яшь чирәм,
Шул ук тулы ай, йолдызлар күрәм...
Сез соң кайларда?..

●

И куандың, и шатландың
Күреп тышкы чибәрлеген!..
И җәфалан, и хафалан
Татып эче зәһәрлеген!..

## Бер эгоистка

Бу дөньяда бер син генә түгел,
Күпләр сала тормыш нигрәсен.
Алар синнән башка яши бирер,
Син алардан башка нишләрсең?

## Ник шулай бу?..

Ник шулай бу? Бер мәхәббәт
Бар гомереңә нур ата...
Ник шулай бу? Бер хыянәт
Бар дөньяңны кыйрата...

●

Илем диеп,
Илгә яла яккан яман.
Пакьлек диеп,
Пычраклыкка баткан яман.

## Бер шагыйрьгә

Син очраган бер чибәргә
Җыр багышлыйсың гелән...
Ә Петрарка мәңге яши
Бер Лаурасы белән!

●

Кем ул, кайда? Ник табалмыйм һаман?
Гел буталып, ахры, йөримдер.
Кемнеңдер мин җанын җылытмаган,
Сөртмәгәнмен яшен кемнеңдер...

## Анам кабере ташына

Ни өметләр безгә баглагансың
исән чагыңда,
Ни теләкләр безгә теләгәнсең
үләр хәлеңдә...
Гүзәл ана! Эш башлаган саен
шуны уйлыйм:
Мин рухыңа синең һәм Илемә
лаек булыйм.

●

Бу каенны
хет кис, хет ват, хет утка як —
карышалмас,
куркып синнән кача алмас...
Тик соңыннан
ни үзеңә, ни балаңа
гүзәл сафлык ләззәтләрен ача алмас.

●

Без, кешеләр, шул кадәр көч-куәт җыйган —
«һә!» дигәнче бар Җир шарын көл итәрлек.
Шул көчтән дә бөек гакыл, ирек кирәк
Җир йөзенең һәр почмагын гөл итәрлек.

*1955—1977.*

## Әхмәт Гадел

### Италмас[1]

Зәңгәр Төньякта гаҗәеп бер ил бар,
Ул илдә шаулыйлар чыршы һәм наратлар.
Ул илнең җилләре бураннар кайната
Һәм бүре туннарда ак бәсләр уйната,
Ул илнең язлары чәчәккә күмелгән.
Яңгырлар ул илдә — карлыган, бөрлегән...
Ул илдә кешеләр шатлыктан һич талмас...
Исемә төшердең барысын да, Италмас!
Киң анда болыннар, гаҗәеп аланнар,
Нәфис ак каеннар һәм татлы баланнар!
Бу илне сагынып күп уйлар уйладым
Һәм ерак сәфәрдә күп юллар буйладым.
Һай, тагы шул якны эзләргә китимме?!
Синең ак чәчләрең — кар иле җитене!..
Сагынам, сагынам чәчәкле кырларны,
Шуларга багышлыйм иң матур җырларны.
Ул илнең язлары чәчәккә күмелгән.
Яңгырлар ул илдә — карлыган, бөрлегән...
Ул илдә кешеләр шатлыктан һич талмас...
Исемә төшердең барысын да, Италмас!

### Мәкләр

Сабын-тауда әтием авыр яраланган.
Фашист тубы сулышыннан тәне янган...
Таң алдыннан иптәшләре көчкә табып,
Медсанбатка киткән аны алып.

Сызланган, тик ыңрашмаган, тешен кыскан.
Шунда аңар тоелгандыр җир упкан күк.
Ул күзләрен төбәгән дә зәңгәр күккә,
Тулсын, дигән, күзләремә зәп-зәңгәр күк.

Иптәшләре бик сак, бик сак атлаганнар.
Ташлы юлның күренмәгән ахыры-соңы да.
Ә әткәмнең күкрәгендә кызыл мәкләр
Искән җилдә җилфердәгән ялкын сыман...

[1] Италмас — сары тюльпан, кыз исеме (удмуртча).

## Айсылу-Кәрәм

Сөю диеп утка ыргылмыйбыз,
Кочып алмый безне киң галәм.
Янып сөю өчен, и гүзәлем,
Син Айсылу түгел, мин — Кәрәм.

Илебез бар, илдә шаулый Идел.
Дулкыннарга таңнан ияреэм.
Идел кебек кинәт кайнау өчен,
Син Айсылу түгел, мин — Кәрәм.

Бер көн килер. Ул көн безгә кирәк.
Шул көн булыр тоташ бер бәйрәм.
Син Айсылу булып килерсең дә,
Каршыдармын сине, мин — Кәрәм.

## Канатлы арыслан

Кечкенә чагымда еш әйтте әнием:
«Әй, йоклама кояш батканда,
йоклама, йоклама.
Канатлы арыслан төшеңә керер,
Төшеңә керер дә, йөдәтер төннәрен,
Исеңә төшереп канатлы көннәрең.

Йоклама офыклар кызарган чагында,
Илеңне карап йөр чапаның ябын да,
Күрәмсең, ул килә офыктан, алыстан —
Канатлы арыслан, канатлы арыслан»...

Үткәннәр — ал кояш.
Киләчәк — йолдызлар.
Без бердәм, без бергә.
Кемнәр ул ялгызлар?
Башларны имибез
Буранда, яңгырда.
Йокы юк, имин без —
Без юлда, бер юлда!..
Төзибез КамАЗлар,
Корабыз БАМнарны.
Шәфәкъне озатып —
кочабыз таңнарны!
Канатлы көннәрдән
Юк без дә калышкан.
Үзебез без, әни, канатлы арыслан,
Канатлы арыслан!

---

[1] Айсылу һәм Кәрәм — төрки-татар халыкларында киң таралган борынгы риваятьтән. Бу риваять буенча ике гашыйк — Айсылу белән Кәрәм — кушылмаячакларын белгәннән соң, утка ташланып үләләр.

Кичер, тәү кат су эчергән
Ак чишмәсе әткәмнең!
Матурлыгыңны күрмичә
Суың эчеп үткәнмен...

Чәчәкләрен күрмәгәнмен
Киң хәтфә болыннарның...
Мин дә бер ерак оныгы
Чал сакаллы болгарның.

Миңа да көч-кодрәт биргән
Бу кырларның икмәге.
Бу җиргә гашыйк йөрәгем
Түгелдер бит тикмәгә?!

Кичер, тәү кат су эчергән
Ак чишмәсе әткәмнең!
Матурлыгыңны күрмичә
Суың эчеп үткәнмен...

**Шамил Маннапов**

# ТУГАН ЯККА КАЙТУ НӘСЕРЛӘР

## Тугрылык

Юлыгыз төшеп, безнең авылга килеп чыксагыз, атлы бер кешене очратмый калмассыз. Моңсу күзләре беләнме, саллы-салмак адымымы — кайсы ягы беләндер үзе дә эшчән атны хәтерләткән бу кеше — минем күршем, ат караучы Габделхак абый булыр. Ул ике куллап көрәшкәндә дә йөгәнен ычкындырмас. Хәл-әхвәл сорашсаң, үзе турында түгел, атлар хакында болай дияр:

— Барысы да яхшы, наныем, тик менә атлар гына кими бара, атлар гына...

Габделхак абыйның атлар яратуы күптәннән килә. Аның әтисе Габдулла абзый да ат караучы иде. Ул вакытта әле совхозда бер-ике бөртек чылбырсыз трактор да даңгыр-дыңгыр килеп чабучы бер ярым тонналы машинадан башка техника юк. Шуңа күрә төп йөкне атлар тарта иде.

Әтисен Бөек Ватан сугышына озаткач, Габделхак абый ат караучы булып үзе генә калды. Хәер, үзе генә дип әйтү дөреслеккә туры ук килмәс. Шат күңелле, җор телле кеше ялгыз кала димени?! Без, тирә-күрше малайлары, үзебездән аз гына өлкәнрәк булса да, «Габделхак абый да Габделхак абый!» дип, һәр вакыт ат караучы тирәсендә бөтерелә идек. Төнлә, әниләрдән рөхсәт алып, Габделхак абый белән болынга атлар саклашырга чыгабыз. Малларны утларга җибәргәч, учак ягабыз, «чикмәнле» бәрәңге пешереп ашыйбыз. Аннан китә әкият сөйләш. Габделхак абый әкиятләрне галәмәт тә күп белә. Аның һәр әкиятендә батыр егет белән алтмыш колачлы Акбүз ат булмыйча калмый. Батыр егет әнә шул Акбүз атның ялыннан эләктереп ала да, теге ничек кенә егып төшерергә тырышмасын, кулын ычкындырмый.

— Тормыш дигән чаптарның да ялын нык тотарга, какса-сукса да, егылмаска, егылганда да еламаска кирәк, наныйларым,— ди иде Габделхак абый кыйссадан хисса чыгарып.

Шулай да аның бер елаганын хәтерлим. Юк, әтисен фронтка озатканда да, көтүгә бүре һөҗүм итеп шуның белән сугышкан төннән соң да түгел.

Бервакыт, ир-егетләрне алган шикелле, атларны да фронтка озата башладылар. Шулар арасында Габделхак абый елның-елында сабан

туена бәйгегә әзерләп килгән Җирән кашка да бар иде. Шуны колыныннан аерып алу ифрат та кыен эш булып чыкты бит, әй. Борыла да үзәкләрне өзәрлек итеп кешни, борыла да кешни Җирән кашка — аратада калган колынын чакыра, мескенем. Кыр капканы чыгып, үргә генә күтәрелә башлаган идек, карасак, авылдан җан-фәрманга чабып бер тай килә. Җирән кашка тае. Ябып калдырган аратасыннан ничек чыккан диген син аны. Килеп тә житте, әнисенә барып та сыенды. Габделхак абый башта аны ачуланса да, аннары муеныннан кочаклап әйтте:

— Кая бармакчы буласың син, нанынкаем? Авылда болай да атлар аз кала лабаса.

Габделхак абыйның сагыш тулы тавышы өзелеп, үксеп куюыннан Җирән кашканың да күзенә яшьләр килде шикелле...

Авылдан төркем-төркем булып киткән ир-егетләр, сугыш беткәч, берән-сәрән генә кайттылар. Тик фронтка алынган атлар гына кире әйләнеп кайтмады. Алар урынына башкаларны — немец ломовойларын китерделәр.

Габделхак абый:

— Фронттан кайталмаган атларга да һәйкәл куясы иде,— дип сөйләгән диләр.

Дөрестерме бу сүз, юктырмы — гөнаһсына керә алмыйм, тик шунысы хак: корыч аргамаклар тере атларны елдан-ел кысрыклый барса да, күрше абый инде киң профильле механизатор таныклыгы алса да, атларга булган мәхәббәтенә тугрылыклы калды.

— Ат ул әкияттәге Сәмруг кош үтә алмас юлларны да кичә, узган сугышлар моның шаһиты булды,— ди ул. Аннары, беразуйланып торгач, өсти:

— Тик менә хәзер алар кими бара шул, кими бара...

Мондый минутларда мин ат караучы абыйның тавышында теге вакыттагы сагыш авазларын ишетәм кебек.

## Сәгъдия апа икмәге

Комбайн ышыгында тамак ялгап утырабыз. Күршем Миңнулла үз кисәген зур итеп капты да әйтеп куйды:

— Их, тәмле дә соң, нәкъ Сәгъдия апа икмәге!

...Сәгъдия апа гомер-гомергә колхоз механизаторлары өчен икмәк пешерде. Осталыгы билгеле булгангамы, әллә инде гаделлеге-тугрылыгы өченме, әлеге эшне елның-елында аңа кушалар иде.

— Синең кулың алтын, Сәгъдия апа,— диләр иде аңа механизаторлар.

Ә Сәгъдия апа матур итеп елмая да:

— Эшләп ашаганга шулай ул, нанныйлар, тир түгеп алганга,— ди. Аның өе янынннан безгә — малайларга тыныч кына узып китүе кыен. Тирә-юньгә таралган тәмле ипи исе борыннарны ярып керә, авыз суларың килә, адымнар акрыная. Яңа гына мичтән чыккан ипи исеннән дә тәмлерәк ис тагын бармы икән?!

Ачык тәрәзәдән Сәгъдия апаның кояш кебек түм-түгәрәк ипиләрне кызыл ашъяулыкка куеп бөтәләвен күренә. Кырга, механизаторларга илтер өчен әзерли инде ул аларны. Аның кояшта янган куллары ипине шундый оста әйләндерә ки, циркатагы жонглер диярсең. Бу эш аңа әллә ничек килешеп үк тора. Ипи тагын да тәмлерәк булсын дип шулай тылсымлый сыман тоела безгә.

Ул арада Сәгъдия апа безне күреп ала да, кулларын чигүле алъяпкыч итәгенә сөрткәләп, тәрәзәгә килә:

— Сез нәрсә, гашыйк егетләр кебек, тәрәзәдән күзегезне ала алмыйсыз, ә? — ди ул көлеп.

Без дәшмибез, борыннарыбызны тарткалап, ялан аяк килеш юл тузанында таптанабыз.

— Мәгез, наныйлар, авыз итегез,— дип Сәгъдия апа безгә нечкә генә итеп ипи телемнәре кисеп бирә.— Картым белән улларымның исән-сау кайтуын теләгез.— Әтисе фронтта һәлак булган күрше малае Миңнуллага зуррак телем әләгә.— Үсеп җиткәч, үзегез иккәне белән игелек күрсәтерсез, наныйлар,— ди Сәгъдия апа, безне озатканда.

Сугыш бетеп, авылдагы һәр морҗадан диярлек ипи исләре тарала башлагач, таныш сукмак онытыла төште. Моңа бәлки безнең теләкләрнең кабул булмавы да сәбәпчедер. Авыр елларны безне ипи белән сыйлаган юмарт апаның ире дә, уллары да сугыш мәхшәреннән әйләнеп кайта алмадылар...

Укуларны тәмамлап, мазутлы кулларыбыз белән ап-ак калачны үзебез эшләп ала башлаганда, механизаторлар өчен ипине Сәгъдия апа түгел, пекарняда ул өйрәткән кыз-кыркыннар сала иде инде.

Шулай комбайн ышыгында утырганда уйларымны Миңнулланың сүзе бүлде.

— Әйдәгез, бергәләшәп Сәгъдия әбигә бөтен бер икмәк алып барабыз! — диде ул.

Без килгәндә Сәгъдия әби сызганып-кыстырынып өй җыештыра иде.

— Исәнме, Сәгъдия әби.

Ул аз гына калтыранган башын туры тотарга тырышып, безгә текәлде:

— Шөкер әле. Ә сез кем малайлары соң?

— Без синең малайларың. Син ипи ашатып үстергән егетләр. Менә үзебез эшләп алган ипине алып килдек.

Сәгъдия әбинең еллар уңдырган сыек зәңгәр күзләрендә бер мәлгә аптырау галәмәте чагылгандай булды. Аннары хәтеренә төшерде булса кирәк, тешсез авызын алъяпкыч итәге белән каплап, көлеп куйды:

— И-и, наныйларым, сезмени әле бу?! Танымый да торам лабаса. Менә рәхмәт...

Ул ипине, яшь бала күтәргәндәй, сак кына итеп кулына алды.

— Унган күренә. Чүпрәсе дә, кабаруы да килгән моның. Улларым эшләп алган да булгач, бигрәк тә тәмледер инде бу ипекәй. Әйдәгез, узыгыз. Сезне үзем салган ипи белән сыйлармын. Чәем дә әле генә кайнап чыкты.

...Шул көннән башлап без янә дә Сәгъдия әби тәрәзәсе турыннан еш уза торган булдык.

## Әти урманы

Авылга кайткан чакларда мин иң әүвәл әти урманы белән күрешәм. Киткәндә иң соңыннан әти урманы белән саубуллашам. Кайтыр юллар да, китәр юллар да шушы урман аркылы уза.

Быелгы кайтуда үзем белән улымны да алдым. Беренче класска керәсе, авылның саф һавасын күкрәк тутырып сулап, көч-сихәт җыеп кайтсын, дидем. Урманга җиткәч тукталдык. Агачларга текәлеп озын-

озак уйга талуымны күргән улым башта дәшмәде, аннары эче пошып булса кирәк, ашыктыра башлады:

— Әти, әйдә инде!..

...Бала чактан үз тавышымны ишеткәндәй булдым.

Әтием мин белә-белгәннән урман каравылчысы иде.

«Зариф ул урманны да тунатмас, утынсыз да калдырмас»,— диләр иде авылдашлар минем әти турында.

«Урман җене кагылгандыр сиңа, шуннан кайтып кергәнең юк. Ялгыз башың ничек кенә эчең пошмыйдыр»,— дип, әни дә еш кына сукрана иде. Әти исә нарат каерысыдай сары мыегы астыннан елмаеп кына:

— Урманда кеше ялгыз буламыни?! Урман җанлы бит ул. Телен аңлый белсәң...— ди иде.

Чыннан да, әти урманга җитте исә агачлар белән сөйләшә башлый.

— Иһи-һи, матурым, сугыш зәхмәте сиңа да кагылган икән,— ди ул, корыган алмагач янына тукталып.— Шыр сөяккә калгансың лабаса. Кышлары бик зәһәр килде шул, кышлары... Сугыш узган урманнарның хәле сезнекенә караганда да мөшкелрәк булды. Агачлар да, солдат кебек, фашистка каршы сугышты. Күпме партизан туган өе итте урманны.

Әти, агач тамырлары кебек нык, каты бармаклары белән әле бер кәүсәне, әле икенчесен сыйпый-сыйпый, һаман эчкәрәк атлый. Ә минем тизрәк авылга, дус малайлар белән уйнарга кайтасым килә. Әледән-әле:

— Әти, әйдә кайтыйк инде,— дим.

— Кайтырбыз, улым, сабыр әйлә,— ди әти.— Әниеңнең чәе өлгерә төшсен. Күрәсең, күпме агач корыган, алар урынына язын-көзен яшь үсентеләр утыртырга кирәк булыр. Ир-егет үз гомерендә, ким дигәндә, бер өй салырга, бер агач утыртырга тиеш...

Ниһаять, без кайтыр юлга борылабыз.

Урманны чыккач, әти ике көпшәле мылтыктан һавага атып җибәрә. Бу аның: «Кайтып киләбез, чәеңне әзерли тор!» — дигән шартлы сигналы.

...Кайчандыр бөтен мәктәбебез белән утырткан яшь агачлар инде үсеп җитте. Алар да урманга кушылып шаулыйлар. Без дә үсеп егет булдык. Тик әти генә чүгә. Күптән ялга чыкса да, урманын ташламый. Урман посадкасындагы корыган үсентеләр урынына яңаларын утыртып, шуларның төпләрен утап-йомшартып йөри бирә. Тагын шунысы бар: өлкәнәйгән саен агачларны кызгануы, урманга булган игътибары һаман арта бара аның. Ул инде утынга да агач кисми, төпсәләр генә кубара. Иртә таңнан балта, ломын алып, урманга китә. Күлмәге лычма тир булып, аркасына ябышканчы төп кубара. Яфрак-туфрак белән күмелгән булсалар да, аларны тиз таба ул. Кайчандыр шул урында мәгърур шаулап утырган имән егетләре, каен кызлары, карама малайлары әле дә хәтерендәдер, күрәсең. Үзе төпне кубара, үзе иске танышын очраткандай сөйләнә:

— Менәтерә, сиңа да вакыт җитте. Картаймыш көнендә тагын бер ялкынланып алырга насыйп икән әле.

Инде мин дә әтине бала вакыттагы кебек ашыктырмыйм. Шулай да, төпләрне төяп, олауны әйбәтләп бәйләгәннән соң, әтинең ашыкмавын абайлагач, әйтми булдыра алмыйм:

— Кайтыйк мәллә, әти?

— Кайтырбыз, улым, кайтырбыз,— ди ул.— Бераз сулу алыйм. Урманнан да аерыласы килми...

— Әйдә инде, әти-и!

Улым тавышын ишетеп сискәнеп киттем. Ул минем бала чак авазым булып ишетелде. Мин улымның бабасы мыегына охшаган җирән чәчләреннән сыйпадым.

— Кайтырбыз, улым, кайтырбыз, бераз сулу алыйк. Бабаң белән дә сөйләшеп туймадым әле...

Улым күтәрелеп миңа карады. Аның гаҗәпләнгән зур күзләрендә агачлар шәүләсе чагыла иде.

## Ялвару

Балалар сабый чакта, җан җылысын тоеп, атага ялваралар:

— Әти, китмә, әти, китмә!

Әтием сугышка чыгып киткәндә шулай дип үземнең дә әтигә сарылуым хәтеремдә.

— Барырга кирәк, улым,— диде әти, никтер тамагын кат-кат кыргалап.— Китәргә кирәк. Илне таптаучы фашистларны куасы бар.

Ил таптаучы булгач, ул фашистлар шул ук бакча таптаучы хайваннар кебек нәрсәләрдер, күрәсең.

Терлек-туар кереп, бәрәңге бакчасын таптаса да, әтинең нык ачулануын белгәнгә, аны юлыннан туктату мөмкин эш түгеллеген аңладым.

— Алайса, мин дә синең белән барам. Ул хайваннарны бергәләп куарбыз.

Әти яшь аралаш елмайды да, мине көчле кулларына алып, түшәмгә кадәр күтәрде.

— Әлегә менә шундый булып үсә тор, улым.

...Балалар сабый чакта анага ялваралар:

— Әни, китмә, әни, китмә!

Һәр көн иртән, әнием фермага җыенганда, үземнең дә шулай дип әнигә сарылуым хәтеремдә.

— Барырга кирәк, бәбкәм,— ди иде әни, мине сөеп.— Малларны эчереп, ашларын җыештырасым, азык саласым бар. Ә син тәрәзәдән минем кайтуымны карап кына тор.

...Үсеп җиткәч, балаларга әти-әниләр ялвара.

— Улым, китмә, бәбкәм, китмә!

Олы тормыш юлына чыкканда әти-әниемнең шулай дип мөлдерәп күзләремә караулары хәтеремдә.

— Китәргә кирәк, әти, укырга кирәк, әни,— дидем мин.— Һөнәр алып, сезгә, илгә-көнгә игелек күрсәтәсем бар.

Аңладылар, фатиха бирделәр.

— Исән йөреп, сау кайт инде, алайса, улым, безне онытма, бәбкәм,— дип озаттылар.

Киттем. Күкрәгемдә типкән ярсу чишмә мине алга — еракларга ашкындырды. Шифалы болыттай күкрәп кайтып, туган кырларыма яңгырдай яуганчы шактый вакытлар узды. Яңгыр тамчылары булып кайткач та: «Бик сагындым сезне, әти, әни!» дип, башлап аларның мине сөеп баккан күз керфекләренә тамарга насыйп булмады шул.

Әтине дә, әнине дә соңгы юлга озатканда, бала чактан хәтергә сеңгән ике сүзне генә кабатладым:

— Әти, китмә!

— Әни, китмә!

Аерылышулар ачысын гөнаһсыз сабый чактан татырга туры килсә дә, бу ике аерылуга һич күнегеп булмый. Мондый аерылышу белән күнел килешми, зиһен ризалашмый. Әти-әни балага кояш кебек, су кебек, һава кебек һәр вакыт кирәк икән шул. Шуңа күрә тылсымлы теләк теләгәндәй әледән-әле кабатлый торам:

— Әти, китмә...

— Әни, китмә...

Балалар ата-анага мәңге ялваралар...

## Су тәме

Авылдан хат килде. «Абый, кышкы каникулда барып чыгарга уйлыйм. Сезгә бирәр әйбер алып киләсе түгелме? Бал, бәрәңге, ит-мазар кирәктер, бәлки...» дип язган энекәш.

Мин уйга калдым. Йомышым юк түгел. Авылдан китертергә ниятләп, нык сагынган-тансыклаган әйберем бар минем. Тик ул энекәш язганнарның берсе дә түгел. Бәлки минем энекәшкә сәер булып та тоелыр. Чөнки мин тансыклаганы — шәһәрдә дә дефицит түгел — торбадан фатирыма шаулап килеп тора. Краннын гына борасы. Әйе, әйе, су ул. Идел янында да суга сусыйсың икән шул. Хәлбуки, мин тансыклаган су гади су гына түгел, ә туган авылым суы! Үзебезнең ындыр артында кайчандыр әти белән икәү тапкан чишмә суы...

Бүгенгедәй хәтеремдә: әтинең сугыштан, Бөек Ватан сугышыннан кайткан елы иде. Солдат итеге белән нык-нык басып, бәрәңге бакчасы казый. Бәләкәй генә көрәгем белән мин дә әтигә булышкан булып йөрим. Яз исе, дымлы туфрак исе, яшь бөреләр исе борынны кытыклый. Рәхәт.

Бервакыт әти мине үз янына чакыра.

— Күрәмсең, улым? — ди.

Карасам, көрәк эзеннән мөлдерәп чыккан су буразна буйлап эз салырга азапланып ята. Мин көрәгем белән туфрак сибеп караган идем, шундук яңадан бәреп чыкты.

— Чишмәне томаларга ярамый, улым,— диде дә кулларын төкерекләп, су чыккан урынны казый, тирәнәйтә башлады. Көрәк сабының яртысы күмелерлек булгач, су яхшы ук тибә башлады. Шуннан соң әти аны янәшә генә агып яткан инешкә төшерде. Чишмә суы үзенә бер төрле тавыш белән зур суга кушылды. Гүяки ул үзенә юл тапканга шатланып, безгә рәхмәт әйтә иде.

Икенче көнне әти чишмәгә каен бура төшерде. Ян-якларына түгәрәкләп тал утыртты. Ялга туктагалган арада сугыш хатирәләрен дә сөйли иде.

Әти фронтта артиллерист булган. Дөресрәге, туп тартып йөрүче атларны караган.

— Дошман — елан, үзе чигенгәндә еш кына суларны да агулап калдыра иде. Шунлыктан атларыма суны буралы чишмә, коелардан алмыйча, яңа гына төшкән снаряд чокырларыннан эчертә идем. Рәсәй җире, улым, безнең халык кебек бит ул: аз гына кагылдыңмы, чишмә булып ургый. Дошман гына аңлап бетермәле түгел аны. Әйе!.. Үзебезгә дә шул яңа чишмәләрдән су алып, чәй куя идек...

Кичен эти чәйне яңа чишмә суыннан кайнатырга кушты. Самаварны эти Берлиннан алып кайткан иде. Дистәләгән медаль төшерелгән Тула самавары. Фашистларның да чәй эчәсе килгән, күрәсең, бездән талап алып киткән булганнар. Эти, чәй яратучы буларак, калдырмаган, үзе белән алган, тик самаварның юлда борыны гына төшеп калган. Эти самаварга яңа борын куйды. Солдат самавары, күпне күрсә дә, эшкә яраклы иде.

Эти шушы җиз самавардан беренче чәшкәне агызып, «каплап» куюга, самавар җизе төсендәге мыекларын сыпыргалап:

— Булган бу, әкәмәт! — дип куйды.

Шул көннән башлап эти самаварны үзебезнең чишмә суыннан гына куйдыра торган булды. Күршедә генә кое да бар, югыйсә. Суы да чипчиста, алып чыгу да җиңелрәк. Чишмәдән китергәндә ике тапкыр тау менәсе бар. Ә бу эш минем өстә...

Кайвакыт суны күрше коедан алам да, чишмәдән китердем дип хәйләлим. Буламы соң! Эти иренен тидерү белән үк сизеп ала.

— Нинди судан куйдыгыз самаварны? — дип сорый.

— Чишмә суы белән,— ди әни, мин әйткәнчә.

— Кил әле, эчеп кара әле.

Әни татып карый да:

— Әллә инде тагын. Сукыр тавыкка бар да ярма. Су су инде,— ди.

— Мин үзебезнең чишмә суын дөньядагы бернинди су белән дә алыштырмыйм. Ә сез, әкәмәтләр, тәмен дә аермыйсыз...

Аннары чәшкәсен читкә этәреп, ачусыз гына:

— Малай, тагын бер тапкыр алдашсаң, матри,— дип куя.

«Су булгач, барыбер түгелме икәнни. Эти аның тәмен ничек аера икән?» дип шакката идем.

Инде хәзер төшендем. Үзем дә су тәменә сизгерләндем. Туган җир суы башка сулардан аермалы була икән шул. Чит җирләрдә йөреп, туган ягын өзелеп сагынган кеше генә тоядыр аның чын тәмен...

## Мөдәррис Әгъләмов

### Тагын бер Көн...

*Виктор Хара истәлегенә*

... Ул җәйне дә нәкъ шундый кич иде,
Шундый алсу иде бу шәфәкъ.
Ә Көн баскан иде бөтен буйга,
Канлы шәфәкъ — гүя эшафот.

Мәңгелеккә китеп бара ул Көн,
Җәлилчеләр сыман ул горур.
Көннәр шулай янып беткәндә дә
Тыштан салмак, тыштан тын булыр.

... Башың имә, кеше, хәсрәт килсә,
Үлем килсә әгәр йортыңа.
Дөнья ул киң... Бер ягында үлсә,
Бер ягында аның көн туа.

Мәңгелеккә китеп бара ул Көн,
Хәтереңә аны салып кал!
Су өстендә каннар алсулыгы,
Элмәкләнеп сикерә балыклар.

Муенында көннең ап-ак болыт,
Хәтерләтә ап-ак яканы...
Ак якага җәелә акрын гына
Ал шәфәкънең алсу ахагы.
Мәңгелеккә китеп бара ул Көн,
Горур карап таулар өстеннән.
Күпме кеше соңгы минутында
Кодрәт алды икән шул Көннән.
Тираннарның холкын Көннәр белә,
Тираннарның холкы бер генә:
Баш игәнгә мунчак кидерә ул,
Имәгәнгә — элмәк кидерә.

Мәңгелеккә китеп бара Хара,
Әманәтен илгә тапшырып.
Эшең генә кала бу дөньяда,
Башкасына булмый баш булып.
Тыныч түгел заман, Җырдагыча —
Ниләр килмәс ир-ат башына.

Һәр көн саен офыктагы Көннәр
Кеше булып баса каршыма.

Мәңгелеккә китеп бара ул Көн,
Яна-яна фани утларда...
Кеше шулай эшафотка менә
Һәр көн төрле континентларда.
Ә бит кеше ялгыш явызлыкның
Тезгеннәрен генә җибәрә, —
Китә мәхшәр... газетларда илнең
Исемнәре генә үзгәрә.

...Шәфәкъ алсу. Су өсләре алсу,
Элмәкләнеп сикерә балыклар.
Тагын бер Көн мәңгелеккә китте,
Хәтереңә, кешем, салып кал!

## Төшке ялдан соң

Кузгалырга вакыт!
Хыял башка, тормыш башка,
Ашка
Ашаган күк ачы катык катып.

«Кара кара, ә ак ак инде» дип,
Чиге күренмәгән гәпләр сатып,
Күп пыскыттык затлы тәмәкене
Бу илаһи җиргә кырын ятып...
Кузгалырга вакыт!

Саздан чыгарылган сыер сыман,
Буразналар сулый, ирек татып.
Сөрәсе җир кара зур авызын
Ачып карап тора тыкырдатып —
Кузгалырга вакыт!

Максатлар нык иде, адымнар нык,
Шуңа микән уздык, һәйләп көлеп...
Баш күтәрсәк — гаҗәп: ыргытканбыз
Дөнья кадәр җирне әйләндереп.

Яңа заман, тизлек заманы бу,
Белмидер ул, димә, әйе, беләм!
Җир белән җыр — нечкә күңеллеләр,
Анда булмый космик тизлек белән.
Ә дальтоник затлар шыбырдаша:
— Яшьләр әле, сары томшыклары...
Салмак кына эри чигәләрдә
Гомер дигән кышның җепшек кары.

... Җир читендә аяк салындырып
Утырган чак булды, күзне йомып.
Җырлар язган булдык: «Яңа шигырь
Тудырабыз»,— дигән сүзне егып,—
Яңгырадык Тукай чорларының
Безнең чорга кайтавазы булып.

... Тудырырга һәм тәзергә килгән
Кеше ничек килә алсын ватып?
... Казлар судан чыккач кагынгандай,
Шикләреңне кой син, шыбырдатып,
Вакыт!

## Хәзрәти кем?

Табынсаң табыла,
Табынмый калырга
Мөмкин дә булмаган шәхесләр булыр.
Хәзрәти Пушкин!
Хәзрәти Тукай!
Хәзрәти Лермонтов!
Хәзрәти Шигырь!

Табынсаң табыла,
Туктаусыз калыга
Аеклар, саеклар... юаннар төптән.
Зәвыгым, нишлисең?
Ал берсен, пот аса!
Нигә син китәсең мәҗүсилектән?

Табынсаң табыла,
Йолдызлар ягына
Кабынып китәләр төркем дә төркем...

... Ә күңел һаман да кемнедер эзли,
Хәзрәти кем соң ул?
Хәзрәти кем?

## Китә алмыйм...

Без йөзәбез... Дөнья ап-ак күбек...
Без йөзәбез менә шашкан кебек.
Безгә тәкъдир язган бөтен ләззәт
Бергә килеп баштан ашкан кебек.
Мин китәргә тиеш таңга чаклы,
Ә бу кичә кабатланачакмы?
Кабатланачакмы бу кичә? —
Китә алмыйм — шуны белмичә.

Тирбәләбез — бу җир безгә бишек,
Юк, ул көймә... — Без барабыз ишеп.
Кеше кулы койган матурлыклар
Безнең белән бара тирбәлешеп.
Бездән соң да шулай барачакмы?
Бу диварлар мәңге калачакмы? —
Меңләп сорау, меңләп уй кичә...
Китә алмыйм — шуны белмичә.

Бездән соңгы буын кемчә сөйләр?
Яңгырармы анда безнең көйләр?
Кабатланачакмы шушы кичтә
Без ант эчкән татлы бу тәгъбирләр?
Безнең дәвам шулай яначакмы?
Арып-талып уйга калачакмы? —
Китә алмыйм — дөнья «юк» дисә,
Китә алмыйм — шуны белмичә.

Илләр бәхетенә җиткән хәтле,
Сакларммы җир затлы хакыйкатьне
Ялган матурлыкка төрмичә? —
Китә алмыйм — шуны белмичә.

Яшәрме җир, эшләр эше барны,
Чәчкә тасма тагып үргән сыман,
Рухи богауларга үрмичә?

Яшәрме җир, күкрәр көче барны,
Көйрәтергә махра төргән сыман,
Гәзит кисәгенә төрмичә?..
Меңләп сорау, меңләп уй кичә.

... Киләчәккә бара алмый шагыйрь,
Бара алмый — шуны белмичә.

## Мин табышмак чишәм

Яралганмын кара туфрагымнан,
Идел-судан, халык җырларыннан,
Ак яулыклы татар карчыгының
Яргаланып беткән кулларыннан.

Яралганмын әнкәм көлтә итеп
Бәйләр өчен җыйган учмалардан,
Көлтәләрдән учма булып кына
Безгә килеп җиткән кыйссалардан.

Яралганмын җил-давыллар узып
Исән калган агач башларыннан,
Диварларга нигез булып яткан
Бабамнарның кабер ташларыннан.

Яралганмын халык иҗат иткән
Табышмактан, әйе, табышмактан...
Әткәм хыялланып эзләп йөргән,
Җавап итеп әнкәм мине тапкан.

Тапкан, табышмакка җавап итеп, —
Шулай тапкан әткәм эзләгәнен,
Тик барыбер бер табышмак булып
Калган минем һәрбер күзәнәгем.

«Үзе сайлап йөрсен, дөнья күрсен» —
Еллар минем аяк-кулны чишкән.
«Тапкырлыкның татлы тәмен белсен» —
Туган халкым сөйләр телне чишкән.

... Яралганмын кара туфрагымнан,
Идел-судан, халык җырларыннан.
Хәзер инде дөнья, чишәр өчен,
Үз алдыма табышмаклар куйган.

Мин дә җавап эзлим әткәм кебек,
Мин табышмак чишәм нәселемә.
Аяк-кулын вакыт чишәр аның,
Сөйләр телен кемнәр чишәр менә?

... Мин табышмак чишәм нәселемә.

## Җилле көндәй җилләләр

Озаккарак китте бугай, озаккарак,
Күзен текәп көткән иде һәммә тараф...

... Чыкты буран, ком бураны,
Өермәсен тыялмады,
Чыкты болыт актарылып,
Офыкларга сыялмады.

Килгән иде кояр булып,
Бар дөньяны юар булып,
Ул яумады...

Җан биргәндәй талпынды да
Ауды басу уртасына
Теткәләнгән ялгыз нарат.

... Озаккарак китте шул, әй, озаккарак...

Алып китте басудагы
Өеп куйган күбәләрне,
Сәлам эшләпә чөйгәндәй,
Алып чөйде түбәләрне.

Керде әллә ничә төргә,
Ә игелек күрсәтергә
Теләмәде.

Тик сөенде давыл белән
Суга төшкән мамык канат,
Еракларга китеп барды
Башын чөеп, горур карап.

...Озаккарак китте шул, әй, озаккарак...

Тәрәзәне ябып куйды
Өйдә булып өлгергәне,
Ишетелде нәрсәләрдер
Чәлпәрәмә бәрелгәне —
Түкте, түкте көчен менә,
Шәхси ләззәт өчен генә
Бар белгәне...

Китеп бара, бар терекнең
Кирәкләрен бирде санап,
Тыныч гомер иткәннәргә,
Имеш, иген игкәннәргә
Бирде сабак.

...Озаккарак китте шул, әй, озаккарак.

Кәпәчләрен тезгә салып,
Картлар тора көлемсерәп:
«Файдасызга очынуны
Яшьләргә бер күрү кирәк,
Яшьләргә бер күрү кирәк».

...Иген шаулый, тургай сайрый,
Ир-егетләр чалгы кайрый.
Хатын-кызлар, тәрәзәдән
Кыр юлына бага-бага,
Камыр изә, токмач сала,
Күгәрченнәр «бүләк» сала
Авыз ачып торучыга,
Моржаларның төтеннәре
Элеккечә туры чыга...

Халык әнә керфекләрен
Офыкларга теки кабат:
— Озаккарак китте шул, әй, озаккарак.

## Авылда шигырь кичәсе

Егерменче еллар тәрәзәсен
Каплап куйганмыни мендәр белән,
Иске мәчет авыл авызында,
Салкын бәрә эчкә — мөнбәренә.

Бер гасырлык гомерендә аны
Җил-давыллар азмы калтыратты...
Ачылырга тора яңа клуб
Янәшәдә генә — ике катлы.

Элек мәктәп иде... Авыл һәрчак
Заман белән бергә күрде аны,
Аның аша алып килде еллар
Авылына яңа әлифбаны.

Аның аша алып килде еллар
Кара гидайларга Ленин сүзен,
Син яңаны кабул итеп кара,
Шул стенаң калсын, шул нигезең.

Ышандымы икән чыра аша
Ракеталы чорны кичәсенә.
Бүген менә яңа заман халкын
Кабул итә шигырь кичәсенә.

Мәчет салкын, халык шагыйрьләрен
Җылытырга әзер тыны белән,
Бу туңуны булмый чагыштырып
Эчке туңу белән...

Сөзеп карый авыл агайлары
Бүрекләрен куеп тезләренә,
Шатлыгың да синең, хәсрәтең дә
Чыга йөзләренә.

Мамык шәлен чөеп иң өстенә,
Күрмәсеннәр дигән кебек кенә,
Шигыремә сабыр, салмак кына
Әнкәм яшьтәшләре килеп керә.

Килеп керә кинәт шигыремә
Яшь егетләр ишекне киң ачып.
Тышта буран, калтыранып куя
Иске мәчет.

Ялга каршы... Әлмәт, Чаллысыннан
Эшче халык кайтып, кереп тулган.
Бертуктаусыз җиңел машиналар
Узып тора авыл урамыннан.

Соңгы елын яши иске мәчет,
Җыелабыз, тагын таралабыз..
Авылкүләм түгел, дөньякүләм
Биегәйде хәзер манарабыз.

Исемебез олы, җисемебез,
Без бар хәзер — түгел югалырлык...
Бернинди көч тә юк җир йөзендә
Безнең манараны кисә алырлык.

... Ялга каршы. Күпме халык кайткан —
Төсләр чуар шундый, хисләр чуар...
Халык урын бирә, төркем булып
Кереп килә арган савымчылар.

Берәм-берәм түргә уза алар,
Халык урын бирә, ала дәшеп...
Шигырьләрем җитдиләнеп кала,
Җитдиләнеп кала иске мәчет.

## «Көймә ю-ю-к!»

Экспедиция. Археолог
Егет ята минем янымда,
Аргы ярга чыгар көймә кирәк,
Тукталганбыз елга ярында.

Экспедиция чордан-чорга
Чыгар өчен юлга чыкса да,
Бу вакытта әле елга аша
Чыгу шуның белән бер чама.

Үртәләбез, гасабиланабыз,
Бәлки бу хәл китәр озакка.
Ә көймәләр ярда. Ә көймәләр
Тимер чылбыр белән йозакта.

Аргы якта эшләпәләр болгап,
Кычкыралар безгә инәлеп.
Ә без менә көймәләргә басып
Җавап кайтарабыз: «Көймә ю-ю-к!»

Ә көймәләр ярда. Әйтерсең лә
Тәгәрәшеп бездән көләләр...
... Кайчак чордан-чорга чыгар өчен
Йозакланган була көймәләр.

Син көймәгә басып кычкырасың
Ерак бабаңнарга: «Көймә ю-ю-к!»
Экспедиция. Йозакларга
Күзне текәп ятам уйланып.

## Әдхәт Синугыл

### Тауларга карап

*
* *

Таулар юкта,
Җирдә мин гүя җирсез!
Таулар барда,
Үзем Таудай тоямын.
Таулар күрсәм,
Бөркет сыман йөрәгем
Канат кагып,
Мин яңадан туамын.

Ут-ялкынсыз
Калса әгәр йөрәгем,
Янартаудан
Илһам алып янамын.

Таулар белән
Тауда туып үстем мин,
Мәңгелеккә
Таулар белән каламын!

*
* *

Кычкырмагыз куркытырдай булып,
Оран салып таулар янында.
Кирәк түгел, зинһар, уятырсыз
Бөркет балаларын тавында.

Кычкырмагыз таулар каршысында,
Күкрәк кагып, таулар барында...
Кеше көлмәсә дә, таулар көләр,
Таулар көлеп карар барына.

Кычкырмагыз таулар каршысында,
Танырдайны таулар таныйлар.
Көчлеләр бит алар кычкырмыйлар,
Көчсезләр тик, куркып, яныйлар...

Кычкырмагыз таулар каршысында,
Куркытулар тауны кирәкме?
Таулар, таулар — куркак җаннар түгел,
Таулар алар — бөркет йөрәкле.

*
* *

Тауларда кара күбәләк —
Кемнең кара күзедер?
Әллә мәрхүм әткәмнең ул
Әйтер кайгы сүзедер?

Тауларда кара күбәләк —
Нәрсә ашап яшидер?
Бәлки ул газиз әнкәмнең
Төн-кара күз яшедер?

Тауларда кара күбәләк —
Кемнең хәләл каныдыр...
Бәлки тавын бирми үлгән
Каһарманның җаныдыр?

Тауларда кара күбәләк —
Шундый нечкә билледер!
Нинди генә булса да, ул —
Табигатьнең яме бер.

*
* *

Өздереп лә уйный бүз курайлар,
Җилләр генә иссен илереп...
Урал дәрьялары акмый тыңлый,
Курай моңнарына бирелеп.

Җилкендереп уйный, әй, курайлар,
Үзәкләрне генә өздереп.
Туып-үскән илләр сагындыра,
Йөрәккәйләр генә өзелеп.

Җиз курайлар уйный таулар җырын,
Моңлы итеп уйный сыздырып.
Курайларга кушылып җырла, күңел —
Былбыл тавышларын уздырып!

## Якташларга сәлам

Якташларым, хатлар язсам сезгә,
Казан белән башлыйм сүземне...
Шушы бер сүз әйтеп бирер төсле
Еллар буе сагынып түзүне.
Казан бүген яңа туган айдай,
Иделдә ул гүя гөлчәчәк.
«Моңлы Казан, нурлы Казан»нардан
Безнең җырлар дөнья гизәчәк.
Шигъри күкрәү булып аның Тукай,
Җәлилләре анда яшәгән...
Казан учагыннан күтәрелгән
Бер чаткыга мин дә охшаган.
Горурланам мин дә менә шуңа,
Чал Казан ул безнең уртак дан.
Учагына сүнмәс ут кабызган
Халкы белән горур ул Казан.
...Хатлар язсам, якташларым, сезгә
Казан белән башлыйм сүземне.
Мин — тауларда туган татар улы —
Монда килеп таптым үземне.

## Илсөяр Ганиева

### Җиргә кушылып

Тамырланып үсәм мин — зур җиргә —
Җан янардай эссе челләдә.
Чиксез далаларда, кыяларда,
Кан коярлык кайнар чүлләрдә.
Үсәм болыт сарыган чал тауларда,
Туңганда да җаным — түзәмен,
Көлгә кала-кала ут эчендә,
Ялкын көлтәседәй үсәмен...
Җырым шулай көрәш мәйданында
Сарылып үсә сыман, түшәлеп,
Җанымның да бөтен авырлыгы
Туган туфрагыма түшәлер,—
Чөнки җиргә кушылып үсәмен!

### Бабамнар турында уйланам

Артты микән бабам куанычы
Азат булгач бер зур кайгыдан:
Йортларының ике почмагына
Терәү салгач кәкре каеннан?..

Тынгы бирми менә шул үткәннәр,
Төшләремне бүлеп уята,
Арык еллар белән күмелеп калган
Заманалар кат-кат уйлата.

Әйтерсең лә әле дә шом салалар...
Йортлар шәүләсе шул яланда,
Салам түбәләрен тузгытып, җил
Скрипка уйный һаман да...

Шомнары да җуелыр, бабамнарны
Куенына алган еллар күк,
...Агыйделкәй ярсый сулыгып-сулыгып,
Шул елларга колак салган күк.

## Еллар аша

Дөнья мине каккан, суккан чакта,
Яки үксез иткән чагында,
Сөялергә хәтта урын калмый
Адашырмын дигән таңымда.

Кыл өстендә торган җирем буйлап
Хак юл ярдым яшьлек язымда,
Еллар чыңлап калды җырлар сыман —
Җырлар батмый мещан сазында...

Үтте шулай күпне күргән гомер,
Күз яшем дә кипте давылда,
Араларда калган еллар аша
Кайтып киләм туган авылга.

...Минем җилкән-аккош ярдан-ярга
Кагыла-сугыла диңгез эзләде.
Язмыш адаштырганда да, әй, туган як,
Синдә калыр салган эзләрем.

**Мәхмүт Хәсәнов**

# КАМИЛ ГҮЗӘЛЛЕКНЕ ЯКЛАП

Гадәти булмаган сәяхәткә чыктык...

Юлыбыз озын. Без Ык елгасы буйлап, бөтен Азнакай районын иңләп, түбән таба төшәргә тиешбез. Без дигәнебез — дүрт кеше: Мәскәүдә үткәрелгән Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыятенең алтынчы съезды делегаты, табигатьне саклау җәмгыятенең район советы председателе Әхәт Гарифуллин, район газетасының фотохәбәрчесе Рәфкать Садриев, мин һәм «вездеход» шоферы.

1977 елның августында район советы башкарма комитеты Ык елгасының су ресурсларыннан, башка төрле табигый байлыкларыннан хуҗаларча файдалану, бигрәк тә елганың тирә-юнь төбәген саклау турында карар кабул иткән иде. Анда «Алга», «Авангард», Мичурин исемендәге һәм Тельман исемендәге хуҗалыкларның терлекләреннән яр буйларын таптату, фермаларыннан пычрак агызу кебек ямьсез фактлар күрсәтелде. Әлеге карарның үтәлешен тикшерү максаты белән килдек без һәрберебез өчен аеруча газиз, ифрат та кадерле булган Ык буена.

Минем үземнең исә чын мәгънәсендә илһам чыганагым ул. Һәр елның берничә аен Ыкның матурлыгы белән күз яуларын алырлык, җаннарны иләсләндерерлек яр буйларында үткәрү хәзер инде гадәткә кергән. Елның теләсә кайсы фасылында булырга тырышам мин бу тирәдә. Бигрәк тә яз-гүзәлкәйнең тантана иткән, кинәнгән чагы — елга йөзе ачылган көннәр шигъриятле була. Офыкларны иңләп кайткан кошлар чыр-былрларын күзәтәсең, аларның канат каккан, зәңгәр күк йөзеннән ишетелгән аһәңле тавышларын тыңлыйсың. Шунда йөрәгеңнән, нәкъ язгы ташкындай, хисләр ургый, шунда күңел түрендә җаңга рәхәт өстәрдәй тылсымлы җыр тугандай була.

Менә аның тугандаш Башкортстанның Шаран районыннан Азнакай районы җирләренә килеп кергән урыны. Бирөдә татар халкының ялкынлы революционеры легендар Мулланур Вахитов исемендәге совхозның Үәкән авылы урнашкан.

Бу тирәләр минем өчен таныш. Совхозның әлеге Үәкән поселогында гадәти булмаган күргәзмә-аукционнарда катнашканым бар. Вахитов совхозы сарык асраучылык белән дан казанган хуҗалык. Элита класслы тәкәләр белән сату да итә ул. Аларны алырга дип республикабыз колхоз-совхозларыннан гына түгел, күрше өлкәләрдән дә киләләр.

Безнең юлыбыз Ык елгасының сул як сөзәклеге буйлап бара. Карашыңны кай тарафларга гына төбәмә — уйсу тугайлар, зәңгәрсу үзәннәр.

Күп тә үтмәдек, сарык көтүләре дә күренә башлады. Беренче булып очраган көтүче янына сугылабыз. Совхозның алдынгы терлекчесе Павел Герасимович Коробков ул. Җил кискән какча йөз. Кояш ашаган каш-керфекләр. Өстендә кожан, аякларында төсен югалткан кирза итекләр. Иярле аты да, йонлач эте дә шунда, янында гына. Утарында 880 баш сарык. Эшләре уңышлы бара. Узган елда, мәсәлән, һәр сарыгыннан йонны уртача 170 әр граммга артыграк кырыккан. Хезмәт хакы да зур — аена 250 сумнан кимеми икән.

Әмма табигать, аны саклау турында сүз чыккач, Павел Герасимовичның йөзенә күләгә сарылган сыман булды. Мул балыгы һәм тирәнлеге белән дан тоткан Садок күлен быел җаен тәмам эштән чыгарганнар. Янына, борчак басуларына гербицид сиптерү өчен, аэродром ясаган булганнар. Нәтиҗәдә балык беткән, күл суы сарыкларга эчертү өчен яраксыз дип табылган. Хәзер дә әле самолетка заправка ясаган урыннар, янгыннан калганга охшап, каралып яталар. Өстендә көзге ачы җилләр хакимлек иткән, бәлки шунлыктандыр, тагын да боегыбрак калган әлеге күл без юлга кузгалып киткәч тә шактый вакыт күз алдында торып газаплады...

Машина алга ыргыла. Каршыда үр һәм калкулыклар тезмәсе. Матур да соң бу тирәләр. Тагын кайда бар соң бездәгедәй куе урманнар, дәрьядай киң басу-болынлыклар. Ык, Стәрле, Мәллә елгалары үзләре генә дә ни тора! Алар 1921 елда шушы төбәктәге халыкны ач үлемнән коткарып калганнар.

Ямьле җәйләр җиттеме, янәшә-тирәләрдән Азнакай ягына ял итәргә киләләр. Көз көннәрендә Бөгелмә, Әлмәт, Лениногорск һәм башка районнардан, автобусларга төялеп, гөмбәчеләр җыела.

Сүз дә юк, табигать бай һәм юмарт. Акыл белән эш иткәндә аның байлыгын тагын да күбәйтергә, юмартлыгын тагын да арттырырга мөмкин. Әмма, кызганычка каршы...

Миңа район аучылар җәмгыятенең җыелышларында катнашырга туры килгәли. Җан әрнеткеч сүзләр, исне-акылны җибәрерлек саннар ишетергә туры килә ул җыелышларда. Браконьерлык, һичкайчан да булмаганча, чәчәк ата икән. Моның өчен фән-техника казанышлары да арсеналга алынган. Менә дигән кораллар, җайланмалардан тыш, акустика җиһазларына кадәр файдаланыла башлаган. Көртлекләрне, мәсәлән, алдалап китерү өчен махсус магнитофон язмалары кулланылуын белдем. Көз көннәрендә басу киңлекләрендә көчле прожекторлар кабына, автомашиналар чаба. Шулай итеп куян аулыйлар. Балыкчылар иң нечкә капроннардан үрелгән аулар, җәтмәләр сала. 1975 елда браконьерлар тарафыннан атылган 9 поши гәүдәсе табылган булган. 1976 елда яраланган килеш читкә китеп газапланып үлгән пошилар саны инде унбишкә җиткән иде...

Тагын бер мисал. Чатыр тавы итәгенә урнашкан Мачаклы поселогы янына 14 баш кыргый кәҗә иярләнә. Көннәрнең берендә кемнәрдер ике-өч машина белән киләләр дә, кәҗәләрнең берьюлы тугызын атып алып китәләр. Бар, номерлары томаланган машиналарны эзләп табып кара!

Моннан өч-дүрт кенә ел элек районыбызда бурсык күп үрчегән иде. Быел исә аучылар җәмгыяте бер генә яңа өнне дә исәпкә кертә алмаган: бурсыклар мәрхәмәтсез рәвештә кырып бетерелгән.

Алда тарихның үзе кебек серле, төрле риваятьләргә керүе белән атаклы Чатыр тавы күренде. Аның куенында «Җәмәй Пугач» чатырлар корып, гаскәр җыеп, көч туплап яткан, дип сөйлиләр картлар. Аның янгыр сулары тирән уемнар белән сырлаган һәм яшел куаклыклар

каплаган итәкләрендә чиксез-хисапсыз санда суер колонияләре яши. Шулай да соңгы елларда бик нык кимеделәр алар. Чөнки суерларны аулау өчен нефть скважиналарының парафинын эретә торган күчмә пар агрегаты куллану «ысулын» тапканнар. Кыяләр икән дә, шлангны өн авызына тыгып пар җибәрәләр ди.

Юлыбыз Мичурин исемендәге колхоз җирләре аша узганда күзебезгә мондый күренеш чагылды. Яр өстенә үк, тагын бер тау кадәрле итеп, минераль ашлама өеп куелган. Әлеге ашлама, яңгыр сулары белән юылып, туп-туры елгага агып төшә. Бу исә барлык тереклек өчен иң зәһәр агу. Шунда ук культуралы көтүлекләрне сугару өчен төшерелгән насос агрегаты тора. Тирә-юнендә мазут таплары. Алардан бер генә метр арадагы Ыкка таба, еланнарга охшап, кара тасмалар сузылган...

Әлеге агрегат Мичурин исемендәге колхозныкы икән. Ә ашламаны, колхозның баш бухгалтеры Хәбибуллин әйткәнчә, мелиорацияләнгән җирләрдән файдалану буенча хуҗалыкара берләшмә председателе Закиров китереп өйдергән.

Актлар төзеп, эшебезне тәгәлләгәч, бу авылдагы күптәнге танышыбыз Кәлимулла ага Хәбибуллинның хәлен белеп чыгарга булдык. Ул шунда туган, гүзәл Ык буенда уйнап үскән. Җиде классны тәмамлау белән колхоз эшенә керешкән. Унҗиде яше тулар-тулмас борын ферма мөдире иткәннәр. Шуннан 1939 елда армия сафларына чакырылган. Мәскәүдән Берлинга кадәр барып җиткән батыр таңкист Кәлимулла Хәбибуллин — фашистлар өне рейхстаг ташына үткен хәнҗәренең очы белән үзенең исем-фамилиясен язган кешеләрнең берсе ул.

1943 елгы «Огонек» журналының бер куш бите Кәлимулланың батырлыгын чагылдыруга багышланган. Төсле фотоларның берсендә якташыбыз үзенең атаклы «Т-34» танкы өстендә басып тора. Икенче бер рәсемдә Хәбибуллин үзләре азат иткән авылларның берсендә кешеләр белән әңгәмә алып бара. Өченче рәсем — Кәлимулла сугышчан дуслары арасында. Шунда ук бу рәсемнәргә аңлатмалар бирелгән. Аннан мондыйрак юлларны укыйбыз: «Безнең зур гына хәрби көчләребез дошман боҗрасында калган иде. Чолганыштагы частьларга ярдәмгә безнең 3 танк җибәрелде. Өч совет танкысы дошман оборонасына бәреп керде. Бу тигезсез көрәштә алар дошманның 30 танкысы белән күзгә-күз очраштылар...» Каты бәрелештә өч танкының икесе җимерелә. Бары тик Кәлимулланың танкысы гына исән. Иптәшләрен югалту ачысыннан тәмам ярсыган танкист өермә булып дошман өстенә ыргыла. «Кәлимулла Хәбибуллин каушап калмады,— дип язып журналда,— ул үзенең батыр көчен күрсәтте, берничә дошман танкысын ялкын ялмады, өч мәртәбә таранга барды, үз машинасының гусеницасы белән дошманның ике үзйөрешле тубын изеп ташлады, зур тизлек белән килеп бәрдереп, дошман солдатлары төялгән 10 автомашинаны юк итте. Дошман боҗрасы өзелде».

Сугыштан соң Кәлимулла ага унике ел авыл советы председателе булып эшли. Инде ул алтынчы дистәне түгәрәкләп килә. Шулай булуга да карамастан, һаман сафта, һаман хезмәттә.

Юлыбыз дәвам итә. Ык буена утырган авылларның төзеклеге, матурлыгы сокланып туймаслык. Менә Сөендек авылы. Монда авылларны яшелләндерүгә, тирә-юнь төбәкне саклауга зур игътибар бирелә. Председателе булып Социалистик Хезмәт Герое Вәгыйз ага Хаҗиәхмәтов эшләгән авыл советы бу мәсьәләне әледән-әле үз секцияләрендә тикшереп тора.

Без яңа юлда. Игътибарыбыз — Ык елгасына якынрак утырган фермаларда, көтүлекләрдә. Алдыбызда районның иң зур хуҗалыгы — «Авангард» колхозы.

Тирә-юньдә көз хакимлек итә. Кургашын сыман авыр болытлар, бар нәрсәне дә җиргә иңдерергә теләгәндәй, җиргә елышып ук йөзәләр дә йөзәләр. Ык өстендә чал башлы дулкыннар шаулаша. Күңелне нәрсәдер бимазалый кебек. Башта — уйлар, уйлар...

Табигать. Бу төшенчәгә без туган туфракны да, иксез-чиксез зәңгәр күкне дә, урман-суларны да, кыскасы, тирә-юнебездәге барлык нәрсәне кертәбез. Табигатьне без өзелеп яратабыз, чөнки ул — кешенең яшел бишеге. Бала ана карынына кендеге белән береккән кебек, кеше күп төрле физик, психологик җепләр белән табигатькә бәйләнгән. Аларны өзү — үз-үзеңне талау гына түгел, һәлакәткә дучар итү дигән сүз. Атаклы язучы Леонид Леонов: табигатьне танып белгән, аның белән якыннан аралашкан кеше күңеле белән баерак, кешелеклерәк һәм намуслырак була, чөнки ул табигать куенында «күңел университеты» узган, дигән фикер әйтә. Лев Толстой да, көннәрнең берендә иң яраткан урыннарында йөреп кайтканнан соң, көндәлек дәфтәренә: шушы кадәр гүзәл табигать куенында булганнан соң кеше күңелендә ачу тоту, үч алу яки үзе кебек үк кешене юк итү кебек хис уяна алырмы икән! Табигать белән, шундый илаһи гүзәллек белән якынайганнан соң кеше күңелендә булган барлык әшәкелек, яман уйлар юк булырга тиеш бит, дигән фикерне язып куя.

Туган якның пейзаж-манзараларына кадәр, үзәкләрне өзәрдәй моңкөйләрдән сугылган тукыманы хәтерләтеп, чыңлап тора сыман. Моның шулай икәнлегенә төшенү өчен Ык буе күренешләренә бер күз сал син. Таң алды эңгерендә тал яфракларының шыбырдап серләшүен тыңлап утырганда, сызылып кына алсуланып таңнар атуын каршылаганда дөньяң түгәрәкләнеп, тормышың тулыланып киткән сыман була. Бәлки бәхет дигән нәрсә дә нәкъ шул үзедер.

Туган якларда ел фасылларының алышынып торуы да үзенчәлекле. Аларның һәркайсы үзенчә матур, үзенчә тәэсирәтле. Менә хисләрне нечкәртеп, кайнар тойгылар уятып, илһам биреп, көч өстәп килгән алтын көзне генә алыйк. Салават күперенең барлык төсләре чагылган диярлек аңарда! Бер үк вакытта фирәзә, җете кызыл, бурлат кызыл, зәгъфран төсләрен күрергә мөмкин. Кая карама — куе томан пәрдәләре эленгән. Ләкин бу хәл озакка бармый, җил чыга. Томан пәрдәсе өзгәләнеп юк була. Бары тик агачлар гына, каядыр җыенгандай, шаулашып хәрәкәтләнәләр... Көзге ачы җилләр шулай аларның башларын тарый, яфракларын җир буйлап очырта...

Табигатьне күз карасы кебек саклау, аны яңадан тергезү мисалларын без Азнакай районы мисалыннан да күпләп китерә алабыз. Менә Чалпы авылы. Ул тоташтан яшеллеккә күмелеп утыра. Бөтен нәрсә уйланылган монда. Әле яңарак кына төзелеп беткән культура йорты хәзердән үк инде шаулап торган парк эчендә. Колхозның йөз гектар мәйданны биләгән җиләк-җимеш бакчасы берничә ел рәттән инде мул уңыш бирә. Иң хикмәтлесе — колхозның ясалма күлләре. Алар, күз тиюдән курыккандай, куе әрәмәлекләргә, җикән-камышлыкларга төренеп яталар. Аларга хәзер киек казлар, көтү-көтү кыр үрдәкләре, тәлтәвечләр ял итәргә төшәләр. Монда мылтыктан ату, җәтмәләр белән балык тоту махсус карар белән катгый тыела.

Авылда агач һәм декоратив куаклар утыртуга аеруча зур әһәмият бирелә. Авылның кайсы гына ягыннан барып кермә, берничәшәр километрга сузылган урман тасмаларына сокланып узасың. Хәзер инде тигез рәтләргә тезелеп үскән яшь топольләрнең күләгәсенә кереп ял итәргә, хәл җыярга мөмкин.

Әлкәй авылының иске зиратындагы яшь наратларны күреп тә күңел сөенә. Алар шундый матур булып үсеп киткәннәр, кышын да, җәен дә бөтен авылга ямь биреп торалар...

Бераздан «Авангард» колхозы басулары башланды. Бай хуҗалык. Башка колхозларга күп яктан үрнәк итеп куела ул. Әмма Тымытыкка житәрәк бик аянычлы күренешкә тарыдык. Мал-туар инде утарларына кайтарып ябылган. Пычрак-сазлык яшь таналарның корсак асларына житкән. Ашарларына салынмаган, кыяфәтләре кызганыч. Калынлыгы метр ярымга житкән тиреслекне ярып сыеклык агып ята. Бернинди тоткарланусыз ул Ык елгасына таба юл алган. Безгә очраган терлекчеләр исем-фамилияләрен әйтергә тартыналар. Без, тирес суы җыелып сазлык-баткаклык хасил булган урыннарны фотога төшереп, колхоз идарәсенә юнәлдек. Шунда колхоз председателе иптәш Харрасовка, әлеге тәртипсезлекләргә юл куйганы өчен, шактый зур суммага штрафка тартылуы турында катгый кисәтү ясалды.

Ык елгасы буйлап түбәнгәрәк төшәбез. Көтүләр кертелүдән тәмам эштән чыгарылган әрәмәлекләр башланды. Яман күренеш бу. Бер көнчыгыш халкында: бер кеше үтсә — эз калыр, йөз кеше үтсә — сукмак калыр, мең кеше үтсә — такыр җир калыр, дигән мәкаль бар. Ә бу тирәләрдән көтү үткән...

Елганың аръягында Башкортстан җирләре. Анда алтын-сары йөгертелгән әрәмәлекләр, урманлыклар белән капланган таулар тезмәсе. Искитмәле матур күренешләр!

Азнакай районында да табигатьне саклау, әйләнә-тирә мохитны яхшырту, табигый ресурслардан хуҗаларча файдалану мәсьәләләренә торган саен күбрәк әһәмият бирелә.

Хәзер районда табигатьне саклау җәмгыятенең 24 меңнән күбрәк әгъзасы бар, урыннарда табигатьне саклау буенча 135 җәмәгать инспекторы эшли. Азнакай һәм Актүбә эшчеләр поселокларында, авылларда ике йөз меңләп төп агач һәм куак, 410 гектар мәйданда урман утыртылды, колхоз урманнары яңартылды, өч гектар мәйданда кыр ышыклау урман тасмалары булдырылды, су эрозиясенә каршы көрәш максаты белән яр-чокыр кырыйларына 31 гектар мәйданда агачлар утыртылды.

Авыл хуҗалыгында файдалану өчен җирләрне колхоз-совхозларга кире кайтарып бирү эше дә эшләнә. 1976 елда колхоз-совхозларга нефтьчеләрдән 826 гектар җир кире кайтарылды.

«Актүбәнефть» идарәсендәге файдаланылучы скважинаның 94 проценты өлеше герметиклаштырылган җыйдыру һәм транспортлау системасына тоташтырылды. Нефтьчеләр башка бик күп чараларны да тормышка ашыралар. Мәктәп балалары кошларны, җәнлекләрне саклау теләге белән рейдлар уздыралар. Өч мәктәп урманчылыгы эшли, аның әгъзалары район территориясендә шактый күп үрчегән суерларны сакларга булышалар. Табигать сөюче укучылар эшенә 3 нче урта мәктәпнең биология укытучысы М. В. Чернова җитәкчелек итә. Татарстан күләмендә уздырылган конкурста бу коллектив былтыр икенче урынны алды.

«Табигатькә ленинчыл караш өчен» девизы белән барган социалистик ярышта районнан өч коллектив Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыятенең Үзәк советы тарафыннан зур истәлек медале, тагын өч коллектив кече медаль белән бүләкләнде, җәмгыятьнең 25 башлангыч оешмасына һәм 18 активистка Үзәк һәм республика советларының Почет грамоталары бирелде. Ә районыбыз республика күләмендә ярышта җиңеп, Күчмә Кызыл байрак, I Дәрәҗә диплом һәм Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыятенең зур медален алды.

Район газетасы үзенең укучыларын «Табигать — халык байлыгы» дигән темага фикер алышырга чакырган иде. Йөзләрчә кеше катнашты бу фикерләшүдә. Гаҗәп тә түгел, чөнки М. Пришвин әйткәнчә: «Табигатьне саклау — Ватанымны саклау» бит ул.

Туйкә авылында яшәүче пенсионер агроном Гарәф ага Фәсхиев үзенең «Кеше тормышы табигатьтән аерылгысыз» дигән мәкаләсендә: «Шомырт, миләш җыю өчен агачларны аудaралар, каеннарны себерке өчен ботап бетерәләр, яшь имәннәрне яфрагы өчен кисәләр»,— дип ачынып язды.

Мөдәррис Усманов үз мәкаләсен: «Берне киссәң — икене утырт», дип атаган иде. Укытучы Ә. Абдуллинаның «Балаларыбызга һәм оныкларыбызга нәрсә калдырабыз?» дигән мәкаләсендә Карл Маркс-ның: киләчәк буынга табигатьне без тагын да баерак итеп калдырырга тиешбез, дигән фикере кызыл җеп булып сузылган иде.

Икмәк комбинаты хезмәткәре Мәгъсүмә Гәрәева — Тымытык кызы. Аның: «Ык буйларын сагынып кайтам...» дигән күләмле мәкаләсендә мондый юллар бар: «Мин үзем гүзәл Ык буенда туып үстем, шуңа күрә сүземне дә бу төбәкнең күрке булып саналган шул елгадан башларга уйлыйм. Бернинди Кара диңгез курортларына да алыштыргысыз тынлыгы, камышлы тугайлары, төбенә кадәр күренмәле чиста сулары белән минем күңел түремдә мәңге сакланыр ул. Ык елгасы буендагы болыннарның ак ромашкаларына яшеренеп бала чагым елмаеп тора сыман, анда тәүге мәхәббәтемнең беренче бөреләре шыткан, куе әрәмәлекләр арасында әниемнең эзләре, өзелеп калган моңнары бар кебек. Су өсләрен бизәгән ак һәм сары төнбоеклары мәңге күз алдымнан китмәс».

Бераздан авторның хикәяләү тоны үзгәрә: «Әмма Ык буйларындагы мең төрле кошлар сайравыннан гөрләп торган куе әрәмәлекләр сирәгәйгәннән-сирәгәя. Су буйлары сыерлар туплавына әйләнә бара. Элекке мең төрле чәчәкләр исе аңкып торган һава да юк...»

Елга буйлап тагын түбәнрәк төшәбез...

Урсай авылының Карповка ягына чыгып китә торган башына җиттек. Бераздан Ык яры буена ук урнашкан дуңгыз фермалары күренде. Шунда юнәләбез. Янә күңелне рәнҗетерлек күренешләр. Күзгә ямьсез* лар, шулай ук краннары ябылмаган торбалардан агып чыккан су тирес өемнәрен тәмам мәлҗерәткән. Шакшы тирес суы Ык елгасына ага... Бу ферма һәм аның уңганнары турында район газетасы битләрендә күп язылды. Нәкъ шул вакытта безнең янга ирле-хатынлы Шәһәдәт белән Мөнирә Гатауллиналар килеп чыкты. Алдынгы терлекчеләр әлеге күренештән чынлап торып уңайсызландылар... Ничә генә ел элек әлеге ферма тирәләре берьюлы берничә көтүне кеше күзеннән яшерерлек әрәмәлекләрдән торган. Хәзер ул тирәләрдә бер генә куак әсәре дә күренми, дуңгызлар сөреп ташлаган чокыр-чакырлар гына каралып ята.

Шул вакыт ферма мөдире Фәрәгать Җамалиев та килеп җитте. Сөйләшү ямьсез төс алды. Башкача мөмкин түгел. Чөнки ферма мөдире нәкъ менә әлеге тәртипсезлекләр, тирә-юньне пычратканы өчен күптән түгел генә бер мәртәбә штрафка тартылган булган.

Урсай авылының икенче башында исә сыерлар фермасы. Мал-туар ишле, 650 баш савым сыер, 400 баш яшь мал. Тирес күп чыга. Әмма монда аңардан «котылуның» җиңел юлын тапканнар — аны Ык елгасы буена гына бушаталар. Шакшы сыекча җыю базларының да рәтләре юк, тулганнар һәм Ык елгасына таба юл ярганнар. Баш зоотехник Р. Гыймаев, колхозның партоешма секретаре С. Кашапов иптәшләр белән дә очраштык. Мондый хәлдән алар да уңайсызланалар, бу кимчелекләргә тиз арада чик куярга вәгъдәләр итәләр.

Әлеге Урсай авылында яшәүче укытучы Тәкыя Шәрипова «Табигать — халык байлыгы» дигән фикер алышуда катнашып: «Туган ягым — бәхет чыганагым» дигән күләмле мәкалә белән чыгыш ясаган. Анда мондыйрак сүзләр дә бар: «Мөгаен, кеше тормышының иң гүзәл сәхифәләре, күңеленә җуелмас тирән эз калдырган истәлекле вакый-

галары табигать белән бәйледер. Бу фани дөньяда тәүге адымыңны атлау белән үк, кояшлы саф һавага, хәтфәдәй яшел чирәмгә омтыласың. Күп тә үтми, житез тәпиләрең сине аллы-гөлле чәчәкләр белән бизәлгән яшел болынлыкка, каз-үрдәкләр йөзеп йөргән агымсу буйларына алып төшә. Әмма бала күңеле моның белән генә канәгатьләнми. Аның күпне белергә омтылучан тынгысыз табигате тагын да арырак, ераккарак карарга сәләтле. Әнә, тагы да арырак карасаң, биеккәккә алып менүче мәһабәт таулар тезмәсе, иге-чиге күренмәгән кара урманнар. Табигать үз баласына торган саен күбрәк серләрен ача, гүзәллеге белән сихерли, әсир итә.— Автор үзенең туган яклары белән мактанырга теләгәндәй, болай дип дәвам итә.— Явым-төшем мул булган быелгы елда Ык буйларының матурлыгына, байлыгына, хозурлыгына кем кенә сокланмады икән! Иртәнге саф жилләр китергән шомырт чәчәкләренең хуш исе сине фирүзә күлләр үзәнлегендә үскән витаминлы үләннәрдән — юасы, кузгалагы, ачы какысы, балтырганыннан авыз итәргә чакыра. Ул арада булмый, тәгәрәп-тәгәрәп жир жиләге пешә, куакларны сыгып, кара карлыганы өлгерә. Июль азакларында ук тамып төшәргә житеп, тәлгәш-тәлгәш кара бөрлегәне үз янына әйди. Аларына шифалы баланы, дәвалы шомырты, витаминга бай карлыганы, гөлжимеше ялгана. Кайчак шулай була: кайсын жыярга белмичә бермәл аптырап каласың: унда да, сулда да, артта да, алда да берсенберсе бизәп, бер-берсен тулыландырып, бер-берсенең дәвамы булып, төрледән-төрле жимеш күз явыңны ала. Мондый чакларда бу камил гүзәллекне, илаһи матурлыкны бозарга базмыйча, жиләк-жимешкә үрелергә кыймыйча туктап каласың. Бер-ике адым артка чигенәсең дә, хәйран булып сокланып карап торасың. Бу мизгелдә күңелең чиксез канәгатьләнү тойгысыннан тантана итә, әйтеп бетергесез куанычың бөтен жаныңны, рухыңны биләп ала».

Сизенәсезме икән, Ык буенда туып-үскән кешеләр нечкә күңелле-ләр, чак кына шагыйрьләр дә. Һичшиксез, гүзәл елга тәэсиредер бу.

Без дә укытучы Тәкыя Шәрипова яшәгән Урсай авылы чигендә, текә яр өстендә торабыз. Монда Азнакай районының чиге. Ык елгасы монда, текә борылыш ясап, Башкортстан жиренә кереп «исәнләшеп» кенә чыга да, яңадан Татарстан жиренә борыла һәм Мөслим районы буйлап үз юлын дәвам иттерә...

Безнең сәяхәтебез шушы урында тәмамлана. Гүзәл Ык белән саубуллашабыз. Хуш! Хәерле юл сиңа, хозур елга. Кабат очрашканга кадәр!..

1977.

## Альберт Хәсәнов

# ГӘРӘБӘ ДИҢГЕЗ ЯРЛАРЫНДА



Туган якларыбызга алтын көзләр килсә, һаман да әнә шул чаклар исемә төшә: елның-елында авылыбыз өстеннән көтү-көтү булып кыр казлары, үрдәкләр, торналар очып узарлар иде. Аларны басуда көлгә күмеп бәрәңге пешереп яткан малайлар арасыннан берәребез күреп ала да:

— Кыр казлары! Киек казлар китеп бара! Алдагы көтү минеке! — дип кычкырып җибәрә. Барыбыз да көзгечә моңсу, әле тегендә, әле монда ертык-ертык болытлар йөзгән күккә таба төбәләбез.

Арабыздан берәү аларны санарга керешә:

— Берәү, икәү, өчәү...

— Санама! Рәтләрен чуалтасың ич!

— Ләкин соң инде. Парадка чыккан солдатлар төсле бер сафка тезелешеп очкан кошларның рәтләре безнең күз алдында ук чуала башлый. Менә бит нинди хәл. Санаганны яратмыйлар. Киек казлар беркавымны шулай тәртипсез, буталышып очалар. Җылы якларга китеп баручы киек кошларның вакыт-вакыт шулай буталышып очуларында аларны санарга керешкән малайның гаебе булмавын ул чакта без әле белми идек шул. Алдан һава ярып очкан кошлар береаздан арткы сафларга күчәләр, аларны моңарчы арткы рәтләрдә ял итеп килгәннәре алыштыра. Шул арада кошлар байтак вакыт буталышкан хәлдә очалар.

Моңсу авазлар белән каңгылдашып киек казлар җылы якларга ашыгалар. Туган яклардан аерылып китү кемгә җиңел? Шул чакларда кайгы белмәгән, хәсрәтне татымаган хыялый башкайларыбызга, кара, бу дөньяда әнә шундый моңсу аерылышулар, сагынып күрешүләр дә бар икән дигән уйлар килә. Шунда әти-әниләребез, абый-апаларыбыз өйрәткән һәм саубуллашкан чакта әйтелә торган матур сүзләр исебезгә килеп төшә.

— Юлларыгыз уң булсын, кошкайлар-р-р! — дип, инде күздән югалып барган киек казларга кул болгарга керешәбез.

— Юлларыгыз уң булсын! Язларын безнең якларга исән-сау әйләнеп кайтыгыз!

Кошлар инде үзләре күптән югалдылар. Әмма аларның моңсу каңгылдашулары әле һаман да колакларыбызда яңгырап тора...

Инде менә Балтик диңгезе ярларына аяк баскач, шушы киек кошлар белән янә дә очраштым. Берәү, икәү, өчәү дип кыр казлары санаган чаклар исемә төште. Күңелгә әллә нинди матур хатирәләр килде...

Чын күңелеңнән гаҗәпкә калыр, хәйраннар булыр нәрсәләр бик күп монда. Кайчандыр граф урманы булган иксез-чиксез паркның тын

сукмакларыннан әледән-әле кыр кәҗәләре, алмачуар, затлы боланнар, антилопалар йөгереп узалар. Кешеләрнең шулай якынлыгы бу җитез аякларны артык куркуга төшерми төсле. Киресенчә, алар үзләре кешегә тартылалар, аның белән янәшә булырга омтылалар төсле тоелды миңа. Бер мизгелгә тирән уйга калгандай тып-тын утырган наратлар, ямь-яшел чыршылар артына посалар да паркта ял итеп йөрүчеләрне кызыксынып күзәтәләр. Аралар нибары өч-дүрт адым калгач кына, качып торган җирләреннән атылып чыгалар да, кояш ялап алган иртәнге чык бөртекләредәй юк та булалар.

Агач ботакларында чыркылдашкан кошлар арасында ниндиләре генә юк. Күпләрен, гомердә беренче тапкыр күргәнлектән, таный да алмыйбыз. Ә карлыгачлар! Алар ояларын парк сукмакларындагы таш урындыкларның асларына, кыйгач тирәкләре артларына ясаганнар. Урман сукмагы буйлап килгән кеше шушы эскәмияләрнең берәрсен сайлап ял итә, куенындагы китабын ачып укып утыра, арыганы, талчыкканы тәмле генә итеп черем итеп ала. Ә кешеләрнең шулай якын булуы карлыгачларны әз генә дә борчымый. Алар үз эшләре белән мәшгуль. Берләре ояларын төзекләндерә, икенчеләре җим ташыйлар. Эштән бушлары, синең баш очында ук пыр-пыр килеп, очып уйныйлар. Кара син бу гүзәллекне, кара син бу хозурлыкны дип исләребез китеп йөрдек без бу паркларда.

Паркның аргы башында, куе куаклар арасында бал кашыгы кебек түгәрәк бик матур күл дә бар. Шушы күлдә йөзеп йөргән йорт үрдәкләре арасында, бер төркем киек үрдәкләр дә күреп, тагын да гаҗәпкә калдык. Декабрь кергән иде. Көннәр суынып китсә, күл өсте боз катламы белән капланса, йорт үрдәкләрен хуҗалары өйләренә алып кайтып китәрләр. Ә бу бичаралар кая барырлар! Хәер, кышлар бу якларда ярыйсы йомшак булалар икән. Урман эче ышык, күл суы туңмый, ничек тә кышларбыз әле дип уйлаганнардыр инде үрдәкләр дә. Ләкин күпләр хәтерли торгандыр, үткән кыш үтә дә суык булды. Гәрәбә диңгез ярларына да котып җилләре исәргә тотынды, көннәр кинәттән генә суынып киттеләр. Тын күлнең дә читләре бозланды. Күлгә шәһәр эченнән агып килә торган җылы сулы кечкенә генә елга коя. Бичара үрдәкләр бары да шул култыкка җыйналганнар. Әмма көннәр шушы килеш торса, боз котламы бу мәйданны да яулап алачак. Алдагы көннәре өчен тирән хафага төшкән үрдәкләр үзара крә-крә килешәләр.

Салкыннар чыннан да озаккарак китте. Чүрәкәйләр йөзеп йөргән түгәрәк бөтенләй кечерәеп калды. Болай торса, бүгенле-иртәле бу мәйданчык та боз белән капланачак. Инде без дә артык түзеп тора алмадык. Беркөн иртән бөтен ял итүчеләр белән бергәләп көрәкләр, ломнар алып килдек тә, бөтен күл өстен чабып ташладык. Багорлар белән тартып боз кисәкләрен яр читенә өеп куйдык. Безнең җан тиргә батып, суга чыланып боз чабуыбызны чүрәкәйләр яр читенә чыгып тын гына күзәтеп утырдылар. Алар өчен тырышып йөрүебезне аңлыйлар төсле. Әледән-әле крә-крә килеп куюлары чиксез зур рәхмәтләрен белдерүләре булгандыр.

Ә ул арада җил Атлантикадан исә башлады. Үзе белән Гәрәбә диңгез буйларына җылы яңгырлар алып килде. Әле кайчан гына бөтен күл өстен басып алырга гайрәт корып яткан боз катламы ярты көн эчендә юкка чыкты. Күл өстендә шатлыкларын-сөенечләрен тыя алмыйча крә-крә килешкән чүрәкәйләрнең тавышлары гына ишетелә. Аларга карыйм да, туган якларыбызның алтын көзләре, авылыбыз өстеннән көтү-көтү булып очып узган киек казлар, үрдәкләр, торналар күз алдыма килә. Көлгә күмеп бәрәңге пешереп яткан малайлар арасыннан берәрсенең, аларны күреп алып:

— Кыр казлары! Киек кошлар китеп бара! Алдагы көтү минеке!— дип кычкырып җибәрүен ишетәм төсле...

## Роберт Рәкыйпов



*Әдәбият сөючеләр Робертны «Идел» альманахының алтынчы санында чыккан «Диңгезче хикәяте» дигән повесте буенча беләләр. Автор — үзе элекке су асты диңгезчесе, запастагы өлкән лейтенант — совет диңгезчеләренең Бөек Ватан сугышы елларындагы батырлыгы хакында яза. Шул тема яшь автор иҗатында төп урын алып тора. Ә үзе ул хәзер Әлмәт шәһәре интернат-мәктәбендә математика укыта.*

*Роберт Рәкыйпов — Әлмәт яшь язучылар берләшмәсенең актив члены. Укучылар карамагына аның шунда укып тикшерелгән шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

### Диңгездә

Диңгез өстен күксел томан баса,
Җиз иләктән койса яңгырлар.
Күз алдымда Җирем чәчәкләре
Хуш ис бөркеп һаман аңкырлар.

Күмеп китәр төсле тау-дулкыннар
Ыргылганда шашып корабка...
Нигә эзлим икән җир кисәген
Карашымны төбәп еракка?!

Җил-давыллы һава диңгез белән
Ишелеп аккан тоташ болытта.
Диңгезченең күңелен ерактагы
Бозлы яр да икән җылыта.

Туган илдән искән көзге җил дә
Җырлап туймас моңлы җыр миңа.
Ватанымның корыч кораблары
Океаннарда — туган җир миңа.

Аяз күктә очса акчарлаклар,
Баш өстендә янса кояшың,
Кочаклардай булып чал диңгезне,
Талпынулы хисләр тоясың.

Диңгез өсте кабат ал чәчәктә,
Кыйгачлана акчарлакларым.
Минем дә шул җитез акчарлактай
Диңгезләрне гизәр чакларым...

## Мин көтәм

Походларда океан өстендә
Җил-давыллар үкереп искәндә,
Мин һаман шул сүзең ишетәм:
— Мин көтәм!

Корыч көймә диңгез төбендә
Йөзгән чакта поляр төнендә,
Мин һаман шул сүзең ишетәм:
— Мин көтәм!

Шомлы җилле төнге сакта да,
Ялгыз һәм йокысыз вахтада
Мин һаман шул сүзең ишетәм:
— Мин көтәм!

*
* *

Күз алдымда кыя атау — Курил яры.
Диңгезләрнең тирәннәре, ярсулары...
Тулпар аттай дулкыннарның чупылдавы...
Колагымнан һич тә китмәс диңгез шавы.

Туган илнең яңа көне туган ягы
Сахалины, Камчаткасы, океаннары...
Яшьлегемнең хәрби кием кигән чагы...
Колагымда һаман да шул диңгез шавы.

Җилбер-җилбер җил уйнаткан кораблары,
Яшьлегемә эзләр уйган вахталары.
Күзем йомсам — күз алдымда давыллары...
Колагымда — һаман да шул диңгез шавы.

## БАМ чаңы

Өем болытларның читләренә
Язгы кояш алтын йөгерткән,
Кар сулары ага челтер-челтер,
Умырзая җирдән баш төрткән...

Киек казлар кайта,
Яшь калалар калка —
Золотинка, Тында, Ургулар.
Амур-егет әнә гайрәт чәчә:
Дулкыннары ярга ургыйлар.
Ишелеп-ишелеп үсә мул чәчәкләр,
Баш әйләнә сихри хуш искә.
Җир шарының иң бай читедер бу
Мәхәббәткә, туйга, дус-ишкә.
Яшь көчләрен дәшеп ил күтәргән
Миллионлаган яшьләр БАМы бу.
Яктылыгын планетага сипкән
Бүгенгенең яшьлек даны бу.
Бу хезмәткә, бу яшьләргә карап
Дөнья хәйран, дөнья таң кала.
Тын океанга кулын суза Байкал,
БАМ өлгерәм диеп чаң кага.

## Безнең яшьлек

Котыптагы зәһәр салкын бураннарга,
Күкрәп аккан Енисейга бирешмәслек.
Бар дөньясын таң калдырып БАМнар кора
Безнең яшьлек.

Ай елмая, Зөһрә йолдыз күзен кыса,
Нинди күркәм, нинди хозур теләктәшлек.
Бу галәмнең тиңсез лачын-пионеры —
Безнең яшьлек.

Болытларга аша безнең ак калалар,
Булса булсын җилер буын сүз әйтмәслек!
Туган илгә КамАЗларны бүләк итте
Безнең яшьлек.

Ленин биргән кызыл байрак нур балкыта —
Киләчәккә дәртләндереп, алга дәшеп.
Ил эндәшсә, баһадирдай әзер тора
Безнең яшьлек.

## Камил Кәримов



*Мин Шәле дигән зур авылның кечкенә бер улы. Гасырыбызның кыл уртасында минем өчен дә бишек эленгән. Туган елым әтиемне җирләгән ел... Әниемнең мичтән ипи алганын өч бала көтеп тора идек.*

*Табигатькә кечкенәдән гашыйк, шуңа, ахры, безнең авылга язлар бик иртә килеп, көзләр соң гына китә торган иде.*

*Мәктәпне тәмамлагач, су скважиналары бораулаучысы булып эшләдем. Хәзер Казан дәүләт культура институтында укыйм.*

*Беренче әсәрләрем «Яшь ленинчы»да басылды.*

# ТӘНӘФЕС

ХИКӘЯ

Колхоз рәисе халыкның кичке ашка утырганын көтеп кенә торган диярсең:

«Тыңлагыз! Колхоз радиочелтәре сөйли. Хәерле кич, хөрмәтле колхозчылар. Ашыгыз тәмле булсын! Белдерүләр тапшырабыз.

Иптәшләр, механизаторлар җитешмәү теңкәгә тия, шуны исәпкә алып, авылда техник мәктәп ачарга булдык. Уналтыдан утыз биш яшькә кадәр булган егетләр-кызлар, ирләр һәм хатыннар бер ел эчендә киң профильле механизатор таныклыгы алачаклар. Стипендия ел дәвамында алтмыш сум, махсус кием-салым биреләчәк. Укулар ноябрьның 15 еннән башлана. Кабатлыйм...»

Сатирә, Гомәрнең ачык авызы янында туктап калган кашыкны күргәч, җәһәт кенә урыныннан торып, радионы сүндереп килде.

— Аша, эч! Әнә, чәең бәке уярлык булган, шул хәтле суытмасаң соң?

Гомәр боткалы кашыгын кире тәлинкәгә куйды һәм тиз генә бер йоту белән чынаякны бушатты да торып китте.

— Кая барасың?!

— Тартып керәм.

— Өйдә генә тарт, чыгып йөрмә! Мич алдына утыр да...

— Хәйдәрләргә кереп чыгасым бар, тәмәкем беткән.

Әгәр бу минутта өй эчендә берәр чит кеше булса, бәлки гаҗәпләнерлек берни дә күрмәс иде. Гомәргә шаккатырлык хәл иде бу. Төтен исе сизсә, тәрәзәләрне ачып, башындагы яулыгы белән өй эчендә дәвыл чыгаручы Сатирә хәзер үзе үк мич алдында тартырга рөхсәт итә! Алай гына да түгел, кунаклар алдында тартыр дип, яшереп куйган «Беломор»ны да кызганмады.

Ә Гомәр кулындагы тәмәкедән тизрәк котылу ниятендә. Мич авызына сыймаган төтен Сатирәнең сулышына иярде.

Сатирә — сыер савучы. Ул ат җигүче Гомәргә караганда күбрәк хезмәт хакы ала. Шуңа күрә үзен гаиләнең иң баш хуҗасы дип исәпли.

— Шул гына җитмәгәние. Ике балаңа ияреп укырга йөрисең киләме? Булмас!!!

Хуҗа кешенең сүзе закон. Гомәр каршы эндәшеп торуны кирәк дип тапмады. Закон чыгаручы кичке савымга, фермага киткәч кенә күршесе Хәйдәрләргә кереп чыгарга булды.

Хәйдәрнең, күтәрә алмаслык бүкәнгә балтасын чабып, уйга калган чагына туры килде.

— Балтаң кысылдымы?

— Кысылды... Ишеттеңме?

— Ишеттем. Алтмыш сум түлибез, ди. Ул акчага бер ай буе дилбегә тартырга бит... Ә монда парта арасына утырып кайткан өчен. Гомер буе ат җигәргә димәгән. Безнең ишеләр техниканы җигә.

— Сатирәңә шулай дип аңлаттыңмы соң?

— Әйтергә ирек бирмәде.

— Минеке дә.

— Нишлик икән, Хәйдәр, ә?..

Хәйдәрнең беләгенә тагын бер ир-егет көче кушылган кебек булды. Ул көчәнеп тә тормыйча, балта чабылган бүкәнне җилкәсенә салды һәм баш аркылы әйләндереп төпкә бәрде. Ничәмә еллар бирешмәгән бүкән урталай ярылды.

— Гомәр, иртәгә үк язылабыз!

Хәйдәрнең иртәгесе бик тиз килеп җитте. Авыл советы нәкъ үзәктә, бара башласаң ярты авылның күзенә чалынасың. Кешегә хәзер ыржаерга гына булсын, сакаллы сабый дип көлмәгәйләре...

Секретарьның төшке ашка кайткан чагын тыкрыкларның берсендә сагалап торып, исемлеккә телдән генә язылдылар.

Октябрь аеның беренче таңын Гомәр тезмәдәге печән эчендә каршы алды. Рәхәт. Урын да җыеп торасы юк. Баскычтан төшешли, юл уңае, абзардагы терлекләргә печән култыклап аласың. Чәч арасындагы печән вакларын гына тарап төшерәсең дә ишегалдындагы баганага кадакланган юынгычка үреләсең. Суы бозланып каткан икән, аптырамыйсың, бит-кулыңны кыйбла яктан искән җилдә җилләтеп алырга була. Өйгә су эзләп кермәссең ләбаса. Сатирә ястыгын бусага төбенә салып ятты бугай. Бар, кереп кара!.. (Сер итеп кенә әйтик, Гомәр белән Сатирәне «Юмор белән Сатира» дип үртиләр бездә.)

Төрле урамнардан ике дистәгә якын кеше җыелды.

Дүрт бүлмәгә бүленгән иске өйне мәктәп дип, егерме биш ел тракторчы булып эшләгән Каюм абыйны класс җитәкчесе дип атап, беренче дәресне башлап җибәрделәр.

Укытучыга тиз генә күнегә алмадылар. Гел мазутлы комбинезоннан күреп ияләнгәнгәме, Каюм Әхәтович кара костюм-чалбар, ак күлмәк һәм бизәкле галстуктан булгач, күбәләкне хәтерләтә иде.

— Бүгеннән башлап сез курсантлар. Сезне фамилиягез белән генә атап йөртермен. Танышуга вакыт әрәм итеп тормабыз, сразы тракторлар китабының беренче битен ачабыз. Кәгазь алып килгәннәр язып барыгыз... Һәрбер үзйөрешле нәрсәнең иң кирәкле өлеше ул — кәкрешипле шатунлы механизмнар. Алар түбәндәгеләр...

Гомәрнең күңеле тынычсыз. Иртәнге савымнан кайткач, Сатирәсе эзләп килмәгәе. Оятка калдыруы бар. Күренә калса, тиз генә янына йөгереп чыгу һәм читкәрәк алып китеп тагын бер кат аңлатып карау уе белән ул гел тәрәзәнең урам ягына каранды, Сатирә күренмәде. Аның караవы, мәктәп ишеге төбенә курсант Әюповның олы кызы Сәлимә килеп басты.

— Фатих, кызың ашарга алып килгән!

Чираттан тыш тәнәфес ясап Сәлимәне алып керделәр. Күкрәк тирәсенең әллә кайсы төшеннән генә дәфтәр тартып чыгарды, укырга килүе икән... Фатихны көч-хәл белән тынычландырдылар.

Тәҗрибәле укытучы Мәгъсүм Хәбирович дәресендә генә мәктәпчә тәртип урнашты. Ул арифметика белән геометрия дигән җисемнәрдән торган математика фәненә өйрәтергә тиеш иде.

Курсантларны парталарга икешәрләп таратып чыкты. Алгы рәткә утырырга теләмәүчеләр дә табылды. Хөснулла Сәлимәгә ошардай егет булганга, Фатихның үтенүе буенча, аларны аерым утырттылар. Гомәр Сәлимә белән, Бәдретдин Хәйдәр белән бер партада.

Сер түгел, Хөснулла берничә тапкыр Сәлимәне таң атканчы урамда тоткан иде. Кызның укырга килүе дә икесе тарафыннан гына уйланылган эш түгел микән әле. Урта мәктәпне тәмамлагач, шәһәргә китеп бармаулары да сәер.

Мәктәп ишеге янына көпчәкле трактор килеп туктады. Рульдә Каюм Әхәтович. Урамнан көнгә әллә ничаклы трактор үтеп китә. Сыный карагач, монысы никтер бик сәер төсле.

Хөснулла Фатихның иңсәсенә төртеп алды:

— Беләм мин моны, Вахитныкы бу. Шәп трактор!.. Әз генә этеп җибәрсәң дә кабына. Вахит аны гел тау башына менгереп сүндерә иде.

— Өр-яңаны бирмәсләр инде, йөри бит...

— Таудан төртеп төшерсәң, син дә...

Хөснулла җәйге айларда прицепщик булып эшләп алды. Шуңа күрә тракторларны тануы бер дә гаҗәп түгел. Аның инде руль тотып утырганы бар. Руль дип, чылбырлы тракторның руле юк, рычаглары гына, кайсысын тартсаң, шул якка борыла. Прицепщикның җир сөреп карыйсы килми димени?!. Каюм абый иде аның тракторчысы (Әйе, Әхәтович). Бик сорагач, бар соң, бер-ике буразна гына сызып кара, диде... Ә үзе чөйне тартып алып, сабанны ычкындырып куйган. Әй, китте Хөснулла алдырып, әй, бара, күрсәң, тузан да чыкмый. Бер әйләнеш ясап туктаса, ни күрсен — буразнада дүрт канатлы сабан. Арткы тәрәзәнең нәрсәгә кирәклеген шунда аңлады инде ул.

— Егетләр,— дип, Каюм Әхәтович янындагыларны күздән кичереп чыкты.— Тракторны класска алып керергә кирәк. Бу безгә күрсәтмә әсбап — тимер китап.

— Булдырса Хөснул гына булдырыр. Трактор белән өйгә керергә ул оста...

Андый хәл булды. Тик Хәйдәр нык арттыра инде, өйгә түгел лә... Хөснулла бер мәл трактор кабызып карамакчы иде, ә тегесе беренче тизлектә калган икән. Кабынды да каршыдагы бура эченә кереп тә китте. Болай җимермәде үзе, чәчте генә. Күрүчеләр бар иде шул...

— Сүтеп алып керәбез дә, класста яңабаштан җыябыз,— диде Каюм Әхәтович.

— Җыйгач кына чыгып китсә?

— Курыкма, Хөснул, көпчәкләрен алып букәнгә бастырырбыз.

Ник дәресләрне көне-төне тоташтан алып бармыйлар икән? Гомәр укыр да укыр иде, өйгә генә кайтасы булмасын. Ә кайтырга кирәк...

Кайтып килә Гомәр... Сатирә, бар ачуын чыбыкка өстәп, ишегалдында келәм кага. Чыбыктан артып калган ачуы көйгән бәрәңге исе булып урамга таралган. Капка кул тидергәнне дә көтмичә ачылып китте. Кояш та гүя шаһит булырга теләмәде, болыт артына кереп посты.

— Укып кайттыңмы, атасы?.. (Мыскыллавы, билгеле.)

— Башлап җибәрдек...

— Нәрсәләр өйрәндегез соң?

— Бүгенгә күп түгел әле, Сатирә. Пешкәк, шатун, терсәкле вал.

— Мин сиңа хәзер күрсәтәм терсәкле-йодрыклы валларыңны.

Һәм Сатирәнең әчтерхан чикләвеге кадәр йодрыклары Гомәрнең җилкәсендә биеп алды. Гомәр кузгалмады да. Җилкәсенең кычытып йөдәткәли торган урынын йодрык астына туры китереп тик басып торды... Әйдә, ачуы басылсын. Кеше ләбаса, җаны булырга тиештер.

— Эшең менә дигәние. Әнә, атыңны Гаптелвәлигә биргәннәр.

— Ну, җиксен инде. Аты да, Гаптелвәли дә бер чама.

— Әз булса да арба төбендә печәне, утыны кайтты.

— Быелгы кышка җитәрлек әзерләдек.

— Киләсе елга нәрсә?

— Трактор арбасына җәеп алып кайтырмын.

— И-и! Җүнләп дилбегә тота белмисең, трактор тагын...

— Атның үз ие, минем үз уем. Ә трактор ул башка, Гомәрнең ие — аның ие.

— Бер көн мәдрәсәдә укыды — инде мулла булган.

— Мәдрәсәдә түгел, мәктәптә, карчык...

— Гомәр дим (бусы инде һичбер мыскыллаусыз), соң, егет чагында укып калырга идең.

— Хәзер нәрсә җитми? Хезмәт хакым килеп торыр, үзем өйдә, йорт эшләренә булышам...

— Ә балалар?!

— Әй, ат хәтле ике кызың өчен ничу...

— Әкрен, өйдә бит, дәрес хәзерләп утыралар.

Класста гына түгел, авылда да бер генә ул Бәдретдин. Аның вак-вак кына атлап йөрүе, атлаганда бөтен буыннарының да хәрәкәтләнүе беркемнекенә охшамаган... Эче тулы җыен юк-бар мәзәк булыр — авызын ачса, сулышына ияреп мәзәк чыгара, ә үзе бер дә көлмәс. Җәй айларында физкультура укытучысы булып эшләде, ә курс ачылу турында хәбәр таралгач, иң беренче булып исемлеккә язылды. Авызына капкан тәмәкесен гармун күреге кебек сырлар. Суырганда чырае әллә ничә төрле кыяфәткә керер. Әгәр шулчак салпы ягына берәр уч салам да кыстырып куйсаң, тәмәкесен иреннең бер читеннән икенче читенә

әүмәләргә керешә, җилкәсендәге бөкресе турая, буе тагын да озынаеп китә.

Ул Хәйдәр белән бер партада. Мәктәпкә иң беренче булып килә. Килә дә, ишектән кергән берсенә Бәдретдингә генә хас сәламен бирә:

— Хәйдәр «телевизор» дигән клубта озаграк утырган, ахры, мәктәпкә килеп җиткән, ә үзе һаман йоклый.

— Гомәр, чалбарыңнан очып чыгасың ич, каешыңны тарттыр...

— Фатих, газиз башыңны ник түбән идең, тапкырлау таблицасын тагын өйрәнә алмадың мәллә?

— Җәмәгать, сүгенәселәрегез сүгенеп бетерегез, Сәлимә килә!..

Дәрестә дә Бәдретдин үз «манерын» саклый бела: сөйләвен тыңлап торсаң — тракторга караган саен көләсең генә килер. Җитмәсә, һәр җөмләнең бер-ике сүзен төшереп калдырган була — кыскалык янәсе.

Каюм Әхәтович бүгенге көнне Бәдретдиннән башлап җибәрде.

— Өйгә нинди эш бирелде әле, Бәдретдин?

— Дизельнең дүрт такты!

— Нинди тактлар инде ул?

— Кертү, кысу, эш эшләү һәм чыгарып җибәрү.

— Тактсызрак сөйлисең.

— Кертү такты, кысу такты, эш такты һәм чыгару такты... Барыбер түгелмени...

— Барыбер түгел шул,— диде Каюм Әхәтович тыныч кына,— барыбер булса, тракторны циркта күрсәтерләрие... Ярый... Хәйдәр, шул тактларның тәртип номерын санап чык әле.

Хәйдәр Бәдретдингә, партадан төшеп тор, дип баш кагып кына ымлап алды.

— Партаны күтәрмә, Хәйдәр, янга чыгып бассаң җайлырактыр,— дигән иде дә, тик соңыннан кире уйлады Каюм Әхәтович.— Тукта, Фатихтан гына сорап карыйк әле.

Фатих хәзер көннәрне тәнәфесләр саны белән генә саный. Бүгенгенең тагын ике тәнәфесе бар. Вакыт дигәнең әкрын үтә, сәгатьләр никтер авыр кыймылдый, әйтерсең тел итеп гер асып куйганнар. Булырмы икән ул соңгы тәнәфес дияр көн?!. Өйдән дә рөхсәт юк, тракторлар да катлаулы нәрсә, геометрия дигәне дә бик шома — тотыныр җире юк. Әллә казылган кадәренчә коесы белән энәсен дә калдырып китеп барасы микән?!. Китүен китәрсең, иптәшләр кала. Трай тибеп бер елың үтәр дә китәр, ә дуслар һөнәрле булырлар. Шәт арабызда Ислам абыйдан остарак җир сөрүчеләр дә бардыр әле. Телевизор, мотоцикл, радиола кебек күчтәнәчләр гел аңа гына димәгән. Ашка сала торган яфрактан үрелгән такыяны Фатихның да киеп карыйсы килә.

— Бәдри, нәрсә булса да ялганла хет, син кызык итеп ялганлыйсың,— дип ялварды Фатих.

Бәдретдин сөйлә дип әйткәнне дә көтми сөйли башлый:

— Түлке бүлдермәгез... Кырык алтынчы елларда колхоз амбарыннан кемдер ике капчык бодай урлаган. Авылга следователь килә. Рус була, кәнишне, шунсыз какой мәзәк! Урамда иң беренче очраган кешене туктата да сорый бу: «Дедушка, как думаешь, кто у вас большой вор»,— ди. Бабай әйтә: «Иди прәме, большой вор через двор, маленький вор каждый двор», ди.

— Ул хәтле карак хәзер дә юк бит ул бездә,— дип бүлдерде Гомәр.

Бәдретдин аңа шундук җавап кайтарды:

— Ат җигүченең бүреге яна!!!

...Дәрескә чакырып кыңгырауны ике кат шалтыраттылар.

Бәдретдиннең керпе тиреле телен йомшарту нияте белән өч кеше бергә берләште. Югыйсә, ул гына фәлән, ул гына төгән, ул гына күп

белә — күпне күргән, аның Мәрзиясе генә иренең укып йөрүенә шат, алар гына чүкердәшеп яшиләр, имеш. Иң яхшы тәкъдиме өчен Гомәр «бригадир» итеп билгеләнде. Хәйдәр аның ярдәмчесе, Фатих — ярдәмченең булышчысы.

Математика дәресләре урта мәктәп күләменнән артмаганга күрә, Хөснулла белән Сәлимәгә күңелсезрәк иде. Мәгъсүм Хәбирович класс журналын актарганда, Хөснулла Сәлимәгә хат яза торган дәфтәрнең уңөченче битен ертып алды. Һәм нидер язып, кызның кабыргасына төртте. Сәлимә дә кәгазьне алып нидер язды һәм киредән Хөснуллага бирде. Бу — дәрес вакытында тавышсыз-тынсыз гына сөйләшү ысулы. Укытучы Хөснулланы такта янына чакырып чыгарды:

— Пифагор теоремасын исбат ит.

— Теорема: туры почмаклы өчпочмакта ике катетның квадратлары суммасы...

Фатих Хөснулланың дәфтәре арасыннан хатны алып Хәйдәргә тапшырды. Ә Хәйдәр сиздермичә генә Бәдретдиннең кесәсенә салып куйды. Бүген стипендия алдылар, акча белән янәшә яткач, хатның Мәрзия кулына керүе көн кебек ачык иде.

Хөснулла «5»ле билгесенә хозурланып, башкалардан ныграк белүенә тагын бер кат ышанып һәм хат турында бөтенләй онытып, башын беләгенә куйган хәлдә, «черем итеп» алырга булды.

...Вакыйга дәрес вакытында барганга, пышылдап сөйләшәләр.

Сәлимә: Хөснулла. Хөснул дим... Хөснул.

Бәдретдин: Хөснул уснул.

Гомәр: Сәлимә, ике бөртек кенә чәчеңне өзеп бир әле.

Сәлимә: Нәрсәгә ул сиңа?!

Гомәр: Юрап карыйм, бабайдан калган осталыгым бар.

Сәлимә: Мә... Әйтеп кара, быел кияүгә чыгам микән?

Гомәр: Бер уч бирмәсәң дә әйтә ала идем. Чыгасың, быел ук. Чәчәк аткансың инде, орлык бирмичә калмассың, Хөснул җиңел кулдан өзәр әле, боерган булса. Менә дигән егет.

Сәлимә: Хөснулны һаман белеп бетерә алмыйм әле, әллә нинди, катлаулы ул...

Гомәр: Өйләнешкәч өч көн ял бирелә, яхшылап танышырсыз.

Сәлимә: Син бигрәк инде, Гомәр абый...

Мәрзия керләр үтүкли. Бәдретдин аның каршысына килеп басты.

— Җимеш, бүген стипендия алдык.

— Чынлапмы?!

Бәдретдин күбрәк булып күренсен өчен тәртипсез бөгәрләгән акчаларны ак дәфтәр бите кебек үтүкләнгән сатин яулык өстенә куйды. Учына ияреп чыккан кәгазь кисәген аралап алмакчы иде, өлгермәде... Кәгазьгә менә нәрсәләр язылган иде:

«Сәлимәкәй! Ник кичә миннән качтың? Төне буе күзгә йокы кермәде.

— Көн саен күрешкәч кызык түгел, сагынылмый.

— Бүген килимме?

— Үбәм дип җаныма тимәссеңме?

— Юк!

— Алайса, өй түренә килмә, кешедән яхшы түгел. Өч аерлы тал янына...

— Вакыты?

— Гайбәтчеләр йоклагач инде.

— Унгамы?

— Унбергә хәтле генә, эти әрли...»

Көнчелек врачлар тарафыннан чир итеп билгеләнә алса, Мәрзиянең диагнозына «тумышыннан килә» дип тә өстәлер иде.

Дөньяда Адәм абый белән Һава апабыз гына көнләшмәгән, диләр, чөнки алар Җир шары хәтле фатирда бары тик икәүдән-икәү генә яшәгәннәр. Ул вакытларда Сәлимәләр дә, башкалар да булмаган... Тыеп кара инде хәзер Мәрзияне.

— Фатихның иранай Сәлимәсеме?!

— Каян белим, һич катнашым юк.

— Икейөзлеләнмә, кем икәне кара пәлтәнә сары чәч белән язылган. Анда гына сары чәч, чәкән мунчаласы төсле...

— Кызма әле, язу рәвеше дә минеке түгел ич!

— Язуны аны кирәксә кырыкка авыштырасың... Китәм, суга төшкәндәй юк булам, чумып-чумып эзләрсең, ну, соң булыр!

Мәрзия теле арганчы әрләде. Йолкынышып та алдылар. Бергә утырып чәй эчтеләр. Тагын дулаштылар...

Бәдретдин йокыга киткәч, ул әкрен генә торып, өч аерлы өянке янына юл тотты. Салкын дип тормады, сәгать ун тулганны көтте. Күрде ул Сәлимәне, Хөснулла белән икесе иде... Әй, йөгерә-йөгерә кайтты Мәрзия. Кайтты да кар салкыны сеңгән тәне белән, йокыга талган Бәдретдиннең кайнар куенына чумды.

Язның чын-чынлап килүе иде. Ишегалдында кош-корт, мал-туар кояшта йокымсырый. Түбәдән тамчы тама.

Менә капкадан Хәйдәр күренде. Өч елдан бирле ватылып, инде әчке әгъзаларын бала-чага сүткәли башлаган матайны карап азапланган Гомәр Хәйдәрне күтәренке күңел белән каршы алды.

— Тәки таптым бит фәлшесен, пешкәге ярылган икән.

— Укыган кеше укыган кеше инде ул.

— Үртәмәсәнә...

— Әйдә киттек, ташла эшеңне.

— Кая киттек?

— Кара, оныткан да тагын. Бүген диплом алабыз бит.

Гомәр сыртына тавык кунган ат шикелле сискәнеп куйды һәм тизтиз ачкычларын җыя башлады.

Мөнир Йосыпов

# КҮРЕНЕКЛЕ ТАРИХЧЫ

Шиһабетдин Мәрҗани яшәгән һәм иҗат иткән еллар (1818—1889) Россиядә феодаль-крепостной строй җимерелә һәм капитализм күтәрелә башлаган чорга туры килә. Бу вакытта төрки телле халыклар арасында да мәгърифәткә омтылыш сизелә башлый. Ш. Мәрҗани бу процесста тарихчы, философ һәм мәгърифәтче буларак билгеле.

Бәхәссез, Мәрҗани гаять киң колачлы галим. Шулай да, беренче чиратта, ул — тарихчы. Мәсәлән, тарих фәнен Мәрҗани «бөтен нәрсәне эченә алган фән», «фәннәр анасы», «дөреслекне тануда арадашчы» дип атый»[1].

Татарларда тарих фәненең Мәрҗанигә кадәрге торышын анализлап, күренекле татар галиме Г. Ибраһимов болай дип язды: «Бездә элгәре әнбия (пәйгамбәрләр — М. Й.) тарихы вә ислам тарихлары бар иде. Бик сирәк кулларда Әбул-Гази[2] да очраштыргалый иде. Ниндидер бер уйдырма «Тәварих әл-Болгар» дигән урам әкияте йөри иде»[3].

Татар тарихы мәсьәләләрен фәнни нигездә беренче тапкыр ачыртып чыгучы Ш. Мәрҗани булды. Бу турыда язучы һәм галим Р. Фәхретдинов ««Мөстафад әл-əхбар...»ның басылып чыгуыннан соң Казан тарихы, ягъни милли тарихыбыз, уйдырмалар һәм әкиятләр кысасыннан чыгып фәнни тарихка әйләнде»,— дип бик дөрес язып үтте[4].

Ш. Мәрҗани иҗаты әле бик аз өйрәнелгән, хезмәтләренең күбесе бүген дә кульязма хәлендә кала бирәләр.

Мәрҗани иҗаты белән кызыксыну XX гасырда гына башлана. Олы галимнең 100 еллыгы уңае белән 1915 елда җыентык чыгарыла. Фактик материалга шактый бай булган ул җыентыкта Ш. Мәрҗани иҗаты дини һәм фәлсәфи күзлектән генә тикшерелә.

Шулай да татар прогрессив интеллигенциясенең күренекле вәкилләре Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк Мәрҗанинең фәнни эшчәнлегенә объектив бәя бирә алдылар. Бөек шагыйребез Г. Тукай аны «Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт»[5] дип атады. Г. Ибраһимов Мәрҗанинең тарихи хезмәтләренә фәнни-объектив бәя биреп, галимнең татар иҗтимагый фикер үсешендә тоткан зур ролен күрсәтте.

30 нчы елларда әдәбият һәм тарих белгече, тәнкыйтьче Г. Сәгъди болай дип язды: «Мәрҗанинең тарихлары татарлар өчен чыннан да нык тикшерелгән, тәхкикъләнеп (төпченеп — М. Й.) беренче кулдан язылган чын иҗади әсәрләр булып чыктылар. Алар чыганак һәм вакыйгаларга чынлап та көчле, үткен бер тәнкыйть карашы йөртеп язылганнар»[6].

---

[1] Ш. Мәрҗани. Мокаддимә китаб вәфият әл-әслаф вә тәхият әл-әхлаф. Казан, 1883, 265 бит.
[2] 1824 елда И. Хәлфин һәм Х. Френ тарафыннан чыгарылган «Шәҗәрәи төрки» күздә тотыла.
[3] Г. Ибраһимов. Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре. «Аң», 1915, № 1, 16 бит. (Алга таба: Г. Ибраһимов. Бөек остазымызның...)
[4] Р. Фәхретдинов. «Казан тарихы» исемле әсәргә рецензия. «Шура», 1910, № 5, 154 бит.
[5] Г. Тукай. Шиһаб хәзрәт.— Әсәрләр, II т., Казан, 1955, 234 бит.
[6] Г. Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1926, 60—69 битләр.

Кызганычка каршы, илленче елларда кайбер тикшерүчеләр тарафыннан Мәрҗани иҗатын ашыгып, берьяклы бәяләүчеләр дә булды. М. Госманов хаклы рәвештә күрсәтеп киткәнчә, Мәрҗанинең чалмасы ул фән өчен эшләгән бөтен уңай нәрсәне каплады, һәм, нәтиҗәдә, галим безнең тарих фәнендә хаклы рәвештә алырга тиеш булган урынын ала алмады[1]. Олы галимгә мөнәсәбәттә әлеге тискәре караш, әлбәттә, үзен акламады, тикшерүчеләр аның татар культурасы тарихында тоткан урынын билгеләүдә үзләренең позицияләрен ачыкладылар.

Ш. Мәрҗанинең гыйльми эшчәнлеген югары бәяләп, күренекле совет галиме И. С. Брагинский: «Ул татар халкының тарихы турында беренче җитди хезмәтләр авторы иде»[2], — дип язды.

Галимнең фәнгә керткән зур өлешен күрсәтеп, М. Ф. Вәлиев: «Ш. Мәрҗани зур укымышлы философ, әдәбият һәм тел белгече, үз халкының һәм күп кенә Көнчыгыш халыкларының тарихын һәм культурасын яхшы белүче кеше»[3], — дип билгеләп уза.

Соңгы елларда татар галимнәре Ш. Мәрҗани мирасын өйрәнүгә шактый өлеш керттеләр. Шулардан М. Гайнуллин, М. Госманов һәм Я. Абдуллинны аерып күрсәтеп китәргә кирәк. Х. Хисмәтуллин тарафыннан төзелгән җыентыкта да[4] шактый гына әһәмиятле күзәтүләр бар.

Бер мәкаләдә генә Ш. Мәрҗанинең тарих фәненә булган карашын, тарихны тикшерү методын ачыклау, шулай ук аның татар халкы тарихын өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеген тулысынча яктырту мөмкин түгел. Шуңа күрә без Мәрҗанинең тарихчы буларак формалашуын, аның тарихи әсәрләрен һәм аларда яктыртылган төп проблемаларны кыскача гына күзәтү белән чикләнәбез.

Безнең карашка, Мәрҗанинең тарихи мирасын һәм аның тормыш юлын өйрәнү өчен иң кулай чыганаклар — аның үз әсәрләре. Соңгы вакытта Мәрҗани иҗатына багышланган кайбер хезмәтләрдә аның турында теге яки бу авторның әйткән сүзләренә таяну тенденциясе яшәп килә, галимнең үз әсәрләренә искәрмәләр бик аз яки бөтенләй юк дисәң дә була. Ә бит Мәрҗани үз вакытында ук әле, Г. Курсави кебек үк, беренчел чыганакларны иҗади тикшерергә чакырып, «Артка, беренчел чыганакларга таба»! дигән девизны күтәреп чыга. Шуңа күрә, тикшерүебезнең төп чыганаклары итеп, Мәрҗанинең басылган хезмәтләре һәм Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенең сирәк очрый торган кульязмалар бүлегендә, Казан тел, әдәбият һәм тарих институты архивында, Ленинград, Уфа, Ташкент китапханәләрендә саклпнучы кульязма китаплары алынды.

Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани 1818 елның 16 январенда хәзерге Татарстан АССРның Арча районында Ябынчы авылында туган. Үзенең килеп чыгышы турында Мәрҗани: «Бабаларым Мәрҗан авылыннандыр», — дип яза. Башта ул Ташкичү авылында әтисендә укый. Белем алуын Бохара һәм Сәмәрканд шәһәрләрендә дәвам итә. Шунда ул Аристотель философиясен дәвам иткән Әл-Фараби (870—950), Әбугалисина (980—1037), Әл-Бируни (973—1048) һ. б. ларның хезмәтләре белән таныша. Сәмәркандта яшәүче зур тарихчы Әбү Сәгыйт бине Габделхай әс-Сәмәркандии белән якыннан таныш була. «Бу галим белән танышлык минем тарих белән кызыксына башлавыма һәм тарихи әсәрләрне өйрәнергә керешүемә сәбәп булды»[5], — дип яза Мәрҗани үзенең иң зур тарихи хезмәте «Вәфият әл-әслаф вә тәхият әл-әхлаф» («Үлгәннәргә мәрсия, оныкларга васыять») китабында. Әбү Сәгыйт әс-Сәмәркандии китапханәсендәге тарихи әсәрләр белән кызыксынып китү, әсәрләрендә болгарлар, аларның Багдад һәм Мәккәгә сәяхәтләре турында мәгълүматлар бирүче Ибне Хәлликән (1211—1282), Якут әл-Хамәви (1179—1229), Ибне әл-Әсир (1160—1233), Хаҗи Хәлифә (1609—1657), Шәмсетдин Димәшки (1256—1327) кебек авторларның хезмәтләре белән танышу да Ш. Мәрҗанинең тарих мәсьәләләре белән кызыксынуын бермә-бер арттырып җибәрә. Ул күп вакытын сирәк очрый торган төрле тарихи китаплар һәм кульязмалар җыюга багышлый. «Ибне Фадлан язмаларындагы Идел буе халыклары тарихына караган

---

[1] М. Госманов. Мәрҗани турында берничә сүз. «Казан утлары», 1968, № 1, 116—121 битләр.
[2] И. С. Брагинский. О природе среднеазиатского джадидизма в свете литературной деятельности джадидов.—«История СССР», 1965, № 6, 27 бит.
[3] М. Ф. Валеев. К вершинам науки. М., 1975, 12—13 битләр.
[4] Шиһабетдин Мәрҗани. Мәкаләләр җыентыгы. Төзүчесе Х. Хисмәтуллин. Казан, 1968.
[5] Ш. Мәрҗани. Вәфият әл-әслаф вә тәхият әл-әхлаф. (Алга таба: Ш. Мәрҗани. Вәфият әл-әслаф...) VI т., 214 бит.

әземтәләрне мин яшь чагымда ук Бохара һәм Сәмәркандта күчереп алдым» [1],— дип яза ул соңрак. Әйтергә кирәк, совет тарихчыларының бәяләве буенча, Ибне Фадлан язмалары Идел буе болгарлары тарихын өйрәнү өчен зур игътибарга лаеклы, бай эчтәлекле әсәр булып тора. Кыскасы, Урта Азиядә унбер ел дәвамында җыйган материаллар Мәрҗанинең шактый гына әсәрләренә нигез булып ята.

1849 елда Ш. Мәрҗани, Урта Азиядән кайтып, Казанда яши башлый. Бу чорда, Г. Ибраһимов дөрес билгеләп үткәнчә, «бөтен татар дөньясында татар феодализмы тарафыннан тудырылган иске идеология хөкем сөрде... Культура һәм идеология тулысы белән руханилар кулында иде» [2]. Димәк, Ш. Мәрҗани язмышын да дин әһелләре, Казан һәм Уфа байлары кубызына биюче гыйльми даирәләр хәл итәргә тиеш иделәр. Алар Мәрҗанигә, Бохарадан кайтып төшү белән үк, имтихан оештыралар. һәм 1850 елның 2 мартында Ш. Мәрҗани 2011 нче указ нигезендә 1 нче Казан мәчетенең баш мулласы һәм аның каршындагы мәдрәсәнең өлкән мөгаллиме итеп билгеләнә.

Гасырлар буе яшәп килгән хорафатларга каршы көрәш ачкан Ш. Мәрҗани кебек принципиаль һәм намуслы кешегә революциягә кадәрге Россиядә яшәве һәм эшләве, билгеле, бик авыр була. Шуңа да карамастан, Ш. Мәрҗанинең җирле край тарихын тикшерү буенча эшчәнлеге нәкъ менә шушында — туган ягында чәчәк ата. Монда ул зур галим-тарихчы буларак формалаша һәм милли тарих фәнебезнең нигезен тәшкил иткән әсәрләр яза.

Мәрҗанигә татар дин әһелләренең күбесе өчен характерлы булган йомыклык хас булмый. Ак чалма һәм яшел чапан кигән галим Казан университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыяте утырышларында катнашып, рус галимнәренең игътибарын үзенә җәлеп итә. 1877 елда археологларның IV Бөтенроссия съездында ул Болгар һәм Казан тарихы турында доклад ясый. Бу Бөтенроссия гыйльми форумында татар галимнәренең беренче чыгышы була.

Ш. Мәрҗани тарих фәне белән бер аяктан атлау өчен көчен кызганмый. Урта Азиядә җыйган чыганакларның җитәрлек булмавы үзен сиздерә башлый. Шуңа күрә ул Петербург галимнәре белән бәйләнешкә керергә тырыша. Аңа үзенең шәкерте — Петербург университетының татар һәм төрек телләре укытучысы Хөсәен Фәезханов (1828—1866) нык ярдәм итә. Мәрҗани үзе дә шәкерте Х. Фәезханов турында зур рәхмәт хисе белән: «Хөсәен Петербург шәһәренә күчмәк улдыгында бу хәлене инкарь иттем вә мурадыннан җуерыр өчен саи кылдым (тырыштым — М. Й.). Ләкин аллаһе тәгаләнең хөкме имеш тәдбирләрем тәкъдиргә муафыйк чыкмады, касдыннан дүндерә алмадым. Ә соңыннан аның Петербургта торганыннан күп файда күрдем», — дип яза [3].

Ш. Мәрҗани белән Х. Фәезханов арасындагы хат язышулар Фәезханов үлгәнгә кадәр дәвам итә. Ул хатлар бу ике галим арасындагы дуслык һәм хезмәттәшлекнең никадәр тыгыз булуы турында сөйлиләр.

Петербургта Х. Фәезханов В. В. Вельяминов-Зернов, В. А. Дорн, Н. И. Лерх, Шәех әт-Тантавилар белән яхшы мөнәсәбәттә була. Күптән түгел генә табылган чыганакларга караганда, Х. Фәезханов шулай ук В. Д. Стасов, Чокан Вәлиханов һәм Ибраһим Алтынсарин кебек алдынгы карашлы җәмәгать эшлеклеләре һәм күренекле мәгърифәтчеләре белән дә тыгыз элемтәдә булган [4]. Петербург галимнәре белән даими аралашкан Х. Фәезханов Мәрҗанине һәр вакыт фән дөньясындагы яңалыклар белән таныштырып тора. Х. Фәезханов аша Ш. Мәрҗани белән В. В. Вельяминов-Зернов һәм Шәех әт-Тантави арасында хезмәттәшлек урнаша.

Ш. Мәрҗани тарихчы буларак 70 нче елларда тәмам формалашып җитә. Элегрәк аны теология мәсьәләләре һәм гомуммөселман культурасы проблемалары кызыксындырган булса, хәзер инде ул башы-аягы белән тарих проблемаларына чума, бөтен көчен тарихи әсәрләр язу һәм аларны бастыруга юнәлтә.

Тарих, Ш. Мәрҗани өчен, беренче карашка күренгәнчә, гади мавыгу түгел, ә бәлки Көнчыгышның схоластик идеологиясенә каршы бер корал да булган. Тарих аңа

---

[1] Ш. Мәрҗани. Мостафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар тарихы өчен китерелгән хәбәрләр). I т., Казан, 1885, 59 бит. (Алга таба: Ш. Мәрҗани. Мостафад әл-әхбар...)

[2] Г. Ибраһимов. Татары в революции 1905 года. Казан, 1926, 26 бит.

[3] Мәрҗани мәҗмугасы. 349 бит.

[4] М. Госманов. Мәрҗани турында берничә сүз. «Казан утлары», 1968, № 1, 118 бит.

практик әһәмияткә ия җитди мәсьәләләрне чишүгә ярдәм итә, үз позициясен нигезләү һәм яклау өчен җитди аргументлар бирә.

Ш. Мәрҗани әсәрләрендә күтәрелгән проблемалар аның политик карашлары белән тыгыз бәйләнгән. Мәсәлән, Мәрҗанинең үз чорында шау-шу тудырган һәм зур уңыш казанган «Назурәт әл-хак...[1] хезмәте феодаль схоластикага, дини фанатизмга һәм йомыклыкка каршы игълан ителмәгән сугыш иде.

«Назурәт әл-хак...» аерым бер проблемага багышланган булса да, анда авторның тарихи, философик һәм этик карашлары да киң чагылыш тапкан. Хезмәттә автор үзен рационалист галим буларак күрсәтте. Ул тәҗрибә һәм сынап карауларның зур әһәмияткә ияләреген ассызыклап, шул вакытта хөкем сөргән гореф-гадәтләрне кире кага, элек шөбһәсез авторитетлар булып саналган әт-Тафтазани, әд-Даваниларның чикләнгәнлеген күрсәтә. «Назурәт әл-хак...»та күтәрелгән «иҗтиһад мөнкарыйз», ягъни актив фикер йөртү дәвере узды, кеше үз акылы, үз тәҗрибәсенә таянып дин һәм тормыш турында фикер йөртә алмый, ул үзеннән элек яшәгән фидакарь фикер ияләре — мөҗтаһидлар гамәлгә керткән кагыйдәләргә таянып яшәргә тиеш дигән карашка каршы чыгу үзе генә дә бик зур әһәмияткә ия иде.

Мәшһүр инглиз галиме Х. А. Р. Гибб, мөселман дөньясының үткәнен тасвирлап: «XVI—XIX гасырлар безнең алдыбызга бигрәк тә караңгылыкка чумган килеш килеп баса, андагы сүрән бөртөрлелекне хәтта дини бәхәсләр дә бозмый» [2],— дип язган иде. Менә шул чак, Г. Тукай әйтмешли, «чыкты, ахры, бездән дә бер бөтен кеше...»

«Назурәт әл-хак...» хезмәте мөселман җәмәгатьчелегендә зур гауга куптара. Эш сүз көрәштерү белән генә чикләнми. Мондый фикер мөселман булмаган кешеләр тарафыннан әйтелгәндә әллә ни әһәмият бирмәскә дә булыр иде, ләкин аны традицион Бохара мәктәбе шәкерте Ш. Мәрҗани күтәреп чыккач, мәсьәлә бөтенләй башка төс ала. Бер төркем татар муллалары (32 кеше) 1887 елның 17 декабрендә шул вакыттагы мөфти М. Солтановка рапорт язалар. Мәрҗанине алар «фетнәче еретик» дип атыйлар, «Назурәт әл-хак...»та күтәрелгән критик тикшерү методы диннең нигезе, аның догматлары булган бөтен нәрсәне җимерү куркынычы астына куя, дип гаепләп чыгалар. Бертавыштан Мәрҗанинең бу хезмәтен тыюны таләп итәләр. Рапорт 1887 елның 17 декабрендә Оренбург духовное собраниесенә җибәрелә һәм 1054 нче номер белән теркәлә [3].

Ш. Мәрҗанине һәм аның хезмәтләрен куралмау ачыктан-ачык сыйнфый характерда була. «Назурәт әл-хак...»ның авторы экономиканың төшенкелегенә, иҗтимагый тормышның катып калуына, һәрбер иҗтимагый инициативаның деспотларча бастырылуына китергән феодаль строй политикасына каршы була. Тиңсез акыл һәм талант иясе, шәхси яктан тел тидермәслек кеше булу һәм хезмәтләрендәге төп идеяләрнең әһәмияте дошманнарына аңлашылып җитмәү генә Мәрҗанине тагын да катырак эзәрлекләүләрдән коткарып кала. Ә дошманнары аңга килгәндә, Г. Тукай әйткәнчә, «Олуглыкта, өстенлектә Шиһаб хәзрәт этләр буе җитә алмаслык җиргә кичкән» [4] була инде.

Ш. Мәрҗанинең мәгариф һәм акыл иреклеге мәсьәләләрен беренче планга куюы, фанатик руханиларга һәм татар халкын артка сөйрәгән феодаль тәртипләргә каршы көрәш идеяләрен күтәреп чыгуы халыкка үз заманында җитәрлек дәрәҗәдә тәэсир итә алмаса да, алдагы буыннарның уянуына, һичшиксез, зур этәргеч була. Мәсәлән, Г. Тукай иҗатында чагылыш тапкан иске мәдрәсә тәртипләрен, надан һәм бозык ишаннарны сарказмлы тәнкыйтьләү — асылда үткән гасырның 70 нче елларында ук Ш. Мәрҗани күтәреп чыккан идеяләрне сурәтле чагылдыру иде. Шулай итеп, Ш. Мәрҗанинең эшчәнлеге туып килүче татар тарих фәнендә генә түгел, ә әдәбиятында да тәнкыйть агымы барлыкка килүгә этәргеч була.

Галимнең басылган тарихи әсәрләреннән иң әһәмиятлесе — ике томлык «Мостафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар». Бу хезмәт татар телендә язылган. Ш. Мәрҗани аны Идел һәм Урал буеның иң борынгы халыкларын тасвирлаудан

[1] Ш. Мәрҗани. Назурәт әл-хак фи фарзыят әл гыйшаэ вә ин ләм ягыйб әш-шәфәкъ (Хакыйкать телескобы). Казан, 1870. (Алга таба: Ш. Мәрҗани. Назурәт әл-хак...)
[2] Х. А. Р. Гибб. Арабская литература. М., 1960, 110 бит.
[3] Р. Фәхретдинов. Асар. III кисак, 173—175 кәгазьләр. (Кульязма СССР Фәннәр академиясенең Уфадагы филиалы архивында саклана.)
[4] Г. Тукай. Шиһаб хәзрәт. «Аң», 1913, № 2.

башлый. Татарларны борынгы болгарлардан килеп чыккан дип исәпләгәнгә күрә, ул борынгы болгар һәм аларның тирә-ягындагы халыклар тарихына да зур әһәмият бирә. Тарихчылар арасында беренчеләрдән хәзерге Урта Идел һәм Урал буе татарларының килеп чыгышын монголлар белән бәйләп аңлата торган теориягә каршы чыга, этнография, көнкүреш һәм матди культура мәгълүматларына таянып, аларның килеп чыгышын болгар теориясенә бәйләп аңлата. Шул ук вакытта ул, төрле чыганакларга таянып, Урта Идел буе татарларының килеп чыгышында башка компонентларның да (кыпчак, угор, фин) ролен инкарь итми.

Бу хезмәтендә Мәрҗани тарих фәненең төрле теоретик мәсьәләләрен күтәреп чыга, тарихка, фән буларак, үзенең карашын ачыклый, аны өйрәнү буенча үзенең принципларын билгели. Әсәр безне Мәрҗанинең дөньяга карашы белән дә таныштыра. Тарихчы буларак, аның турында шактый тулы мәгълүматлар бирә.

«Мостафад әл-әхбар...»ның II томында Казан краеның Россия составына кергәннән соңгы тарихы яктыртыла. Монда татарларның мәктәп, мәдрәсә, мәчет кебек мәгариф һәм дин учреждениеләре тарихы, шулай ук мәгариф өлкәсендә зур хезмәт күрсәткән, аерым эз калдырган укытучылар, муллалар һәм башка эшлеклеләрнең тәрҗемәи хәлләре бирелә. Әсәрдә тарихи экскурс, лирик чигенешләр, шәхси истәлекләр дә күп. Автор шулай ук XVII гасыр азагы һәм XX гасыр башларындагы социаль-экономик хәлне сурәтли[1].

Билгеле, Ш. Мәрҗанинең бу хезмәтенә дә хәзерге көндәге таләпләр белән якын килергә ярамый. Иң элек ул үзенә кадәр язылган җитди хезмәтләргә таянудан мәхрүм ителгән була, чөнки андыйлар бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Авторның социаль-политик карашлары чикләнгән булу да үзен сиздерә. Ул тарихны сыйнфый аңлаудан ерак торган. Шуңа күрә крайның социаль-экономик торышы тарихчы тарафыннан өстәнрәк, эчке анализсыз бирелгән. «Мостафад әл-әхбар...»да күбесенчә политик тарих яктыртылган. Бу — авторның методологиясе һәм тикшерү методикасы белән дә аңлатыла. Ш. Мәрҗани хезмәтләрендә без чыганакларны классификацияләү белән дә очрашмыйбыз. Әсәрнең билгеле бер территориаль һәм хронологик рамкалар белән чикләнмәгәнлеге дә аның композицион төзелешен беркадәр таркаулаткан. Г. Ибраһимов язып киткәнчә: «Әсәрнең тышкы киеме чибәр түгел, андагы материал да Европа галимнәренең әсәрләрендәгечә ачык вә табигый тәртип белән тезелеп бармаган. Ләкин ул вакытта без артык бернәрсә көтәргә хакыбыз да юк иде...»[2].

Бу җитешсезлекләр исә ул чордагы бөтен татар галимнәре өчен дә хас булган һәм аларга карап әсәрнең әһәмияте кими дип әйтеп булмый.

Ш. Мәрҗанинең бу хезмәтен бәяләгәндә татар галимнәре бер фикердә булалар. «Әмма «Мостафад әл-әхбар...»ларга киленсә,— дип яза Г. Ибраһимов,— аларның әһәмияте үткәндәге бер дәвердә булган хезмәтләр өчен генә түгел, болар бүген дә һәм киләчәктә дә үзләренең кыйммәтләрен югалтмаячаклар, чөнки болар безнең милли тарихыбызның бердән аталары, икенчедән нигезләредер»[3].

Җамалетдин Вәлиди исә болай дип билгеләп уза: «Безнең татарлар өчен иң мөһим, иң билгеле әсәр шөбһәсез ике җөлед (том — М. Й.) «Мостафад әл-әхбар...»дыр. Болар безнең тарихыбызның анасы дип әйтергә ярарлык әсәрдер. Шиһаб хәзрәт үзенең тарихларында гади бер риваятьче, вакыйгачы булып бармый, язган нәрсәләрен бик строгий тәнкыйть вә мөхкәмәдән (хөкемнән — М. Й.) кичереп яза»[4].

Рус галимнәре дә Мәрҗанинең бу хезмәтенә югары бәя бирәләр. 1895 елның 2 нче январенда Казан университеты профессоры Н. Ф. Катанов шул университет каршындагы археология, тарих һәм этнография җыелышында җирле авторларның тарихи хезмәтләрен анализлап, болай ди: «Казан галиме Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтенә килсәк, ул этнографик һәм тарихи эчтәлегенең байлыгы ягыннан рус теленә генә түгел, башка Европа телләренә дә тәрҗемә ителергә лаеклы»[5].

Ш. Мәрҗанинең бу тарихи әсәре әле дә әһәмиятен югалтмый. 1948 елда Татарстан тарихының аерым дәверләрен тикшергәндә академик Б. Я. Греков һәм Н. Ф. Ка-

---

[1] Ш. Мәрҗани. Мостафад әл-әхбар... II т., 1900, 7 бит.
[2] Г. Ибраһимов. Бөек остазымызның... 17 бит.
[3] Шунда ук, 16 бит.
[4] Ж. Вәлиди. Мәржани. «Вакыт», 1914, № 1464, 18 апрель.
[5] Известия Общества археологии, истории и этнографии, XIV т., 4 нче чыг., Казан, 1898, 470 бит. (Алга таба: ИОАИЭ.)

линин бу мәсьәләдә иң дөрес һәм тулы мәгълүматлар бирүче авторлар дип түбәндәге тәртиптә биш авторны күрсәтәләр: Хисаметдин ибне Шәрәфетдин, Шиһаб Мәрҗани, Каюм Насыйри, Мөхәммәт Зариф Хөсәенов һәм М. М. Рәмзи. Әгәр дә беренчесенең мәгълүматлары ачыктан-ачык ялган, өченчесенең тарих фәненнән аз хәбәрдарлыгын, дүртенчесенең мәгълүматлары фрагменталь булуын, ә соңгысының — берьяклы һәм компилятив характерда булуын исәпкә алсак, бердәнбер ышанычлы чыганак булып Ш. Мәрҗанинең «Мостафад әл-әхбар...»ы гына кала.

Ш. Мәрҗанинең иң зур тарихи хезмәте — «Вәфият әл-әслаф вә тәхият әл-әхлаф». Әсәр гарәп телендә язылган. Ул VI гасырдан алып XIX гасырга кадәр яшәгән Көнчыгыш галимнәренең, әдип, шагыйрь, дәүләт эшлеклеләренең тәрҗемәи хәлләрен, хезмәтләрен кыскача яктырта торган био-библиографик әсәр. «Вәфият әл-әслаф...» некролог принцибында төзелгән. Шәхесләр турында мәгълүматлар мәрсия рәвешендә бирелә. Бу хезмәттә әл-Фараби [1], Ибне Рөшд [2], Әбугалисина [3], әл-Мәгари [4], Алишер Нәвои [5] һ. б. лар турында кызыклы мәгълүматлар бар. Автор Ибне Хәлликән, Ибне Әсир, Ибне Хәлдун, әш-Шахрастани кебек авторитетларның әсәрләренә таяна. Хезмәттә шулай ук Көнбатышның дәүләт эшлеклеләре — Петр I, Карл XII, Наполеон I турында да кайбер мәгълүматлар бар.

Ш. Мәрҗани чоры өчен мондый типтагы тарихи әсәрләр бик табигый, чөнки татар галимнәренә тирән йогынты ясаган гарәп историографиясенә тәрҗемәи хәлләргә зур әһәмият бирү, сәяси елъязмалар белән тарихи шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләрен тыгыз бәйләнештә бирү хас иде. Авторның стиле 775—868 нче елларда яшәгән бөек гарәп язучысы һәм энциклопедисты әл-Җаһиз һәм Ибне Хәлликәннәр стилен хәтерләтә. Теге яки бу шәхес турында язганда Мәрҗани әсәренә төрле мәзәкләр һәм кызыклы вакыйгалар да кертә. Бу исә, мавыктыргыч итү белән бергә, аның бәясен дә күтәрә, Урта гасырны өйрәнү чыганагы буларак та әһәмиятен үстерә.

Әсәр кульязма хәлендә КДУның Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә, сирәк очрый торган кульязмалар бүлегендә саклана. Аның 411 биттән торган беренче томы — «Мокатдимә» (Кереш) өлеше генә басылган. Монда автор тарих, дин, культура, этнография мәсьәләләрен тикшерә. Кереш үзенең формасы белән Ибне Хәлдунның «Мокатдимә»сен хәтерләтә һәм тарихи шәхесләргә багышланган 6 томдагы материалны аңлау өчен яхшы теоретик кулланма булып тора.

1864 елда Казанның «Дәр әл-фөнүн» матбугатында Ш. Мәрҗанинең «Горфәт әл-хәвакыйн ли арфәти-л-хәвәкыйн» әсәре дөнья күрә. Ләкин, кызганычка каршы, ниндидер сәбәпләр аркасында китап сатуга чыгарылмый. Шуңа күрә ул Урта Азия тарихы белгече В. В. Бартольд һәм башкаларның игътибарыннан читтә кала.

Үз вакытында «Аң» журналы билгеләп үткәнчә, «Мостафад әл-әхбар...»ның I томы Идел буе халыклары тарихын өйрәнү өчен әһәмиятле чыганак булса, «Горфәт әл-хәвакыйн...» X—XII гасырлар Урта Азия тарихын өйрәнү өчен шундый ук зур чыганак ул. Чынлап та, Ш. Мәрҗанинең бу хезмәте моңарчы бөтенләй өйрәнелмәгән проблемага — Урта Азиянең монголларга кадәрге тарихын өйрәнүгә багышланган. Тарихчының бу хезмәте ул вакыттагы гаҗәп катлаулы һәм буталчык мәсьәләне — политик аренага Чыңгыз хан килеп чыкканчы Урта Азиядә 200 елдан артык төрки кабиләләрнең кайсы хакимлек итүен ачыклый. Моңарчы Европа галимнәре Урта Азиянең бу чоры турындагы кайбер мәгълүматларны бары Мөнәҗим-пашаның «Сәхаиф әл-әхбар» (Язма хәбәрләр)еннән генә алганнар.

Шулай итеп, Ш. Мәрҗанинең «Горфәт әл-хәвакыйн...» хезмәте, В. В. Бартольд хезмәтләре чыкканга кадәр, көнбатыш уйгурлар, яки В. В. Григорьев һәм В. В. Бартольд терминологиясе белән әйткәндә Караханидлар [6] турында иң дөрес һәм тулы мәгълүматлар бирүче бердәнбер әсәр була. Мәрҗанинең бу хезмәте хәзер дә әле үзенең әһәмиятен югалтмаган. Мәсәлән, әсәрнең Ташкент каллиграфы Морад Хаббаз әш-

[1] Ш. Мәрҗани. Вәфият әл-әслаф... II т., 406—407 битләр.
[2] Шунда ук, III т., 222 бит.
[3] Шунда ук, II т., 528—533 битләр.
[4] Шунда ук, II т., 551 бит.
[5] Шунда ук, IV т., 212 бит.
[6] «Караханидлар» терминын беренче тапкыр В. В. Григорьев кулланган һәм аны В. В. Бартольд та кабул иткән. Кара: В. В. Бартольд. Очерки истории Семиречья.— Сочинения, II т., I кисәк, М., 1963, 41 бит.

Шаши тарафыннан 1941 елда Казан нөсхәсеннән күчерелгән булуы да шул хакта сөйли [1].

Ш. Мәрҗанинең 1877 елның 13 августында археологларның IV Бөтенроссия съездында В. В. Радлов тарафыннан укылган «Гилаләт әз-заман фи әхвали Болгар вә Казан» (Болгар һәм Казан патшалыкларының тарихы) хезмәте дә зур әһәмияткә лаек. Хезмәтнең төп нөсхәсе һәм тәрҗемәсе шул съезд хезмәтләрендә басылып чыга. Татар тарихчысының бу хезмәтенә алга таба И. Ф. Готвальд, Н. П. Загоскин һәм Н. И. Ашмариннар да мөрәҗәгать итә. Казан университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыяте җитәкчесе С. М. Шпилевский да шул җәмгыятьнең гомуми җыелышында сөйләгән речендә (1879 елның марты) Ш. Мәрҗанинең җирле крайны өйрәнүдәге эшчәнлеген югары бәяли [2].

Ш. Мәрҗанинең гарәп телендә язылган «Ихтисар ән-нәҗүм әз-зәхирә фи әхвал Мисыр вә әл-Каһирә» (Мисыр һәм Каһирә тормышындагы якты йолдызларның кыскача тарихы) хезмәте дә тарихи әсәр. Г. Гобәйдуллинның күрсәтеп китүенә караганда, ул ике томнан торган. Хәзергә аның бары бер генә томы табылган [3].

Бу хезмәтендә Ш. Мәрҗани гарәп һәм алар белән янәшәдәге илләр турында күп кенә мәгълүматлар бирә, ул илләрнең галим һәм хөкемдарлары биографиясе белән таныштыра. Бу әсәр Идел буе халыклары тарихы өчен дә әһәмияткә ия.

Инде кыскача йомгак ясап шуны әйтергә кирәк: XIX гасырның икенче яртысында яшәгән татар тарихчылары арасында Ш. Мәрҗани, һичшиксез, беренче урында тора. Аның феодаль-крепостной строй таркалу һәм буржуаз мөнәсәбәтләрнең көчәя баруы шартларында формалашкан дөньяга карашында XIX гасырның алдынгы демократик идеяләре дә, шул вакыттагы буржуаз историографиянең чикләнгәнлеге дә чагыла.

Киң карашлы һәм күп кырлы галим буларак, Ш. Мәрҗани тарих фәненә аеруча зур игътибар биреп, бу өлкәдә күп кенә җитди хезмәтләр дә язып калдыра. Алдынгы карашлы тарихчы буларак, Ш. Мәрҗани бу фәннең предметы һәм методы турында фәнни теорияләр биргән, гаять күп төрле чыганаклардан файдаланган, татар халкының этногенезы мәсьәләләрен күтәргән. XIX гасырның икенче яртысында татар историографиясенә Ш. Мәрҗани керткән өлеш бүген дә зур фәнни мирас булып кала бирә.

---

[1] Үзбәкстан Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты материаллары. Инв. № 5741.
[2] ИОАИЭ, III т., 1884, 20—31 битләр.
[3] Мәрҗани мәҗмугасы, 336 бит.

Нурмөхәммәт Хисамов

# ТУКАЙ ИҖАТЫНДА БОРЫНГЫ ӘДӘБИЯТ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Тукай иҗаты татар әдәбиятының күп гасырлык үсешенә йомгак ясый. Бу декларация түгел, бәлки әдәбият тарихындагы мөһим бер хакыйкатьне раслау.

Такташ «Иҗадиятем турысында» дигән мәкаләсендә «Бакырганидан алып, Тукай аркылы хәзергә кадәр... сузылып килгән» поэтик традицияләрне яңабаштан карап чыгуы хакында әйтә. Совет чорының бөек шагыйре Тукай шигъриятен борынгыдан килә торган бөтен төрки поэзиянең тарихи юлына йомгак итеп күрә.

Монда безнең өчен нәрсә аеруча мөһим соң? Тукай иҗаты төрки поэзиядә сигез гасыр буена (чынлыкта бу тарих зуррак та әле) тупланган традицияләр системасының аерылгысыз өлеше итеп карала. Мәгълүм булганча, бөек шагыйрь иҗаты күп төрле традицияләр синтезыннан гыйбарәт әр-яңа күренеш тә ул. Әдәбият фәне аңардан татар һәм гомумән Көнчыгыш поэзиясеннән килә торган башлангычны да, рус һәм Көнбатыш Европа поэзиясеннән килгән башлангычны да, татар халык иҗатыннан килгән агымны да аермачык билгеләп узды. Шагыйрьнең новаторлыгы да галимнәребез тарафыннан шактый киң яктыртылды. Әмма традицияләрне тулы үзләштергән талант кына новаторлыкка ирешә ала.

Тукай, барыннан элек, татар һәм төрки поэзия традицияләренә таянып иҗат иткән шагыйрь. Сүз аның әдәбият тарихында гасырлар буе сыналган һәм чарланган шигъри формалардан файдалануы хакында гына бармый. Аларын аның тәртеп күрсәтүе бик ансат. «Кыйссаи Йосыф»ның рефренлы дүрт юллыгын да, газәл яки касыйдә формасын да аңарда күп очратырга мөмкин. Мәхәббәт лирикасында Фәрһат белән Мәҗнүн исемнәре очрауга безнең күз алдыбызга Низами һәм Нәваи каһарманнары килеп баса. Әмма шагыйрьнең куәтле иҗат ихтыяры бөтереп алып яңа шигъри рәвешкә керткән традицион күренешләрнең эзен абайлау читенрәк. Аларның җеп очлары тирәнгә яшерелгән.

Әдәбият тарихының елдан-ел яңа мәгълүматлар белән баеы баруы бу турыда да сүз алып барырга мөмкинлек бирә. Бигрәк тә борынгы әдәбият ядкарьларын өйрәнү XX йөз башы һәм совет чоры поэзиясендәге аерым күренешләрнең традицион асылына якты сибә. XIX йөз азагында һәм XX йөз башында халык кулындагы китапларның актив репертуары ачыклана бару да аерым шагыйрьләрнең шигъри дөньясына, әсәрләренең әдәби, иҗтимагый һәм тарихи фактурасына ныграк үтеп керергә мөмкинлек бирер. Һәрхәлдә, Тукайның шигъри дөньясы белән танышу аның үз чоры китап репертуарының зур күпчелеген тирән белгәнлеген күрсәтә.

Тукайның атаклы «Эшкә өндәү» шигыреннән үзенчәлекле шигъри фразеологиясен алыйк:

Булса калдырмак бераү ушбу җиһанда изге ат,
Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт, иҗтиһат.

Виртуозларча рифмалаштырылган бу ике юллыкның безне беренче юлы кызыксындыра.

«Җиһанда изге ат калдыру» дигән тәгъбири әйләнмә халык телендә бөтенләй очрамый. Үзеңнән соң яхшы истәлек калдыру турындагы бу әйләнмә рустагы «доброе имя» төшенчәсенә туры килә. Төшенчәнең моңа якынрак яңгырашын татар теленең көнбатыш диалектында, ягъни мишәрләрдә, очратабыз. «Яхшы ат» тәгъбире «яхшы атлы булып сөйләү», «яхшы атлылану», «яхшы атлы булып кылану» кебек негатив контекстта кулланыла. Ул кешенең ялган абруй өчен тырышуын, ялагайлануын аңлата. Әдәби телдә «изге ат» тәгъбиренең антонимы активрак кулланыла: «Яман ат», «яман аты чыгу». Кыскасы, «җиһанда изге ат калдыру» тәгъбире саф әдәби кулланылыштагы әйләнмә була бирә.

Шагыйрьнең күзенә чалынырлыкниндирәк чыганактан килеп керде икән ул «Эшкә өндәү» шигыренә?

Хисам Кятибнең XIV йөздә иҗат иткән «Җөмҗөмә солтан» дастанында шушындый юллар бар:

**Табмас ирди киши дөньйадин морад,**
**Бәс калур ирмиш җ и һ а н д а и з г ү а д.**

Тукай поэтик фразеологияне максат формасына күчергән: «булса калдырмак бирәү...». Чыганагы, һичшиксез, шушы әсәр булырга охшый. Идел буе поэзиясенең бу күренекле ядкаре халык арасында кульязма хәлендә дә, басма китап рәвешендә дә киң таралган булган. Археографик экспедицияләр вакытында аның кисәкләрен әле дә еш очратырга туры килә.

Котыбның «Хөсрәү вә Ширин»ендә, Хисам Кятибнең әле телгә алып киткән әсәрендә актив кулланылган поэтик фразеологияне Тукай әсәрләренә сибелгән энҗеләр кебек җемелдәгән хәлдә еш күзәтергә мөмкин. XX йөз шагыйре иҗатын борынгы әдәбиятка нык җепләр белән тоташтырып торган, гасырлар сынавы эчендә үзләренең төсен җуймаган андый шигъри бизәкләр Тукай поэзиясенең затлы орнаментларын тәшкил итәләр.

Татар халкы кулында йөргән китаплар арасында Идел буе төрки поэзиясенең оригиналь әсәрләре белән беррәттән сәнгатьчә югары тәрҗемә әсәрләре дә күп булган. Аерым алганда, XIII йөз фарсы поэзиясенең күренекле вәкилләреннән Фәридетдин Гаттарның (Шәех Гаттар дип тә йөртәләр) «Пәнднамә» китабы татарлар арасында киң таралган булган. Г. Таһирҗановның «Казан утлары»нда (1975 ел, 10 сан) чыккан «Әдәби бәйләнешләр һәм аларның нәтиҗәләре» исемле мәкаләсендә дә бу хакта мәгълүматлар китерелә: «Урта гасыр классик фарсы әдәбияты әсәрләре татарлар арасында соңгы дәверләрдә дә киң таралган, кайбер истәлекләр хәтта гасырлар буена мәдрәсәләрдә дәреслек булып хезмәт иткән. Әйтик, ...Фәридетдин Гаттарның «Пәнднамә» (ягъни «Нәсихәтнамә») исемле дидактик поэмасы нәкъ шундыйлардан. Бу күренекле суфи шагыйрь иҗаты белән дә Тукайның нык кына таныш булганлыгына поэтик дәлилләр бар. Шагыйрь әсәрләренең формасы кайчакта ничаклы оригиналь һәм үзенчәлекле булып тоелмасын, аларның нигезе еш кына үзләренең төрки элгәрләренә барып тоташа.

Тукайның музыкаль аһәңе һәм хис кайнарлыгы белән аеруча истә кала торган камил формалы «Күңел» шигыре реакция чорында язылган. Шагыйрь шул караңгы елларда үзенең кешелеген җуймас өчен таяныч эзли һәм ул таянычны үз шәхесендә булган якты башлангычта таба. Лирик геройның ул сыйфатлары шушы рәвешле барлана:

**Инкисар ит гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, күңел!**
**Күп сөекледер бөтеннән таңрега сынган күңел.**

**Игътила итсәң, канатың ач, вакыт җитте бугай,**
**И тумыштан гарше әгълаларга җилкенгән күңел!**

**Син йоларсың һәр һәлакәттән, ышаныч бар сиңа,**
**Яр читендә торганымда, ярдәмең булган күңел!**

**Яхшы аңла: юк сафа инсанлыгыңны җуймыйча,**
**И шуны саклау юлында күп газапланган күңел!**

Шигырьнең өлгесен Тукай Шәех Гаттар әсәреннән алган. Тулаем парлы рифмага корылган бәетләрдән, ягъни ике юллыклардан торган шигъри әсәр эчендә шагыйрьнең үткен күзләре шушы юлларны аерып алган:

**Мөбәтәладыр гыйсияндыр к ү ң е л,**
**Үткән эш дәрдинә пошимандыр к ү ң е л.**

Бу әле бәләкәй очкын гына. Шагыйрь аны иҗат учагында дөрләтеп системага китерә, зур бер шигыренең калыбы итеп үстерә һәм аңа газәл формасы бирә.

Тукай шигыренең эчке тыгызлыгы, фикри һәм хисси үткенлеге башлыча антитезалы фикерләвенә бәйле. Кискен каршылыклар белән тулы бер чорда яшәгән шагыйрь үзенә таныш әсәрләрдәге контрастлы буяуларны күңеленә җәһәтрәк сеңдергән, күрәсең. Шәех Гаттарда шундый контраст мәгънәләр, антитезалы тасвир еш очрый.

**Берси гадел ичрә ирди аңа яр,**
**Бери ялгызлыкда ирди яри гар.**

Яки менә мондый юллар:

**Бер колыныйң башыйга пычкый чәкәр,**
**Беригә әйләр кәрамәт таҗ-ү зәр.**

**Бер кешигә кәнҗ илә нигъмәт бирүр,**
**Беригә йүз рәнҗ илә михнәт бирүр.**

**Беригә рузи кыйлыбдур тәхт-ү таҗ,**
**Бери туфрак үзрә йатур карный ач.**

**Б е р и г ә   а л т у н   т а б а к и д а   н а н   б и р ү р,**
**Б е р и   н а н   т и б   х ә с р ә т и н д ә   ж а н   б и р ү р.**

Суфи шагыйрь бу әсәрендә иҗтимагый гаделсезлекне фаш итү максатын күздә тотмый, билгеле. Ул тормышның мондый контраст тасвирын илаһиятнең кодрәтенә дәлил итеп кенә китерә. Янәсе, илаһиятнең бар нәрсәгә көче җитә, теләсә берәүгә таҗ бирә, ә берәүне ачка үтерә. Китерелгән өзектә безнең өчен бигрәк тә соңгы ике юл игътибарга лаек.

Тукайның зур иҗтимагый яңгырашка ия «Көзге җилләр» шигыре тулысынча контраст тасвирга корылган. Бигрәк тә ил 1911 елгы ачлыктан интеккәндә зиннәтле туклык һәм кызганыч мохтаҗлык антитезасы шагыйрь күңелендә калкып чыга һәм катлаулы хәрәкәткә килә. Кайчандыр күңеленә уелып калган контрастлы тасвир тетрәткеч куәтле яңа шигырьнең яралгысына әверелә.

**Куйсалар монда корткалар төшкән тешен алтын белән,**
**Бер телем икмәк, дип, анда назлы нечкә бил җылый!**

Монда чорның социаль портреты да, шагыйрьнең эстет характеры да, сугышчан гуманизмы да нәфрәт һәм мәхәббәт төенендә тупланган. Картинаның парадоксаль асылы шунда ки, инде үлсә дә кызганыч булмаган күренеш бизәнә, зиннәт тагына, ә яшәргә үтә хаклы зат элементар шартларга мохтаҗлыктан һәлак була. Соңгысының һәлакәте гүзәллек һәлакәте дә булганга, икеләтә фаҗигале. Шушы контраст тулаем гаделсезлекнең иләмсез сынын тудыра. Бу — иҗтимагый каршылыкларның үтә кискенләшкән чоры, капитализм дәвере.

Гаттарда «туфрак үзрә карны ач» ятучы кеше тәхет һәм таҗ иясенә каршы куелса, бу контраст андый ук гаделсезлек булып күз алдына килми әле: илдәге бер кешенең, хөкемдарның бар ил халкыннан өстен булуы андый протест уята да алмагандыр. Берәүнең «алтын табакта туенуы, берәүнең икмәк хәсрәтендә җан бирүе» Тукай чорына аваздашрак инде. Төрле чорда яшәгән бу ике шагыйрь үзләре дә ике төрле булып күз алдына килә. Берсендә күренешне тыныч барлау булса, икенчесендә ачынып, ярсып гаепләү.

Әдәбиятыбызның иң борынгы ядкарьларыннан «Кыйссаи Йосыф» поэмасы Тукай күңелендә аеруча тирән эз калдырган. Моны шагыйрьнең тавышы ачылган беренче шигырьләрендә үк кулланылган үлчәм һәм калыптан да, әсәрнең исемен турыдантуры телгә алуыннан да күреп була.

«Йосыф-Якуб китабы»ның көен көйлим», — ди ул «Дусларга бер сүз» дигән шигырендә. Болар әле традицияләрнең күзгә күренеп торган тышкы ягы. Әмма Кол

Гали поэмасыннан килә торган поэтик идеяләр, образ һәм мотивлар шагыйрь иҗатында танылмаслык дәрәҗәдә эшкәртелеп тирәнгә яшерелгәннәр.

Шундыйлардан «җан кошы» мотивының Кол Галидән алып Тукайгача («Өзелгән өмит» шигыре) үстерелүе хакында үз вакытында «Казан утлары» журналында (1973 ел, 4 сан) язып чыккан идек инде.

XX йөз башы татар шагыйре образны капитализм чорының шагыйрь һәм җәмгыять, шәхес һәм җәмгыять проблемасына бәйли. Бу мисалда поэтик традицияләрнең озак тарих буена югалмый ялганып килүе һәм шифалы зәмин ачылуга куәтле булып яңаруы кызык. Шигъри мотив эволюциясенең бер башы Кол Галигә, бер башы Тукайга тоташуы бу очракта турыдан-туры булмыйча, озын чылбырлы бәйләнешләр аша сузылуын күрдек. Хәлбуки, эпик шагыйрь әсәрендәге аерым эпизод һәм мотивлар лирик шагыйрьгә турыдан-туры килеп кереп тә яңача фикердән кичерелү очраклары да бар. Шул ук «Өзелгән өмит» шигырендә шагыйрь дөнья белән рухани хушлашканның соңында әнисе хатирәсенә мөрәҗәгать итә:

**Күз яшең дә кипмичә еглап вафат булган әни!**
**Гаилэсенә җиһанның ник китердең ят кеше!!**

**Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,**
**һәр ишектән сөрде углыңны мәхәббәт сакчысы.**

**Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,**
**Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!**

Ана каберенә яшь коюның эмоциональ контексттагы урыны «Кыйссаи Йосыф»тагы мәгълүм эпизодны хәтерләтә.

Агалары тарафыннан коллыкка сатылган, аягы-кулы богаулы Йосыф, туган җире Кәнганнан чыгып киткәндә, дөядән сикереп төшә дә анасы каберен кочып елый. Анасына үзенең зарын сөйли:

**Әй, дәрига, газиз анам йатурмусән,**
**Бу хәл ичрә бәнем хәлем белүрмусән,**
**Бакып бәни бу хәл үзрә күрәрмусән,**
**Әлләрим, аякларим баглу имди.**

Кол Галидә ана кабере туган җир төшенчәсе белән үрелгән. Ана кабере белән хушлашу туган җире белән дә хушлашу булып тора. Тукайның ана каберенә яшь тамызуы үз биографиясенә бәйле мотив, билгеле. Ул — анасыннан яшьли ятим калган. Нәкъ шушы момент аны Кол Гали әсәренең каһарманы Йосыф белән бәйли. Алар арасында язмыш уртаклыгы бар. Йосыф та кече яшьтән анасыннан ятим калган. «Өзелгән өмит»тәге лирик эпизодта Тукайның анык ук булмаса да, үзен Йосыф язмышында күз алдына китерүе шәйләнә.

Мотивның эмоциональ контекстта типологик уртаклыгы турында әйтеп тә торасы юк. Берсе туган ил белән хушлашуга, икенчесе дөнья белән мораль хушлашуга бәйле рәвештә шагыйрь күңелендә калкып чыккан.

Бер мотив поэзия тарихында берничә мәртәбә кабатлана икән, сүз традиция турында барырга тиеш. Ана кабере мотивы татар халык поэзиясендә дә «Кыйссаи Йосыф»тагы рухта эшкәртелгән. Экспедицияләр вакытында еш язып алына торган «Әнкәем» дигән җыр-мөнәҗәттә шушындый юллар бар:

**Бер тавыш бир кабереңнән,**
**Бәбкәем, дип, әнкәем!..**

Җыр, күрәсең, гасыр башында иҗат ителгәндер. Аны өлкән буын вәкилләре «Туган тел» көенә җырлый. Кабердәге анасыннан зарыгып җавап көтүдә, һичшиксез, «Кыйссаи Йосыф»тагы эпизод тәэсире чагыла. Анда Йосыфка анасы җавап бирә.

Ә Муса Җәлилнең «Соңгы үпкә» шигырендәге шушы юллар очраклымы?

**Үләм, дидем, ярый, тик кайгырдым,**
**Күреп үлсәмче, дип, кызымны!**
**Анам кабере — туган туфрагыма**
**Куеп үлсәмче, дип, йөземне!**

Совет шагыйре тормыш белән хушлашканда ана каберенә баш куя алмавына көенә. «Ана кабере» аңарда «туган туфрак» төшенчәсеннән аерылгысыз. Монда да традиция көче күренә. «Кыйссаи Йосыф»тагы кулмәк мотивын «Ана шатлыгы» шигырендә Муса Җәлилнең нинди көчле эшкәртүен инде проф. Г. Һаиржанов күрсәтеп үткән иде. Кыскасы, татар поэзиясе үсешендә мөһим этапларны тәшкил итүче шагыйрьләрнең Кол Гали мирасына таянулары эпизодик очраклар гына булмыйча, системалы, эзлекле бер күренеш икән. Алай гына да түгел, Тукайның, мәсәлән, рус шагыйрьләренә таянып иҗат иткән әсәрләренең дә шигъри фактурасын борынгы әдәбияттан, аерым алганда, «Кыйссаи Йосыф»тан килгән мотивлар сугара.

Лермонтовтан ирекле тәрҗемә ителгән «Пәйгамбәр» шигыре Тукай лирикасында мөһим урын тота. Поэзиянең кешеләргә хак сүз илтергә тиешлеге кебек иҗтимагый вазифасы һәм хакыйкать өчен көрәшүче каһарманның изүче җәмгыять шартларындагы фаҗигасе, томана мохитның гаделлек көрәшчесенә карата рәхимсезлеге гәүдәләнә бу шигырьдә. Әсәрнең асыл яңгырашы Лермонтов идея трактовкасына туры килә. Икътибасның С. Рәмиев тарафыннан Пушкинга ияреп язылган шул исемдәге шигыре белән идея полемикасы Гали Халит хезмәтләрендә тулы ачылган һәм әсәргә идея анализы да җентекле ясалган.

Безне биредә шигырьнең поэтик фактурасы кызыксындыра. Ә анысы Лермонтовтан шактый аерыла.

Илаһият лирик каһарманга пәйгамбәрлек куәсе биреп, халыкка хак сүзне җиткерергә боера.

Лермонтовта:

**Провозглашать я стал любви**
**И правды чистые ученья...**

Тукайда:

**Керештем мин мәхәббәткә, карендәшлеккә өндәргә...**

Лермонтовта:

**В меня все ближние мои**
**Бросали бешено каменья.**

Тукайда:

**Җәмигы әкъребам, дустлар, карендәшләр, замандашлар**
**Миңа каршы котырдылар, рәхимсез аттылар ташлар.**

Теманың нигез моментларында ике шагыйрь дә уртак. Әмма алга таба шигырь фактурасында аерма китә. Һәм ул ике шигырьгә ике төрлерәк идея-эстетик яңгыраш бирә.

Лермонтовта:

**Посыпал пеплом я главу,**
**Из городов бежал я нищий,**
**И вот в пустыне я живу**
**Как птицы, даром божьей пищи;**

Тукайда:

**Сөйләнде өстемә күп нфтира, бөһтан усал телләр,**
**Сибелде зур хәкарәт берлә хәтта башыма көлләр.**

«Башка көл сибү» детале икесендә ике төрле мәгънәви борылыш ясый. Лермонтов пәйгамбәре үз эченә бикләнә. Деталь «Тәурат»тан алынган. Ул Якын һәм Урта Көнчыгыш халыклары этнографиясенә тоташа. Башка көл сибеп үзенең кайгы өенә бикләнү борынгы яһүдиләрдә, гәрәпләрдә матәм ритуалы булып торган. Тукай аның мәгънәсен яки төшенмәгән, яисә үз халкына аңлашылмаячагын истә тоткан. Аның пәйгамбәре башына көлне кешеләр сибә. Монысы иске татар тормышыннан алынган деталь. Берәр зур җинаятъ саналырлык эш өчен кешене битенә корым ягып, өстенә көл сибеп, авыл буйлап йөртү күренешләре матур әдәбиятта да чагылыш тапкан. Шагыйрь көл сибүне артык дәрәҗәдә мәсхәрәнең билгесе итеп күрә, детальне «хәтта» кисәкчәсе белән көчәйтә. Нәтиҗәдә хакыйкать көрәшчесенә карата җәмгыять тарафыннан күрсәтелгән рәхимсезлек картинасы куертыла. Тукай пәйгамбәренең гуманистик мәгънәсе көчәйтелә, образ тагын да трагикрак яңгыраш ала.

**Теләнчә рәүше берлән мин качып чыктым шәһәрләрдән.**
**Менә хәзер япа-ялгыз торам бер читтә, сахрада.**

Монысы Лермонтов белән уртак. Ә инде табигатьтәге җан ияләренең пәйгамбәргә итагате турындагы деталь рус шагыйрендә утә җыйнак, бары ике юл:

**Завет предвечного храня,**
**Мне тварь покорна там земная;**

Тукай бу детальне җәя төшә.

**Күрәм гаден, сәмүден, бар булып, үткән халыкларны,**
**Күрәм диңгез төбен, уйнап, йөзеп йөргән балыкларны.**
**Миңа кол анда бар җанвар: арыслан, хәттә капланнар.**
**Нәбиләргә тимәслекнең мокатдәс гаһден алганнар.**
**Догамны тыңлый йолдызлар — кечесе, зурлары бергә, —**
**Мине тәгъзимлиләр шатлыкла уйнап нурлары берлә.**

Бу кадәресе инде «Кыйссас әл-әнбия»га һәм «Кыйссаи Йосыф»ка барып тоташа. Кол Гали әсәрендә кардәшләре Йосыфны коега салып кайткач, аталарына бүре ашады, дип хәбәр итәләр. Аталарының таләбе буенча соңыннан авызын канга буяп бер бүре тотып китерәләр дә: «Йосыфны шул ашады»,— диләр. Бүре телгә килеп, нахактан үзен аралый һәм: «Пәйгамбәрләр ити безгә хәрам имди»,— дип җавап бирә. «Нәбиләргә тимәслекнең мокатдәс гаһде (вәгъдәсе, анты)» дигәндә Тукай, һичшиксез, шушы шигъри фактка таяна. Ә инде табигать тасвирын җәя төшүе Тукайның романтизмына бәйле. Кешене табигать баласы итеп карау, табигать белән кеше гармониясен рәхимсез җәмгыятькә каршы кую мәгърифәтчелекнең гуманизм концепциясенә барып тоташа. Романтизм да шуңа таяна.

Галимҗан Ибраһимовның «Диңгездә» һәм «Табигать балалары» хикәяләрен, Сәгыйть Рәмиевнең «Авыл» шигырен алыгыз — барысында да табигатьне җәмгыятькә каршы кую кебек романтик концепция гәүдәләнә. Тукайның «Кярханәдә» шигырендә дә шуңар аваздаш мотивлар чагыла. Машиналар тавышы изгән эшчене шагыйрь табигатькә качарга өнди:

**Качсиде моннан,**
**Шул җирләргә, кайда**
**Сайрый кошлар анда...**

Монда, әлбәттә, шагыйрь иҗатындагы утопик характердагы йомшак яклар да чагылып китә.

«Пәйгамбәр» шигыре Тукайның башка бик күп шигырьләренә дә утә нечкә идея җепләре белән барып тоташа.

**Зәгыйфьләнгән, таланган, өсте-башы нинди керләнгән!.. —**

дигән юлдан соңрак «Кыйтга» шигыре үсеп чыга.

**Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш:**
**Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.**

Хәлсезләнгән шагыйрь үзенең үкенечле хәлен пәйгамбәренә охшаш итеп күрә.

«Пәйгамбәр» шигырендәге сәламәт, көчле мотивлардан хакыйкать өчен корбанлы көрәш зарурлыгын раслау, мәсхәрә һәм кимсетүдән курыкмау, түбән шартлар белән санашмау идеясе «Бер татар шагыйренең сүзләре» (Күкрәк биреп каршы торам, миңа милләт хәзерге көн мылтык, ук атар булса да), «Милләтчеләргә» (Көймә бата; йота торган балык өчен фида булган мөрәүвәтле бер җан кирәк), «Ваксынмыйм» (Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкыңа, әллә нинди былчырак баулар салалар гаклыңа), Гыйззәтуллина-Волжскаяга багышланган шигырендәге горурлык һәм көрәш тәвәккәллеге идеяләренә барып тоташа. Бер-берсенә тыгыз берегеп барган шушындый мотив һәм идеяләр Тукай иҗатының каршылыклы бөтенлеген тәшкил итәләр.

Борынгы әдәбият тирән һәм җентекле итеп яңа өйрәнелә башлады. Ул тикшерену дәвамында соңгырак чор сәнгатькярларының иҗат чишмәләре дә тулырак ачылыр һәм поэзиянең кызыклы күренешләре заман укучысы өчен аңлаешлырак, анығрак булып күз алдына килер.

# ӘНИЕМ ХАТИРӘЛӘРЕННӘН

*Әниемнең вафатына инде егерме ел тулып узды. Әдәби һәм гыйльми эшкәмуеннан чумып, мин аның язмаларын моңарчы тәртипкә китерә дә, матбугатка тәкъдим итә дә алмадым. Хәлбуки, бу эш бик кирәк иде. Мәгълүм булганча, минем әнием — бөек шагыйребез Габдулла Тукайның яратып, аның хакында: «Тугры килсәм, сүз сөйлим салкын гына, булса да күкрәк тулы ялкын гына», дип язган кешесе.*

*Г. Тукайның тормыш юлы, аның иҗат кредолары турында соңгы елларда галимнәребез шактый җитди хезмәтләр чыгардылар. Ләкин Тукай темасы ахырынача яктыртылсын өчен алда күп тикшеренүләр үткәрелергә тиеш әле. Чөнки Тукай безнең әдәбиятыбызда шундый гаҗәеп бер шәхес ки, аны өйрәнү туктаусыз дәвам итәчәк.*

*Менә шул караштан чыгып һәм Г. Тукайны өйрәнүгә бер өлеш булыр дигән ышаныч белән, мин укучыга әнием истәлекләрен тәкъдим итәм.*

*Мәрхүмәнең бик әйбәт бер гадәте бар иде. Ул да булса, буш вакытларында көндәлек язып кую һәм исендә калганнарны кәгазьгә теркәү. Әлбәттә, ул боларны бары үзе һәм якыннары өчен генә эшли иде. Зур матбугатка чыгу күздә тотылмаганга, язмаларның җөмлә шомалыклары, имла дөреслеге турында ул артык баш ватмаган. Миңа бу хакта да уйланырга туры килде. Ахырда мин язмаларның мәгънәсенә, стиленә һәм фактик деталенә һич кул тидермәгән хәлдә, аларны җиңелчә редакцияләргә батырчылык иттем.*

*Әле тәкъдим ителә торган истәлекләр икесе ике дәфтәрдә, гарәп шрифты белән, берсе шәмәхә кара, икенчесе карандаш белән язылганнар. Алар минем архивымда саклана.*

*Әйтергә кирәк, әлегә язмаларның кечкенә бер өлеше генә бирелә. Аларны эшкәртүне мин дәвам иттерәм. Әгәр укучы кирәк тапса, үз вакыты белән матбугатта бастырып чыгарылыр дип уйлыйм.*

**АТИЛЛА РАСИХ**

# ЯШЬЛЕК ХАТИРӘЛӘРЕМНӘН ИСТӘ КАЛГАННАРЫ

(42 нче ел 1. IV языла башланган иде бу.)

«Үтте инде ул вакытлар, мәңгегә югалдылар,
Акрын типкән карт йөрәккә тирән эз калдырдылар».

«Тормышымның агымында инде ул киткән агып,
Кайгыртуда файда юктыр, булмый инде кайтарып».
*(Болар минем юаткычларым)*

Минем башымнан бик күп төрле вакыйгалар үтте, мин бик кадерле затлар белән таныш һәм утырдаш булганга, тарих сәхифәләремне актарып, истә калганнарын язарга уйладым. Очлап чыга алсам, бәлки берәр файдасы тияр. Һич булмаса, Атиллам анасының тулы биографиясе белән танышыр.

**Зәйтүнә Хәйдәр кызы Мәүлүдова Чистапулия.**

Әтинең әүвәлге хатыны Мәфтүхә әни бала тапканда вафат, үзе дә, балалары да үлеп беткән. Безнең әнине (Шәмсеҗиһан Камалетдин кызы) 1880 елны 20. I дә никахлап алган.

1881 ел 9. III та беренче Шакир абый туган, 9. VIII та вафат булган, 1882 елны Рабига апа туган. Бик күп авырлыклар күреп, алты бала калдырып, 1921 нче ачлык елны холерадан Урсайда вафат булды.

1884 15.X да мөхәррәм 6 сында икенче Шакир абый туган. 1886 да Хәдичә апа туган. 1888 дә Габдрахман абый туган, 1944 12.XI да вафат. Яшь чакта байда малай, приказчик, революциядән соң инспектор. Наркомпроста финансист-плановик булып эшли.

1889 29.IX дә Бәдриҗиһан апа туган. 1921 елда Чистайдан приют балалары белән Себергә күчеп барганда поездда алты баласын, авыру ирен калдырып, тифтан вафат булган. Томскида җирләп калдырганнар.

1891 — Хәдичә апа туган һәм үлгән дә. «1893 ел 18 август чәһаршәмбе көн төнлә сәгать 3 тә кызым Биби-Зәйтүнә дөньяга килде. Ходаем бәхетен, тәүфигын, озын гомерен бирсен, амин» дип яза әти. 1895 тә Габдулла туган, 1897 дә үлгән. 1897 дә Мәрьям туган, 1898 дә вафат булган. (Болар һәммәсе әтинең китап тышына язган язуыннан күчерелде.)

Безгә исеме мәгълүм беренче бабабыз Мәүлүд булган. Шуңа күрә дә безнең фамилия Мәүлүдовлар дип йөртелә. Мәүлүднең улы Миәссәр булган. Миәссәр бабай бик бай булган, шәһәр саен йорт һәм хатын алган. Казан, Мәскәү, Нижний (Мәкарҗә), Чистай шәһәрләрендә зур-зур йортлары, кибетләре булган, имеш. Миәссәрнең улы — Садыйк бабай. Ул әтисе белән килешә алмаган, ди. Аннан аерылып чыгып, урта тормыш белән генә көн иткән. Хатыны Гайшә әби кечерәк кенә, таза гына, бик уңган хатын булган. Бабай озак тормаган, Гайшә әби ике бала (Хәйдәр, Фатыйма) белән тол калган. Ул Чистайда ир һәм кыз балаларны укыткан. Аны бөтен Чистай халкы «Сабак абыстай» дип атый иде. Безне дә «Сабак абыстай Хәйдәренең кызлары» дип йөртәләр иде. Заманында зур дәрәҗәле укытучы булган.

Чистай шәһәре Кама елгасы буендагы саф һавалы, бик чиста өяз шәһәре иде. Кара туфраклы җир булганга, элек тирә-якта иң күп иген озатучы бер пристань иде. Шәһәрнең төн ягында — Кама елгасы, көньягында һәм көнчыгышта — урман. Көньяктагысы җиде чакрым, көнчыгыштагысы бер ярым чакрым гына. Шуңа күрә берсен якын, каршы урман, икенчесен ерак урман дип йөртә идек.

Көнбатышта болынлык китә. Шуңа күрә шәһәрнең һавасы бик яхшы.

Шәһәрдә ике мәчет, дүрт чиркәү булса кирәк. Урысларның духовный училищесы бар иде, гимназия соңрак салынды бугай.

Менә мин шул саф һавалы, агар сулы, мул игенле Чистай шәһәренең таш мәчет мәхәлләсендә, мәчеткә каршырак Зариф абзыйлар йортында 1893 ел 18 августта дөньяга килгәнмен.

Мин үземнең әтием белән торган вакытымны бик аз хәтерлим. Мин туган йорт Зариф абзыйлар каралтысы эчендә капкага карап тора торган өч тәрәзәле, тәбәнәгрәк кенә, иске булса да бик эре бүрәнәләрдән салынган бер өй иде. Өйнең эче өчкә бүленгән. Кергәч тә ишек каты, ике тәрәзә — түр як, бер тәрәзә — бүлмә як. Ишек катында сул якта тәрәзә, тәрәзә янында бик биек сәке. Без аны «әти сәкесе» дип йөртә идек. Әти шунда замаска баса торган булган (үзенең тегермән ташы кебек зур түгәрәк ташын куеп). Икенче башында тәбәнәк кенә тагы бер сәке. Анда әни камыр баса иде. Шуның янын-

да биек кенә җирдә кечкенә тәрәзә бар. Зур икмәк миче, кечкенә сәке ягында казан. Ишектән кергәч, туры түр якта ишек бар. Түрдә буйдан-буйга зур сәке, сәке өстендә бер иске сандык, сандык өстендә түшәк-ястык; юрган киртәгә эленгән. Идәндә сары зур иске самавар.

Шулай ук ул бүлмәдә дә тәрәзә янында буйдан-буйга сәке бар. Монда без, балалар, йоклыйбыз. Сәләмә мендәрләр мич башында, тышы яхшырагы киртәгә кыстырылган. Өскә, аска сала торган сәләмә бишмәтләр киртәгә эленгән. Бүлмәгә керә торган мич арасында кашыклык. Шунда тәлинкә-кашык. Әни сәкесендә аш бушата торган бер агач табак, кашыклыкта аш бүлә торган зур татар кашыгы. Башка җиһазны хәтерләмим.

Мин белгәндә без биш кенә бала идек. Юкса, әни ун бала тапкан. Әти белән бары егерме ел торган. Мин сигезенче бала.

Кичләрен әти безнең һәммәбезне җыеп сәкегә утырта да үзе төрле хикәя китаплары («Сал-сал ибн Дал», «Сәет Баттал газый», «Каһарман катил») укый. Әтинең язган язулары да бик матур, чиста. Ул үзе бик күп укыган, галим кеше булган диләр иде, тик мулла гына булырга теләмәгән, маляр булып эшли, кайвакыт, китерүче булса, көзгеләр коя, мин карап торам. Ул эшләр дә булмаса, тәрәзә пыяласы куеп йөри. Шуңа күрә аны пыялачы Хәйдәр дип йөртәләр.

Безне, яратыбрак әйтергә теләсәләр, «Сабак абыстай Хәйдәренең кызлары» диләр, инде баераклар исә «Пыялачы Хәйдәр кызлары» гына дип җибәрәләр иде. Әз генә хәтердә: Шакир һәм Габдрахман абыйлар мәдрәсәгә йөриләр. Аннан кайткач, я кузна уйнарга чыгалар, я зур-зур капчыклар алып Кама буена пычкы чүбе, йомычка җыярга китәләр. Әни пычкы чүбен ягып, мич кызгач, кисәү белән болгап безгә күрсәтә. Мич ут валчыклары белән тула. Безгә шул бик кызык тоела иде.

Рабига апа белән Бәдриҗиһан апа Гайшә остазбикәгә кадим сабагына йөриләр иде. Әмма мин Рабига апаның өйдә торганын бер дә белмим. Бары кадер кичләрен мәктәптә хатыннар җыелгач, Рабига апаның матур тавышлы бер кыз белән «Мөхәммәдия» укыганын гына бераз хәтерлим. Әни: «Безнең Рабиганың тавышы бигрәк матур, бигрәк моңлы», — дия иде.

Апалар-абыйлар укырга киткәч, мине мич башына мендереп куялар. «Өй җылынгач төшәрсең». Мин бик ябык, бик кечкенә идем. Беләкләрем тазарак кешенең баш бармагы кебек нечкә, тотып селкесәң өзелергә торгандай. Мин мич башында чыралар (анда әнинең ярып куйган чыралары күп була иде), әтинең ислемайдан бушаган кечкенә шешәләре, Камәр җиңгинең җептән бушаган кәтүк я шпулькалары белән уйный идем. Чыралардан балалар ясыйм, шешәләрне укытучы итәм (апалар сөйләве буенчадыр), шулар белән сабак-сабак уйныйм.

Элек эшсез кешеләр, «биржа» дигән бер җирдә җыелып, эш булмасмы дип көтәләр иде. Ничектер бер кич әтине эзләп «биржа»га бардык. Әти мескен замаскага буялган киндер алъяпкычтан, таякка таянып тора. Аның аяклары авырта. «Әйдә, балам, барыбер эш булмас инде», — дип, мине кулымнан тотты да кайтып киттек.

Бер яз көне мин Бәдриҗиһан апам һәм иптәш кызларым белән коры җирдә кырмыскалар карап, аннан тәти чичкалар (фарфор ватыкларына шулай ди идек) белән уйнап тора идек, ишегалдында ике марҗа кызы күренде. Белмим, бәрәңге, белмим, суган сатарга кергәннәр. Кызларның берсе таеп егылды. Үзе кыска күлмәктән, ыштан балагы күренми (татарларда ул күлмәктән күренеп йөри, юкса. Бер вакыт ситсы аз булганга, әни миңа ыштанны кыскарак итеп теккән дә, Газизә абыстай: «Икенче төрлене булса да ялгап куй», диде). Теге кызларның улыгын өчпочмаклап алга китереп бәйләгәне егылгач, «батюшки» дип кычкырды да сикереп торды. Без аның ни әйткәнен белмәсәк тә, сүз безгә бик

кызык тоелды. Әти, әни өйдә юк иде, тиз генә өйгә кереп балаларны сызганып, күлмәкне ыштан бөрмәсенә кыстырып, яулыкны өч почмаклап бәйләп чыктык та үзебезне нәкъ шул кыз кебек булдык дип, таеп егылабыз да, «батюшки» дип дүртәү бердән кычкырабыз. Бусы безнең театр, кино... Без ул көнне бик кызып китеп, шул килеш уйный-уйный, урамга ук чыгып киттек.

Суда егылып уйнаганда күрше Вәли бабай килеп чыкты. Мин тиз генә качып өлгерә алмадым. Вәли бабай мине һәр вакыт, Шәмси бутылкасы чыккан, кая, алып кесәмә салыйм әле дип, минем котымны ала, чынлап кесәсенә бөтәрләп салыр да алып китәр дип курка идем. Кайвакыт апам, мине яклап, ул кесәгә сыймый, дисә дә, Вәли бабай бишмәтенең кесәсен күрсәтеп, кая, салып күрсәтим, әле монда син дә сыярсың, чирек хәтле булсаң да, ди иде. Мин урамда уйнаганда, апам, «Вәли бабай кайта» дип әйтүгә йортка капка артына кача идем. Шулай да Вәли бабай — кечерәк кенә, түгәрәк ап-ак сакаллы юан кеше — капка янына җитүгә: «Бутылка кая китте, аны кайда качырдыгыз?» — дип, апалардан сораган булып, мине куркытып үтеп китә иде.

Бу юлы да Вәли бабай үтеп китүгә мин урамга чыктым. Юл уртасында бик кызу гына уйный башлаган идек, чаттан әти килеп чыкты. Апа уенын ташлап: «Әти кайта!» — дип кычкырды да өйгә таба чаба башлады. Мин дә аның артыннан йөгердем. Мин өйгә кергәндә апа түр сәкесе астына артка ук кереп поскан иде. Мин дә сәке астына мыштым гына кереп яттым. Ул арада әти кайтып керде. «Кая болар, кая качканнар?» — дип, ишектән керүгә туп-туры сәке астын карый башлады. Апаны табып, аны аягыннан тартып чыгарды. Миңа да чыгарга кушты. Мин бик куркып кына чыктым, тик әти безне кыйнамады (әти дә, әни дә балаларын кыйнап үстермәгәннәр. Әни, кая гөмбә, кая чыра, дип кенә куркыта иде. Без чыра белән кыйный, гөмбә белән «төсли» дип бик курка идек. Шулай да әни бер мәртәбә мине «төсләде». Ачуланып түгел. Төнлә мин куркып, җылап уяна башлаган идем. Әтинең мине кутәреп, «кызым Зәйтүнә, кызым Зәйтүнә, җылама, без бит бу», дип юатканын ачык хәтерлим. Шуннан соң мине «төсләргә» куштылар. Бер шаярганда әни миңа, «бик шаяра башладың, күптән сине «төсләргә» кирәк иде, төнлә дә куркынасың», дип, иске бишмәткә томалап яткырды. Гөмбәне яндырып бишмәт җиңе аша шуның төтенен җибәрде. Шул «төсләү» дип атала иде).

Сәке астыннан чыккач, әти, икенче алай ямьсезләнеп, урамда пычракта уйнап йөрмәгез, дип орышты. Без шунда ук уйнарга чыгып чаптык.

Шулай да без урамда күп уйнамый идек. Белмим, әниләр тыйдымы, белмим, анда җитәрлек кызык түгел идеме. Бер вакыт күрше Камилә абыстайларның өйләре янында җәелгән ташларны кубарып, комнарны алып уйнаган идем. Алар берсе дә өйдә юк — Садыйк абзый да, Камилә абыстай да. Шуннан өйгә кердем. Пәнҗешәмбе көн булган, күрәсең, әни идәннәр юып чыккан, самаварны бик матур итеп агартып куйган, зур эскәтер җәеп, өйалдында идәнгә, сәрин җиргә, чәй әзерләгән. Кеше саен берәр телем сап-сары яңа гына пешкән икмәк кисеп куйган (апага баш, миңа баш арты), берәр шакмак шикәр куелган, табак белән әрчеп пешерелгән бәрәңге китерде. Шулай урамнан уйнап арып кергән килеш бик тәмләп ашап-эчеп утыра идек, Камилә абыстай килеп керде дә минем бөтен кәефемне җибәрде. «Безнең өй алдындагы ташларны кубарганнар, кем эше дисәк, Зәйтүнә эше, имеш, кешеләр күргәннәр. Садыйк абзыең полицейский китертәм дип әйтә», диде. Тамагыма нидер тыгылды, күземә яшь килде, әни белән апага карарга куркам, үзем әнине дә бик кызганам. Шулай мине орышты да Камилә апа чыгып китте. Әни дә, алай ярамый, кызым, менә ни хәл итәрбез менеп әйтсә, дип куркыта. Шуннан соң чит кеше коймасы янына артык бармас булдым.

1907 ел җәй көне без Чистайдан күчеп Казанга, абыйлар янына торырга килдек. Абыйлар Казанда Әбрар Бәхтиев кибетендә приказчик булып эшлиләр иде.

Билгеле, ул елларда татар матбугаты нисбәтән бик алга бара торган чак. Төрле газета-журналлар һәм китаплар чыга. Абыйлар исә барлык яңа китап-газеталарны алып кайталар. Без һәр яңа нәрсәне йотлыгып укыйбыз, тагын киләселәрен сабырсызлык белән көтәбез.

Җәй үтеп, сентябрь ае керү белән, без апам белән русско-татарская школага укырга кердек. Ул вакытларда апа унҗиде-уналтыда, миңа ундүрт яшь тулган. Без һәр көн уникегә кадәр укыйбыз да кайтып эшкә утырабыз. Әни икенде, ахшам арасында эшләгәнне бер дә яратмый, күзгә зарары бар, бәхет ким була, дип, безне ул вакыт эшләтми иде. Без дә кич белән, абыйлар эштән кайтканчы, урамга йөрергә чыгадыр идек.

Габдулла Тукайның Казандагы татар матбугатында шигырьләре басыла башлагач та, мин аның шигырьләрен аерым бер ләззәт һәм дәрт белән укыйм һәм яңаларын түземсезлек белән көтә идем. Шул хәтле матур, туры, рухка азык бирә, үзен телең белән әйтеп бирә алмый торган нәрсәләрне матур, үткен каләм белән әйтә белүче кешене күрәсем, шигырьләрен укыганын үз авызыннан ишетәсем килә башлады.

Без Бәдриҗиһан апам белән һәр вакыт бергә йөри, бер-беребезне яхшы аңлаша идек. Апам белән сөйләшеп, Тукай белән танышу юлларын эзли башладык. Без кичләрен йөрергә чыккан саен хәзерге Г. Тукай урамындагы «Чаткы» кинотеатры каршысында торучы Шәкүр Аппаковларның Фатыйма, Гөлсем исемле кызларын алып чыга, бергә йөри идек (алар гимназиядә укыйлар иде).

Мин, гадәтемчә, бер көнне Аппаковлар өенә керсәм, анда Фатыйх абыйны (Фатих Әмирханны — А.Р.) очраттым. Билгеле, мин аның белән күрешмәдем. Ул вакыт без ирләрдән кача идек. Мин ишектән күренү белән ул минем кем икәнлегемне сораган. Сеңелесе Фатыйма: «Чистайдан килгән Зәйтүнә исемле кыз. Тукай белән күрешү өчен үлә язып йөри инде», — дигәч, Фатыйх абый: «Әлек үзем белән күрешсен, мин Тукай белән күрештерермен», — дигән. Мин моңа бик шатланып, апам белән бергәләп килергә вәгъдә бирдем, тугрысы, Фатыйма аша әйттердем. Шатлыкны апам белән уртаклашырга чаптым.

Билгеле, ул вакытта, бигрәк тә безнең кебек түбән катлаудан чыккан кызлар арасында, егетләр белән күрешү бик зур гаеп санала иде. Шуңа күрә без әнидән бик курка идек — белсә, безне үтерер кебек тоела иде. Юкса, безнең әни бик йомшак табигатьле, абыйлар исә аңлы приказчиклардан санала. Ләкин гайбәт сөйләрләр дә, аларга авыр тоелыр дип, без аларның хәтерен калдырмаска тырыша идек. Моның кызлары азгын, егетләр белән чуала, диярдәй яман телләрдән бик сакланабыз, үзебезнең намус-гыйффәтебезгә нихәтле ышансак та, халыктан бик курка, пычрак исем аласыбыз килми иде. Шуның белән беррәттән үк Тукай белән күрешәсебез килү дә фәүкылгадә иде. Аның һәр шигырен укыган саен: «Аһ, кайчан гына күрербез. Шул шигырьләрен укыганын үзеннән ишетсәң иде бер», — дия идек.

Фатыйх абый күрештерергә вәгъдә биргәч тә, без аның белән ничек күрешербез дә, ниләр генә сөйләшербез икән, дип апа белән хафага төшә идек. Аның шигырьләрен бик яратып укуыбызны, безгә аларның ошаганын, безне уятканын әйтсәк, ул көләр генә кебек тоела иде. Егетләр белән гомеребездә күрешкән булмагач, Фатыйх абый белән күрешүдән дә шүрлибез, уңайсыз кебек тоела. Бик мәгънәсез булса да, үзе белән күрешмичә генә безне Тукай белән таныштырсын иде, дибез. Ни-

һаять, вәгъдәләшкән вакыт җитеп, апа белән мәктәптән чыгуга Аппаковларга кердек. Ялгышмасам, Фатыйх абыйлар «Әльислах» редакциясе өенә торырга күчкәннәр иде. Алар югары катта торалар, Фатыйх абый белән туганы Ибраһим абый Әмирханов та бар иде. Күрештек, байтак кына сөйләшеп утырдык.

Безнең калтырый-калтырый күрешкәнне күреп, ни дәрәҗәдә каушаган булуыбызны Фатыйх абый тиз аңлап алды. Күңелле, җайлы, туган агалар кебек тәмле, йомшак сөйләшүе белән безне тиз тынычландырды. Күптәнге танышлар кебек сөйләшеп өч-дүрт сәгать үткәнен сизми дә калдык.

Фатыйх абыйның үзенә бик охшаган рәсемнәре булганга күрә, сурәтен тасвир итеп тормыйм. Беренче күрешүдә ул кайчан Казанга килүебез турында сорашты. Иялашәсезме, Казан ошыймы, Чистайны сагынасызмы, диде. Аның үзенең дә Чистайда булганы бар. Минем туганнан туган Камилә апам Фатыйх абыйның әтисе Зариф хәзрәтнең энесе Нәҗип муллада кияүдә... Без Нәҗип хәзрәтне дамелла җизни дип йөртә идек. Фатыйх Әмирхан үзенең Чистай хатирәләрен сөйләп, безнең укуларның ничек баруы белән дә кызыксынды.

Аның яныннан чыккач, өйалдында гына апа белән сүз алышып, мин яңадан Фатыйх абый янына кердем дә: «Мишәр кызлары» исемле мәкаләне алмадыгызмы?» — дип сорадым. «Алдым», — дигәч, имзаны Бәдрелҗиһан Чистапулия дип куегыз, дидем. Бу сүзләрне ишеткәч, Фатыйх абый, сезнекемени ул, бик яхшы мәкалә, мин аны, әлбәттә, бастырачакмын, дип калды. Мәкаләне без мәктәптә дәрес арасында гына язып, кайтышлый почтага ташлап киткән идек.

Шуннан соң байтак вакытлар үтте. Фатыйх абый авырып, аягына баса алмас булды. Ул бөтенләй редакциягә күчеп килде. Без еш кына анда кергәли башладык. Тагын Фатыйх абыйны йөдәтергә тотындык. Аңар тәмам ияләндек, риясыз, туганнарча ачыктан-ачык сөйләшә башладык. Ул апаны димләмәк булып күрештерергә булгач, безгә ничегрәк үз-үзебезне тотарга, ничек сөйләшергә кирәк икәнен әйтеп, яхшы киңәшләр бирә иде. Без аны бик бимазалый башласак, «дүртегезне (үзенең ике туганнан туган сеңелесе, апа белән мин) берьюлы Тукайга тотып бирермен инде»,— дия иде. «Зәйтүнә, сине дүртенче хатын итеп бирермен, яме»,— ди. «Теләсәң ундүртенче итеп, әмма Тукайга гына бир»,— дим мин. «Аһ, Тукай шагыйрь бит ул, аның шигырь укыганын бер генә ишетсәм дә разый булыр идем әле, кая ул безне алу»,— дия идем.

«Син дисең, имеш ки, шагыйрьгә барам. Барма, барма, син әрәм, аңгар әрәм! Үз уеңча, шагыйрь ул җырлый, дисең. Җыр исә тыңларга күңелле дисең...»

Шулай итеп, яз да якынлашты, 1908 елның яз ае. Белмим, март башымы, уртасымы, бер якшәмбе көнне апам белән хәзерге Г. Тукай һәм Татарстан урамнары почмагындагы Таһиров йортында торучы бер танышларыбызга эш белән утырырга бара идек, редакция яныннан узарга туры килде. Редакция тәрәзәсе ачык, Фатыйх абый исә тәрәзә янында утыра булып чыкты. Без шул якка чыгып, күрешеп узганда, ул: «Кая барасыз, озак тормагыз. Озакламый миңа Тукай киләчәк», — диде. Без аңа бара торган урыныбызны күрсәттек.

Без мәктәптән кайтуга гадәттә эшкә утыра идек. Абыйлар эшли торган кибет өчен күлмәк, мендәр тышлары чигә идек. Шуңа күрә бер минут эшсез тормый, кая гына барсак та, эшебезне алып бара идек.

Ул көнне танышларыбызда чәй эчүгә апа эшкә утырды. Мин Тукай килмәдеме икән дип белер өчен, әни бер йомыш кушкан иде, шунда гына кереп чыгам дип, чыгып киттем. Капкадан чыгуыма Фатыйх абыйның сеңелесе Гөлсем безнең арттан килеп җитте. «Фатыйх абый тиз килсеннәр, Тукай килде дип әйтергә кушты», — диде ул. Мин тиз генә апам янына кереп: «Апа, тиз бул, әни бик ачуланып килде, бик тиз кайтып

житәргә кушты»,— дип алдадым. Юкса, Фатыйма апа безгә әллә нәрсә пешерә башлаган иде. Ә ашап утырсак, Тукайның китеп бару куркынычы бар. Фатыйма апаның үпкәләвенә карамастан, без чыгып киттек. Аппаковларга барып кергәндә залдан Ибраһим абый килеп чыкты.

— Әйдәгез, кызлар, үзегез күптән «таныштыр, таныштыр!» дип йөдәткән Тукай белән күрештерәм. Тизрәк булыгыз, Тукай китеп тә барыр ул,— дип, безне зал якка чакырды. Ул үзенең култыгын сузды: мин барып Ибраһим абыйга тотындым. Гөлсем миңа, апа Гөлсемгә, апага Фатыйма. Мин Ибраһим абыйдан, анда кемнәр бар, дип сорадым. Ул «Фатыйх, Тукай, «Әльислах» редакторы Вафа Бәхтияров», — диюгә, Фатыйма: «И, кеше бик күп икән, кермибез», — диде. Апа да: «Олы кеше Вафа да булгач, кыенрак шул. Оят та», — дип өстәде. Гөлсем дә минем кулдан ычкынды, мин дә ирексездән Ибраһим абыйның кулыннан кулымны алдым. Барыбыз да аптыраште калдык. Мин иптәшләрне димлим, керәсем килә. Берәр эш белән Вафа абый китмәс микән, димен. Ибраһим абый бездән көлә. Вафа нишләп олы кеше булсын, аның мыегы минекеннән дә кечкенә. Булмаса, үлчәп карыйбыз, ди, тик гадәттә минеке зуррак булса, ул сугыша башлый, дип безне көлдерә. Без, әйдә керик, дип Ибраһим абый артына баштагы тәртип белән тезеләбез дә. Фатыйма тагы киреләнә башлый. Мин тагы аны орышырга керешәм. Шулай сатулаша торгач, Ибраһим абый, миңа керергә вакыт, кермисезме, алайса, хушыгыз, дип кузгала башлады. Мин «керәбез» дип куйдым. «мин керәм, кызлар, калсагыз, соңыннан үкенмәгез», дигәч, минем артка Гөлсем, аның артына апа, соңра Фатыйма тезелеп кереп киттек.

Мин туп-туры Фатыйх абый янына барам. Минем артта Гөлсем белән апа, ә Фатыйма ишеккә хәтле килә дә керми кала. Аның шундый гадәтләре бар инде. Кешене котырта, ә үзе читтә кала, соңыннан көлә.

Зур залда «Әльислах» редакциясе. Урам як тәрәзә каршында бер караватт тора. Фатыйх абый шул караватка утырып тора, аның алдына кечкенә өстәлме дим, табуреткамы куелган. Башкалар Фатыйх абый тирәсенә урнашканнар... дурактан карта уйныйлар. Керүгә мин барып Фатыйх абый белән күрештем. Ул безне: «Туташлар, шагыйрь Габдулла Тукаев белән таныш булыгыз», дип, безнең исемнәребезне атап, Тукайга тәкъдим итте. Тукайның өстендә кара пинжәк, юллы күлмәк, кара галстук, аягында ботинка. Үзе ялан баш, чәче озын да, кыска да түгел. Без кергәндә генә күтәрелеп бер карады да, күрешкәндә урыныннан тора төшеп, кулларыбызга карап кына күреште. «Исән-сау йөрисезме» кебек сүзләрдән соң яңадан карталарга тотынып, шуларга текәлде. Мин исә һич күзләремне ала алмый аны күзәтәм. Әмма Тукайга бер дә рәтле карта керми. Фатыйх абый аңа каршы бик рәхимсез каты йөри. Ә минем алар арасына кереп, Тукайны рәнжетмичә йомшак кына йөрисем килә, мәгәр җөсаратым җитми. Тукай карта алган саен, «шул инде, бәхетсез кешегә һәр вакыт кире килеп тора, бер бәхетсез булган кеше гел бәхетсез», ди. Ул буш кулы белән чәчен сыпырып зарланган саен минем йөрәгем әрни, аны бәхетле итәсем килә. Мин, ниһаять, катгый карарга киләм. Уенга катнашырга кирәк. Тик шул вакытта гына алгы якта әнием тавышы ишетелде. Мин коелып төштем. Без апа белән бер-беребезгә карашып алдык та ашыгыч кына саубуллашып чыгып киттек.

Бу минем Габдулла Тукай белән беренче очрашуым булды. Ул көнне әни анда үз эше белән генә кергән икән. Әни бер бүлмәгә кереп китүгә, без апам белән тиз генә өйгә йөгердек. Әни сизмәсә дип, шул арада апам нәзер дә әйтергә өлгерде. Ул һәр вакыт шулай, зур куркыныч читләп узса, безнең капка төбендә хәер эстәп торучы карчыкка биш тиен, куркыныч азрак булганда ике я өч тиен бирә иде.

Габдулла Тукайны без икенче тапкыр Рабига һәм Бәдриҗиһан апаларым белән Екатерининский (хәзерге Г. Тукай) урамыннан барганда

очраттык. Безнең яннан гөрләп трамвай узды. Олы апам Рабига: «Трамвай тәрәзәсеннән бер рус башын селкеп узды,— диде.— Сезгә түгелме?» Бәдриҗиһан апамның күзләре үткен. Ул карау белән: «Тукай», диде. Мин анык күрмәсәм дә, сәламләп башым идем. Трамвай ул арада дугасыннан чатыр-чотыр утлар чәчрәтеп борылды да күздән югалды. Бу вакыйганы искә алуым шуннан, озак та үтми, шагыйрьнең «...гә» исемле шигыре басылып чыкты.

Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген;
Ул шуңар да шатлана бит: чын җүләр түгел диген!
Күргәнең бармы әле корьәндагы мәдхияни?
Ул синең васфында: «ля шәркыйя, ля гарбия»,— ди!
Күк китабының сине белгәнлегенә шаккатып,
Ул хәзер алган «Сабах»тан бер Кәләмулла сатып.

Шул ук Екатерининский урамында Тукайны мин тагын бер тапкыр очраттым. Без Бәдриҗиһан апам белән «Әльислах» редакциясе яныннан узып бара идек. Тәрәзәдән генә Фатыйх абыйны һәм идарәдә утырган кешеләрне күреп уздык. Кеше күп булганга күрә керергә кыймадык. Ләкин күп тә китмәдек, апам: «Әнә, Тукаев килә», диде. Ул арада Г. Тукай үзе дә килеп җитте. Безнең белән гадәтенчә кыяр-кыймас кына исәнләште. Мин аның янына барып кул биреп күрештем. Апам да килеп күреште. Шагыйрь ашыккан сыман күренә. Ләкин мин, аның юлын кисеп, «Кая барасыз?» — дип сүз башладым.

— Редакциягә. Фатыйх анда микән, сез булмадыгызмы?

— Тәрәзәдән күрдек. Кеше күп булганга күрә кермәдек.

Һәм мин аның ни эшләп йөрүен төпченә башладым. Ул исә әдәбият кичәсе оештырып йөрүләрен, шунда хор өчен кирәкле материаллар әзерләвен әйтте. «Сез килерсезме?» — диде. Барырга киңәш итте. Үзе сөйләшкәндә күбрәк түбән карый, миңа йөзенә карамаганда гына күз ташлый. Мөмкин кадәр карашларның очрашмавын тели, күрәсең, һәм дә тизрәк китәргә ашкына. Мин аның кулыннан тоткан килеш байтак вакыт сөйләшеп тордым. Яз көне булганга, аяк асты пычрак иде. Мин сөйләгәндә, ул аягы белән сулы балчыкны изгәләп тора. Бу лыбырдыкның сүзе озынга китте дигәндәй, миннән тизрәк ычкынырга тели кебек үзе. Мин бәлки аның безнең белән сөйләшәсе килмидер дип, бәлки кеше-кара күрүеннән хурланадыр дип уйладым. Җитмәсә, аннан аерылгач, апам мине орышырга тотынды. «Кешене шул кадәр аптыратмасаң. Беләсең бит, ул эш кешесе. Эше ашыгычтыр, синең белән сөйләшәсе генә килеп тормас. Ә син бер алдына, биш артына төшәсең. Шул хәтле чекрәя-чекрәя күзләренә карамасаң, күреп туймыйсыңмы әллә? Котым калмады. Бу инде: «Габдулла әфәнде, мин сезне сөям» дип әйтәме дип торам».

Апамның мондый сүзләренә минем ачуым чыкты. «Нишләп мин алай әйтим? Ул бит минем абыем кебек кеше. Аның миңа карау ихтималы да юк. Олы кеше, караса сиңа карар. Мин аны бары тик хөрмәт итеп кенә сөйләшәсем килә, якыннан таныш буласым килә», — дидем.

Кайчак минем ачуымны китерү өчен апам болай җырлый иде:

Күк күгәрчен күктә уйный, башлары әйләнмәсә;
Бик сөйсәң дә баралмассың, чәчләрең бәйләнмәсә.

Яки:

Карар инде, карар инде, карап туялмас инде.
Ни кадәрле карасаң да, ул сиңа булмас инде.

Бик дустанә генә сөйләшкәндә, үзенең Фатыйх абый белән, минем Тукай белән булуны да хыялланып куя иде. Андый чакларда үзебезнең хыялдан үзебез оялып, кеше сизмәсен тагы дигәндәй, як-ягыбызга карана идек. Аннары тагы:

Бүген күргән өч егетнең жем-жем итә кигәне,
Фатыйх алма, Ибрай хөрмә, Тукай кура җиләге,—

— дип тә җибәрә идек.

Габдулла Тукай белән без тагын әдәбият кичәсендә күрештек. Ялгышмасам, ул кичә мәдрәсә ташлап чыккан шәкертләр файдасына ясалды.

Фатыйх абый безгә контрамарка бирергә һәм үзе янына беренче рәткә утыртырга вәгъдә итте. Кичәгә барганда ак күлмәк, ак калфаклардан барырга кушты. Апам, Фатыйма белән бергә, бик матур «тегермән» эчендә чәчәк, конфетти сатачак иде.

Кичә бик күңелле барды. Бигрәк тә минем кебек андыйны гомерендә беренче мәртәбә күргән кешегә һич онытылмаслык булды. Тукай үзенең «Утырышу» шигырен укыды. Кулында бөтәрләп тоткан бер кәгазь бар иде. Тавышы бик каты да, бик йомшак та түгел — уртача, яхшы итеп, интонация белән укыды. Бик озак кул чапканнан соң гына чыгып, тагын бер шигырен укыды. Сәгыйть Рәмиевнең нәрсә укыганын хәтерләмим. Шәкертләр хор белән «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр»не җырладылар.

Антракт булды. Мин тиз генә биш тиенлек конфетти барып алдым да сәхнәдән чыгуларын көтеп тордым. Тукай костюмнан, галстуктан иде, башында кара хәтфә кәләпүш. Кызларның һәммәсенә калфактан, ирләргә кәләпүштән бару шарт итеп куелган иде. Минем күлмәгем ак булса да, калфагым кызыл хәтфәдән иде, ак төслесен таба алмадым.

Алдан Тукай килеп чыкты. Кулымдагы конфеттидан күп кенә алып аңа сиптем. Бөтен чәче, кәләпүш өсте матур кәгазьләр белән бизәлде. Соңра Сәгыйть Рәмиевкә бераз сиптем дә, калганын тагы Тукайга сибеп, аның кулын кысып, мөвәффәкыйяте белән тәбрик итә башладым. Ул көлеп баш иде, рәхмәт әйтте. Аннан бер кырыйгарак китеп сөйләшә башладык.

Залда музыка танцы көйләрен уйный, кызлар-егетләр бии. Кызларның күкрәкләрендә чәчәк, егетләр әллә нинди күк тасмалар, бантлар таккан. Югарыдан кәгазь тасмалар төшерәләр дә бөтен биючеләр бергә шул серпантинга бәйләнеп бииләр. Без шул кызыкны карап торабыз.

— Ничек, кичә сезгә ошыймы? — ди Тукай.

— Бик ошый. Монда килгәч, мәктәбебез белән бер мәртәбә Большой театрда гына булдым. Мондый әдәбият кичәләрен күргәнем булмаганга, моннан артыгын күз алдыма да китерә алмыйм, — дим.

— Сез танцевать итмисезме, теләмисезме? — дип сорый.

— Әле яңа гына танцыга өйрәнә башладым, белмим. Мин өйрәнгәч, сезнең белән генә танцевать итәргә телим. Бергә танцевать итәрбез, яме? — дим мин.

— Мин дә яңа өйрәнә башладым. Мин дә сезнең белән генә танцевать итәрмен, — ди ул, көлә.

Ул, кем белән килдегез, дип сорады. Апам белән килдем, кайтканда бергә кайтырбыз, халык киткәндә сез дә кайтасыздыр бит? дидем.

Тукай ризалык белдерде. Шуннан соң ул тәмәке тарту бүлмәсенә кереп китте. Мин, кәгазьләр алып, Фатыйх абый янына килеп утырдым да хатлар язарга тотындым. Бер ягымда Фатыйх абый, икенче ягымда Ганибайның энесе диделәр, Мәхмүт бай утыра. Бик күп энҗе белән чиккән кәләпүш кигән, күзенә бик калын итеп сөрмә тарткан, калын, озын, таза гәүдәле. Шул кеше күзләрен бик чекрәйтеп карый башлагач, тиз генә урынымнан торып, икенче креслога күчтем. Фатыйх абый көлә. Шундый матур итеп үзегезне яратып карап торган кеше яныннан ник шудыгыз, ди. Ул да дикъкать иткән икән. Ярлы гына киемдә булсам да, миңа күп кешенең күзе төшә, җазибәле күзләрем кешене бик тиз тарта иде. Уйнаклап тора торган шаян бер кыз идем.

Кичә тәмам булды. Мин, ни хәтле эзләсәм дә, Тукайны таба алмадым. Апа, әйдә инде, кешедән калабыз, дигәч, безне көтеп торган Ибраһим абый, Солтан Рахманкулый, Фатыйма, Гөлсемнәр белән кайтып киттек. Кичәдән Аппаковларга кайттык. Кичә ничек үтте, нәрсәләр ошады, ошамады — үзара анализларга тотындык. Мин кичәнең яхшы үтүен әйтеп, Тукай «Утырыш»ны укыганда бер дә күзен миннән алмады, «Һәрбер тешен карыйм, түшен карыйм» дигән җирен укыганда шул хәтле оялдым, дип әйтә салдым. Фатыймага шул җитә калды. Тукайның сиңа бик исе киткәндер инде, дип көләргә тотынды. Мин дә апам алдында мыскыл итүләренә бик-бик хурландым. Мин, тиле, үземне кешегә исәпләп, Тукай миңа карый дип сөйләп утырам. Тукай минем кебек ярлы мишәр кызына карамаса, монда гимназистка һәм курсисткалар беткәнмени! Укыганда күзе төшсә төшкән, әмма күңеле һич булмагандыр. Г. Тукай хакында шундый уйда булуым, ул үзен шулай олы тотканда, кыз башым белән аның янында шул хәтле кыю йөрүем оят бит. Ул һәрвакыт миннән көләдер, иптәшләренә дә әйтеп бергә көләләрдер кебек тоелды. Чынлап шулайдыр. Мин «бергә кайтырбыз» дигәч тә күренмәде бит. Безнең Болгар номеры янында узачакны белә бит. Ул я безне көтми китте, я без китсен дип чыкмый торды, дип тә уйладым.

Белмим, басылып чыкмаган идеме, «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләрни диләр» шигыре безгә бик ошады. Шуны кемнән генә булса да сорап аласыбыз килә иде. Тукайны күреп тә булмый, уңайсыз да. Бу кызлар сагыз кебек ябышты дияр төсле. Шулай да кичәгә катнашып йөргән Фәхрелислам Агиевтән (балалар журналы «Ак юл»ның редакторы) сорадым. Белмим, Агиев үзе әйткәнме, Тукай аны ничек ишеткәндер, бер көнне редакциядә эшләүче Таһиров әфәнде безгә шул шигырьне китереп бирде. «Менә сез сораган икәнсез, сезгә Тукай бирде», диде. Без күп рәхмәт әйтеп алдык һәм бик уңайсызландык. Миндә, Тукай безнең белән күрешкәндә шулай салкын торса да, безгә хәерхаһ, кемнәндер сораганыбызны белеп, шигырен җибәргән, дигән фикер туды.

Без Чистайдан Казанга, абыйлар янына торырга дип килсәк тә, Казанда тормыш бик авыр булганга, әни яңадан үз йортыбызга кайтып китәргә уйлады. Абыйлар приказчик, без көн-төн канва чигәбез. Алай да тормыш алып баруы авыр. 1908 елның җәй башында Казаннан китәргә әзерләндек. Абыйлар багажларны төшерә китте, әни аш хәзерли, без, форсаттан файдаланып, тиз генә редакциягә киттек. Тукай очрамасмы, Фатыйх абый белән саубуллашып китәрбез дип барсак, бәхеткә каршы, Тукай шунда булып чыкты.

Фатыйх абый янында кеше күп, ул бик мәшгуль иде, без ишектән генә Таһировны дәшеп, Тукайны чакыруын үтендек. Тукай килеп чыкты да, без бергәләп урам ягына таба киттек. Ул редакциядән чыкканда ике кесәсенә кулларын тыккан килеш иде. Күрештек. Үзебезнең бүген Чистайга бөтенләй китәчәгебезне әйтеп, «монда бары сезне күрергә килдек» дигәч, «бик жәл» дип куйды. Байтак сөйләшеп тордык. Хәл-әхвәл сорашылды. Ул: «Казан ошамадымыни?» ди. Мин: «Безгә бик ошый да, әниебез китәргә тели», дим. Ул: «Укуыгыз әрәм була», ди. Мин: «Ни эшлисең, моннан соң да дәвам иттерергә тырышырбыз», дим. Ул күңелсезрәк булгач, мин кат-кат аның исәнлеген сораштым. Аның бер күзендә аз гын ак бар иде, шуның нидән булганын сорадым. Ул: «чәчәктән» диде. Хат язарга адрес сорадым, хат язышырга булдык. Кайсы пароход белән китәсез, кайчан? Мин сезне озата төшәрмен, ди. Без сәгать уникедәме, икедәме (ачык хәтерләмим) «Савин» пароходы белән дидек. Саубуллашып киттек. Без бик күпкә хәтле борылып карап кул изәдек. Ул фуражкасын селкеп калды да, без чатны борылганда кереп китте. Ул кергәч, без дә борылып киттек.

Шуннан соң мин Тукайны бер дә күрмәдем. Бары кеше аркылы гына хәбәрләр алдым.

Без, Тукай белән күрешеп кайтуга, тиз генә аш ашадык та пристаньга киттек. Безне озатырга ике абый, бер туганнан туганыбыз Ибраһим, монда абыйлар белән бергә эшли торган Чистай егете Кирам төшкәннәр иде.

Абыйлар әни белән өченче класста утыра калдылар, без дүртәү югары палубага мендек. Апам егетләр белән Идел ягына китте, мин, Тукай килмәсме дип, пристань якта калдым. Ни хәтле карасам да, кызганычка каршы, Тукай күренмәде. Белмим, килә алмадымы, әллә безнең янда егетләр барын күреп, монда мин артык, дигән фикер белән «күренмәдеме».

Без Чистайга кайткач та, матбугатта «Кызык гыйшык» дигән шигырь басылып чыкты. Аны безгә жизни «укыгыз» дип китереп биргән иде. Апам белән икәү тиз генә тау астына төшеп укый башладык. Безнең өй тау башында. Тау астында чирәмлек, елга ага. Шигырьне укыйбыз:

> Бер хәбәр бар: ул хәзер киткән бугай.
> Шәһрене күптән барып җиткән бугай...

Язуы Тукай стиле, әмма имза «Ялкын»[1] да, «Шүрәле» дә түгел. Апа, моны Агиев язгандыр, диде. Мин дә шуңа күндем. Алар Агиев белән дус иде. Апа аңа карточкасын да биргән иде. Хәер, ул шагыйрь түгел бит, югыйсә.

Без «... шигырь язсам да, ялган кул куям» дигән сүзләрне искә алмаганбыз. Шигырьне укыгач, бер-беребезгә бик озак карашып тордык. Кем язганлыгын төшенә алмадык. Мин үзем турында язган дип уйлауны зур хата дип исәпләдем. Элекке фикерләремнең барысы да кирегә чишелә килгәнгә күрә, тагы бер тапкыр ялгышудан курыктым. Үземә: ул миңа бары укуга дәртле, шат күңелле, ягымлы бер милләттәшем, татар кызы дип, агаларча, дусларча гына карый, дигән фикерне утыртырга теләдем. Мин бик яшь идем әле.

1909 елның язында безнең апаны кияүгә бирделәр. Мине дә сораганнар иде. Әнигә, ике кызыңа берьюлы туй ясыйк, диделәр. Тик әни, Зәйтүнәм бик яшь әле, ул китсә, бөтенләй ялгыз калам, дип бирмәде.

Ялгышмасам, август айларында Казаннан «Сәйяр» труппасы театр куярга килде. Шунда Тукай Габдулла Кариевка «Чистайга барсагыз, анда минем таныш ике кызым бар, шуларга контрамарка җибәр», дигән. Театр булачагын ишеткәч, минем бик барасым килде. Тик әни анда бармый, иптәш кызларым да шулай ук андый җирләргә йөрми. Театрга йөрүне ата-аналары бик начар эш дип хисаплаганга күрә, сорарга да куркалар. Рәтле иптәш булса, әнине күндереп була, тик бергә барырга кеше генә юк.

Шулай да Ибраһим абыйларга киттем, аның анасы «бармагыз» дигәндә дә Ибраһим, шиксез, барачак. Ибраһимның әнисе — җиңгине «барыйк» дип йөдәтеп тора идем, Ибраһим үзе кайтып керде. Ул әнесе Исмәгыйльгә: «Зәйтүнәләргә бар. Казаннан артистлар килгән, аларга ике контрамарка җибәрделәр, Тукай бирергә кушкан», дигәч, мин килеп чыктым да, контрамаркаларны алып, без җиңги белән бергә театрга барырга булдык.

Ул ел шулай узды. Мин кышын балалар укытырга Курсага киттем. Үзем дә укыдым, яңа ачылган җәдид мәктәбендә балалар да укыта башладым. Җәен өйгә кайтып тагы канва чиктем. Мине тагы кияүгә чыгарга димли башладылар. Мин елап абыйларга хатлар язам, абыйлар әнигә «Зәйтүнәне көчләү булмасын» дип язгач кына бу эш туктала.

---

[1] Бу шигырь беренче тапкыр «Әльислах» газетасының 1908 елгы 17 июнь санында «Мәҗнүн» имзасы белән басылган. Шигырь астында 12 июль, 1908 датасы бара. Кара: Г. Тукай. Әсәрләр. 1 том, Татарстан китап нәшрияты, 1975 ел, 387 бит — Ред. искәрмәсе.

1910 елның җәй айлары иде. Тәрәзә янында канва чигеп утырам. Капка төбендә сагыз чәйнәп, суга баручы һәр хатынга берәр сүз кычкырмый калмый торган тау асты Мәрьям апа: «Зәйтүнә, сезгә әллә нинди урыслар килә», дип кычкырды. Үрелеп карасам, чыннан да Ибраһим белән бер кеше килә.

Рөхсәт сорап өйгә керделәр. Ибраһим мине шунда Габдулла Кариев белән таныштырды. Бу ел да артистлар килгән дә спектакль кую өчен бер хатын-кызлары җитми икән, шуңа күрә минем катнашуымны үтенеп килгәннәр.

Самавар куеп чәй эчтек. Мин уйнарга каршы түгел, әнине Ибраһим күндерсә, мин риза, дидем. «Яшь хатын» драмасында миңа карт хатын ролен ятларга кушып, кунаклар китеп бардылар. Икенче көнне Ибраһим килгәч, әни яраткан энесенә каршы килә алмады. Бары: «Зәйтүнәне егетләр янында калдыра күрмә, зинһар», дип кенә Ибраһимнан үтенеп калды.

Театрда мине Габдулла Кариев каршы алды. Ул Сәхибҗамал Гыйззәтуллина, В. Мортазин һәм башкалар белән таныштырды. Рольне яхшы ятлаган идем. Суфлер Касыйм Шамильский иде.

Минем уйнавымны ярattылар. Беренче катнашуда ук булдыра алуыма канәгатьләнүләрен белдерделәр. Кариев мине озата барды. Әни өйдә юк иде. Чәй эчтек, иркенләп сөйләшеп утырдык. Кариев: «Тукайдан сезгә сәлам, — диде. — Тукай да монда килергә булып калды, иртәгә телефон белән сөйләшәм». Мин Тукайны бик ныклап чакыруын үтендем, үземнең бик күрәсем килгәнне әйттем. Номерга төшәргә кыен булса, зинһар, үзебезгә килсен, безнең өй кунакны бик ярата, дидем. Ул, Тукайның сезнең хакта язган шигырьләрен күргәнегез бармы, диде. «Юк, кайсы шигыре минем хакта?» дигәч, ул Г. Тукайның өченчеме, дүртенчеме шигырьләр җыентыгын алып, шундагы «...гә» дигән шигырьне күрсәтте. «Шигырьне язгач та миңа укыды, бу кем турында дип, миннән сорады. Мин бит коръән хафиз, сезне белмәсәм дә, Зәйтүнә исемле берәр туташ хакындадыр дигәч, бик шатланды», диде. Кариев миннән: шуны әйткәнгә ачуланмыйсызмы? дип сорады. Мин бик шатмын, бәлгакес, сезгә рәхмәт кенә әйтәм дип, Тукайны тагы бер тапкыр чакыруын үтендем.

Икенче, өченче көннәрне мин Кариевны күргән саен: «Тукай кайчан килә?», дип сораштырсам да, ул «сөйләшә, очрата алмадым» дип җавап бирде. Кариев миңа Тукайның фоторәсемен (хәзер Казанда Горький музеенда саклана — А. Р.) «Һәдияне Һәдия» дип язып бирде, үзенекен дә калдырды. Ялгышмасам, үзем дә бер рәсемемне бирдем бугай.

Көзен мин тагы Курсага укытырга киттем. Берникадәр вакыттан соң миңа Чистайдан бер якыным хат яза. «Фатыйх абый сине язучы Тукаевка димләп хат язган. Без «Үзенә яз» дип синең адресны җибәрдек», ди. Шуннан соң мин Казаннан Фатыйх абыйдан хат алдым. Тәассыфка каршы, анда мине башка кеше соратуы хакында әйтелгән иде. Әлек бик сагынып сәлам язылган, аннары — без Казанда чакны Фатыйх абыйлар белән кулларга сугып «песием-песием» уйный идек, — шуны искә алган. Кулларынның сугылудан кызаруы беттеме әле, дигән. Үземнең хәлем, кәефем, ничек вакыт үткәрүләрем вә нинди хисләр белән яшәвемне белешкәч, мине Вафа Бәхтияровның үзенә соратуын әйтә. Шуннан соң гына хатның бер почмагын бөкләгән дә шунда: «Тукай да сине онытмый», дип язып куйган. Үзенең дә бер дә онытмавын әйткән. Фатыйх абыйдан мондый хат килгәннән соң, минем кәефем бик кырылды. Әллә хатны ялгыш укыдыммы дип тә уйладым, бер җавап та бирмәдем, хатны кешегә күрсәтмәдем. Бары үзем белән бергә укыткан Сафия дустыма, бер кешегә дә әйтмәячәгенә ант иттереп (Сафия Галиева — мәрхүм язучы М. Галиның тормыш иптәше — А. Р.), Вафага сораткан җи-

рен генә укыттым. Юкса, егетләрдән әллә нинди хатлар ала, дип уйлауларыннан курыктым.

Ул җәйне мин Казанга бара алмадым. Өйгә кайтып хәзерләндем дә, әллә кемнәргә кияүгә бик сорый башлагач, тиз генә Бубига укырга киттем. Үзем ике ел балалар укыткач, миңа бу белем генә җитмәгәнлегенә төшенгән идем.

Уникенче елны җәен Бубидан кайткач, Казанга бару белән Фатыйх абыйны күрдем. Һәр вакыттагыча Габдулла Тукайның хәлен сораштым. «Әле син анда бармадыңмыни? Ул бик авырый. Син хәзер үк шунда бар!» — диде Фатыйх абый. Мин, шул минутта ук Тукайның кайда торганын сорап, чыгып та киттем. Фатыйх абый үзе Арча кырында тора иде. «Болгар» номерлары янында трамвайдан төшеп, Тукай янына барганда Фәхрелислам Агиев очрады. «Туташ, кая барасыз?» — ди. Мин: «Тукаев янына, аның хәлен белергә барам», — дигәч: «Хәзер минем шуннан чыгышым, сез анда кермәгез», — диде. Мин, ничек, нигә, минем аны күрәсем килә, хәлен беләсем килә дигәч, Агиев: «Туташ, зинһар кермәгез, Тукаевны харап итәсез, Тукайны сөйсәгез, аңа аз гына хөрмәтегез булса, кермәгез, һәлак итәсез аны», — диде. Мин, ни эшләргә дә белмичә, бу ни хәл, ничек мин Тукайны харап итим, дип аптырап калдым. Башым әйләнеп китте. Мин шулай да, башымдагы калфагымны салып, «Болгар» кунакханәсенең ишек төбенә килдем. Тәрәзә янында күз яшьләремне сөрткәләдем. Фатыйх абый, «хәзер үк бар», диде, монысы кермә ди, дип бераз уйланып торганнан соң, ишектән бер аягымны атлаган идем, «Тукаевны сөйсәгез, аңар хөрмәтегез булса, зинһар кермәгез, харап итәсез», дигән сүзләр колагымда чыңлады. Мин ни хәтле күрәсем, керәсем килсә дә, Тукайга булган мөкатдәс хөрмәт хисем хакына үз теләгемне корбан итеп булса да, кермәскә тиеш дип, җылый-җылый кайтып киттем. Икенче көнне иртүк Чистайга китеп бардым. Шулай итеп, Тукайны күрү насыйп булмады. Мин, ул терелер дә, икенче елларны күрешербез дигән өмет белән үземне юатып торганда, икенче елны аның вафат хәбәрен генә ишеттем.

Бу хәбәр миңа бик каты тәэсир итте, әнинең күрше бүлмәдә генә утыруына да игътибар итмичә, үксеп җылый башладым. Әни минем янга чыкты. «Ник елыйсың?» — ди. Мин: «Тукаев үлгән...» дигәч, мине орышырга тотынды. Үзең дә үләрсең әле син, ди. «Мин үлсәм дә ярый, ә Тукайга үләргә ярамый», дим.

Мин Казанга барсам, Тукай бардыр, исәндер кебек тоелды. Пароходны сабырсызлык белән көтеп алдым. Казанга килеп төшүгә иң элек каберлеккә киттем. Ул вакыт Тукай кабере капка янында ук, бер калайга «Шагыйрь Габдулла Тукаев» дип язылган иде.

Фатыйх абый янына бардым. Ул да, барып керүгә, йөрәгемне әрнетеп: «Туташ, Тукай үлде бит», диде. Мин: «Шулай икән шул, нигә үтердегез?» — дидем. Ул: «Мин синнән сорыйм, нигә үтердегез?» Мин: «Аны алып калырга аның янында түгел идем бит. Сөйләп-сөйләп тә димли белмәдегез бит», дидем. Ул: «Сезне Тукайга соратып Чистайга хат яздым. Аннан отказ хәбәре килде» дигәч, күзләрем атылып чыгардай булып, Фатыйх абыйга карадым.

Ул Тукайга соратудан соң нинди җавап булуы турында минем хәбәрем бар дип булса кирәк, Вафа өчен тәкъдим ясаган икән.

# «ӘЛЛҮКИ» НИЧЕК ТУГАН?

«Мин кечкенәдән ук җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем».

Г. Тукай

Бөек Ватан сугышына чаклы ук Татарстан Язучылар союзы клубында әдәби җомгалар бик күңелле үтә иде. Ул үзенә яшьләрне генә түгел, өлкән яшьтәгеләрне дә тарта, әдәби җомгаларга барлык язучылар да килә. Кичә бәйрәм төсен ала, зал шыгрым тулы була иде.

Татар халык шагыйре Габдулла Тукай һәм күренекле әдип Фатих Әмирханның якын дусты, хезмәттәшләреннән берсе Вафа Бәхтияров та әдәби җомгага даими йөрүчеләрнең берсе булды. Ул Г. Тукай урамында тора, ә мин аның күршесендә. Ул үзе өлкән яшьтә иде инде. Без Г. Тукай урамыннан язучылар клубына җәяү бергә барабыз, җәяү кайтабыз. Ул миңа «Мөхәммәдия»дә Ф. Әмирханнар белән театр куюлары, «Әльислах» газетасы редакциясендә эшләүләре, «Шәрык» клубындагы кичәләр турында тәфсилләп сөйли. Шулай итеп, ике ара юлны сизми дә кала идек. Мин биредә укучыларга шул истәлекләрнең берсен — бөек шагыйребез Г. Тукай белән турыдан-туры бәйле булганын — тәкъдим итмәкче булам.

«Менә бу — «Шәрык» клубы йорты,— дип башлап китте Вафа абый үзенең сүзен. Бервакыт шуның югары катында кечкенә генә өй мәҗлесе ясадык. Мәҗлестә Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев һәм мин булдым. Әле дә күз алдымда: Г. Тукай, башын бер яккарак салып, акрын тавыш белән бик моңлы итеп, бер-ике җыр башкарды. Без Тукайның болай матур һәм моңлы җырлавына рәхмәт әйтеп кул чаптык. Бераз вакыт үткәч, Сәгыйть Рәмиев, артистларча баскан килеш, көчле тавыш белән бер озын көйгә, аннары кыска көйгә җырлады. Аңа да барыбыз кул чаптык. Шуннан соң Тукай сүзгә кереште:

— Һай, Сәгыйть дус, тавышың көчле, көе матур, тик...

Сәгыйть Тукайга:

— Я, нәрсә «тик»? Әйтеп бетер, «тик» дип эчеңдә калдырма, — дип үпкәле тавыш белән сүз ташлады.

Тукай:

— Алай булса, «тик»не дә әйтәм, син, Сәгыйть дус, кызма да, ачуланма да. Матур җырладың, барыбызның да күңел булды. Тик (ул тагын пауза ясый)...

«Тик» сүзе яңадан кабатлангач, үзсүзле Сәгыйтебез тәмам кызып китте.

— Тагын «тик?» Нәрсә әйтергә телисең соң син? Я, әйтеп бетер!

Мәҗлестәгеләр Сәгыйтьне тынычландырырга тотындылар. Шуннан соң Габдулла Тукай сүзен дәвам итте:

— Сәгыйт дус, жырлавың барыбызга да ошады; көе дә, жырлавың да матур. «Тик» дигәнем шул инде: жырларыңның сүзләрен яратмадым. Син — хөрмәтле мөхәррир, милләтебезнең бай иҗатын беләсен, тик жырлаганда иске мәдрәсә шәкертләренә иярәсен. Милләтебезнең матур жыру көенә:

Калэш-шәйхе фишшифа, дип
Укыганың мантыйкмы?
Ма вөжәтде, валлаһ, җани,
Синнән гайре артыкны,

— дип жырлавыңны «тик» дип әйтәм. Матур жырны бу сүзләр белән пычратма, сүзләрең ямьсез дип әйтүем генә,— дип, Тукай сүзен бетерде.

Сәгыйт Рәмиев:

— Их, Тукай, Тукай! Матур сүз белән жырла дип мине өйрәтәсен. Алай бик күп белсәң, я, миңа матур жырны табып бир әле. Бәлки матур сүзләрне үзең генә сочинять итеп бирерсең, аның исе дә килмәс,— дип мыскыллы көлеп куйды.

Сәгыйт сүзләренә каршы Тукай:

— Я, Сәгыйт дус, шул сүз өчен үпкәләмә инде. Милләтебезнең теле бай, кирәк булса, жырын да, сүзен дә табарбыз,— дип жавап бирде. Шуннан соң Тукай башка темага сүз башлагандай:

— Сәгыйт дус, син иртәгә сәгать уннар тирәсендә «Әльислах»ка минем янга кереп чык әле,— диде.

— Нигә?

— Жыр, сүз табарга кушасың бит. Бәлки мин сиңа жырларга жыр табармын.

Икенче көнне Сәгыйт нәкъ унда минем янга килеп житте.

— Әйдә, Вафа, теге дәрвиш янына кереп чыгыйк әле. Жырлар табам, диде бит. Әгәр тапмаса, өйрәтермен мин аны,— дип, Тукай эшли торган бүлмәгә чакырды.

Без кергәндә, Тукай өстәл артында нәрсәдер укып утыра иде. Тукай, безне күргәч, кинәт урыныннан сикереп торды. Көләч, шатлыклы тавыш белән:

— Ә, Сәгыйт дус, исәнмесез! Әйдә, түргә уз! Әле генә сине, бүген килерме икән, дип уйлап алган идем. Бик яхшы, бик яхшы килдең әле. Менә, Сәгыйт дус, шушы кәгазьне кара әле,— дип, бер бит кәгазь сузды.

Сәгыйт кәгазьне алып эченнән укый башлагач:

— Юк, Сәгыйт дус, син аны шыңшып, жырлап укы! — диде.

Кәгазьдә хәзер инде һәркемгә таныш булган түбәндәге жыр теркәлгән иде:

Ишеттем мин кичә: бераү жырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле,
Әллә нинди зарлы, моңлы көй...

Сәгыйт, кәгазьне укып чыккач, авыз эченнән шыңшып карады һәм, кинәт борылып, Тукайны кочаклап алды.

— Габдулла әфәнде, син мине гафу ит, кичә сине рәнжеттем бугай. Хәзер бу сүзләр белән рәхәтләнеп жырлап булса кирәк,— дип, яңа сүзләр белән кычкырып жырлап жибәрде. Бу — Тукай сүзләренә «Әллүки»нең беренче тапкыр жырлау иде. Шулай итеп, «Әллүки» жыры «Шәрык» клубында беренче, «Әльислах» редакциясендә аны беренче тапкыр жырлап репетиция ясалды,— дип, Вафа абый сүзен бетерде.

Язып алучы ВӘЛИ ХАҖИЕВ.

Мәхмүт Нигъмәтҗанов

# ТИБРӘТМӘКТӘ КҮҢЕЛНЕҢ КЫЛЛАРЫН

Габдулла Тукай чоры бездән еraklашкан саен мәшһүр шагыйребез иҗаты һаман яңа мәгънәви тирәнлекләре белән ачыла бара. Ул иҗат иткән образлар сәнгатьнең яңадан-яңа төрләрендә яшәеш ала. Г. Тукай әсәрләренең яшәү куәте, озын гомерлеге аның иҗатының чын мәгънәдәге бай халыкчан чыганакларга тоташкан булуында, заманның төп прогрессив фикерләрен чагылдыра алуында. Без моны хәзерге татар совет музыкасы мисалында ачык күрәбез. Шагыйребез иҗаты белән илһамланмаган татар композиторы юк дип әйтергә мөмкин. Чыннан да, музыка сәнгатебезнең иң күркәм җимешләре Тукай исеме белән бәйле. Ф. Яруллинның «Шүрәле», Г. Гобәйдуллинның «Кисекбаш», Ә. Бакировның «Су анасы» балетлары, Н. Җиһановның «Кырлай» симфоник поэмасы нәкъ менә Тукай шигъриятендә бөреләнде. С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, З. Хәбибуллин, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, Р. Яхин, А. Монасыйпов җырлары һәм инструменталь әсәрләре дә Тукай шигърияте нигезеннән мәйданга күтәрелде. Мондый музыкаль әсәрләрнең саны йөздән артык исәпләнә. Шагыйрь бу әсәрләрдә композиторлар, башкаручылар һәм тамашачылар белән бергә яши, бергә хисләнә, киләчәккә бер сафта атлый.

Мәгълүм ки, Г. Тукай шигырьләре әле Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк халык көйләренә салына, халык моңнары эчендә яши башлый. Шагыйрьнең «Милли моңнар», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Өзелгән өмит», «Туган тел» әсәрләре халкыбызның «Әллүки», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү» кебек иске көйләренә тирән хисфикерләр салып, аларны яңа эчтәлек белән баета, чын халыкчан, юнәлештә ул көй-моңнарны үз асылларына кайтара. Халык җыры хәзинәсенә кергән ул әсәрләр авылдамы яисә шәһәрдәме булсын — һәр төбәктә сөеп башкарыла, яратып тыңланыла. Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев, Заһид Хәбибуллин, Алмаз Монасыйпов һәм башка композиторларыбыз тарафыннан хор өчен эшкәртелгән җырлар үзенчәлекле милли хор үрнәкләре булып китте. Алар Татарстан җыр һәм бию ансамбле репертуарының алтын фондын тәшкил итә. Концерт залларында, театр сәхнәләрендә Тукай сюжетларына язылган музыка әсәрләре даими яңгырый, аларны Татарстан дәүләт симфоник оркестры, М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры симфоник оркестры, хор коллективлары, һәвәскәр ансамбльләр, аерым җырчылар башкара. Шулай итеп, «Тукай музыкада» дигән тема махсус тикшеренүне таләп итә торган аерым бер фәнни өлкә икәне үзеннән-үзе аңлашылып тора. Һәм бу тема киләчәктә үзенең тикшеренүчеләрен көтә.

Г. Тукайның татар халык иҗатын өйрәнүгә зур өлеш кертүе һәркемгә мәгълүм. Аның халык музыкасы һәм җырлары хакында әйткән фикерләре белгечләр игътибарын күптәннән җәлеп итеп килә. Музыка фольклористикасына ул чыннан да беренче нигез ташларын салучылардан булды. Г. Тукай татар көйләрен ике типка — озын һәм кыска көйләргә бүлеп карый, аларның стиль һәм ритмик төзелешләре үзенчәлекләрен ачыклый, кара-каршы җырлау, җырның ике өлешенә нисбәтле поэтик параллелизм һәм башка хасиятләргә игътибарны юнәлтә. Һәм, ниһаять, нәкъ менә Габдулла Тукай аңа хас зирәклек белән озын татар көен башкарудагы нечкә бер үзенчәлекне тотып ала: «Бездә җырланган чакта тавышның йомшак булуы, вә бераз уен коралы авазына охшашрак булуы, вә иреннәрнең дә мөмкин кадәр аз ачылуы» кулай күрелә,— ди ул. Һәм ул моны татар көенең эчке бер хасиятеннән килә торган күренеш дип аңлау ягында тора. Халкыбыз көйләрен башкару үзенчә-

лекләре бездә әле хәзергә кадәр тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Бу өлкәдә кулга алырлык нинди дә булса фәнни хезмәтне атап әйтүе кыен. Казан дәүләт консерваториясе вокал кафедрасы, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты сәнгать секторы галимнәре башкаручылык сәнгате мәсьәләләрен тикшерүдә кыюсызлык күрсәтәләр. Бу исә республикабызда җыр культурасы, җырчылык сәнгате торышында чагылмый калмый.

Г. Тукай — татар халык җырлары тарихын җыя башлаучы да. «Халык әдәбияты» исемле лекциясендә ул «Тәфтиләү», «Ашказар», «Җизнәкәй», «Касимский Ибрай» һәм башка әсәрләр тарихына кагылышлы кызыклы мәгълүматларны терки, җыр һәм көйләр тарихын җыюның бик кирәкле эш булуын искәртә. Хәлбуки, әле һаман да музыка белгечләребезнең бу өлкәгә кулы тими, җырлар тарихы һәм аларның яшәеш рәвеше даими һәм системалы төстә өйрәнелми диярлек. Хәер, бу юнәлештә бернинди хезмәт тә юк дигән сүз түгел. Мәсәлән, композитор Җ. Фәйзинең 1971 елда Татарстан китап нәшрияты дөньяга чыгарган «Халык җәүһәрләре» китабында күп кенә җырларның легендалары китерелә, теге яки бу җырның кайчан, кайсы төбәктә иҗат ителүе, тарала башлавы күрсәтелә. Әмма ул мәгълүматларны әле көйләрнең фәнни тарихы дип атавы кыен. Чөнки көй тарихын музыканың төрле стильләрен, жанрларын, тарихи-типологик катламнарын системалы өйрәнү аша гына нигезле ачыкларга мөмкин. Юкса, ул еш кына очракта көйнең тууы, яшәве хакындагы легенда булудан узмый, һәрхәлдә, теге яки бу җырның күп төрле яшәеш күренешләреннән берсе булып кына калырга мөмкин. Г. Тукай моны бик яхшы сизеп һәм белеп эш иткән. «Озын вә кыска көйләребез тугрысында халык авызында төрле сүзләр сөйләнә, аның барчасын да җыеп язу шактый озак заман эстидер. Шулай да, сүз арасында, халык авызындагы сүзләрнең үземә ишетелгән кадәресен бераз язып китәргә ярый»,— ди ул.

Әдипнең фәнни таләпчәнлегенә, җаваплылык хисенең уяулыгына сокланмаслык түгел. Әлеге мәгълүматларны «көй тарихы» диюдән бигрәк, «төрле сүзләр» дип кенә атый. Әмма шул ук вакытта алар бүгенге фольклористикабыз өчен кыйммәтле материал булып хезмәт итә.

Халык күңеленең «һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгесе» булган халык җырларын җыю-өйрәнү хакында Г. Тукай әйткән фикерләр фольклористика фәне, музыка белеме өчен принципиаль әһәмияткә ия. «Мәгъмүр Болгар шәһәрләре, болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез «халык шигырьләрен» туплар да ватмады, уклар да кадамады»,— ди әдип. Безнеңчә, шагыйрь вакыттан өстен тора торган халык сәнгатендә, җырмоңнарында борынгы болгар халкы сәнгать традицияләре сакланып килүен искәртә кебек. Шагыйрьнең киң белем даирәсе, гаҗәп бай интуициясе тарихи ретроспективаны тирәнтен сиземләргә мөмкинлек бирә. Иң соңгы фәнни тикшеренүләр нәтиҗәләре сәнгать һәм культура тарихы белгечләрен шундый фикерләргә этәрә һәм бүген инде аны күп яктан дәлилләп була.

Г. Тукайның әдәби-публицистик эшчәнлегеннән музыка тәнкыйте дә читтә калмый. Татар театры аякка баскан, музыкаль тормыш җанлана башлаган чорда ул алдынгы эстетик позицияләрдән торып, яшь сәнгатебезнең халыкчан үсентеләрен кайнар рәвештә яклап чыга, шушы үзәк юлдан читкә тайпылучыларны, түбән зәвыкле әсәрләрне таратып, мещанлык стихиясенә куәт бирүчеләрне зәһәр тәнкыйтькә дучар итә. Әдипнең матбугаттагы чыгышлары арасында без татарлардан Фәттах Латыйпов, Камил Мотыйгый кебек беренче профессиональ җырчылар, «Шәрык» клубы каршындагы кыллы музыка кораллары оркестры һәм аерым музыкантларның башкару осталыклары, репертуары, иҗат йөзләре хакында гаҗәеп үткен күзәтүләрне очратабыз. Татар көйләре язылган граммофон пластинкаларын да ул, күбесенчә, коммерция максатларында чыгарылган вульгар язмалар буларак, ачы тәнкыйтьли. «Милләтебез диңгезенең энҗеләре төптә ятып, «ул-бу»лары гына өскә калка шул...» — дип яза әдип.

Г. Тукайның халык җыры, музыка сәнгате хакындагы фикерләре бүген дә актуальлеген югалтмаган. Аның идея-эстетик позициясе, үз халкына киң эстетик тәрбия бирү теләге белән янып яшәве, даими төстә халык мәнфәгатен кайгырта белүе,— барысы да чорыбыз әдипләре, тәнкыйтьчеләре өчен үрнәк булып тора.

Якыннанрак, җентекләбрәк карaганда, шагыйрьнең музыкаль зәвыгы нинди булган, ул нинди көйләрне аеруча яраткан икән? Мондый сорау аерым бер мәгънәгә ия булса кирәк. Мөһим тарихи чорларның идея-эстетик тәҗрибәсен туплаган башка эшлекләләр кебек үк, Тукай иҗаты гаять күпкырлы һәм гыйбрәтле. Ул бер бөтенне тәшкил итә һәм Г. Тукайның музыка өлкәсендәге «симпатияләре» һәм «антипатияләре» бердәм эстетик системага нигезләнә.

Мәгълүм булганча, шагыйрь халыкның түбән катлаулары арасында үсә, хезмәт халкы моңнарын, музыкаль фольклор традицияләрен күңеленә сеңдерә.

1905 ел революциясеннән соң татарларда музыка сәнгате чагыштырмача кызурак темпта үсә. Көнкүрешкә рус, Европа музыкасы, революцион эчтәлекле җырлар үтеп керә, яшьләрнең музыкаль зәвыклары төрләнә, музыкаль тормыштагы яңа күренешләргә бәя бирергә, үсү юнәлешләрен билгеләргә кирәк була. Г. Тукай, халык иҗатына таянган хәлдә, хезмәт иясе халыкның, алдынгы интеллигенциянең эстетик позицияләрен формалаштыруда, матбугат битләрендә чагылдыруда турыдантуры катнаша. Монда аңа, әлбәттә, аның бай табигате, күпкырлы таланты да ярдәмгә килә. Бала чагыннан ук ул җырларны күп белүе, моңлы итеп башкаруы белән аерылып тора. «Мәдрәсәдә үк мине җырчы диләр иде», — дип яза ул. Шагыйрьнең җитлегү чорында музыкаль тормыш шактый чуар булган. Көнкүрештә бер-берсенә төрлечә йогынты ясап, берничә музыкаль катлам янәшә яши: традицион крестьян җырлары; татар, рус һәм башка көйләр элементлары бергә үрелүдән туган шәһәр көйләре; дини йолалар белән бәйле мөнәҗәтләр һ. б. Үзенең демократик теләк-омтылышларына нисбәтән, Г. Тукай, бер яктан, халык хиссиятен чагылдыра торган традицион милли көйләргә, икенче яктан, шәһәрнең үсеп килә торган демократик музыка сәнгатенә йөз тота. Әдипнең рус классик музыка хәзинәләре белән кызыксынуы да мәгълүм. Ул, мәсәлән, П. И. Чайковскийның «Евгений Онегин» операсын югары бәяли, опера сәнгатендә хәбәрдарлыгы аз булуына пошына.

Шагыйрь озын көйләрдән «Әллүки», «Зиләйлүк», «Ашказар», «Сакмар су» кебек әсәрләрне аеруча якын кабул итә, башкарак типтагы «Түмән көе», «Тәфтиләү», «Сүнгән дәрт», «Әтнә», «Әй дуслар, мал кайда» һ. б. җырлар да күңеленә хуш килә. Болар барысы да Г. Тукайның музыкаль-эстетик зәвыгы киң булуы хакында сөйли. Һәм, әйтергә кирәк, аның зәвыгы вакыт сынавын уңышлы үтте: шагыйрь яраткан җырлар бүген милли музыкабызның асыл фондын тәшкил итә һәм Ватаныбыз халыклары хәзинәсенә халкыбыз керткән өлеш булып та тора.

Үз заманының җырчылары арасыннан Г. Тукай Фәттах Латыйпов кебек саф халыкчан моң белән җырлаучыларны өстен күрә, аларның репертуарын милли көйләр «диңгезендәге энҗеләр» дип атый. Егерменче йөз башларында модага кереп, пластинкаларга язылып киң тарала башлаган сай эчтәлекле җырларны пропагандалауга ул милли сәнгатьне бозу, халыкның эстетик хисләрен кимсетү дип карый. Традицион музыкаль фольклорны яклавы белән Г. Тукай музыка чаралары, музыка сәнгате теленең чисталыгы өчен көрәшә. Шагыйрьнең бу фикерләре дә бүген актуальлеген югалтмаган. Кайбер яшь композиторларыбызның халыкчан традицияләрдән бигрәк, шәрык аһәңнәре белән мавыгулары, Европа ритмнарын талымсыз куллану очраклары күңелдә ризасызлык хисе кузгата. (Монда сүз милли музыкабызны, С. Сәйдәшев, З. Хәбибуллин иҗатындагыча, тирән һәм табигый рәвештә баеткан әсәрләр хакында бармый, әлбәттә. Аларның тәҗрибәсе, киресенчә, музыка сәнгатебезне тугандаш халыкларның музыка хәзинәләре хисабына үстерү юлындагы зур мөмкинлекләр хакында сөйли.) Күргәнебезчә, Г. Тукайның халык музыкасына мөнәсәбәте аның идея-эстетик карашларының аерылгысыз бер өлешен тәшкил итә. Тукай һәм татар музыкасы күпкырлы һәм катлаулы тема ул. Аны без шагыйрьнең халык җырына мөнәсәбәте, Тукай тормышында музыканың нинди урын тотуы, аның шигъриятенең музыкальлеге җәһәтеннән дә өйрәнергә бурычлы[1]. Без исә биредә атаклы шагыйребезнең музыка өлкәсендәге карашлары, бүгенге музыка сәнгатебез үсеше өчен әһәмияте булган эстетик омтылышлары мәсьәләләренә генә игътибарны юнәлтергә тырыштык. Болар киләчәк тикшеренүләрдә һичшиксез киңрәк яктыртылыр, музыка тормышыбызның хәзерге ихтыяҗлары белән бәйләнештә гәүдәләндерелер дип ышанырга кирәк.

[1] Композитор Җ. Фәйзинең «Габдулла Тукай һәм музыка» исемле мәкаләсе бүген дә шушы темага багышланган иң җитди хезмәт булып кала. Кара: «Совет әдәбияты» журналы, 1943 ел, 4 сан.

**Роберт Бикмөхәммәтов**

# ТАТАР ПРОЗАСЫНДА ЭШЧЕ ОБРАЗЫ

Хәзерге татар әдәбиятындагы эшче образы турында фикер йөртү, гомумән, әдәбиятыбызның төп үзенчәлекләрен, үсеш перспективаларын ачыклау белән бәйләнгән. Татар язучыларының чорыбыз өчен аеруча зур әһәмияткә ия булган, эшчеләр темасы һәм бүгенге производство казанышлары белән даими кызыксынулары бик табигый.

Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, Ә. Баянов, Ш. Бикчурин, А. Расих, Ә. Еники кебек әдипләрнең роман һәм повестьлары эшчеләр турындагы совет прозасы китапханәсен шактый нык тулыландыралар. Э. Касыймов, М. Хәсәнов, М. Хәбибуллин, М. Зарипов, Д. Вәлиев әсәрләре дә хаклы кызыксыну тудыра. Эшче проблематикасына шундый зур игътибар иң беренче нәүбәттә хәзерге татар әдәбиятының үзенчәлегенә, аның үзенә бер төрле идея-әхлакый җирлегенә, социаль-аналитик эзләнүләренә бәйле.

Эшчеләр темасын яктырткан татар прозасының үсеш юлы, аның казанышлары һәм кимчелекләре, гомумән, әдәбиятыбыз эволюциясе белән дә тыгыз бәйләнештә. Бу темага багышланган прозабызга бәя биргәндә аның күп миллэтле совет әдәбиятында үзенчәлекле бер урын алып торуын да истән чыгарырга ярамас.

Партиянең XXV съездында иптәш Л. И. Брежнев производство темасы турында болай диде: «Хәзер бу тема чын художество формасы алды». Чынлап та, күп милләтле совет әдәбиятында җитлеккән социалистик җәмгыять төзүче хезмәт кешесе образларыннан тулы бер галерея тудырылды. Моңа татар язучылары да мул өлеш кертәләр. Шофер һәм предприятие җитәкчесе, слесарь һәм лаборатория башлыгы, скважиналар бораулаучы һәм завод директоры, бөек төзелештә эшләүче баш инженер, балта остасы һәм мехчы, бетон коючы һәм фән-техника революциясенең яңа офыкларын ачучы галим хезмәте укучы өчен бер үк дәрәҗәдә якын һәм кызыклы. Кара алтыны һәм бөек төзелешләре белән данлы Татарстан эшчеләре турында язылган әсәрләр күп милләтле совет әдәбиятында ныклы урын алдылар. Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романындагы Уразмәтовлар династиясе, Журбиннар (В. Кочетовның «Журбиннар» әсәре) яки Рудаевлар династиясе (В. Поповның «Бу да гадәти эш көне» әсәре) белән янәшә тора. Г. Ахуновның «Хәзинә»сеннән Лотфулла Дияров, Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романыннан Фәез Насыйбуллин, Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар»ыннан Ишморза Уразмәтов, Ш. Бикчуринның «Каты токым» китабыннан Фазыл Зөбәеров образлары туган илебезнең эшчеләр сыйныфы турындагы карашларыбызны бермә-бер киңәйтә һәм тулыландыра төшәләр. Татар прозаиклары иҗат иткән бу геройлар В. Кожевников, В. Липатов, Г. Пенджикидзе, М. Колесников, Ә. Мохтар, М. Траат, П. Загребельный, В. Бубнис тарафыннан тудырылган образларга аһәңдәш. Әлеге проза китапларында, шулай ук А. Гельман, И. Дворецкий һәм татар драматургы Д. Вәлиев пьесаларында без чорыбызның төп геройларын очратабыз.

Партиянең XXV съездында иптәш Л. И. Брежнев әдәбият һәм сәнгатьнең бурычлары турында сөйләгәндә, иҗат интеллигенциясе «коммунистик җәмгыять төзелеше-

нең гомумпартия, гомумхалык эшенә һаман күбрәк өлеш кертә» дип күрсәтеп узды. Бу сүзләр совет әдәбиятының шактый зур иҗади көчләреннән саналган Татарстан язучылар оешмасына да тулысынча кагыла.

Җитлеккән социализм әдәбияты хәзерге иҗтимагый үсеш характеры, фән-техника революциясенең масштаблары киңәю, социалистик демократиянең тирәнәюе, замандашыбызның рухи потенциалы үсү белән билгеләнә. Җәмгыятебезнең бу әһәмиятле үзенчәлекләре яңа Конституциядә закон тәртибендә беркетелде. Бу зур документта бүгенге көн казанышлары гына теркәлеп калмады, ә шулай ук безне киләчәккә илтү юллары да билгеләнгән. Гомумән, Конституциядәге байтак статьялар әлеге сөйләшүгә турыдан-туры мөнәсәбәттә тора.

Профсоюзларның XVI съездында, партия Үзәк Комитетының 1977 елгы май Пленумында иптәш Л. И. Брежнев ясаган чыгышларда илебезнең тарихи эволюциясе тәҗрибәсен гомумиләштерүче мөһим положениеләр бар. КПСС Үзәк Комитетының Бөек Октябрьның 60 еллыгы турындагы карарында илебездә булып узган зур тарихи үзгәрешләргә тирән анализ ясалды. Ул бөек үзгәрешләр совет чынбарлыгыннан илһам алып үсә барган татар әдәбиятында да киң чагылыш тапты.

Хәзерге татар әдәбияты, шул җөмләдән прозасы да, үзенең рухи-әхлакый эзләнүләрендә югары гражданлылыгы белән аерылып тора. Аңа олы җаваплылык һәм партиялелек хас. Әдәбиятыбызның халык тормышының киң панорамасын тудыруга омтылышы шуның белән аңлатыла. Хәзерге заманда халыкчанлык төшенчәсе яңача яңгыраш тапты. Әдипнең социаль-фәлсәфи фикере аерата зур әһәмият алды. Хезмәт кешесе образын һәм аның рухи-әхлакый сыйфатларын киң планда күрсәтү әдәбиятның үзәк проблемасына әверелде. Тормышны алга әйдәп баручы замандашыбызның, җәмгыять белән тыгыз мөнәсәбәттә торучы шәхеснең эчке дөньясы һаман да тирәнрәк һәм масштаблырак итеп үзләштерелә.

60—70 нче еллар татар прозасы тематик яктан киңәйде һәм төрләнде. Бу исә чынбарлык полифониясе, халык туплаган зур тәҗрибә белән аңлатыла. Реаль тормышны үзенең барлык күренешләре һәм төп сыйфатлары белән колачлап алырга, хәзерге чынбарлыкны калку һәм тирән итеп күрсәтергә, заман рухына аһәңдәш образлар тудырырга омтылулар да тематиканы бермә-бер баета төшә. Әдәбият бердәм, тыгыз организм ул. Анда тема һәм стиль агымнары бер-берләрен баета. Әйтик, Г. Ахунов һәм Г. Әпсәләмовның иҗтимагый яктан ярсу темпераменты А. Гыйләҗев һәм Ә. Баяновның фәлсәфи-художество эзләнүләре белән кушыла. Иҗат юнәлешләренең күп тармаклы булуы — әдәбиятыбызның мөһим казанышы. Иҗтимагый үсеш закончалыкларын, замандашыбызның интернациональ характерын өйрәнү әүвәлгечә төп юнәлеш булып кала. Иң беренче нәүбәттә кешелеклелек мөнәсәбәтләре күздә тотыла. Язучы совет кешесенең социаль һәм әхлакый, рухи һәм иҗтимагый сыйфатларын ачып бирүне төп максат итеп куя.

Соңгы егерме еллар татар прозасына эшче образын Ә. Еники белән Г. Әпсәләмов алып керде («Вөҗдан», «Сүнмәс утлар» әсәрләре). Иҗтимагый-политик тормыш, әдәбият һәм сәнгатьнең яңа югарылыкка күтәрелеш елларында язылган бу китаплар яңа дәверне башлап җибәрделәр. Шул ук вакытта аларда иҗади традиция һәм әдәби үсеш дәвамчанлыгы да бик ачык чагылды. Җитлеккән социализм әдәбияты үзеннән әүвәлге әдәбияттан шактый аермалы. Ул проблематикасы, поэтикасы белән дә, художество процессының характеры белән дә бөтенләй яңа һәм үзгә. Әмма әдәбият, шул җөмләдән проза, үткәннең иң матур традицияләрен үзенә мирас итеп ала. Татар әдәбияты да үз традицияләренә, рус һәм күп милләтле бөтен илебез әдәбиятлары традицияләренә таянып эш итә, революциягә кадәрге классика тәҗрибәсен иҗади үзләштерә.

«Вөҗдан» һәм «Сүнмәс утлар» — шушы эзләнүләр нәтиҗәсендә туган әсәрләр. Аларда художникның индивидуальлеге киң планда күренә. Мәгълүм ки, зур талантка һәм кабатланмас үзенчәлеккә ия булган язучы гына бөтен совет әдәбиятында лаеклы урын алырлык, әдәби процесста тирән эз калдырырлык әсәрләр иҗат итә ала. Г. Ахуновның «Хәзинә», Ә. Баяновның «Ут һәм Су», Ш. Бикчуринның «Каты токым» романнары шундыйлар рәтенә керә. А. Расихның «Дустым Мансур», Э. Касыймовның «Томан аша», М. Хәсәновның «Кама таңнары», Р. Төхфәтуллинның «Агымсу», М. Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да...», М. Зариповның «Квартирага ордер»

исемле китаплары да талант һәм индивидуальлекнең органик бердәмлегендә язылган әсәрләр.

Заман герое характерының төп сыйфатларын ачып бирүдә татар прозаикларының актив эшләве ил күләмендә билгеле. Бу җәһәттән әдәбиятыбызның башка жанрларында ирешелгән уңышларны да билгеләп үтү кирәктер. Аерым алганда, Д. Вәлиевнең киң танылган драма әсәре һәм С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы» поэмасы шулай ук илкүләм әһәмияткә ия.

Күп милләтле совет әдәбияты тарихыннан күренгәнчә, барлык милли әдәбиятлар да тигез адымнар белән генә үсмиләр. Бу уңай белән Е. Книпович фикере игътибарга лаек. Ул болай ди: милли культуралар үсешендә «кайсыдыр бер мизгелдә сикереш ясала, теге яки бу төркем алга атылып чыга — республикалардан берсенең «чәчәк ату чоры» башлана»[1]. Әдәби үсеш процессында я бер әдәбиятның, я икенчесенең билгеле бер дәрәҗәдә алга чыгуы мәсьәләсендә ул хаклы, әлбәттә. Е. Книпович монда литва прозасының чәчәк атуы һәм башка әдәбиятларга йогынтысы турында яза (И. Авижюсның «Югалган йорт-җир», Ю. Марцинкявичусның «Көлүче нарат» исемле әсәрләре).

Илебез әдәбиятлары үсешенең гомуми законы — үзара якынаю һәм чәчәк ату, үзара якынаю аркылы чәчәк ату, чәчәк ату аркылы үзара якынаю законы татар әдәбияты мисалында да киң чагыла. Милли үзенчәлеккә ия сыйфатларны гәүдәләндерү, эшче темасын үзләштерүдәге уңышлар тагы бер кат бөтен совет әдәбиятының гомуми нигезләре ныгый баруын раслый. Гомумән, барлык әһәмиятле юнәлешләрдә — заман, тарих темасын ачып бирүдә, милли характерлар тудыруда яңа уңышларга ирешә барып, татар әдәбияты үзенчәлекле һәм бай әдәбиятка әверелде. Бер үк вакытта бу процесс социалистик реализм методы мөмкинлекләреннән һаман да тулырак файдалануга, партиялелек һәм коммунистик идеялелек принциплары ныгуга, татар әдәбиятының рус һәм башка халыклар әдәбияты белән үзара якынаюына алып килә. Татар әдәбияты үсешендә бөтен совет әдәбиятына хас гомуми сыйфатлар һаман да ачыграк гәүдәләнә. Аның нигезе шунда: илебездә яңа тарихи гомумилек — совет халкы барлыкка килде. Шуңа да эшчеләр сыйныфы темасына язылган татар прозасы һәм гомумән әдәбияты интернационализм пафосы белән сугарылган.

Сүз татар язучыларының хәзерге заман эшчеләр тормышы белән җитди кызыксынуы турында барганда бер факт игътибарны җәлеп итә. Татар әдәбиятында саф «авыл» яки «производство» язучылары юк. Татар совет әдәбиятына нигез салган Ш. Камал, Г. Ибраһимов һәм Ф. Әмирханнар кебек, бүгенге татар прозаиклары да күп төрле тема һәм проблемалар өстендә уйланалар; аларның уй-фикерләре халык, ил язмышына юнәлгән. Мисалга эшче темасына аеруча актив эшләгән авторларны алыйк. Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романында төп игътибар производство темасына бирелсә, шул ук авторның «Газинур» һәм «Ак чәчәкләр»ендә инде сүз сугыштагы батырлык һәм врачлар хезмәте турында бара. Г. Ахунов нефтьчеләр тормышыннан язылган «Хәзинә» романыннан соң, совет властен урнаштыру өчен барган көрәшне яктырткан «Идел кызы» романын язарга кереште. Ә. Баянов «Яшьлегемне эзлим» исемле лирик повестьтан соң «Ут һәм Су» романын иҗат итте. Әсәр ГЭС төзелешендә эшләүче ике инженер арасындагы конфликтка корылган. Күп тә үтмәде, автор «Төлке тоту кыен түгел» дигән яңа әсәре белән чыкты. Бу әсәрендә инде язучы шагыйранә йөрәкле авыл картының характерын, авылда социализм төзелешендә бу герой үткән катлаулы юлның тирән мәгънәсен бөтен нечкәлеге белән ачып бирә. А. Расих, Э. Касыймов, М. Хәбибуллин кебек эшче темасына язучыларның да проблемалар диапазоны шактый ук киң. Үз чиратында «авыл темасы» осталары — әйтик, Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев — ГЭС төзелеше турында, инженер хезмәте турында язалар (Р. Төхфәтуллинның «Агымсу», А. Гыйләҗевнең «Зәй энҗеләре» китаплары). Шунысы кызыклы, нефтьчеләр турындагы беренче очеркларны, моннан егерме еллар элек, шагыйрь Ш. Маннур, ә КамАЗ турындагы беренче лиро-эпик әсәрне — «Дәверләр капкасы» поэмасын шагыйрь С. Хәким язып чыкты. Бүгенге көн үзәгендә торган проблемаларга кискен йөз тоту иң әүвәл Г. Бәширов, И. Гази, Ф. Хөсни, М. Әмир, А. Расих кебек өлкән буын әдипләр прозасында сиземләнде.

[1] Е. Книпович. Художник һәм тарих. Мәкаләләр. М., «Советский писатель», 1968, 192 бит.

Шушы кыскача күзәтеп чыгу үзе генә дә татар прозасында заман проблемаларының киң планлы һәм масштаблы үзләштерелүен раслый. Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, Ш. Бикчурин, А. Расих, М. Хәбибуллин, Ә. Баянов эшче темасын совет халкының социаль-сыйнфый үзгәрешләре белән тыгыз бәйләнештә хәл итәләр. Бу исә эшче кешенең бүгенге чынбарлыкта тоткан урыны белән билгеләнә. Табигый ки, социаль яктан киң нигезләнгән бу позиция зур культуралылыкны, масштаблы фикер йөртү һәм совет әдәбиятының бөтен художество тәҗрибәсенә нигезләнүне таләп итә. Эшче темасы — халык, ил һәм кешелек дөньясы язмышын аңлатып бирү ачкычларыннан берсе ул. Хәзерге этапта — совет җәмгыятенең социаль бертөрлелеге үскән, гомумхалык дәүләте чәчәк аткан, социалистик демократия киңәйгән чорда — барлык тема һәм проблемаларның үзара бәйләнеше тагын да ачыграк чагыла. Татар прозасы җәмгыять һәм халыкның күтәрелү юлын, татар милләтенең социалистик узаңы үсешен тирәнтен анализлый. Социаль масштаблылык фәлсәфи фикерләр тирәнлеген, сәнгатьчә камиллекне таләп итә.

Татар прозасы беркайчан да фәкать техник прогрессны күрсәтү белән генә мавыкмады. Аның социаль-аналитик яктан җитлеккәнлеге дә әнә шунда. Ә инде Чешков тибындагы геройлар һәр вакыт ачыктан-ачык каршы тәэсир, ризасызлык тудыралар. Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романында участок начальнигы Борис Филинов кебек шундый типларга каршы көрәш яктыртыла. Хәер, бер карашка алар үзләрен хаклы дип саныйлар, эшне җайга салу өчен тырышып йөриләр. Шул ук вакытта алар кешеләргә, табигатькә карата салкын канлы, битараф. Әсәр Филинов кебекләр белән ышандырырлык бәхәскә корылган. Андыйларга каршы һәм аларны дөрес юлга бастыру өчен көрәшергә кирәк. Автор социалистик гуманизм идеалларын югары күтәрә, табигатьне яклап чыга, кеше күңеленең сафлыгы өчен көрәшә. Шулай ук Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, Ш. Бикчурин, Э. Касыймов, М. Хәбибуллин, Д. Вәлиевларны да техника мәсьәләләре генә кызыксындырмый, алар мөһим сорауларга җавап бирергә омтылалар. Әйтик, совет кешесенең тарихи новаторлыгы нидән гыйбарәт; киләчәктә ул нинди булачак; Татарстанда фән-техника революциясе процессы ничек бара; татар эшчеләр сыйныфы нинди үзгәрешләргә дучар булды?

Бу сорауларга беренчеләрдән булып Ә. Еники белән Г. Әпсәләмов җавап бирергә омтылыш ясадылар. Алар үз алларына куйган проблеманы төрле индивидуаль яссылыкта, классик үрнәкләргә таянып хәл иттеләр. Ә. Еникинең «Вөҗдан» повестенда һәм бигрәк тә Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романында производство үз традициясе, үз атмосферасы, үз тормыш рәвеше булган үзенә бер төрле дөнья итеп тасвирланды. Бу әсәрләрнең һәр икесендә технологияне камилләштерү өчен көрәш беренче планга куелды һәм ул көрәш гаилә-көнкүреш линияләре белән бергә үрелгән иде.

Туган илебез күләмендә киң яңгыраш алган В. Кочетовның «Журбиннар», Г. Николаеваның «Юлда көрәш» тибындагы романнарга алмашка соңгы егерме еллар эчендә яңа типтагы әсәрләр килде. Аларда производство, технологик планда алганда да, сюжет-композиция үстерелеше белән дә, илебез һәм халкыбыз тормышының иҗтимагый-экономик үсешебезнең органик өлеше итеп карала. Мондый типтагы роман һәм повестьларда бик әһәмиятле иҗтимагый-политик, социаль һәм рухи-әхлакый проблемалар алга куела. Бу әсәрләр совет эшчеләр сыйныфының узаңы формалашу процессын күрсәтү өлкәсендә яңа иҗтимагый-идеологик баскычка күтәрелделәр.

Шул җәһәттән Г. Ахуновның «Хәзинә» романына тукталып узыйк. Әсәрдә Татарстанда соңгы унъеллыклар эчендә барлыкка килгән социаль, әхлакый үзгәрешләр күрсәтелә. Автор нефть һәм газ, бөек төзелешләр республикасы турында традицион крестьян темасы белән тыгыз бәйләнештә язарга мөмкин булуын исбат итте. «Хәзинә» авыл, гомумән республика тормышын тамырдан үзгәрткән куәтле нефть индустриясен әдәбиятта чагылдыруның яңа эпохасын башлап җибәрде. Әсәрнең төп темасы — ата-бабалар васыятенә тугры булып калган һәм үзе үзгәргән, бер үк вакытта тормышны да үзгәрткән халык. Нефтьчеләр темасы халыкның үткән тормышын бүгенге көн белән бәйләүнең яңа мөмкинлекләрен ачты. Әсәр традицион художество алымнары белән язылса да, күтәргән тормыш проблематикасы белән яңа. Бу исә чынбарлыктан килә.

Эшче темасына язучы авторлар, сурәтләү объектларының уртаклыгына һәм иҗат позицияләренең үзара якын булуына да карамастан, бер-берләреннән нык аерылалар. Г. Ахунов зур проблемалар белән янып яши. Аны крестьяннар, эшчеләр сыйныфы һәм интеллигенция язмышы борчый. Шуңа да әдип әдәби традицияләргә тугры — эчке халәте һәм рухы белән Ш. Камал, Г. Бәширов, И. Газиның эпик традицияләренә якын тора. Бу фикерне А. Расихка карата да әйтергә мөмкин. Ул «Дустым Мансур» романында, классика үрнәкләрен файдаланып, авыл егетенең эшчеләр коллективына килеп керүен тасвирлады. А. Расих үз әсәрендә үткәнне чагылдырса, Г. Ахунов исә үткән белән бүгенгене бергә бәйләп бирә. Г. Ахуновның новаторлык җирлеге әнә шунда.

Ш. Бикчурин үзенең иҗади эзләнүләрендә күпмедер дәрәҗәдә Г. Ахуновка якын тора. «Хәзинә»дә бораулаучылар коллективында урнашкан дуслыкны күрсәтүгә шактый зур урын бирелгән — аларны хезмәт бергә туплый, хезмәт яңа җиңүләргә әтәрә. Ш. Бикчурин исә эшчеләр арасындагы олы дуслыкны тасвирлауга тулы бер роман багышлаган. Анда төрле характерлы кешеләрдән бердәм интернациональ коллектив оешуы күрсәтелә. Әсәр күләме белән зур түгел, әмма үз эченә бик күп язмышларны сыйдырган. Әсәрне укыганда күз алдыбызга якты буяуларга, кояш нурларына бай, җанлы ил тормышы килеп баса. Шул рәвешчә, Ш. Бикчурин да, Г. Ахунов кебек үк, халыкны үсештә, хәрәкәттә күрсәтү юлыннан атлый.

Укучы Г. Ахунов, Ш. Бикчурин, А. Расих әсәрләрендә образларга бай дөньяга килеп керсә, тиз арада барлык персонажлар белән дә танышырга өлгерсә, Ә. Баянов китапларын кулына алгач, ул бер, сирәк очракта — ике герой язмышына юлыга. Әсәрләренең бөтен тукымасын автор — «Ут һәм Су»дагы Фәез Насыйбуллин булсынмы, яки «Төлке тоту кыен түгел» повестендагы Тата карт булсынмы — үзе яраткан образны тасвирлауга кора. Ә. Баянов әсәрләренең сюжет-композиция төзелеше, стиль үзенчәлекләре Ахунов яки Бикчурин романнарыннан бөтенләй үзгә. Автор шул ук теманы — җәмгыять һәм эшчеләр сыйныфы, заман һәм шәхес проблемасын бөтенләй башка яссылыкта хәл итә. Әдипне әхлакый проблемалар, заман образы, яңа дөнья кешесе формалашу процессында килеп туа торган рухи һәм этик конфликтлар дулкынландыра. Авторның вакыйгаларга караганда геройның эчке дөньясын тасвирлауга күбрәк игътибар бирүе, метафорик стильгә, образ-символларга мөрәҗәгать итүе дә шуның белән аңлатыла. Композиция коруда, образлар тудыруда ул башкаларны кабатламый, тел-сурәтләү чараларын файдалануның яңа мөмкинлекләрен ача.

Ә. Баяновны изгелек һәм явызлык, кешеләргә ышаныч һәм аларга битарафлык мәсьәләсе борчый. Шул ук вакытта аның олы мәхәббәт темасына да игътибары зур. Әсәрдә Фәез Насыйбуллин белән янәшә сылу Кама-Камилә образы җылы хис белән сурәтләнә. Ярларында зур төзелеш барган Кама елгасының гүзәллеге, нәфислеге бирелә бу образ аша. Вакыйгалар тезмәсе авторга менә шушы ике геройның характеры һәм дөньяга карашы формалашуны калку итеп күрсәтергә мөмкинлек бирә. Ә. Баянов «авыл» прозасы, бигрәк тә А. Гыйләҗев, Ә. Еники һәм Р. Төхфәтуллиннар прозасының бөтен әхлакый атмосферасын, масштаблылыгын һәм киңлеген эшчеләр мохитына алып керә. Әдипнең бу алымы отышлы: әхлакый, рухи проблематика яңа киңлеккә чыга, гүя ки ул заманны бөтен тулылыгы белән колачлап ала.

Күрүебезчә, татар прозасында эшче образы төрле яссылыкта — иҗтимагый-социаль, рухи-әхлакый аспектларда сурәтләнә. Эшче темасы М. Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да...», М. Хәсәновның «Юллар, юллар», М. Зариповның «Квартирага ордер» повестьларында тагын да үстерелә һәм киңәйтелә. Әмма әлеге әсәрләр күтәргән проблемалары, аларның характеры, язучының индивидуаль иҗат алымы белән генә түгел, шулай ук сәнгатьчә эшләнешләре, камиллек дәрәҗәсе, тәгәлләнгән булу-булмаулары белән дә башкалардан нык аерылып торалар.

Аларның авторларына үз-үзләренә таләпчәнлек җитми кебек. Әмма хикмәт анда гына да түгел. Үй-фикерләре белән дә, күтәргән проблемалары белән дә көн кадагына суккан байтак әсәрләр ни өчен соң еш кына сәнгатьчә гәүдәләнә алмый? Тәнкыйтьчеләр моны гадәттә түбәндәгечә аңлата: әдәби әсәрләрнең дәрәҗәсе төрле булу авторларның чынбарлыкны төрлечә үзләштерүләреннән килә. Мәсәлән, «Эшче

рухы» дигән мәкаләсендә Ф. Хатипов[1] М. Хәсәновның «Кама таңнары» һәм М. Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да...» китапларындагы кимчелекле якларны авторларның тормыш һәм производствоны, хәзерге техника һәм технологияне начар белүләренә бәйләп аңлатырга тырыша.

Әлбәттә, тормышны тәпле белергә, производствоны җентекләп үзләштерергә һәм аны матур әдәбиятта дөрес сурәтләргә кирәк. Ләкин М. Хәсәнов һәм М. Хәбибуллин әсәрләренең художество дәрәҗәсе тормышны һәм производствоны белмәүгә бәйләнмәгән. Шулай ук Г. Ахунов белән Ә. Баяновны, Ш. Бикчурин белән М. Зариповны, Г. Әпсәләмов белән Э. Касыймовны да тормышны һәм производствоны төшенеп җитмәүдә гаепләп булмый. Ә инде язучы хезмәтенә бәя биргәндә моны бердәнбер яки төп критерий дип санау игътибарны бөтенләй читкә алып китә, әсәрнең художество ягын онытуга китерә. Әдипнең уңышы, әлбәттә, беренче чиратта, тормышны белү белән билгеләнә, ләкин әсәр гражданлык рухы, югары идеялелек белән сугарылырга, художникның таләпчәнлегенә нигезләнергә һәм иң мөһиме — аның эзләнүчән, социаль-актив фикер йөртүенә таянырга тиеш.

Чынбарлыкны үзләштерү сәнгатьчә камиллеккә омтылганда гына уңай нәтиҗә бирә. Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында, съезд материалларында урта кул әсәрләргә каршы, художество камиллегенә ирешү өчен көрәш төп бурыч итеп билгеләнде, халык казанышы булган талантның әһәмиятенә югары бәя бирелде. Тәнкыйть теге яисә бу әсәргә һәм әдәби процесска сәнгатьчә камиллек мәсьәләләренә җитди игътибар иткәндә генә дөрес бәя бирә ала.

Соңгы елларда Э. Касыймовның «Томан аша» һәм «Һаваларда тургай» дилогиясе турында күп язылды, аның очланып бетмәве, таркау һәм сүлпәнлеге, төп конфликтның ачылып җитмәве турында әйтелде. Әмма әсәрдәге бу кимчелекле якларны язучының химия заводлары эшен йомшак өйрәнүе белән аңлатырга тырышу нигезсез. Әсәр белән ныклап танышу моның киресен раслый: автор нефтьчеләр турында язу өчен дә бик җентекләп һәм тәпле әзерләнгән. Вакыйгалар агышындагы сүлпәнлекне производство конфликтының (җир астындагы тозлы сулардан бик файдалы һәм арзан эремәләр аерып алу процессының) бик озынга сузылуы белән аңлату да бәхәсле. Производство технологиясен тасвирлау геройларны киң планда күрсәтергә мөмкинлек бирә икән, әсәрнең озынга сузылуыннан һич куркырга ярамый! Кыскасы, автор үзенә тиешлене яхшы белә, тормыш тәҗрибәсе дә җитәрлек. Димәк, әсәрнең кимчелеге монда түгел.

«Производство-технология» пәрдәсен ачып, әсәрнең бөтен тукымасына күз салганда, мәсьәлә ачыклана кебек. Асылда, Э. Касыймов романы, Ф. Хатипов уйлаганча, гипосульфит, йод һәм бром проблемасын сурәтләүгә корылмаган. Г. Ахунов романы да скважинадагы авария, Ә. Баяновның «Ут һәм Су» китабы да шлюз һәм кешеләр имгәнүе турында түгел. Ш. Бикчурин романында да сүз скважиналарны авыш бораулау турында бармый. Бу әсәрләрнең бөтенесе, шул җөмләдән «Томан аша» китабы да, эшчеләр сыйныфы турында, аларда хезмәт халкы тормышы гәүдәләнеш тапкан.

Талантлы язучы Э. Касыймов тормышны кирәгеннән артык киңрәк, панорамалырак күрсәтергә омтылуы белән шактый оттырган. Ул тормышның табигый агышын тудыруны төп максат итеп куйган. Беренче карашка хикәяләүдәге сүлпәнлек геройларның, вакыйгаларның үзара тыгыз бәйләнештә, эзлекле тәртиптә сурәтләнелмәвеннән килә. Төп мәсьәлә — производство конфликты игътибар үзәгеннән читтә кала.

Әлбәттә, әсәрне тәнкыйтьләргә кирәк. Тик язучының уй-фикерләрен, үзалдына куйган бурыч-максатын да аңларга тырышырга иде бит.

Хикмәт шунда, кызыклы һәм актуаль уй-фикерләрен язучы ахыргача ерып чыга алмаган. Авторның максаты әсәрне оештыруда, геройларны сурәтләүдә яңа формалар таләп итә. Э. Касыймов исә берничә сюжет линиясен бер үк төрле талгын, сүлпән хикәяләүгә кору белән чикләнеп калган. Куелган максатка тәңгәл килерлек яңа форма уйлап табарга аның көченнән килмәгән.

Үзгәреп торучы чынбарлыкны сурәтләүдә авторның төп позициясе әдәбиятның художество мөмкинлекләреннән тулырак файдалану, жанр һәм аны үзләштерү, эчтәлекнең эстетик новаторлыгы мәсьәләләре — эшчеләр сыйныфы турындагы татар прозасы һәм гомумән татар әдәбияты өчен үзәк проблема булып кала бирә. Бәла

[1] «Казан утлары», № 8, 1976.

шунда: язучылар аны һаман аңлап җиткермиләр. Безнең әле хәтта иң яхшы дигән әсәрләр дә югарыда әйтелгән кимчелекләрдән азат түгелләр.

Мәсәлән, Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романында олы проблема күтәрелә. Ләкин авторга кайбер шелтә белдерәсе килә. Әсәрдә эпик һәм лирик линияләр бер-берс белән тыгыз үрелмәгән, күп урында очеркка тартымлылык сизелә, еш кына бер үк төрле сюжет алымнары кабатлана. Ирексездән Ә. Баянов үз иҗатына нилектән таләпчәнлек белән якын килми икән дигән сорау туа.

Төп сәбәпләрдән берсе, минемчә, жанр проблемасы. Төгәлрәк әйткәндә, татар язучылары роман, повесть, хикәя жанрын тагын да камилләштерү һәм җентекләп үзләштерү зарурлыгын аңлап җиткермиләр булса кирәк. Ә бит жанр язучының төп идеясен сизгер тоеп алырга, сыгылмалы һәм үзгәрүчән булырга тиеш. Үзендә жанр яңача хәл ителгән әсәр генә камиллек баскычына күтәрелә ала.

Күп милләтле совет әдәбиятында проза жанры үрнәкләре гаять күп. Шуларның кайберләрен күрсәтеп үтик. И. Авижюсның «Югалган йорт-җир», С. Залыгинның «Тозлы тарлавык» романнары классик проза үрнәгендә иҗат ителгән, С. Крутилинның «Липяги», В. Астафьевның «Балык-падишаһ», Ә. Мохтарның «Чинар» исемле романнары новеллаларга корылган. Г. Марковның «Себер» романы эпик жанрда язылган. В. Распутин, А. Адамович, Ч. Айтматов, Ф. Мөхәммәдиев һәм В. Быковлар да повесть жанрының бик күп төрле үрнәкләрен бирделәр. Ә бу исә алар иҗатының новаторлык йөзен билгели. Идея никадәр тирән һәм оригинальрәк, тормышчанрак булса, аның жанр формасы да шул кадәр үк камил һәм үзенчәлеклерәк булып чыга.

Татар әдәбиятында жанр камиллегенә ирешкән «производство» әсәрләре дип Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар», Г. Ахуновның «Хәзинә» романнарын искә алырга мөмкин. Башка әсәрләр хакында болай дип әйтеп булмый әле. Ә менә «авыл» прозасында (А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар» әсәрләре) хәл күпкә әйбәт. Г. Бәшировның «Намус»ы классик роман жанры үрнәге булып кала.

Эшчеләр сыйныфы турында язылган әсәрләрнең кимчелеге, минемчә, татар әдәбиятында роман жанрының әлегә җитәрлек үзләштерелмәгән булуыннан килә. Проза турында соңгы ун еллар эчендә булып узган бәхәсләр жанрларның үзара бәйләнештә булуын һәм бер-берләрен тулыландырып килүләрен тагын бер тапкыр исбат итте. Алар өчен катгый, каноник кагыйдәләр юк. Жанр бер законга — язучының төп идеясенә генә буйсына. Ә бу исә тормышны һәм әдәби-эстетик закончалыкларны белүгә бәйләнгән.

«Сугыш» яки «авыл» прозасының чәчәк атуы турында уйлаганда, анда жанрларның үзара бәйләнеше нык үсконлеген күрәсең. Авыл темасына юлны иң әүвәл очеркистлар ачты. С. Залыгин, Ф. Абрамов, В. Распутиннарның фәлсәфи-этик прозасы Овечкин, Иванов, Троепольский очерклары җирлегендә барлыкка килде. «Сугыш» прозасында бу тенденция тагын да көчлерәк үсеш алган.

Татар прозасы очеркка, документаль прозага мохтаҗ. Минемчә, Г. Ахунов Ардуан турында әдәби әсәр түгел, ә документаль повесть язса, отар гына иде. Шулай ук Э. Касыймовка башта химиклар турында, Ә. Баяновка ГЭС төзүчеләр турында очерклар китабы язып, аннары романга тотынырга кирәк булгандыр. Бу очракта коры информация мәгълүматлары, технологик проблематика документаль җирлектә яктыртылыр, ә әдәби әсәр үзенә чын роман эчтәлеге алыр иде. Мәсәлән, рус әдәбиятында очеркист һәм публицистларның зур отряды эшли. Бай фактик материал нәкъ менә шулар тарафыннан оператив эшкәртелә. Татар әдәбиятында исә язучы үзенә-үзе юл салырга мәҗбүр була.

Тәнкыйтькә килгәндә, ул жанрны ачыклау белән, проза әсәрләренең жанр үзенчәлекләрен билгеләү белән махсус шөгыльләнергә тиеш.

Татар әдәбияты новаторлыкка йөз тота. Аеруча әһәмиятле проблематика (барыннан да элек, эшче образы проблемасы) өлкәсендә бик нәтиҗәле бәхәсләр туа, перспективалы художество юнәлешләре барлыкка килә. Эшчеләр сыйныфы темасына язылган проза әсәрләре әдәбиятыбызны тормыш үзе күрсәтеп биргән проблемалар, жанр өлкәсендәге табышлар белән баетты. Шуңа да карамастан, эшче темасы әле үзенә новаторларның күбрәк килүен көтә. һәм, гомумән, әдәби үсеш юлы да новаторлык хәрәкәте итеп каралырга тиеш.

Г. Ахунов, Ш. Бикчурин, Ә. Баянов, Э. Касыймов бу авыр һәм катлаулы юлның

алгы сызыгында баралар. Аларның уңышы зур һәм саллы. Шулай да бу әдипләр новаторлык эзләнүләрен көчәйтергә, бу өлкәдә тагын да җигелебрәк эшләргә бурычлылар.

Җитлеккән социализм дәверендә күп милләтле совет әдәбияты зур үзгәрешләр кичерде. Хәзерге социалистик реализм сәнгатенең элекке этаплардан аермасы турында уйланып, Г. Ломидзе болай дип яза: «Милли культуралар өчен барлык мөмкинлекләр ачыла, һәр милләтнең тарихи һәм культура тәҗрибәсендә күп еллар дәвамында тупланган һәм ныгып урнашкан барлык кыйммәтле, тотрыклы, яшәүгә сәләтле нәрсәләр бер үзәккә укмаша... Социализм милли культураларга югары биеклекләргә ирешү, беркем тарафыннан әйтелмәгән сүзләрне әйтү мөмкинлеге бирә»[1]. Совет тәнкыйтендә әйтелгәнчә, яңа поэтика туа. Анда милли әдәбият совет классикасы һәм дөнья әдәбияты тәҗрибәсе белән байый. Совет чынбарлыгы үзе язучыны тиз үзгәреп торучы бүгенге көнгә марксистик-ленинчыл позициядән карарга, совет әдәбиятының тарихи үсеш традицияләрен үзләштерергә мәҗбүр итә. Безнең совет әдәбияты, аның сугышчан отряды булган татар әдәбияты да, дөнья әдәбияты белән иңгә-иң торып заман юлыннан атлый. Аның үсеш закончалыклары дөнья әдәбияты белән бәйләнештә билгеләнә.

Революция белән бергә туган совет әдәбияты дөнья күләмендә яңа офык ачты. Ул үз үсешен новаторлык белән башлап җибәрде. һәм проблемалы асылы белән дә, художество формасы белән дә новатор булып кала. һәр вакыт халыкка хезмәт иткән һәм камиллеккә омтылган татар классикасы традицияләре дә новаторлыкка өйрәтәләр.

Татар прозасы үзенчәлекле һәм шул ук вакытта күп кенә әдәбиятларга хас үсеш юлы узды. Ул, XIX йөз ахырында туып, 1905 елгы революция чорында чәчәк ату чоры кичерде. Бу чорда Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Әмирхан кебек мәшһүр талант ияләре әдәбият мәйданына чыктылар. Алар иҗатында критик реализм методы җитлекте; шушы ук әдипләр соңыннан татар әдәбиятында социалистик реализм методын нигезләүдә җиң сызганып эшләделәр. Татар совет прозасы бүген сыйфат ягыннан яңа күтәрелеш чоры кичерә.

Татар әдәбияты формалашуда аңа һәр вакыт рус әдәбияты уңай йогынты ясады. Татар прозасы үсешенә рус әдәбияты йогынтысын ачыклау милли-специфик традицияләрне төгәл аныкларга, халыкчанлык җирлеген үстерергә, искергән идея һәм формаларга каршы көрәш алып барырга ярдәм итте.

Татар әдәбиятының үсешендә совет әдәбиятларының үзара бәйләнеше чиксез зур роль уйный. Шундый бәйланыш формаларыннан берсе — тәрҗемә. Ә тәрҗемә исә — язучының шәхси эше генә түгел. Гомумсоюз күләмендә танылу, рус телендә чыгу һич кенә дә художникның шәхси эше дип каралмаска тиеш. Рус теленә тәрҗемә ителү, әдәби әсәрнең күп милләтле аудиторияне яулап алуы милли әдәбиятның эчке процессларына көчле йогынты ясый, аны идея һәм иҗади яктан туплый.

Бездә бу эш сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да әлегә нык аксый. Соңгы елларга күз салганда, зур куаныч белән Ш. Бикчуринның В. Чивилихин тәрҗемәсендә дөнья күргән «Каты токым» романын күрсәтергә кирәк. Әмма мондый уңышлы тәрҗемәләр бик аз! Татарстан язучылар оешмасына тәрҗемә һәм тәнкыйть өлкәсендә, гомумән художество-эстетик бәйланышларның барлык өлкәләрендә элементәләрне ныгыту турында бик ныклап уйларга кирәк. Бөтенсоюз масштабында татар әдәбияты мәнфәгатьләрен күрергә һәм яклап чыгарга, татар әдәбиятын күп милләтле совет әдәбияты белән бәйли торган бәйланыш җепләрен киң сузарга кирәк. Иң мөһиме — әдәбият фронтында иҗади дуслык.

Татар әдәбиятында, шул җөмләдән прозасында, нык үскән социализм җәмгыяте чиксез зур динамизм, бөек әхлакый идеаллар җәмгыяте булып күз алдына килеп баса. Халыкның барлык катлаулары зур үзгәрешләр процессына тартылган. Бу процесста совет халыкларының бердәм гаиләсендә чәчәк атучы, бөек совет халкы дигән киң төшенчәгә органик һәм табигый рәвештә керүче татар халкының да иң гүзәл сыйфатлары тагы да байый һәм үсә бара.

Язучының югары нәтиҗәгә ирешү җирлеге — идеялелектә, партиялелек белән халыкчанлыкта, чынбарлыкны һәм совет кешесен ачык, дөрес чагылдыруда.

[1] Г. Ломидзе. Төп критерий. «Вопросы литературы», 1976, № 10, 26—27 битләр.

# КҮП КӨЧ КУЕЛГАН

Нинди дә булса милли телнең аңлатмалы сүзлеген төзү — гаять катлаулы һәм җаваплы эш. Академик А. С. Чикобава сүзләре белән әйткәндә, дәүләт өчен халык санын алу никадәрле кирәк булса, телне өйрәнүдә аның лексик составын һәм эчке мөмкинлекләрен ачыклау шул кадәрле үк мөһим. Әмма телдәге сүзләрне, халык санын алган кебек, кыска вакыт эчендә генә барлап чыгып булмый. Бүгенге көн лексикасы еллар, гасырлар буена җыйналган байлык ул. Тел — халык тарихының көзгесе.

Хәзерге көндә төрки халыклардан төрекмәнлеләр, әзербәйҗанлылар, кыргызлар аңлатмалы сүзлекләрен булдыру бәхетенә ирештеләр. Казакъ теленең ике томлык сүзлеге басылып чыккач, галимнәр уникe томлык сүзлек төзүгә керештеләр (аның ике томы басылып чыкты да инде). Һәм менә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең беренче томы дөнья күрде[1].

Татар лексикографиясенең бүгенге торышын, сүзлек хәзинәбезне күзалларга ярдәм иткән бу хезмәт буш җирдә калкып чыкмады. Ул, беренчедән, Каюм Насыйриның «Ләһҗәи татари»е белән Җ. Вәлиди сүзлеге (аның әлиф, би, ти хәрефләреннән башланган сүзләре генә басылган) традицияләрен дәвам иттерсә, икенчедән, ике телле, диалектологик, терминологик, алынма һәм фразеологик сүзлекләрне төзегәндә тупланган бай тәҗрибәгә таянып төзелде.

Яңа сүзлекне төзегәндә Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре татар теленең XIX гасыр ахырыннан алып, хәзерге көнгә кадәр гомумкулланышта булган лексик һәм фразеологик байлыгын туплап кына калмыйча, сүзләрнең мәгънәләре белән мәгънә төсмерләрен ачуны, эмоциональ-стилистик кулланылыш үзенчәлекләрен билгеләүне максат итеп куйганнар. Һәм, безнең фикеребезчә, бу бурычны алар уңышлы гына хәл иткәннәр.

Сүзлектәге һәр сүз үзенең семантик, стилистик һәм грамматик үзенчәлекләре белән күз алдына килеп баса. Тибы буенча ул хәзерге әдәби телнең норматив сүзлеге булса да, мондый хезмәтләр, кагыйдә буларак, күпмедер дәрәҗәдә борынгырак заманнарга хас сүзләрне дә үз эченә алалар. Чөнки хәзерге әдәби тел кинәт кенә тумаган, ул иске татар әдәби теленең дәвамы булып тора. Мәгълүм булганча, соңгысы чын мәгънәсендә халыкның аралашу коралы булып китә алмаган: ул чыгтай, госманлы төрекләренең тел элементлары, гарәп һәм фарсы алынмалары белән нык чуарланган. Бары тик XIX йөз урталарында гына татар әдәби теле сөйләм теленә якыная башлый, әдәби тел халыкчан юнәлештә үсүгә юл тота. Шул чорларда һәм XX йөз башларында, бигрәк тә классик әдәбият әсәрләрендә кулланылган сүзләр дә аңлатмалы сүзлектә урын алырга хаклы, чөнки алар эстетик тәрбия, матурлык-гүзәллекне тоя белү сәләтен һәм сөйләм культурасын тәрбияләүче чаралар булып тора.

Фәнни нигездә төзелгән сүзлек бай картотекага таянырга тиеш: сүзләрнең мәгънә төсмерләрен ачудан тыш, ул кайвакыт килеп чыга торган субъективлыкка юл куймауга да ярдәм итә. «Татар теле аңлатмалы сүзлеге» нәкъ шулай төзелгән дә. Әзерлек чорында классикларыбыз (Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Г. Камал һ. б.) белән өлкән буын язучыларыбыз (Г. Бәширов, Н. Исәнбәт,

[1] Өч томда. 1 том. Казан, 1977 ел. Редколлегия: Л. Т. Махмутова, М. Г. Мөхәммәдиев, К. С. Сабиров, Ш. С. Ханбикова.

Ә. Еники, М. Әмир Г. Әпсәләмов һ. б.) әсәрләрендәге һәр сүз күчерелеп алынып, барлыгы өч миллионга якын карточка тупланган. Моннан тыш авторлар тормышыбызның төрле өлкәләренә караган сүзлекләр, халык авыз иҗаты әсәрләре, дәреслекләр, газета-журналлар, фәнни-популяр әдәбиятны да киң файдаланганнар. Шуңа күрә дә сүзлектә **алу, ачу, аш, бакча, буй, дуга, ипи** кебек гади көнкүреш төшенчәләрен белдерүче сүзләр белән бергә **вәкарь, вөҗүд, гасаб, игълан, инсан, агрегат, аэропорт, аэрочана, бацилла, велюр, готика** һ. б. шундый алынмаларны күрергә мөмкин. Аларның көндәлек тормышта еш кулланыла торганнары инде алынма дип түгел, ә татар теленең үз сүзләре сыман кабул ителәләр. Шундыйлардан **багаж, битараф, блок, вариант, ватман, арматура, астронавт, вагъдә, вәкил, девиз, инкяр, итагать, ихтыяр, иҗтимагый, демократ** һәм башка сүзләрне китерергә мөмкин.

Сүзлекне төзүчеләр пуристик агым нәтиҗәсендә дөнья күргән яки кайбер авторларда гына кулланылган, яисә чит телдән тәрҗемә ителеп, халыклашып китә алмаган сүзләрне хаклы рәвештә игътибардан читтә калдырганнар. Әмма телнең пассив лексикасы итеп саналган сүзләрне сүзлеккә кертү-кертмәү мәсьәләсендә тагын да таләпчәнрәк булырга да мөмкиндер әле.

Күп төрле һәм зур күләмле махсус терминологияне сүзлек өчен сайлау проблемасы лексикографиядә әлегә хәл ителеп җиткәне юк. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең керешендә киң кулланылышта йөри торган терминнарның гына китапка алынганлыгы турында ачык әйтелә. Шулай да кабул иткән принциптан читкә тайпылулар да юк түгел. Мәсәлән: **архипастырь, багбан, геликон, глетчер, диванханә, инкунабула** кебек сүзләрне сүзлеккә кертмәгәндә дә зыян килмәс иде.

Ни сәбәптәндер, сүзлектә **аксеркә, актүш, алгыч,** атлас (география), **ашыт, балбал, биртек, бортпроводница** (чөнки **бортмеханигы** кергән бит), **борын** (мыс, коса) сүзләре китерелмәгән. Авторлар, аларны искә алып, сүзлекнең кушымтасында бирерләр дип ышанасы килә.

Сүзлеккә аерым диалекталь сүзләрнең кертелүен дә уңай күренеш дип санарга кирәк, чөнки сөйләшләрдән кергән кайбер сүзләр әдәби телне тулыландырып, аны төрле стилистик бизәкләр белән баеталар. Беренче томга кертелгән **аҗаган, буйдак, болдыр, игәч** сүзләренең әдәби телебездә функциональ максат белән генә кулланыла башлап, тора-бара төп сүзлек фонды бирәмлегенә әверелүен искә төшерик. Асыл мәгънәсе «киртә» булган **иннек** сүзе дә матур әдәбият битләрендә күбрәк урын ала башлады. Сүзлектә китерелгән мисалларга караганда, аның «киртә» һәм шуңа тыгыз бәйле мәгънәләрдә . К. Тинчурин, Т. Гыйззәт, М. Гали, Ш. Маннур, Н. Фәттах әсәрләрендә кулланылганын күрергә мөмкин. Димәк, ул да аерым диалект чикләрен үтеп чыккан.

Хезмәт ияләренең гомуми культурасы үсүе лексикографларның тел культурасы мәсьәләсенә җитди игътибар бирүләрен таләп итә. Тел культурасы өчен кирәш әдәби тел сүзлекләрендә стилистик характеристиканы да үз эченә ала. Төзүчеләр һәр сүзнең кулланылыш өлкәсен билгеләргә омтылганнар. Сүзлектә китерелгән һәр сүз янындагы махсус билге ул сүзнең нинди очракта кулланылырга тиешлегенә ишарә итә. Мәсәлән, **гайрәт** сүзе төп мәгънәсе ягыннан көч-куәтне белдерсә, сөйләм телендә «хәл, егәрне, үз вазифасын үтәү сәләтен» («Картайдым, гайрәтем юк эш эшләргә») һ. б. өстәмә мәгънәләрне бирә ала.

Моңарчы чыккан сүзлекләрдән аермалы буларак, яңа хезмәттә сүзләргә грамматик характеристика бирелгән. Махсус билгеләр сүзнең кайсы сүз төркемнәренә карaганлыгын, аның аерым грамматик формаларын, синтаксик функцияләрен күрсәтәләр. Мисал өчен **аркылы** сүзен генә алып карыйк. Ул, рәвеш булып килеп, «нәрсәнең булса да иңе, киңлеге буенча; буйны иңгә кисеп үтә торган юнәлештә», сыйфат буларак «буйны иңгә кисеп үтә торган юнәлештә беркетелгән, куелган, эшләнгән» һәм җөмләдә сыйфатның исем функциясендә килгән «иң, киңлек» («Аркылысы буена тиң булсын») мәгънәләренә ия. Ә инде җөмләдә бәйлек булып килә икән, ул вакытта «бер яктан икенче якка кисеп үтү белән бәйләнешле эш-хәрәкәтнең урынын белдерү» (күпер аркылы чыгу), «эш-хәрәкәт булып үтә торган ике нокта арасындагы урынны белдерү» (Казанга Арча аркылы кайту) һәм башка шундый мәгънәләргә ия була.

Мәгънә һәм аның төсмерләренең бөтен тулылыгы белән төгәл китерелүе, грамматик характеристиканың конкретлыгы, стилистик анализның нечкәлеге, фразеологик материалның күплеге ягыннан күпчелек аңлатмаларны сүзнең яшәеше белән кулланылыш үзенчәлекләрен билгеләүче лексик

этюдлар дип санарга мөмкин. Мәсәлән, тугыз мәгънә һәм дүрт мәгънә төсмере булган **авыз** сүзенә тагын шул сүз кулланылган 79 фразеологик берәмлек теркәлгән. Бу исәпкә аларның фразеологик вариантлары керми. Мәсәлән, бик күп һәм оста сөйләүчегә карата «Авызына җен төкергән», «Авызына иблис төкергән», «Авызына саескан төкергән» дип тә әйтәләр. Урынны экономияләү өчен алар хаклы рәвештә җәя эчендә генә күрсәтелә. Шулай ук **ике** сүзенә төп-төгәл 120 (!) фразеологик әйтелмә тупланган, аңлатылган һәм татар әдәбиятыннан, халык авыз иҗатыннан китерелгән мисаллар белән расланган.

Кызганычка каршы, сүзләрнең мәгънәләрен ачыклауда кимчелекләр дә юк түгел. **Алкышны,** мәсәлән, «хуплау яки котлау билгесе итеп кул чабу» дип кенә аңлату аның эмоциональлеген йомып кала. Тәрҗемә сүзлекләрендә ул «овация» дип бирелә бит.

Шулай ук **аерылгысыз, аерылмас, аерылмаслык** сүзләренең аңлатмалары да ахыргача уйланып җиткерелмәгән кебек. Аларның берсен икенчесенә кайтарып калдырганчы, берләштереп, бер мәкаләдә бирү дөресрәк булган булыр иде. Моннан тыш, **аерылмаслык** сүзенең «аерылмаслык рәвештә» дигән мәгънә төсмерен аерып чыгару төп сүзне кабатлауга кайтып кала.

Кайбер сүзләр, ни өчендер, тәрҗемә генә ителеп, аңлатмалары китерелмәгән. Мәсәлән: **абрикос** «өрек агачы» дип һәм икенче мәгънәсе «шул агачның эре төшле, көзгылт-сары төстәге җимеше» дип бирелә, ә шул ук вакытта **бананга** «Җылы якларда үсә һәм җимеше өчен үстерелә торган эре яфраклы күпьеллык үләнчел үсемлек» дигән аңлатма бирелеп, аның җимеше икенче мәгънә итеп каралмый; **госбанк** «дәүләт банкысы», **горком** «шәһәр комитеты» дип кенә күрсәтелә.

Ләкин мондый сирәк кенә күренгәләп киткән җитешсезлекләр хезмәтнең әһәмиятен һәм югары фәнни дәрәҗәсен әллә ни киметә алмый. Сүзлекне төзүчеләр, кыенлыгы ягыннан инә белән кое казуга тиң, әмма шул ук вакытта гаять кирәкле һәм мактаулы эшкә тотынып, күп көч куйганнар, һәм максатка ирешкәннәр дә. Хәзер инде сүзлекнең башка томнары чыгуын зур түземсезлек белән көтәргә кала.

**ФӘРИД ХӘКИМҖАНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# СҮЗЛЕКТӘ ФӘННИ ТЕРМИНОЛОГИЯ

„Хәзерге татар әдәби теленең аңлатмалы сүзлеген төзү инструкциясе"н СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институты 1964 елны бастырып чыгарган иде.

Менә хәзер без сүзлекнең беренче томын кулыбызга алдык. Дөрес, исеме чак кына үзгәргән — ул «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» дип атала. Ләкин исемдәге шушы чак кына үзгәреш тә аның лөгатьләген киңәйтергә, сүзлекне колачлырак итәргә мөмкинлек биргән, әлбәттә.

Галимнәрнең зур коллективы тарафыннан озак еллар дәвамында төзелгән «Аңлатмалы сүзлек» олы хезмәт булганга, аңа һәрьяклы, тулы бәя бирү — гомумән килләчәк эше, чөнки сүзлекнең икенче һәм өченче томнары чыгасы бар. Бу мәкаләдә бары тик аерым бер моментка — сүзлектә фәнни терминология мәсьәләләренә генә тукталыначак.

Мәгълүм булганча, фәнни терминология телнең җитлегү һәм үсеш дәрәҗәсен күрсәтә, аның актив кулланылу даирәсен билгели һәм, ахыр чиктә — курыкмыйча әйтик — аның килячәген хәл итә.

Без, Мольер комедиясендәге гомере буе проза телендә сөйләшеп тә шуны белми йөргән беркатлы агай шикелле, көндәлек тормышыбызда ике сүзнең берендә терминнарга мөрәҗәгать итәбез. Ике сүзнең берендә, чөнки, әйтик, «атом төше» генә түгел, «чикләвек төше» дә — термин. Мәгънәви чикләре төгәл билгеләнмәгән терминнарсыз без томанлы төшенчәләр диңгезендә адашып, бер-беребезне аңлаудан **гаҗиз** булыр идек. Шөкер, һәр күренешне, һәр объектны, һәр яңалыкны колачларга тырышкан фәнни терминология бар. (Һәм аның янында сүзнең мәгънә чикләрен киңәйтә дә, тарайта да ала торган томанлы һәм серле шигърияткә дә урын җитәрлек.)

Узган гасыр азакларында, татар теленең беренче фәнни атамаларын иҗат иткәндә, Каюм Насыйри ана телебезнең фән теле була алуына, моның өчен аның чара-мөмкинлекләре җитәрлек булуына ышанып эшләгән.

Революциядән соң, бөтен илдә халык мәгарифе җәелдерелү уңае белән, күп кенә милли телләрдә, шул җөмләдән татар телендә дә, фәнни терминологияне эшләү бурычы бөтен кискенлеге белән килеп баса һәм ул моңарчы беркайда да күрелмәгәнчә кыска вакыт эчендә хәл ителә. Утызынчы еллар башына инде безнең тотрыклы фәнни терминологиябез барлыкка килә. Татарча фәнни терминологияне эшләү тәҗрибәсенең башка төрки халыклар телендәге терминология үсешенә сизелерлек йогынты ясавы мәгълүм.

Төрле елларда төрле тармаклар буенча чыгарылган терминологик сүзлекләребезнең саны өч дистәдән артып китә. Соңгы ун-унбиш ел эчендә генә дә биология, физика, математика, астрономия, техника, авыл хуҗалыгы, география буенча русча-татарча терминологик сүзлекләр нәшер ителде, химия буенча сүзлек әзерләнеп ята.

Табигый, фән-техника революциясе чорында бик күп яңа төшенчәләр барлыкка килде. Фән белән бергә, безнең терминология дә үсте, катлауланды. Иске терминнарны яңабаштан карарга туры килгән очраклар да бар. Татарча газета-журналлар, мәктәп дәреслекләре, төрле ярдәмлекләр, популяр әдәбият яңа туган атама һәм терминнарның татарча тәңгәлен табуда, яңа терминологияне гамәлгә кертүдә зур эш башкардылар.

Менә шушы терминология «Аңлатмалы сүзлек»тә ничек чагыла соң? һәм ул анда ни дәрәҗәдә чагылырга тиеш?

Сүзлекне төзүчеләр күп санлы чыганакларга таянып эш иткәннәр. Картотека төзү өчен файдаланылган әдәбият исемлегендә, сүзлек һәм белешмәләрдән тыш, революциягә кадәрге һәм революциядән соңгы вакытлы матбугат, революцион прокламацияләр, уку ярдәмлекләре, авыл хуҗалыгы, техника һ. б. тармаклар буенча татарча чыккан китаплар күрсәтелә.

Һәм, чыннан да, сүзлеккә теркәлгән яңа атамалар һәм фәнни төшенчәләр аз түгел. Менә кечкенә генә исемлек: **автотөягеч, азимутчы, атом-төш, бактериаль ашлама, виражлау, газүлчәгеч, гранулалаштыру, диктат политикасы, дренажлау, интенсивлаштыру, ясалма иярчен, йолдызлап тоташтыру, йөртүче ракета**... Бу исемлекне тагы да киңәйтергә мөмкин булыр иде.

Безнең карашка, төзүчеләр аерым очракларда уңышсыз терминологияне дә теркәп, талымсызлык күрсәткәннәр. Берәр мәкаләдә, әсәрдә, я булмаса китап-брошюрада теге яки бу сүзнең «ялтырап китүе» ул сүзнең телебездә тамыр җәйгәнлеген күрсәтми әле. Китапның авторы яки тәрҗемәче, үз «манарасыннан» карап, үз зәвыгына һәм белем даирәсенә таянып «тәкъдим иткән» һәм озакламый кире кагылган атамалар да байтак (безнең терминология тарихында андый сүзләргә мисал итеп, гадәттә, **буйөрткеч** — пароход, **алгарыш** — прогресс, развитие, **әчелек** — кислота, **чапкыч** — рубильник электрический, **сакланма** — запас кебек тәкъдимнәрне китерәләр). Мондый абыну-сөртенүләр терминология үсешендә гадәти бер хәл, әлбәттә.

Беренче томда күбәләктәй кыска гомерле терминнар күп түгел, ләкин бар: **градуирлау** (бүлемләү — 276 бит), **галәмче** (космонавт — 258 бит), **буш атом** (ирекле яки бәйсез атом — 197 бит) шундыйлардан. Димәк, каталогка таян, әмма җанлы телне дә онытма. Артык-портыкларны таный бел.

Сүзлекчеләр игътибарыннан читтә калган берничә сүзгә карата да сүз әйтик.

Беренче томга **«давыл кошы»** кергән, ләкин ни өчендер икенче варианты, бик мөһим күчерелмә мәгънәгә дә ия булган **«давыл хәбәрчесе»** юк. М. Горькийның «Давыл хәбәрчесе турында җыр»ын яшь Фатих Хәсни тәрҗемә иткәнгә дә шактый гомер узган бит. «Давыл хәбәрчесе» вариантын 1972 елда нәшер ителгән «Русча-татарча биология терминнары сүзлеге»ндә дә табарга мөмкин. Аңлатмалы сүзлектә **альбатрос**ның давыл хәбәрчеләре отрядына кергәнлеге әйтелгән булса, аңлатма откан гына булыр иде (чөнки тәрҗемәләрдә бу ике сүзне чиратлаштырырга мөмкин булуы аңлашылачак). Сәрвәр Әдһәмова «Робинзон Крузо» әсәрен тәрҗемә иткәндә **дирбия** сүзен «корабль такелажы», «снасти» мәгънәләрендә уңышлы куллана. Кызганыч, тәрҗемәченең бу табышы сүзлектә чагылмый. Татарча чыккан кодексларда (1974) **зат** сүзе юридик «лицо» мәгънәсендә кулланыла (монда шәхес һәм кеше сүзләре бармый, чөнки берәр оешма яки, әйтик, колхоз да юридик «лицо» булырга мөмкин). Аңлатмалы сүзлеккә «зат»ның бу рәсми мәгънәсе кереп өлгермәгән.

Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсендә саклана торган күптәнге кульъязма сүзлекләр дә, үткән чор терминологиясенең көзгесе буларак, игътибардан читтә калырга тиеш түгел. Аларда без, мәсәлән, стена мәгънәсендәге **ниргә** сүзен (кала ниргәсе), **буралгы** (бродяга — сукбай; бурлак?), **ботарлау** (җәза: четвертование), **тизгер** (скорый) кебек бүген дә эшкә яраклы сүзләрне очратабыз. Мин сүзлектә **баз өй** (подвальное помещение, землянка), **бизән[д]ек** (украшение), **имтияз** (отличие) кебек, тәрҗемә практикасында бик кирәге чыга торган сүзләрне дә тапмадым. Хәзиндә бар сүзләр бит. Аңлатмалы сүзлектә билгеләмәләрнең кыска һәм төгәл булуы зарур. Ташка уеп язылгандай җыйнак стильгә ия булмаса, аңлатма яки ярымйортылы булып кала, яисә, озынга китеп, дәреслек текстына охшый башлый, ә аны, әлбәттә, сүзлекнең күләме сыйдырмый.

Беренче том бу юнәлештә мәгълүм уңышларга ирешкән. Тел-әдәбият белемнәренә, сәнгать төрләренә караган күпчелек аңлатмалар җыйнак һәм төгәл. Ләкин фәнни терминнарга бирелгән байтак кына аңлатмаларда мәгънәви төгәлсезлекләр калган, кайбер билгеләмәләр көпшәк һәм якынча. Аңлатмаларга стиль бердәмлеге җитми. Әйтик, **автотөягеч** — «йөкне автомат рәвештә төйи торган машина» дип аңлатыла (7 бит). Хәлбуки, хәзерге «робототехника» мондый камил автоматлар ясау дәрәҗәсенә ирешмәгән әле. Автотөягеч — фәкать үзйөрешле төягеч кенә һәм аны кеше идарә итә. Сүзлек **гроссмейстер** сүзенә «шахмат яки спорт буенча иң югары дәрәҗә» дип аңлатма бирә (278 бит). Хуш, ә шахмат үзе спортның бер төре түгелмени? Шахмат белән шашкадан кала, тагы кайсы спорт төрендә гроссмейстерлар бар? 392 биттә инглиз тозы «магний оксиды» дип күрсәтелә. Бу, әлбәттә, ялгыш. Тоз булгач, ул инде оксид түгел. Инглиз тозы — магний сульфаты һәм ул чыннан да «эч йомшарткыч дару» исәпләнә. Математик термин булган **авышма** сүзенең аңлатмасы мәгънәсез чыккан. **Альфа нурларга** бирелгән аңлатманың да асыл мәгънәсенә төшенүе кыен: ул русча чыганактан ялгыш тәрҗемә ителгән. Дөресләп әйтсәк, «Альфа нурлар — кайбер матдәләр радиоактив таркалган вакытта бик зур тизлек белән ыргытылган уңай корылмалы кисәкчекләр ташкыны» булыр. Сүзлектә **азот кислотасына, биш бармак**ка, **византиябле**гә, **галактика**га, **гомумилек**кә, **гудрон**га, **гюрзага** һәм кайбер башка сүзләргә бирелгән аңлатма һәм билгеләмәләр дә теге яки бу яктан аксыйлар.

Аерым очракларда аңлатма белән шул сүзгә мисал-иллюстрация арасында ярашмаучанлык күзгә ташлана. Әйтик, **гипноз** сүзе (270 бит) «йокы яки ярым йокы халәте» дип аңлатылса да, иллюстрациясе түбәндәгечә: «Ә бераздан [аудитория] Заһидның лекциясе белән, гипнозга эләккән кешедәй, бөтенләй мавыгып китә». Бу очракта мисалның авторы Атилла Расих гипнозны йоклату мәгънәсендә түгел, бәлки залдагы кешеләрне әсәрләндерү, җәлеп итү, таң калдыру мәгънәсендә куллана бит. **Бетерешү** сүзенең өченче мәгънәсенә мисал итеп «Алты-биш Сапый» кебегрәк гайре табигый тигезлек китерелә: 5 ав = 3 ав. «Ав»ларны «бетерештергәч» (дөресе: кыскарткач), бишнең өчкә тигез булуын күреп аптырабрак каласың.

Бүгенге терминологиядә бәхәсле һәм әлегә «утырып җитмәгән» лексик берәмлекләр дә бар. Шуларның берсе — спорттагы **алка** мәсьәләсе. Аңлатмалы сүзлектә аның ике төрле мәгънәсе теркәлгән: атына торган боҗра һәм хоккей уенында кулланыла торган түгәрәк, яссы резина. Беренчесендә матур әдәбияттан мисал китерелүенә дә карамастан, ул гамәлдәге терминологияне дөрес чагылдырмый: төп термин—боҗра. Ә боҗраның бу мәгънәсе нишләптер игътибардан читтә калган. Вакытлы матбугатта спорт комментаторлары хоккей шайбасын гадәттә алка дип йөртәләр. Сөйләм телендә исә без шайба сүзенә күнеккәнбез. Перспективада **шайба** вариантының өстен чыгачагы шиксез (өстәвенә, «алка» — ялгыш калька үрнәге генә). Шуңа күрә сүзлектә, алканың бу мәгънәсен биргән очракта да, аңлатма өлешенә «шайба» дип өстисе каяган.

**Игез, игезәк, икеләч, игәч** сүзләренә карата түбәндәгеләрне әйтәсе килә. Игез балаларның төрле күзәнәктән яралганнары һәм бер күзәнәктән яралганнары була. Моның әһәмияте теория белән генә чикләнми, ул, мәсәлән, селекция эшендә бик мөһим. Хәзерге вакытта шушы ике төр генотиплы бала организмнар өчен рус телендә ике сүз: «близнецы» һәм «двойни, двойняшки» терминнары кереп бара. Татарча терминологиядә дә аларны аерып йөртү өчен ике сүз кирәк, әлбәттә. «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге»ндә «близнецы»—«игезәкләр» дип, ә «двойняшки» — «икеләч бала» дип тәкъдим ител-

гән (1971 ел). Дөрес, халык телендә тагын «игәч» («игәч бәрәннәр») сүзе дә бар, бәлки анысы отышлыраклыр. Һәрхәлдә, махсус әдәбиятта аларны аерып йөртү зарурлыгы булганга, лексикографлар биологларга ярдәм кулы сузарга тиешләр. «Аңлатмалы сүзлек»нең беренче томы әлегә бу мәсьәләгә битараф караган.

Сүзлектәге аңлатмалар күп очракларда рус сүзлекләреннән тәрҗемә итеп алынганлыктан һәм сүзлекләр дөнья күргәнгә байтак сулар аканлыктан, аңлатмалар арасында искергәннәре дә күренә. Аерым очракларда лексикографик сүзлекләргә генә түгел, теге яки бу фән тармагы буенча яңа чыккан белешмәләргә дә мөрәҗәгать итү файда китергән булыр иде. Тугандаш республикаларда чыгып килә торган энциклопедияләрне мин шундый чыганаклар исәбенә кертәм.

Аңлатмалы сүзлекләрдән һәр сүзнең тарихын яктыртуны таләп итеп булмый. Моңысы — этимологик сүзлекләр бурычы, киләчәк эше. Ләкин, бүгенге ихтыяҗны да исәпкә алып, аерым очракларда этимологик моментларны да искәреп китәргә мөмкин (мәгънәдәге тарихи төсмерләрне ачу өчен генә булса да). Мисалга **дәрман** һәм **дәрт** сүзләрен алыйк, чөнки бу яктан алар чыннан да бик гыйбрәтле. Беренче том «дәрман»ның ике мәгънәсен ача. Берсе — «рухи һәм физик мөмкинлекләр; көч, хәл». Икенчесе — «күңелсезлекләрне һ. б. ш. борчуны җиңел кичерергә, аннан арынырга ярдәм итә торган яки рухи канәгатьләнү китерә торган нәрсә...» Соңгысы күчмә мәгънә дип искәртелә. Күчмә мәгънәме? Дәрман сүзенең төп мәгънәсе шул түгелме икән? «Борынгы төрки сүзлек»тә (Мәскәү, 1969 ел) **дәрман — дару, дәва** дип аңлатыла (XV йөзнең ахыры, XVI йөз башлары кульязмасы буенча). Ягъни бу сүз фарсы теленнән төрки телләргә асыл мәгънәсендә килеп кергән. «Дару», дәва» мәгънәсе «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә теркәлгән. Дәрт сүзенең дә, исем-термин буларак, ике мәгънәсе ачып бирелә: 1) «ашкыну һәм рухи күтәренкелек, омтылыш; рухи көч»; 2) «ярату, мәхәббәт хисе». Хәлбуки, дәрт (дәрд) сүзенең төп мәгънәсе — авыру, газаплану. Ул да «тузга язылган» сүз, төркигә фарсыдан XVI йөзгә кадәр үк кергән. Димәк, аның беренче томда бирелгән мәгънәләре — икенчел мәгънәләр. Дәрдмәнд — кайгысы булган кеше; бичара, гаҗиз; авыру кеше, хаста. Хәтерлисезме, Закир Рәмиев «чишмәи әбелхәят» эзләве турында яза. Ләкин:

**Тез йөгендем, яшь тамыздым.**
**Дәрткә дәрман алмадым,**

— дип, кайгысына һәм гаҗизлегенә дәва таба алмавыннан зарлана (1908 ел). Әлбәттә, «Дәрт бар, дәрман юк» дигән әйтемнең бүгенге мәгънәсе — «теләк бар, көч кенә юк». Ләкин, күрәсең, аның борынгы мәгънәсе башка: «чире бар, дәруы юк». Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре»ндә без моны кире яктан расланый торган мәкальне очратабыз: «Дарусыз дәрт булмас» (2 том, 936 бит). Бу мәкальне бабаларыбыз «Дәрмансыз дәрт булмас» рәвешендә әйткәннәрдер кебек. Үзбәктә: «Дардига дармон булмок» тәгъбире яши. Аның беренче мәгънәсе: кемне дә булса авырудан терелтү. Шул рәвешле, дәрд сүзе дә, безнең телебездә эчке үзгәрешләр кичереп, тора-бара «ашкыну», «ярату» мәгънәләренә ия булып киткән икән. Аңлатмалы сүзлек бу ике сүзнең асыл мәгънәләрен абруйлы мисаллар белән дәлилләп, киләчәк өчен беркетеп куя алган булыр иде. Без аларны онытып барабыз икән ләбаса!

Шулай ук «индеец», «индус», «гыйнвар» сүзләренә этимологик искәртүләр ясалган булса, сүзлектәге аңлатмалар откан гына булыр иде.

Теләк һәм киңәш тәртибендә тагы бер сүз.

Сүзлек төзүнең һәм аның өстендә эшләүнең үз алымнары, спецификасы бар. Бер җиреннән тартсаң, ул икенче урыннан сүтелеп китә. Күләмле сүзлекнең тел үсешеннән беркадәр артта калуы да аңлашыла. Әмма бу «арттальк» мөмкин кадәр азрак булырга тиеш һәм моңа ирешүнең юлы бер генә: җанлы тел белән элемтә корректуралар вакытында да өзелмәскә, яңалыклар кертелә барырга тиеш. Сүзлекне кат-кат рецензияләтү һәм махсус редакцияләү зарур. «Аңлатмалы сүзлек»нең культурабыз, телебез үсешендә тоткан урыны шуны таләп итә.

**АДЛЕР ТИМЕРГАЛИН.**

# ТЫН АЛАН ШАУЛЫЙ

*Драматург Сәет Кальметовка 60 яшь*



Әдәбиятның зур булгач, хәтта язучыларның исемнәре дә кабатлана башлый. Татар әдипләре арасында ике Туфан, ике Нуруллин, өч Миңнуллин, ике Әхмәтҗанов, ике Галиев, ике Гыйззәтуллин (Таҗи Гыйззәт тә бит әле), ике Юзиев... әле бүгенге көндә актив иҗат итеп яшиләр.

Әле тагын ике Сәет бар ич! Икесе дә драматург: Сәет Шәкүров белән Сәет Кальметов. Болары яшьтәшләр диярлек. Сәет Шәкүровның 60 еллыгын узган ел ахырында шаулатып билгеләп үткән идек. Сәет Кальметовка исә менә шушы апрельдә алтмыш яшь тула.

Аның юбилее уңае белән әйтелгән шушы кыска гына сүзнең, шулай бер караганда бик коры, тагын бер караганда шаянрак төстә башлануына да Сәет Кальметов үзе сәбәпчедер.

Драматург буларак, ул — нигездә комедияләр авторы. Аның илле еллыгына багышлап язган мәкаләсен Сәет Кальметов белән байтак еллар янәшә яшәгән, бер иҗат коллективында эшләгән Гариф Ахунов «Усал телле драматург» дип атаган. Дуслар сүзе дөрес булса, үзен шулай олылау драматург һәм кеше Сәет Кальметовның күңеленә сары май булып яткан ди.

Сәет Кальметов — күрше Башкортстан жиреннән. Ул 1918 елның апрелендә Яңаул эшчеләр поселогында туа. Җидееллык белем алгач, Ташкентка барып чыга, бередә икееллык сәнгать студиясендә укый. Сугышка чаклы Ташкент, Чиләбе татар театрларында художник булып эшли.

Сугышта ул — танкист. Бүгенге көндә карт солдат Сәет Кальметовның күкрәген сугышчан медальләр бизи.

Аның хезмәт юлы табылган була, сугыштан кайту белән Ютазы, Буа театрларында художник, актер, режиссер булып эшли. Буада 1947 елны үзенең беренче сәхнә әсәрен — «Безнең кияү» исемле бер пәрдәле пьесасын иҗат итә.

Бүген Сәет Кальметовның театрда эшчәнлегенә кырык ел тулса, аның драматург буларак иҗат итеп килүенә утыз ел, димәк. Җимешле хезмәт еллары болар.

Театр тормышы белән яшәгән яшь драматург бер пәрдәле беренче пьесасыннан соң рухланып сәхнә әсәрләре иҗат итә башлый: «Нурия һәм аның дуслары», «Йолдызлар балкый», «Ышанычлы юлдаш», «Үкенерсең, кодагый», «Тамгалы йорт» кебек комедияләре Буа, Әлмәт, Республика күчмә театрлары репертуарында бер-бер артлы ныклы урын ала.

Сәет Кальметовның әле башлангыч мәлдә язылган пьесаларыннан берсе — «Йолдызлар балкый» комедиясенә бәя биреп, Гариф Ахунов: «Халыкчан үткен тел, сәхнә әсәрләре өчен зарури булган динамика, яшьләрнең самими юмор белән өртелгән кызыклы язмышлары бу әсәрне тормышчан итә», дип язган иде.

Мондый сыйфатлар Сәет Кальметов драматургиясенә тулаем хас диярга кирәк. Драматургиясенең нәкъ шундый төпле сыйфатлары аның әсәрләрен Татарстан һәм Башкортстанның бик күп театрлары сәхнәләренә күтәрде, авторга тамашачыларның мәхәббәтен яулап алып бирде. Шулай да Сәет Кальметовның художник, артист, режиссер, драматург буларак соңгы егерме еллык эшчәнлеге Әлмәт дәүләт драма театры белән бәйләнгән. Биредә аның таланты үзенең барлык матур сыйфатлары белән ачылды, иҗат шатлыкларын һәм көенечләрен ул күбрәк шул коллективта татыды. Тамашачылар мәхәббәтенә шунда лаек булды.

Авторның тормыш биографиясеннән, сугыш биографиясеннән туган «Зәкия» драмасы бу театр сәхнәсендә өч йөз мәртәбә уйналды. Сәет Кальметовның дистәдән артык драма әсәре төрле елларда «Үсү юлы» әдәби альманахында, «Тын алан шаулый», «Соңгы очрашу», «Күңелле сәхнә», «Үкенерсең, кодагый» кебек җыентыкларда басылып чыкты, бик күп профессиональ һәм үзешчән сәхнә репертуарларын бизәде.

Сәет Кальметов иҗатының әле башлангыч чорында язылган «Тын алан шаулый» исемле пьеса 1951 елда ук Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында бер сезон буена сәхнәдән төшми уйналган иде. Драматург үзе дә шул тын алан кебек халык белән берләшеп яши, халыкчан рух белән язылган әсәрләрен язып, тын алан сыман әледән-әле тыйнак кына шаулап алгалый тора. «Сәет Кальметов Бөек Ватан сугышын солдат булып узган кебек, әдәбиятта да солдат булып атлый һәм аның дистәдән артык пьесасы сәхнә аша кешеләрне коммунистик рухта тәрбияләүдә солдат булып катнаша» (Г. Ахунов).

Әдәби полк солдатлары әнә шулай олы мәркәзләрдә генә түгел, авыллар уртасында утырган кечерәк башкалаларда да иҗат итеп, халыкка хезмәт күрсәтеп яшәп яталар. Шуларның берсе — Сәет Кальметовка бүген 60 яшь тула.

Ул бүген мактаулы юбилее белән котлаган хатлар ала, каләмдәшләренең, тамашачыларының тәбрик сүзләрен кабул итә, иҗади дуслыкның җылысын тоя. Тын аланның тын гына шаулаганы һаман ишетелә.

**Х. ЗАРИПОВ.**

# КӨЙЛӘРЕНДӘ ЧОРЫБЫЗ СУЛЫШЫ

*Композитор Бату Мулюковка 50 яшь*

Бату Мулюковның әле музыка грамотасын да ныклап үзләштереп өлгермәгән чакларында чыгарган көйләрен тыңлагач, зур белгечләрнең «композитор булып туалар» дигән сүзләре искә төшә. 1946 елны язылган, хәзерге вакытта Г. Зәйнашева сүзләренә җырлана торган «Төзүче җыры» да шул хакта искәртә кебек. Ул җырдагы заманыбызга хас тизлек ритмы, интонацияләрнең яңа һәм саф яңгыравы С. Сәйдәшевне юкка гына кызыксындырмагандыр. Татарстан радиосында һәм үзешчән коллективларда егерме ел буе башкарылуына карамастан, бу әсәр аһәңе белән һаман да күңелне үзенә җәлеп итә. Иҗатының татар музыкасына яңа интонацияләр алып килүе, композиторның бүгенге музыканы ишетүендәге үзенчәлекләре В. И. Ленинның йөз еллык юбилеен үткәргәндә аерата ачык күренде. Хор өчен язылган «Гасырлар кешесе — Ленинга» җырын башкармаган бер генә район яки профсоюз үзешчән хор коллективы булмады дисәк тә ялгышмабыз. Моны без районнардан халык иҗаты йортына һәм хор җәмгыятенә килгән концерт программаларыннан ачык күрәбез.

Бату Мулюков республикабыз музыка тормышына югары гражданлык пафосы белән сугарылган патриотик җырлары белән килеп керде. Ә. Давыдов сүзләренә язылган «Яшә, партия!» җыры да хор коллективлары репертуарында ныклы урын алып тора.

Композиторның иҗат диапазоны киң. Вакыт-вакыт аның илһам дәрте кителмәгән борылышлар, яңа ачышлар ясап куя. Б. Мулюковның Г. Тукай сүзләренә язган «Егет

илә кыз», «Хатыннар хөррияте», башка шагыйрьләр белән иҗат иткән сатирик җырлары музыкабызда беренче карлыгачлар булды.



Профессиональ сәнгатькә килгәнче, Бату Мулюков зур тормыш университеты уза. Бөек Ватан сугышы елларында ул — яшүсмер малай — фронтка китүчеләрне хәрби комиссариат ишегалдыннан гармун уйнап, җырлап озата. Кулына гармун тоткан малайны яралы сугышчылар янында — госпитальләрдә дә еш очратырга була. Ә 1943 елның җәендә Батуны Оренбург өлкәсендәге Каргалы авылының «Чулпан» колхозына чакыралар. Язгы чәчүдән башлап, кар төшкәнче ул шушы колхозда яши. Көндезге ял вакытында һәм эштән соң, гармунда уйнап, колхозчыларның күңелен ача. Ярышта җиңүче булып чыга колхоз ул елны. Монда бәләкәй гармунчы һәм тырыш егет Батуның да өлеше була. Менә шул вакытлардан башлап гади гармунчыда үзенә зур таләпләр куйган профессиональ музыкант күренә башлый. Бату үзлегеннән пианинода, скрипкада, мандолинада уйнарга өйрәнә. Оренбург татар драма театрында музыка өлеше белән җитәкчелек итә, спектакльләргә көйләр яза. Аның күңеле яңа моң эзли. 1949 елда Оренбургка иҗади концерт белән килгән С. Сәйдәшев Батуның көйләре белән кызыксына, фортепианода кабат-кабат уйнатып карый, көйләрнең оригинальлегенә бәя бирә, аны Казанга укырга чакыра.

Һәрбер композиторда дирижерлык сәләте яшеренеп ята диләр. Ә Бату аны профессия итеп сайлый һәм Казан музыка училищесын хор дирижеры буларак тәмамлый, һәм консерваториядә композиторлыкка укыганда инде ул урта мәктәпләрдә җыр дәресләре алып бара, хор түгәрәкләре оештыра. Кеше тавышының табигатен җентекләп өйрәнгән яшь композитор, җиң сызганып, күптәнге хыялын — оригиналь музыка әсәрләре иҗат итү теләген тормышка ашыра башлый.

Ул, беренче буларак, балалар өчен күп тавышлы кантаталар яза. Китап нәшриятында аның «Татарстан» кантатасы, «Яшь космонавтлар», «Бөтен ел матур», «Кем булырга?» җыентыклары басылып чыга. Ул татар композиторларының әсәрләрен балалар тавышына көйләп оранжировкалар ясый, балаларга яңа әсәрләр өйрәтә, аларның концертларын оештыра. Б. Мулюков җитәкчелек иткән хор коллективы ярышларда җиңеп чыга һәм күп санлы мактау грамоталарына лаек була.

Бату Мулюков үзенең барлык иҗат куәтен хезмәт кешеләренә юнәлтә. 1957 елда консерваторияне тәмамлагач, «Игенче җыры», «Уңыш бәйрәме», «Оста куллар» кебек зур популярлык казанган җырларын, симфоник оркестр өчен «Хезмәт турында поэма»сын яза. Аның бизәкләргә бай «Бәйрәм увертюрасы», кырыс тонда язылган монументаль «Симфония»се, «Скрипкалар ансамбле өчен концерт»ы, тынлы оркестр өчен сюита, кыллы квартетлары һәм башка пьесалары да хезмәтне, тыныч тормышны данлыйлар. Партия һәм дәүләт тормышындагы зур юбилейларны ул махсус язылган әсәрләре белән каршылый. Казанның Ирек мәйданына Батуның «Комсомол маршы»н тыңларга килүчеләр аз түгел. Бу марш менә инде 18 ел тынлы оркестрлар репертуарыннан төшми.

Күптән түгел китап нәшрияты композиторның «Җырларымнан белерсең» исемле җыентыгын бастырып чыгарды. Җыентыкта аның төрле елларда иҗат ителгән бер бәйләм җырлары урнаштырылган. Бу китабы өчен дә автор музыка сөючеләрдән рәхмәт хатлары ала.

Бату Мулюков Бөек җиңүнең утыз еллыгына багышлап, «Ветеран җыры», «Курганнар» һәм легендар Панфилов дивизиясенең егерме сигез каһарман сугышчысын тәрбияләгән атаклы комиссар Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров турында «Панфиловчы Әхмәтҗан» балладасын язды. Бу зур күләмле героик-психологик әсәрдә халкыбызның

киләчәге, якты көннәре өчен барган канлы көрәш картиналары тәгәлләнгән образ булып күз алдына баса. Әлеге әсәрләре Б. Мулюковны яңа иҗат баскычына күтәрә.

Б. Мулюков халык моңына зур ихтирам саклый торган композитор. Соңгы елларда ул «Зиләйлүк», «Кыр казы», «Башкорт биюе» һәм башка халык көйләрен эшкәртте һәм инструментларга салды.

Композитор Б. Мулюков республикабыз музыка тормышында актив катнаша. Мәктәпләрдә музыкаль тәрбия эшләрен җәелдерүгә ярдәм итә, республика районнарында оештырылган җыр бәйрәмнәрендә дә аны еш күрергә мөмкин. Үзе белән тынлы оркестрлар алып чыгып, ул йөзләрчә кешедән торган хор коллективлары чыгышларын әзерләүгә булыша, аларга дирижерлык итә. Үзешчән композиторларның семинарларын уздыру, районнарда хор җәмгыятьләре оештыруда да аның хезмәте бар. Б. Мулюков республикада беренче баянчылар һәм хор җитәкчеләре курсларының җитәкчесе булды.

Татарстан композиторларының XIV һәм XV пленумнарында композиторның хор өчен язылган «Татарстан гүзәле», аерым җырлары һәм «Чаллыда бәйрәм» увертюрасы башкарылды. Бу увертюра — симфоник һәм тынлы оркестрны бергә кушып башкару өчен язылган зур күләмле әсәр.

1976 елның җәендә дә композитор Татарстан районнарына яңа җырлары белән чыкты. Шулар арасында «Сагынып кайттым сине, Богадым» тамашачыларга аерата хуш килде. Бу турыда алар композиторга болай дип яздылар:

«Хөрмәтле Бату Гатауллович! Сезнең «Сагынып кайттым сине, Богадым» җырын районда авыл хуҗалыгы алдынгылары җыелышыннан соң үткәрелгән концертта хор белән җырладылар. Бу яңа көй тамашачыларга бик ошады... Сезгә, колхозчылар һәм яшьләр исеменнән, әйбәт җырыгыз өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәбез, иҗатыгызда зур уңышларга ирешүегезе теләп калабыз».

1977 елның ноябрь аенда Татарстан композиторларының IV съезды булды. Б. Мулюков съездга хор, симфоник оркестр, солистлар өчен язылган «Казан» исемле монументаль, эпик һәм драматик ораториясе белән килде. Менә бу оратория һәм кечерәк күләмле башка әсәрләре съезд концертларында тамашачыларга җиткерелде һәм уңыш казанды.

Танылган композитор Казан культура институтында оркестр дирижерлары хәзерләү буенча доцент вазифасын үтәүче өлкән укытучы булып эшли. Шулай ук ул Татарстан Композиторлар союзы идарәсе председателе урынбасары да.

Бүгенге көндә дә ул халык иҗатын өйрәнүен дәвам итә, зур күләмле яңадан-яңа әсәрләр язу дәрте белән янып яши.

Талантлы композитор Б. Мулюковка 1977 елда Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. Республикабызның барлык музыка сөючеләре аны илле еллык юбилее белән котлыйлар, композитордан заманыбыз рухына тиң булырлык яңа әсәрләр көтәләр.

**Самат ШАКИР.**

# МӨНИР МАЗУНОВ

Шагыйрь Мөнир Мазуновка 60 яшь тулды. М. Мазунов 1918 елның 3 апрелендә Пенза өлкәсенең Лопатин районы Иске Карлыган авылында туа. 1935 елны үз авылларында җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Әстерхан шәһәрендәге педагогия техникумында укый, соңыннан Ижевск шәһәренә укытучы булып килә. 1939—1946 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә, Бөек Ватан сугышында катнаша, «Тревога» исемле фронт газетасының хәбәрчесе була. Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә М. Мазунов партия сафларына керә.

Сугыштан соңгы елларда М. Мазунов Татарстан радиокомитетында редактор булып эшли, шул ук вакытта Казан дәүләт педагогия институтында читтән торып укый. 1953 елдан алып Татарстан Культура министрлыгының радиоинформация бүлегендә, 1960—1964 елларда Татарстан китап нәшриятында өлкән редактор булып эшли.



Мөнир Мазуновның беренче шигыре 1937 елда Әстерханда басыла. Аннары Ижевскида «Ленин юлы» газетасында яшь шагыйрьнең берничә шигыре дөнья күрә. Бөек Ватан сугышы елларында ул актив язышa башлый. Аның сугыш чорында туган күпчелек шигырьләре һәм очерклары үзе эшләгән «Тревога» газетасында басылып тора. 1944—1945 елларда берничә әсәре Татарстанда чыга торган яшьләр альманахында, «Совет әдәбияты» журналында, төрле җыентыкларда басыла.

Шагыйрьнең күпчелек шигырьләре совет солдатларының хезмәтен, авыл яшьләренең кызыклы тормышын чагылдыруга багышланган. Бу шигырьләрдә яшьлекнең кайнар һәм саф хисләре сизелә.

М. Мазунов үзенең җыр һәм кантаталары белән дә укучыларга билгеле. Аның сүзләренә композиторлар Ә. Бакиров, М. Мозаффаров, З. Хәбибуллин, С. Садыйкова, И. Шәмсетдинов, Р. Яхин тарафыннан дистәләрчә җыр язылган. Шагыйрьнең «Гасырлар кешесе Ленинга», «Туган як», «Әниемнең җылы кочагы» исемле җырлары халык арасында яратып җырлана. М. Мазуновның җырлары «Безнең тавыш», «Яшьлек җыры», «Әйдәгез, җырлыйбыз», «Гөлкәй», «Туган як» дигән җыентыкларга тупланган.

Шагыйрь балалар өчен дә актив яза. Аның «Елда уникe ай», «Син дә белергә тиеш», «Нәни төзүчеләр», «Ак күгәрченнәр» кебек китапларын балалар яратып укыйлар.

М. РОБЕРТ.

## Фәнис Яруллин

### Күз

Күк йөзе — күзгә басу,
Болытлар кибән-кибән.
Җилкәсендә сәлам ташып
Кибәнне җилләр өйгән.
Кибәннең иң өстендә
Эшләпәле карт кебек —
Кояш карап тора җиргә
Тавышсыз гына көлеп.

### Океан

Өстебездә зәңгәр күк,
Астыбызда океан.
Шул океанда үземне
Капитан итеп тоям.
Ләкин безнең океанда
Давыл булмый, җил булмый.
Мачтабызның өстенә
Акчарлак килеп кунмый.
Балыгы бар, суы юк,
Әкияттәге кебек ул.
Җилсез, сусыз, давылсыз
«Океан» дигән кибет ул.

### Безнең әби

Безнең әби укый белми,
Үзе шундый шәп яза:
Иртән торып май яза,
Кич утырып йон яза.

### Күзгә күренеш

Күк йөзендә елак кояш
Бер бата, бер калка.
Җил урманның чәчен ала
Елата-елата.

## Кран

Урамда эшли кран,
Муенын кая борган?
Хәрәкәте бик салмак —
Цирктагы фил сымак.

Әнә ул зур панельне
Ничек җиңел күтәрде.
Фил үрелеп алгандай
Учыбыздан шикәрне.

## Җиңеләйтү чарасы

Әнкәсе белән Ләйлә
Кибеттән кайтып килә.
Кайтасы юл шактый бар,
Әкрен генә атлыйлар.
Ләйләсе сумка тоткан,
Сумкасы иңен сыккан.
Алыр иде әнисе,
Кулында бар бәбисе.
Кемнән ярдәм көтәргә.
Ничек кайтып җитәргә?
Ярты юлны узгачтын,
Телне ярым сузгачтын,
Тагын кибет күрделәр —
Ансына да керделәр.
Һәм алдылар шоколад,
Шоколадка Ләйлә шат.
Сал, әни, ди, син монда,
Урын бар, ди сумкамда.
Юлның калган яртысын
Кайтты Ләйлә җил дә җил.
Шоколад та салгачтын,
Сумка булды җип-җиңел.

## Зәки Нури

### Алтын балык ялвара

*Хыялый әкият*

Шундый сәер була бу очрак:
Яр буенда — чүп-чар. Су — пычрак.

Үлән шиңгән, кипкән таллыгы...
Ә Пушкинның алтын балыгы

Нәкъ шушында — урын тапкан бит?! —
Бер кармакка килеп капкан бит.

Белә балык сынау үтәсен, —
Бабай нәрсә таләп итәсен:

Я ун келәм, я бер «Жигули»
Китерүне сорар дип уйлый.

Карый балык Идел-диңгезгә:
«Ник куркыныч хәзер син безгә?»

Дигән төсле... Картны көлдереп,
Үз теләген алдан белдереп,

Үтенә ул: «Башны ашама! —
Зинһар, мине суга ташлама!

Әкият малын заман киметте,
«Бар» дигәнне «юк»ка тиң итте.

Мин тончыгам — мазут күп анда.
Суның төбеч басты чүп анда...

Калыйм, бабам, коры җирдә мин,
Синең белән булыйм бергә мин.

Бу ярда бит зирәк, тапкыр син!
Ни теләсәң, шуны таптыр син!

Эзләт! Таптыр! Дөнья гизәрмен,
Тормышыңны синең бизәрмен.

Саф су куйсаң тулы тагарак,
Йөзәрмен мин шунда тәгәрәп...

Тырыш мине эшкә җигәргә,
Бик үтенәм: суга җибәрмә!»

## Менә сиңа дуслар

*Ауда булган хәл*

Ике дуска очрый бер кабан.
Тидерәлмәгәч атып берсе дә,
Өсләренә килә теге һаман,
Ачуыннан ярсый-бүртенә.

Бер дус шулчак агач башына үрли —
Ярый әле, куе, карт урман! —
Икенчесе борылып тиз-тиз йөгерә...
Кабан чаба аның артыннан.

Авыз ера агач башындагы —
һәр күңелдә була ич шайтан! —
«Нәби шулай йөгерә алырдыр дип
Уйламаган идем һич кайчан...»

...Очрый әле дусның шундые да:
Саклар өчен бары үз җанын,
Тик ялгызы качар урын таба
Күтәргә дип бәла узганын.

## Төлкеләр һәм керпеләр турында

— Бер йоның юк, өстең тулы чәнечке.
Сыйпыйм дисәм — тәпиемне чәнечте.

Бу тирене кем соң яратсын ди?
Күңел күзен кемнең каратсын ди?..

Ник булмаска сиңа куян йонлы,
Минем кебек, әйтик, төлке тунлы?

Сүз әйтергә һичкем кыймас иде...
Күзем сине күреп туймас иде!

Сал чәнечкеңне! Әйдә, килешик без,
Шул бәхеткә, әйдә, ирешик без!

Йөртер идем сине гел күтәреп,
Яшәр идек рәхәт көн үткәреп! —

Шулай диеп күп сайрады төлке,
Тел талдырып ул мактаган керпе

Кирәк булгач, тотып буар өчен, —
Үз дөньясын җиңел куар өчен...

Арабызда төлке ишеләр дә
Бар бит әле... Андый кешеләргә

Безнең тәнкыйть чәнечке булып күренә —
Үтә ала хәтта йөрәк түренә.

Үч итеп без төрле төлкеләргә,
Яшел урам ачыйк керпеләргә!

## Тыйнак була белү

Бер помидор, никтер исе китеп,
Бакчадашы, дусты, ише итеп,
Бер кыярга әйтте — оялмады,
Озын телен чөнки тыялмады:
— Үзең шома, буең-сының ыспай!
Ник кызара белмисең син, дускай?
Менә дигән шәп бит озынлыгың?
Шунысы гаҗәп: ник юк кызыллыгың?

Җавап өчен кыяр сүз алмады,
Чөнки аның йөзе кызармады
Һәм әйтмәде: «Ә син яшел бул!» дип.

Тыйнакларның төп сыйфаты шул бит!

### ХӘЗИНӘЛӘР ИЛЕНДӘ

Шушы елның 25—27 январе көннәрендә Төмәндә язучылар һәм тәнкыйтьчеләрнең «Бөек төзелеш батырлары һәм совет әдәбияты» дигән темага багышланган Бөтенсоюз иҗади конференциясе булып узды. Анда союздаш һәм автономияле республикалардан килгән 100 дән артык язучы, шагыйрь, тәнкыйтьче, шул исәптән, Татарстан Язучылар союзыннан шагыйрь Зәки Нури һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафиннар катнашты.

Төмән якларын илебездә генә түгел, бөтен дөньяда иксез-чиксез хәзинәләр иле буларак беләләр. Әйтик, монда һәр тәүлек саен җир асты катламнарыннан 620 мең тонна нефть һәм 240 миллион кубометр газ чыгарыла. Якындагы елларда исә бу саннар тагы да үсә барачак. Димәк, әлеге җитди конференциянең ни өчен нәкъ менә Төмәндә уздырылуы яхшы аңлашыла булса кирәк.

Конференцияне КПСС Үзәк комитеты члены, СССР Язучылар союзы идарәсенең беренче секретаре Г. М. Марков ачты. Аннары кунакларны КПСС Үзәк Комитеты члены, партиянең Төмән өлкә комитеты беренче секретаре Г. П. Богомяков Көнбатыш Себер экономикасы үсешенең гаять зур перспективалары белән бик дәлилле таныштырды. «Знамя» журналы баш редакторы В. М. Кожевников, «Октябрь» журналы баш редакторы А. А. Ананьев, «Юность» журналы баш редакторы Б. Н. Полевойларның докладлары әдипләрдә зур кызыксыну уятты.

Конференциядә, күп кенә башка иптәшләр белән беррәттән, КамАЗда хезмәт героикасы дигән темага Р. Мостафин да информация ясады.

Бу көннәрдә Төмән шәһәренең күп кенә культура сарайлары, клублары һәм вузларында язучылар белән хезмәт алдынгылары, иҗат интеллигенциясе һәм студентлар арасында истәлекле очрашулар булып узды. Шундый очрашулардан нефтьчеләр культура сараенда, эшче яшьләр клубында Зәки Нури чыгышлар ясады. Чыгышларда Төмәндә яшәүче яшь татар шагыйре Булат Сөләйманов та катнашты.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

23 нче декабрьда Тукай клубында Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының ачык җыелышы булып узды.

КПСС Үзәк Комитетының декабрь Пленумы (1977 ел) карарлары һәм алар яктылыгында Татарстан язучылары алдында торган бурычлар дигән темага доклад белән язучы М. Е. Скороходов чыгыш ясады. Эшлекле һәм зур җанлылык белән үткән фикер алышуларда Г. Ахунов, Ф. Хөсни, тәнкыйтьче Р. Мостафин һәм башкалар катнашты.

Соңыннан Язучылар союзы председателе урынбасары Фәрваз Миңнуллин февраль аенда узачак 1977 ел йомгакларына әзерлек чаралары һәм аның программасы белән таныштырды; Язучылар союзы секретаре М. Хәбибуллин СССР Язучылар союзы членлыгы билетларын алыштырырга әзерлек һәм бу эшне оешкан төстә, зур җанлылык белән үткәрү кирәклеге хакында белдерү ясады.

* * *

2 нче февральдә Союз каршындагы яшьләр белән эшләү комиссиясе һәм яшьләрнең «Идел» әдәби альманахы редколлегиясенең берләштерелгән утырышы булды. Анда «Идел»нең чираттагы 10 нчы санына керергә тиешле әсәрләрнең кульязмалары турында фикер алышу булды. Чыгыш ясаучылар авторлар арасында яшь, әсәрләрен әле беренче тапкыр гына укучылар игътибарына тәкъдим итүче язучы һәм шагыйрьләр булуын, тематик географиянең шактый киңлеген уңай яктан билгеләп уздылар. Шуның белән бергә аерым авторларның әсәрләрендәге кимчелекләргә дә игътибар ителде. Фикер алышуда яшьләр белән эшләү комиссиясе председателе Ш. Галиев, Ш. Маннур, Ш. Рәкыйпов, И. Юзеев, Т. Миңнуллин, Г. Рәхим, И. Иляловалар катнашты.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Бүлек утырышында драматург Сәет Кальметовның иҗат отчеты тыңланды. Чыгып сөйләүчеләрдән Ю. Әминев, Г. Афзал, Ә. Маликов һәм башкалар драматургның соңгы елларда язган кече формадагы әсәрләренә (юмореска, скетч, кечкенә хикәя) анализ ясадылар, алардагы уңай һәм кимчелекле яклар күрсәтелде.

* * *

Декабрь аенда Мәскәүдә хәзерге армия һәм флот темасын яктыртучы язучыларның Бөтенроссия киңәшмәсе булган иде. Шунда катнашучы Владимир Мальцев киңәшмә эше турында бүлек язучылары алдында чыгыш ясады, кызыксындырган күп кенә сорауларга җавап бирде.

*
* *

Язучы Ш. Бикчурин һәм Лениногорск әдәбият берләшмәсе членнары Шөгердә, С. Кальметов Әлмәт бораулау идарәсе коллективында, К. Булатова Мәмәт авылында (Әлмәт районы) әдәби очрашуларда булдылар. Алар үзләренең әсәрләрен укыдылар, әдәбияттагы яңалыклар турында сөйләделәр.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

КПСС Үзәк Комитетының иҗат яшьләре белән эшләү турындагы карары Татарстан язучыларының игътибар үзәгендә. Шагыйрьләр секциясе шул уңай белән М. Горький исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь С. Хәким белән очрашу үткәрде. Ул яшь шагыйрьләргә үзенең кызыклы һәм бай иҗат тәҗрибәсен сөйләде. Шулай ук бүгенге татар совет шагыйрьләре иҗаты, илебез һәм дөнья поэзиясенең төп тенденцияләре хакында җанлы әңгәмә алып барылды.

*
* *

Поэзия секциясенең чираттагы утырышында яшь шагыйрьләр Рашат Низамиев һәм Харрас Әюповның кулъязма җыентыклары тикшерелде. Аларның иҗатлары турында махсус сүз белән шагыйрьләр Г. Рәхим һәм Зөлфәт чыгыш ясадылар. Фикер алышуда шагыйрьләр Ә. Баянов, Р. Фәйзуллин, И. Юзеев, М. Әгъләмов һәм Р. Гатауллиннар катнашты. Һәр ике авторның шигырьләре, нигездә, уңай бәяләнде. Тәнкыйть һәм киңәшләрне искә алып төзәткәч һәм тулыландыргач, аларның иң яхшы шигырьләрен Татарстан китап нәшриятына тәкъдим итәргә дигән карар кабул ителде.

*
* *

Балалар әдәбияты секциясенең чираттагы утырышында яшь язучы Камил Кәримовның хикәяләре һәм повесте тикшерелде. Аның иҗаты турында язучы Ф. Шәфигуллин сөйләде. Язучылардан Л. Ихсанова, А. Тимергалин, Х. Халиков, М. Мазунов, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин һәм Зөлфәт авторга кыйммәтле фикерләр һәм киңәшләр әйттеләр. Кулъязма Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителде.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

Гыйнвар аенда Лениногорск шәһәренең культура сараенда танылган язучы Шамил Бикчуринның иҗат кичәсе булды. Кичәне кереш сүз белән Лениногорск район башкарма комитеты председателе иптәш Гыйлаҗев ачты. Ул Ш. Бикчуринның «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнүе турында СССР Верховный Советы Президиумы Указын укыды. Юбилярның иҗат эшчәнлеге турында Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Әдип Маликов чыгыш ясады.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе исеменнән Ш. Бикчуринны шагыйрь Гәрәй Рәхим, Татарстан китап нәшриятының баш редакторы язучы Вакыйф Нуруллин, Азнакайдан язучы Мәхмүт Хәсәнов, нефтьчеләр оешмалары вәкилләре, мәктәп балалары котлады.

Ш. Бикчуринга «Татнефть» берләшмәсе һәм нефть-газ промышленносте профсоюзлары өлкә комитетының, шулай ук КПСС-ның Лениногорск шәһәр комитеты, шәһәр һәм район советларының мактау грамоталары, төрле оешмалардан күп санлы адреслар тапшырылды. Кичә ахырында шәһәрнең үзешчән сәнгать коллективлары көче белән әдәби-музыкаль концерт куелды.

*
* *

Азнакай эшчеләр поселогының Техника йортында язучы Мәхмүт Хәсәновның 50 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Кичәне кереш сүз белән КПСС-ның Азнакай райкомы секретаре Әсгать Фазылович Хәмидуллин ачты. Юбилярның иҗаты турында язучы Рафаил Төхфәтуллин сөйләде.

Шашин исемендәге Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсе генеральный директоры урынбасары Үзбәк Саттаров Мәхмүт Хәсәновка берләшмәнең һәм нефть-газ промышленносте профсоюзлары өлкә комитетының Мактау грамотасын тапшырды.

Юбилярны нефть төбәгендә яшәүче каләмдәш дуслары исеменнән Татарстан Язучылар союзы идарәсе члены, Язучылар союзының Әлмәт бүлеге җитәкчесе Әдип Маликов, язучы Хәсән Сарьян, шагыйрь Разил Вәлиев, каләмдәшләре Шамил Бикчурин, Хәниф Хәйруллин, Азнакай нефтьчеләре һәм район хезмәт ияләре вәкилләре котлады. Соңыннан язучының иҗатына багышланган концерт булды.

*
* *

Гыйнвар аенда Актерлар йортында язучы Аяз Гыйләҗевнең 50 еллыгына багышланган әдәби кичә булып узды. Язучының күп кырлы һәм бай иҗаты турында докладны аның каләмдәше Х. Сарьян ясады. Кичәдә язучының прозасыннан өзекләр укылды, сәхнә өчен язылган әсәрләреннән аерым эпизодлар күрсәтелде. Иҗат интеллигенциясе, хезмәт ияләре һәм яшьләр күп җыелган бу бәйрәм зур күтәренкелек белән узды.

*
* *

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында үткәрелгән бер әдәбият кичәсе шагыйрә Г. Зәйнәшева иҗатына багышланды. Артистлар Ә. Афзалова, З. Басыйрова, Ә. Яһүдин, Г. Ильясов, Ф. Сөләйманова һ. б. авторның шигырьләрен укыдылар, аның сүзләренә язылган җырларны башкардылар.

## ИЛЕБЕЗ НӘШРИЯТЛАРЫНДА

«Прогресс» нәшриятында «Поэзия Европы» дигән китапның 3 нче томының 1 нче китабы чыкты. Бу китап Советлар Союзы халыкларының классик һәм хәзерге шагыйрьләре иҗатына багышланган. Шигырь-

лэр рус, инглиз, немец, француз теллэреңдэ бирелгэн.

Бөек шагыйрьләр арасында Г. Тукайның да бу җыентыкка өч шигыре кертелгән. Шигырьләрне рус теленә В. Звягинцева, Р. Моран, С. Липкин тәрҗемә иткән. «Алтынга каршы» дигән шигыре оригиналда — татар телендә дә бирелгән.

* * *

Мәскәүдә «Молодая гвардия» нәшриятында «Литература и ты» дигән җыентыкның 6 нчы чыгарылышы дөнья күрде. Анда әдәбият белгече М. Гайнуллинның «Каюм Насыйри» дигән мәкаләсе басылган. Ул күренекле галим, язучы, мәгърифәтченең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыра.

* * *

Ленинградның «Аврора» китап нәшриятында «Искусство народов СССР. Живопись. Скульптура. Графика» дигән китап чыкты. Ул 1917—1970 елларны эченә ала. Анда совет художникларының әсәрләре, аларның кыскачы биографиясе һәм китапка кергән рәсемнәргә характеристика бирелгән.

Китапта Татарстаннан РСФСРның халык художнигы, СССР Художество академиясенең член-корреспонденты, И. Е. Репин исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты, СССРның Дәүләт һәм Г. Тукай исемендәге республика премияләре лауреаты Харис Якупов әсәре дә урнаштырылган.

* * *

Татарстан китап нәшриятында А. Г. Әминев һәм Г. М. Әдһәмоваларның «Урта мәктәптә әдәбият укыту методикасы» дигән китабы басылып чыкты. Урта мәктәптә укыту методикасы мондый тулы күләмдә беренче тапкыр басыла. Анда күпьеллык тарихы булган татар әдәбиятына бәйле рәвештә, методиканың тарихы, мирасы һәм бүгенге көндәге торышы күрсәтелә. Укучыларга коммунистик тәрбия бирүдә әдәбиятның мөмкинлекләре, төрле әдәби жанрларны укыту-өйрәнү алымнары, техник җайланмалар белән эш итү, дәресләрне планлаштыру, хәзерләү, үткәрү үрнәкләре һ. б. турында сөйләнелә.

Филология фәннәре докторы, профессор М. Х. Хәсәнов редакциясендә чыккан бу китап әдәбият укытучыларына, студентларга ярдәмгә тәкъдим ителә.

## ТЫНЫЧЛЫК ФОНДЫНА

Казанның Муллануp Вахитов исемендәге химия комбинаты клубында тынычлык фондына концертлар һәм кичәләр уздыру соңгы елларда матур бер традициягә әйләнеп китте.

Шундый бер концертта Татарстанның халык артисткасы композитор Сара Садыйкова, ТАССРның атказанган артисткасы Зифа Басыйрова, күренекле баянчы Рокыя Ибраһимова һәм башкалар катнашты. Татар халык көйләре һәм композиторларыбыз әсәрләре башкарылды.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Үзбәкстанның Касан районы «Шәрык йолдызы» колхозы һәм «Кара-Ком» совхозында Совет Кораллы Көчләренең 60 еллыгына багышланган кичәләр булып узды. Аларда шагыйрь һәм гражданин буларак Муса Җәлил батырлыгы дигән темага филология фәннәре кандидаты, Үзбәкстан Журналистлары союзы премиясе лауреаты Исхак Зәбиров чыгыш ясады.

Бу очрашуларда шулай ук үзбәк язучысы Самат Кадыйров, хезмәт һәм сугыш ветераннары, яшьләр һәм мәктәп балалары катнашты.

## КУЛЬТУРА ЯҢАЛЫКЛАРЫ

КПСС өлкә комитетында «Зур Идел» дигән бишенче зона сәнгать күргәзмәсен оештыру комитетының утырышы булды. Анда күргәзмә залын булдыру, Татарстан рәссамнарының иҗатын тагын да активлаштыру һәм башка мәсьәләләр каралды.

* * *

Республика сәнгать мәктәпләре директорларының һәм аларның урынбасарларының уң көнлек кышкы укулары тәмамланды. КПСС Үзәк Комитетының һәм СССР Министрлар Советының авыл халкына культура хезмәте күрсәтүне тагын да яхшырту чаралары хакындагы карары яктылыгында сәнгать мәктәпләре алдындагы бурычларны чагылдырган доклад белән ТАССР культура министры урынбасары М. Т. Низамиев чыкты. Семинарда катнашучылар Казан галимнәре, культура эшлеклеләренең эчтәлекле лекцияләрен тыңладылар, тәҗрибә алмаштылар.

* * *

Күренекле язучы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Николай Бирюковның Ялтадагы музей-йортында аның иҗатына багышланган III фәнни конференция булды. Бу музей-йортка илебезнең төрле якларыннан киләләр, бирелә әдәби кичәләр үткәрелә. Чыгышларда шагыйрь Зәки Нури да катнашты. Аның Татарстан турындагы шигырьләре зур кызыксыну белән тыңланды.

* * *

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә «Тартюф» яки «Алдакчы» (татарча «Суган суфие») әсәре куелды. Француз сәхнәсе реформаторы Мольерның акыллы юморы Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсендә татар тамашачысы өчен аңлаешлы һәм якын.

Спектакльнең режиссеры — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Празат Исәнбәт. Сәхнәне Г. Тукай премиясе лау-

реаты Энәс Тумашев бизәгән. Музыка житәкчесе — Фуат Әбүбакиров.

Спектакльдә театр коллективының төп көчләреннән РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Габдулла Шамуков, РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты, Г. Тукай премиясе лауреаты Ринат Тажетдинов һәм башкалар катнаша.

*
* *

М. Гафури исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы башкорт академия театры татар совет язучысы А. Гыйләжевнең «Югалган көн» дигән әсәре буенча эшләнгән спектакль күрсәтте. Аның режиссеры БАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, С. Юлаев премиясе лауреаты Р. Исрафилов. Бу әсәр моннан элек Казанның В. Качалов исемендәге зур драма театрында, Барнаул һәм Иваново шәһәрләре театрларында рус тамашачыларына да күрсәтелгән иде.

Әсәр бәхетле язмышка юлыкты. Ул авторлар хокукын саклау буенча Бөтенсоюз агентлыгы (ВААП) ел саен ике тапкыр рус, инглиз, немец телләрендә чыгара торган «Вестник»та соңгы елларда унбер пьеса арасында чит ил театрларына тәкъдим ителде.

*
* *

Татарстан композиторларының чираттагы музыкаль пәнжешәмбесе аеруча жанлы узды. Ф. Әхмәтовның «Житен чәчәге», «Тәрәзә юа кызлар», «Жиребезнең шәфкать туташы», «Ут салма йөрәгемә» дигән жырлары композиторларда һәм музыка белгечләрендә зур кызыксыну тудырды. И. Якуповның яңа «Рапсодия»се турында кызу бәхәс барды. Капма-каршы фикерләр әйтелде. Кыскасы, бүгенге татар совет музыкасы турында житди сөйләшүгә әйләнгән бу пәнжешәмбе авторлар һәм анда катнашучылар өчен дә файдалы булды.

*
* *

Татарстан китап нәшрияты «Яшь скрипкачы» жыентыгының беренче кисәген бастырып чыгарды. Аның төзүчесе һәм редакторы — Казан дәүләт консерваториясенең өлкән укытучысы Ш. Монасыйпов. Хрестоматия рәвешендә төзелгән бу жыентыкта күренекле татар композиторларының скрипка өчен язылган әсәрләре һәм халык көйләре тупланган. Әсәрләр укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып урнаштырылган.

«Яшь скрипкачы» жыентыгы шулай ук һәвәскәр музыкантларга да кызыклы һәм кирәкле кулланма булыр. Мондый жыентык, музыкаль ихтыяжны искә алып, республикабызда беренче мәртәбә чыгарыла. Ул Татарстан Композиторлар союзы һәм Мәскәүнең Гнесиннар исемендәге музыка-педагогия институтының кыллы уен кораллары кафедрасы тәкъдиме белән чыгарылды.

*
* *

Киностудияләрдә иҗат ителгән иң яхшы фильмнар ел саен илебез халыклары телләренә тәрҗемә ителеп тора. Аларның сыйфат дәрәҗәсе ничек?

СССР Кинематографистлар союзы правлениесенең фильмнарны тәрҗемә итү Бөтенсоюз комиссиясенең Бакуда булган VI пленумы әнә шул мәсьәләне тикшерде. Пленумда Казан киностудиясе режиссеры, ТАССРның халык артисты Ф. Шәрәфиев катнашты һәм соңгы еллардагы тәрҗемә фильмнар турында үзенең уй-фикерләре белән уртаклашты.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

*
* *

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм житмеш яше тулу уңае белән язучы Фатих Хөсни Октябрь Революциясе ордены белән бүләкләнде.

*
* *

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм илле яшь тулу уңае белән язучы Шамил Бикчурин «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде.

*
* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының балет солисты Камил Гайнуллинга Татарстан АССРның халык артисты дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы һәм драматург Аяз Гыйләҗевкә Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет әдәбияты һәм матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Мәхмүт Хәсәновка Татарстан АССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде.


*
* *

«На боевом посту» дигән журнал редакциясе узган ел Октябрьның 60 еллыгына багышланган әдәби конкурс игълан иткән иде. Шушы конкурс уңае белән журналның быелгы 1 нче санында басылган ике хикәясе өчен татар язучысы Фәнис Яруллин редакциянең Почет грамотасы белән бүләкләнде.

# КАЗАН УТЛАРЫ

Рөстәм Яхин музыкасы

Мөнир Мазунов сүзләре




Күккә карыйм,
Айны, йолдызларны
Күргәнем бар күпме мәртәбә! —
Әйтерсең лә
Кемдер юмартланып,
Алтын сипкән зәңгәр хәтфәгә.

Җиргә карыйм,
Төнге Идел өсте
Көннәр көнләшерлек яп-якты, —
Казан җәйгән
Ука толымнарын,
Шул күренеш мине йоклатмый.

Кем сокланмас
Айлы төннәренә:
Көмеш дулкыннарың — бер
зәвык.

Казан-суның
Ап-ак беләгендә
Күперләре алтын беләзек.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Сезне журналыбызның 5 нче санында чыгачак материаллар белән таныштырабыз.

Ул сан Равил Фәйзуллин шигырьләре белән башланып китә. Роберт Миңнуллин, Салисә Гәрәева, Харрас Әюпов шигырьләрен дә май аенда укырсыз.

Күләмле әсәрләрдән Роман Солнцевның «Көймә ватылса — утын» повесте басылачак. Бу әсәрендә якташыбыз татар халкының бүгенге тормышын сурәтли.

Май ае илебезгә җиңү алып килгән ай. Бөек Ватан сугышы тәмамлануга күп еллар үткән саен истәлекләре яңара гына бара. Үлемсез геройларның язмышы турында торган саен күбрәк әсәрләр языла. Шулардан берничәсен — язучы Шамил Рәкыйповның «Днепр ярында таллар бар» дигән очеркын һәм «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Шәмси Хамматовның «Дәһшәтле еллар авазы» дигән публицистик мәкаләсен тәкъдим итәбез. Зәки Нуриның «Хатка каршы хатлар яздык» дигән көлке хикәясе дә Ватан сугышы сәхифәләренә багышлана.

У. Алиевның «Гомерлек сабак» дигән очеркы исә бүгенге көн геройларын сурәтли.

«Бүгенге поэзия турында сөйләшү»не дәвам итеп, Хатип Госман «Яшьләр һәм остазлар» дигән мәкалә белән катнаша.

Таҗик әдәбияты классигы Садретдин Айниның тууына 100 ел тулу уңае белән әдипнең «Беренче тәэсирләр» дигән хикәясен, культурабыз тарихына караган мәкалә, һ. Такташ укыган китаплар турында кызыклы информацияне, китап күзәтү, балалар өчен шигырьләр, шаян шигырьләрне һ. б. да сез «Казан утлары» журналының май саныннан укый аласыз.

Бүгенге әдәбиятның торышы белән кызыксынучылар Нил Юзиевның «Әдәбият фәне методологиясенә камиллек» дигән мәкаләсе белән танышачаклар.

«Безнең календарь», «Укучылар сүзе», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» дигән бүлекләр дә күп кенә кызыклы материаллар бирәләр.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210